

# Казан утлары

5.1985

*Бөек Җиңүнең 40 еллыгын*



# БӨЕК ҖИҢҮГӘ




40 ЕЛ

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.

Габдулла Тукай.

Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Муса Җәлил.

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң
Гомерең озын булa.

Фатих Кәрим.

## «Батырлык дәвам итә» конкурсы йомгаклары

Бөек Ватан сугышында совет халкының фашизмны җиңүенә 40 ел тулу уңаеннан «Казан утлары» журналы иң яхшы хикәяләргә «Батырлык дәвам итә» конкурсы игълан иткән иде.

Жюри, конкурска килгән хикәяләр белән танышканнан соң, мондый нәтиҗәгә килде:

1. «Батырлык дәвам итә» конкурсы язучыларның һәм башка авторларның хикәя жанрындагы эшчәнлеген активлаштыруга сизелерлек йогынты ясады, Бөек Ватан сугышы елларында совет халкының фронтта һәм тылдагы тиңдәшсез батырлыгын, җиңүче солдат каһарманлыгының буыннан-буынга күчеп яшәвен, аның яшь буынны хәрби-патриотик рухта тәрбияләүдәге ролен чагылдыруда матур өлеш кертте.

2. Бүләкләрне түбәндәге авторларга тапшырырга карар кылынды:

I бүләк (150 сум) — Фоат САДРИЕВКА («Авыш басу икмәге», 1984 ел, 12 сан);

II бүләк (100 сум) — Афзал ШАМОВКА («Якташым», 1984 ел, 11 сан);

II бүләк (100 сум) — Геннадий ПАУШКИНГА (Үткел», 1985 ел, 5 сан);

III бүләк (75 сум) — Роза ХАФИЗОВАГА («Урак өсте», 1984 ел, 7 сан);

III бүләк (75 сум) — Мәгъсум ХУҖИНГА («Бәхет җире», 1985 ел, 3 сан).

Редакция җиңүчеләрне ихластан котлый, конкурста катнашкан барлык авторларга тирән рәхмәт белдерә һәм иҗатларында яңадан-яңа уңышлар тели.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

5

1985

*Бу сан Бөек Җинүнең 40 еллыгына багышлана*

«Батырлык дәвам итә» конкурсы йомгаклары . 2

Хәтергә иң тирән уелганнардан. *Түгәрәк өстәл янында әңгәмә* . . . . . . . . . . . . . 5

Г. КУТУЙ. Туган ил. *Шигырь* . . . . . . . 24

Н. БАЯН. Хат язсам да... *Шигырь* . . . . . . 24

Х. КАМАЛОВ. Безне өйдә көтәләр. *Роман* . . 25

1946—1985: ике фото . . . . . . . . . . . 100

Ш. МӨДӘРРИС. Күп булса да... *Шигырь* . . . 102

Ә. ДАВЫДОВ. Кулларыма... *Шигырь* . . . . 102

Безнең авылдан да сугыш узды... *Балалар язы* . 103

Н. АРСЛАНОВ. Сугышчы төше. *Шигырь* . . . 106

С. ХӘКИМ. Йолдыз. *Шигырь* . . . . . . . . 106

Р. ИШМОРАТОВА. Рәйханә. *Повесть* . . . . 107

Ә. МАЛИКОВ. Тугрылык. *Поэма* . . . . . . 148

Г. ПАУШКИН. Үткел. *Хикәя* . . . . . . . . 151

Ә. РӘШИТОВ. Тантана. *Шигырь* . . . . . . . 157

К. ЛАТЫЙПОВ. Куллары белән. *Шигырь* . . . 157

А. ЯКОВЛЕВ. Генерал язмалары . . . . . . . 158

Н. ХИКМӘТ. Егерме сигез хикаясе. *Поэма* . . . 163

Н. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Халык батырлыгы һәм әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . 170

Җ. ГЫЙЛМАНОВ. Бөтенесе — фронт өчен . . 176

Г. САБИРҖАНОВ. Җиңелмәс туганлык . . . 181

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

А. ҖӘЛӘЛЕВ. Каһарманлык елъязмасы . . . 184
М. ӘХМӘТГАЛИЕВ. Прикладка куеп язылган хатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
З. НУРИ. Фронт мәзәкләре . . . . . . . . 189
Ю. ГОРШУНОВ. Җиңүгә рухландырган җыр . 192

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

## *Этот номер посвящается 40-летию Великой Победы*

Итоги конкурса на лучший рассказ «Подвиг продолжается». Беседа за круглым столом писателей-участников Великой Отечественной войны.

Стихи **А. Кутуя, Н. Баяна, Ш. Мудариса, А. Давыдова, Н. Арсланова, С. Хакима, А. Рашитова, К. Латыпова.**

Поэмы «Верность» **А. Маликова**, Рассказ о двадцати восьми» **Н. Хикмета.**

Продолжение романа **Х. Камалова** «Нас ждут дома».

Повесть **Р. Ишмуратовой** «Райхана». Рассказ **Г. Паушкина** «Перевал».

**Отрывки из сочинений школьников «И нашей деревни коснулась война».**

**А. Яковлев.** «Записки генерала».

Статьи **Н. Гиззатуллина** «Героизм народа и литература», **З. Гильманова** «Все для фронта», **Г. Сабирзянова** «Нерушимое братство», **А. Залялова** «Летопись героизма».

Публикация «Письма с фронта».

Фронтовая сатира.

На нашей обложке — творчество художника Ю. Ананьева.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.

Производствога бирелде 28.02.1985 ел. Басарга кул куелды 14.05.1985 ел. ПФ 02095. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64049. Заказ Ф-100. Бәясе 90 тиен

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1985 ел.

# ХӘТЕРГӘ ИҢ ТИРӘН УЕЛГАННАРДАН

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА ӘҢГӘМӘ

**Тарихыбызның кайсы сәхифәсен генә алып карасак та, язучыларыбызның халык белән һәрчак бергә булуларын, партиянең ил алдына куйган бурычларын үтәүдә актив көрәш сафында атлауларын күрәбез. Тыныч хезмәт көннәрендә дә шулай бу. Социалистик Ватаныбыз иминлеге куркыныч астында калганда, аңа дошман явы ябырылганда исә язучыларның әлеге сыйфатлары аеруча калку гәүдәләнә.**

**1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында, кулларына корал тотып, немец фашистларына каршы чыгучы каһарманнар арасында 1215 язучының булуы — моңа ачык дәлил. Аларның 460 ы яу кырында батырларча һәлак булды. Дошманга нәфрәт тәрбияләүчән, җиңүгә рухландыручан әсәрләр язып кына түгел, каләмнәре кәгазьгә төшергән фикерләрне раслап та күрсәтү өчен, туп-туры фронтка юл алып, фашистлар белән йөзгә-йөз килеп сугышкан совет язучылары арасында Татарстан әдипләре дә байтак. Шуларның кырыклабы бүген дә сау-сәламәт, җиң сызганып иҗат итәләр.**

**Укучыга яхшы мәгълүм ки, фронтовик язучыларыбызның күбесе журналга үзләренең яңадан-яңа әсәрләре: романнары, повесть-хикәяләре, шигырь-поэмалары белән әледән-әле катнашып тора. Бөек Җиңүнең 40 еллыгын каршылаганда, алар бигрәк тә дәртләнеп яздылар.**

**Редакция моңарчы журналда яңа әсәрләре белән күренергә өлгермәгән фронтовик язучыларыбызны түгәрәк өстәл янына әңгәмәгә чакырды. Аларның һәрберсе сугышта кичергәннәре турында бик озак итеп сөйләргә әзер иде. Әмма бу очракта утлы юлларны урап кайткан язучыларга ул елларда хәтерләренә иң тирән уелып калган бер генә исталекле вакыйгага тукталырга тәкъдим ителде.**

## Мәхмүт Хөсәен

1941 елның 22 июне. Без таң алдыннан гына мәктәптә уздырылган чыгарылыш кичәсеннән кайттык. Күңелләр көр, рух күтәренке. Сулап туймаслык сирень исләре борын яфракларын кытыклый. Рәхәт! Җирнең иң бәхетле кешесе сыман тоям үземне. Уйларымда — ап-ак колонналы Казан университеты. Тик өйгә кайтып, татлы йокыга чумган гына идем, мине иңнәремнән селкеп уяттылар. Күзләремне ачсам: каршымда йөзләре агарын-

ган әнием басып тора: «Тор, улым, тизрәк! Гитлер безгә каршы сугыш ачкан!..»

Бер атнадан әтине армиягә алдылар. Күп тә үтми, мин дә үзем хыялланган университетка түгел, изге теләгемнең тамырына ут төрткән гитлерчыларга каршы сугышка китеп бардым. Мин фронтка килеп җиткәндә, әтием батырларча һәлак булган иде инде. Йөрәгем тулы нәфрәт ялкыны! Менә тиз генә укытып-өйрәтеп, взвод командиры иттеләр. Җанга туплап үч ташкынын, давылланып-ярсып, алга ыргылдым: «Әтием өчен! Газиз Ватан өчен!» Шул ялкыным Җиңү көненәчә сүнмәде.



...1943 нче елның җәй ае иде бу. Курск—Белгород дугасында фашистлар һөҗүмгә күчтеләр. Сугышлар бик киеренке төс алды. Батарея командиры буларак, пушкаларымның утын көчәйттем. Дошман ныгытмаларын җимереп, һөҗүмгә баручы пехотачыларга юл ачтым. Безнең часть, гитлерчыларның катлаулы оборонасын өзеп, алга — Смоленск каласына омтылды. Шушы көннәрдә турыдан-туры яу кырында Ленин партиясе членлыгына кабул ителдем. Җиңүгә рухландырган партбилетымны күкрәгемә кыскан хәлдә, тупчыларым белән бергәләп, Смоленск урамнарына беренчеләрдән булып азатлык кояшы алып кердек. Озакламыйча Белоруссия туфрагына да аяк бастык. Сугышлар Орша янында кабынып китте. Бәрелешләр Боброво авылы өчен барды. Безнең дивизия алдына таң белән Бобровоны алырга дигән сугышчан бурыч куелды. Ә Боброво пункты һәр яктан да өч рәтле траншеяләр белән уратылган. Траншеяләр алдында — мина кырлары, тимер чыбыклы ныгытмалар. Авылның йортлары көчле дот һәм дзотларга әверелдерелгән. Таң беленүгә, артиллерия хәзерлеге башланды. Безнең пехотачылар дошман крепостен штурмларга ташланды. Көтмәгәндә дошманның «Тигр» җитәкчелегендә авыр танклар төркеме күренде. Алар, ата-ата, безнең алгы сызыкка якынлашалар. Пушкаларым, үзләрен сиздермичә генә, тып-тын торалар. Баш танкка 400 метр чамасы ара калгач, команда бирдем:

— «Тигр»ларга каршы ут! Ут! Ут!

Пушкаларым бердәм ут ачтылар. Өлкән сержант Локатуш расчеты өч снаряд белән баш танкны җимерде. Икенче танк та кара төтенгә чорналды. Калганнары кире чигенделәр. Тын алырга өлгермәдек, гитлерчылар кабат контратакага күтәрелде.

— Берсен дә җибәрмәбез! Көчәйтегез утны! — дип боердым.

Иң киеренке мизгелдә орудие командиры Локатуш һәлак булды, наводчик Борһанов каты яраланды... Озак уйлап тормастан, наводчик урынына үзем бастым да, рәхимсез ут ачып, дошманның өченче танкын яндырдым. Бүтәннәре калкулык артына кереп яшеренделәр дә бераздан яңадан һөҗүмгә күчтеләр.

— Күбрәк снаряд китерегез! Дусларның үлеме өчен, ут! — дип, тупларымның утын көчәйтә төштем. Фашистларның рәтләре сирәгәя барды. Инде бераз ял итәбез дигәндә, пушкалар тирәсендә ниндидер бер авыр снаряд ярылып, менә аяктан екты, шинелемә ут капты. Җиргә ауган килеш, тәгәри-тәгәри, капкан утны сүндерә-сүндерә, аңымны җуйдым...

Гитлерчыларны кысрыклауны сигез айдан соң гына Ленинград фронтында дәвам иттем.

# Рафаил Төхфәтуллин



Сугыш хатирәләре турында сүз чыктымы, үзенә кызыгын да, кызганычын да сыйдырган бер вакыйга исемә килә дә төшә.

1943 елның январь төнендә без, II— Мәскәү пулемет-миномет училищесы курсантлары, Козельск дигән станциядә эшелоннан төштек Сафларга тезелеп, юлга кузгалдык. Соңыннан белгәнебезчә, Үзәк фронтның Брянск юнәлеше икән бу. Таң атып килгәндә, ярым җимерек бер авылда туктадык. Юл күрсәткече язуыннан белдек: авылның исеме Монастырское икән. Монда безне төрлебезне төрле подразделениеләргә бүлделәр, өр-яңа винтовкалар, күп итеп патроннар, гранаталар («лимонка») алдык. Яңа взвод командирыбыз, бездән бер-ике яшькә генә олырак яшь лейтенант (кызганыч, фамилиясен хәтерләмим), безне бер читкәрәк алып китеп, сафка тезде, һәрберебезнең исем-фамилияләрен, кайдан икәнлегебезне сорашты. Танышу тәмамлангач:

— Сезнең чын граната ыргытканыгыз бармы әлә? — дип куйды.

Юк иде, училищеда болванкалар ыргытып кына күнегү үтә идек.

Лейтенант безне тагы да арырак, кар каплаган бер инеш борылышына алып килде.

— Һәрберегезгә өчәр граната ыргытырга рөхсәт итәм. Аннары, ярга мишеньнәр куеп, винтовкалардан да атарсыз. Кулларыгыз, күзләрегез күнегә торсын,— диде.— Передовойга караңгы төшкәч кенә китәбез әле. Тик киткәнче запасларыгызны тулыландырырга онытмагыз.

Безнең шатлык-куанычыбызның иге-чиге юк иде. Чын граната ыргытабыз, винтовкадан атарга да патроннар чикләнмәгән. (Моңарчы, училищеда, патроннар санап кына, иң күбе — бишәрләп кенә бирелә иде.)

Әй, китте гөрс тә гөрс граната ыргыту, шарт та шорт винтовкадан ату. Колакларың гына чыдасын. Без малай-шалайга артыграк ирек куюын абайлапмы, лейтенант яр буеннан кул изәп нидер кычкырды. Юк, күрмәмешкә-ишетмәмешкә салышабыз, ату-ыргытуыбызны беләбез.

Шул чак якында гына тагын бер шартлау гөрселдәде. Аның артыннан икенчесе, өченчесе. Юк, безнең «лимонка» шартлавы гына түгел иде монысы. Үзәкләрне өзәрдәй сызгырып килә дә дәһшәтле иттереп шартлый. «Лимонка» кебек кар өстендә кара тап кына калдырмый, зур-зур кантарлар актарып чокырлар ясый. Ул арада кемдер ачыргаланып кычкырды, ыңгыраша да башладылар...

Безнең күнегүләрне тактик чара дип уйлаган, ахры, немец, авыр минометлардан өстебезгә ут ачты. Һәр ачы сызгыру синең өстеңдә генә шартлар кебек, берсе шартлауга, икенчесе сызгырып килә. Кая ышыкланырга, кай тарафка йөгерергә белгән юк...

Безгә очсыз-кырыйсыз кебек тоелса да күпмедер вакыттан соң, шартлау-сызгырулар туктады. Дүрт-биш иптәшебез, яраланып, санротага китте. Ә яшь лейтенант, ачык йөзе, безнең кулларыбызны, күзләребезне күнектерә торуны кайгыртуы белән мәхәббәтебезне яулап алырга өлгергән ягымлы командирыбыз, авыр ярадан һәлак булды.

Шуннан соң ике көн, ике төн буе ниндидер биеклекне алу өчен сугышлар барды. Аннан ары да III-Белоруссия һәм III-Прибалтика фронтларында күп сугышларда катнаштым. Әмма «кулларыбызны, күзләребезне күнектерү өчен» генә башлаган әлеге «сугыш уены», беренче мәртәбә дары исе иснәвебез хәтеремә бик тирән уелып калды.

Безнең малайлыктан чын-чынлап чыгу көнебез булды ул.

# Мөхәммәт Садри



...Миңа складның кораллар бүлеге начальнигы вазифасын йөкләделәр. Бу склад Смоленск өлкәсенең Волоста-Пятница тимер юл станциясе тирәсендә, урман эчендә иде. Сугыш кирәк-яраклары палаткалар белән ябылган, ә солдатларым Орел белән Брянск шәһәрләре тимер юл деполарыннан килгән өлкән яшьтәге эшчеләр иде. Көндез частьларга җиңел пушкалар, автоматлар, приборлар озатабыз, алгы сызыктан җыеп кайткан, сафтан чыккан коралларны юып-чистартып ремонтлыйбыз. Алары да алгы сызыкка китә тора. Ә караңгы төшә башлагач, яшеренеп кенә карьерга килгән йөк вагоннарыннан танкка каршы ата торган снарядлы ящикларны йөк машиналарына бушатабыз. Ельня читенә—алгы сызыкка ашыгабыз. Анда трофей снарядлары, сафтан чыккан кораллар төяп, таң алдыннан складка кайтабыз.

Көндез, снаряд төяп, юлга чыгуны уйлама да. Чөнки фашист козгыннары җирдә бер генә машина, бер генә кеше күрсәләр дә, түбән төшәләр, әзәрлеклиләр, бомбалар ташлап, пулеметлардан атып, юк итәргә тырышалар иде. Без төнлә белән дә сакланып эш иттек.

Резерв фронты белән командалык итәргә Г. К. Жуков килгәч, безнең эш тагын да киеренкеләнде, һәм аның җитәкчелегендә Резерв фронты гаскәрләре, сентябрь башында фашистларны бәреп чыгарып, Ельня Дугасын азат иттеләр. Бу, дошманның Мәскәүгә турыдан-туры бәреп керү өметен өзгән беренче зур җиңү иде. Бу җиңүгә алгы сызыкны снарядлар, кораллар белән тәэмин иткән безнең кыр складында хезмәт итүче сугышчыларның да өлеше зур булды.

Әлеге җиңүдән соң, Г. К. Жуковның Ленинград фронтына җибәрелгәнлеген белдек. Нәкъ шушы вакытта, көнчыгыш-көнбатыш фронтында безнең гаскәрләр өчен авыр чор башланган, дошман Ельняда җиңелүе өчен, үч алырга, шул фронтны өзеп,безнең тирәне чолгап алу куркынычы тудырган икән. Кыр склады командиры миңа тапшырылган кораллар бүлеге территориясен тикшереп чыкты. Бу вакытта минем карамактагы күп нәрсә хәрби частьларга озатылган. Ләкин, урман читендә, көпшәсе югары күтәрелгән, тягачлы, еракка ата торган зур пушка бар иде. Командир, аның янына килде дә, бераз уйланып торгач, миңа карап:

— Бу — бик кыйммәтле корал, син аны ашыгыч рәвештә Мәскәү ягына озат!— диде.

Урман читендә, зур пушка янында ялгыз басып калдым. Пушкам миңа:

— Инде ни эшлибез, туган?— дип эндәшкәндәй булды.

Мин аңа карап тордым да:

— Белмим шул!— дип, күңелем йомшарып, елап җибәрдем.

Шул чакта мин балаларымны, хатынымны, кызымны искә төшердем. Бу коралны озата алмасам, ул дошман кулына эләксә... Мин бу пушка янында үләргә дә әзер идем. Автоматым да корылган, гранаталар да бар иде. Юк, ул дошман кулына төшмәскә тиеш. Бу — холкымның үзгәрү, ныгу мизгеле булды кебек. Шуннан соң нинди генә авырлыклар күрсәм дә, Берлинга барып җиткәнче, күземнән яшь чыкмады. Әчемә җылы керде, командир

паровоз чакырткан икән. Машинист бу тирәдә миннән башка берәүнең дә булмавына аптырап:

— Пушка кайда?— дип сорады.

— Урман читендә. Тик аны монда тарттырып китерергә бер нәрсә дә юк,— дим.

Аптырашып торган арада, җир астыннан чыктыларммыни, карьер артыннан ике кеше күренде. Мин аларга: «Трактор кирәк иде, табарга булышмассызмы?»— дидем.

Алар үзара киңәштеләр дә, ризалашып китеп бардылар. Күп тә үтмәде, тракторга утырып килделәр. Пушканы тарттырып караган идек, көпчәкле трактор аны урыныннан да кузгата алмады. Бу ике иптәш тракторны иң зур тизлектә куып кабат китеп бардылар. Икенче бер көчле трактор алып килделәр. Шушы трактор ярдәмендә дәһшәтле пушканы бер платформага, тягачны — икенчесенә урнаштырдык. Машинист аны Вязьма ягына элдертте.

Паровоз киткән якка карап торган арада, миңа ярдәм күрсәткән кешеләрне дә «ай күрде, кояш алды», тракторлары белән бергә күздән юк югалдылар. Аларның кем икәнлекләрен белеп өлгерә алмавым үкенечле булды. Әмма бу мәрхәмәтле кешеләр, шушы вакыйга соңрак, Мәскәү янындагы сугышларда, госпитальдә,аннары беренче Украина фронтында, Польша җирләрендә, Германиядәге сугышларда, Бреслау, Берлин, Прагада да исемнән чыкмады.

Җиңүдән соң өйгә кайткач, бу станциягә хатлар яздым, телеграммалар җибәрдем, ләкин җавап ала алмадым. Күп еллар үткәч, тагын хат яздым, җавап булмады. Шуннан, йөрәгем түзмәде, поездга утырып Смоленск якларына киттем, таныш станциямә төштем. Анда эшкә сугыштан соң туган яңа кешеләр килгән икән. Товар кассиры М. Белова мине картайгач туган җирләрен сагынып кайткан ике ветеран Е. Евстегнеев, А. Казаков белән очраштырды. Алар урман читендәге зур пушканы күргәнлекләрен хәтерләделәр, ләкин озатырга кемнәр булышканын әйтә алмадылар. Шулай да, алар, станциянең ул чактагы начальнигы Петр Денисович Васильевны күреп сөйләшегез, бәлки ул беләдер дип, аның адресын бирделәр.

Мин Мәскәүгә кайтып, яңадан поездга утырдым да 1941 елда авыр сугышлар кичергән якка юнәлдем.

Бекасово станциясенә төшкәч, җыйнак берничә квартиралы ак йорт янында таза гәүдәле, тәбәнәгрәк бер кешене күреп:

— Сез Васильев түгелме? — дип сорадым.

— Әйе, нигә кирәк?

— 1941 елда еракка ата торган пушканы трактор белән тарттырып озатырга сез ярдәм иттегезме?

— Әйе, мин булыштым!

— Ә икенчегез?

— Ул тракторчы һәм стрелочник Мудрашов иде. Һәлак булды.

Петр Денисович Васильев эвакуацияләнеп киткәннән соң бик күп станцияләрдә эшләгән, дошманны җиңү өчен фронтка күп ярдәм иткән, сугыштан соң җимерек станцияләр хуҗалыгын торгызуда күп көч куйган. Ә 1967 елда чыныккан коммунистны Бекасово станциясе начальнигы итеп билгеләгәннәр.

Шулай итеп, кырык ел буена йөрәгемдә саклап йөргән кешемне табу бәхетенә ирештем. Аның турында «Гудок» газетасына яздым. Петр Денисовичка сиксән яшь тулу тантанасы зурлап билгеләп үтелде, аны карчыгы Ксения белән бөтен уңайлыклары булган яңа, якты квартирага күчерделәр.

# Салих Баттал



Без сугышка бер гаиләдән биш егет чыгып киттек. Өчебез көнбатыштагы фронтларда, икебез — Фоат энем белән мин — көнчыгышта, Япония империалистларына каршы бәрелешләрдә катнаштык. Җиңү көнен күрү бәхетенә өчебез генә ирештек: мин һәм энеләрем Мөбарәк белән Фоат Батталовлар. Әле гражданнар сугышында ук үзен курку белмәс кыю җанлы итеп күрсәткән Галимҗан абыебыз хәбәрсез югалды. Ә Бөек Ватан сугышына үз теләге белән киткән (бер аягы аксаганга, аны сугышка алмаганнар иде) Габдулла энем, мәгълүм булганча, соңгы гомерен мәшһүр җәлилчеләр сафында кичергән, фашистлар тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителгән булып чыкты.

Мин сугышта Тын океандагы һава көчләренең майор Орлов командалык иткән 5 нче Аерым махсус эскадрильясе составында тизйөрешле бомбардировщик экипажы командиры идем. Очышларымның берсендә булган вакыйгага исемә төшсә әле дә тетрәнеп куям.

Японнарның сугыш объектын бомбага тотарга задание алып, звено составында өч самолет белән юлга чыктык. Безне истребительләр озата баралар. Фронт сызыгын уттек дигәндә генә тирәбездә зенит снарядлары ярыла башлады. Безне озатучы истребительләр, үзләренең пушка уты белән зенитчыларның утларын басар өчен, түбән төштеләр. Шуннан алар, безне калдырып, кире өйгә кайтып киттеләр, чөнки аларның баклары кечкенә, безнең кебек күп бензин запасы ала алмыйлар, шуның өчен безне озатып бик озак бармыйлар.

Минем самолет кинәт тетрәп куйды. Әйтерсең лә аның канаты астына зур тимер чүкеч белән суктылар. Шул вакытта ук ул сафтан читкәрәк тайпылды. Мин аны кире үз урынына кайтардым да штурманнан:

— Сиздегезме? Эш нәрсәдә? — дип сорадым.

Дүрт бакта күпме бензин барлыгын күрсәтә торган приборлардан берсенең стрелкасы күзгә чалынырлык дәрәҗәдә тизлек белән сулга авыша башлады. Нәкъ шул чакта, укчы-радист та канатның арттагы кырыеннән бензин агуы турында хәбәр итте. Димәк, сул канат эчендәге кырый бакка снаряд китеге тиеп, аны тишкән. Берәр чарасын күрмәсәң, бөтен бензин агып бетәчәк һәм безгә, заданиене үтәмичә, дошман җиренә төшеп утырырга туры киләчәк.

Иң башта мин тишек бакны башка баклар белән куша торган кранны ябып куйдым. Шуннан соң башымда береннән-бере катлаулырак сораулар туа башлады: бу вакыйганы командирга әйтергәме, юкмы? Әйтә калсаң, командир безнең экипажны өйгә борып җибәрмәсме? Шулай безне сугыш заданиесен үтәүдән мәхрүм итмәсме? Радио аша бирелгән бу хәбәрне җир өстендәге самурайлар ишетеп шатланмаслармы? Командирга әйткән тәкъдирдә дә башта төп мәсьәләне хәл итәргә кирәк: объектка кадәр барып, заданиене үтәр өчен һәм кире аэродромга кайтыр өчен калган өч бакның бензины җитәрлекме, әллә юкмы? Бу мәсьәләләрне өстәл янына утырып, кулыңа карандаш тотып хәл итсәң, яхшы булыр иде, ләкин хәзер кул — штурвалда, үзем — дошман җире өстендә. Мәсьәләне хәл итәр өчен бирелгән вакыт та секундлар белән санала.

Әлбәттә, бу юлы бензинны граммлап, юлны метрлап, вакытны секундлап санап тормыйсың, һәммәсен дә түгәрәкләп исәплисең. Ялгышсаң да, соңын-

нан тик үзеңә файда чыгарлык итеп ялгышасың. Шулай хисаплаганнан соң бер нәрсә шиксез иде: заданиене үтәп, кире үз аэродромыбызга кайтып җитәрлек булмаса да, фронт сызыгын үтеп, үз ягыбызга чыгарлык бензин бар иде.

Алай да күңел самолетның исән чагындагы кебек күтәренке түгел. Төрле уйлар башка килә. Дошман җиренә утыртырга туры килсә, самолетны яндырырга уйлап,кесәдәге шырпыны капшап карыйм. Сугыш объекты өстендә моторлар туктаса-нитсә дип, Гастелло үрнәге турында да уйлап куям.

Менә объектка да килеп җиттек! Бомбаларны туры ташлау теләге миндә башкаларныкына караганда зуррактыр кебек тоела, чөнки, башка самолетларда очучы иптәшләр белән уртак нәфрәт өстенә, миндә хәзер яралы самолетым өчен аерым үч алу теләге дә бар. Инде бер кат яраланган булгач, объект тирәсендәге зенит уты да ул кадәр куркыныч тоелмый.

Хәрби телдә коры гына «объект» дип аталган нәрсәбез — дошман аэродромы. Самолетларыбызның очу тизлеге һәм башка тактик чаралар аркасында объект өстенә шундый кисәктән генә килеп чыгабыз, тегеләрнең истребительләре дә һавага күтәрелеп өлгерми. Тик бер звеноларының моторлары эшләгәне күренә. Алар хәзер очып китәчәкләр һәм безгә һөҗүм итәчәкләр...

Ләкин безне җитәкләүче командир мәсьәләне бик тиз аңлый һәм кыю рәвештә хәл итә: без сафка тезелгән килеш аэродром мәйданына бомбалар ташлап үтәбез. Күтәрелеп китәр өчен йөгерә башлаган дошман истребительләренең икәве бер-бер артлы бомба базларына эләгеп муеннарын сындыралар. Өченчесе, бомба базыннан читкә борылганда янтаеп, канатын җиргә сыдыра һәм каерылып чыга. «Бүген Совинформбюро, әйтик, илле самолет юк ителде, дип хәбәр бирсә, шуның өчесе безнеке булыр»,— дигән уй башка килеп китә. Ләкин күңел әле моңар гына канәгать түгел. Тагын күбрәк юк итәсе, сугышны тизрәк бетерәсе килә. Командир да, шул теләкне аңлаган кебек, безнең сафны капонирлар (самолетлар өчен җиргә казып ясалган оялар) өстеннән үткәрә. Алар маскировка сеткалары белән капланган булсалар да, командирның үткен күзеннән һәм безнең бомбалардан котыла алмадылар.

Задание үтәлде. Юк, тулысы белән үтәлмәде әле, калган өлешен дә үтисе — сызылган маршрутлар буенча үз аэродромыбызга кайтып җитәсе килә. Командир да, минем бензинны юлга җиткерергә теләгән кебек, экономик режимда оча. Каршыда — истребительләр. Алар дошманныкы түгел, үзебезнекеләр, безне каршы алырга киләләр. Күңелгә шундый шатлык тула, әйтерсең лә, без инде кайтып җиткәнбез, ашханәгә кергәнебез дә бер өстәл артында сөйләшеп утырабыз!

Үз җиребез өстенә кайтып- җитү белән, әле күптән түгел генә әнә өстендә утырган кебек тынычсыз вакытлар әллә кайчан, былтыр булган хәл кебек тоела башлады.

Бензинның аэродромыбызга кайтканчы җитүе дә мине гаҗәпләндермәде, бик табигый тоелды. Бер тамчы бензиным булмаса да, үз илебезнең һавасы минем самолетны очырып йөртер иде кебек.

Аэродромда без тишек бакны алмаштырдык. Аның эчендә кайткан снаряд кыйпылчыгын безнең аэродром зенитчылары өйрәнер өчен сорап алдылар һәм аңардан АКШ келәймәсе таптылар... Менә сиңа союзниклар! Үзләре японнар белән ничә елдан бирле сугышалар, ә үзләре аларга снарядлар сатып яталар икән! Алар өчен самурайларның җиңелүләреннән дә бигрәк, сугышның дәвам итүе кирәк. Бөтен дөнья кан диңгезенә батсын, тик аларның снарядлары, кораллары, товарлары сатылсын да, кесәләре табыш белән тулсын!

Аларның һәрбер долларында пычрак тиере, һәрбер долларында кан эзләре булу турында Ленин әйткән бөек, ачулы сүзләр, шушы снаряд китеген күргәч, тагын ачыграк булып хәтергә килделәр. Немец фашизмын һәм япон милитаризмын тар-мар иткәч тә, әле тынычлык өчен көрәшнең дәвам итәчәген, бөтен көчебез илебезне ныгытуга багышланырга тиешлеген ачык аңладым.

# Сәет Шәкүров



Чибәр иде ул. Зифа буйлы, мөлаем йөзле. Һәрвакыт пөхтә, чиста йөри иде. Сугыш вакыты булуга карамастан, шинелендә кечкенә генә тап яки җыерчык күрмәс идең. Балтырларына сыланып торган хром итекләренең кунычлары көзгедәй ялтырыйлар иде. Куллары йомшак, чәчләреннән хуш ис аңкып тора иде. Сирәк-сирәк кенә булса да аның миңа орынып киткәләгәне булды. Ничек орынмыйсың? Без аның белән бер взводта, хәтта бер расчетта идек. Бер мәртәбә бергә йокларга да туры килде безгә, ул чибәр кыз белән. Бик кыска вакыт арасында булды ул хәл, шулай да онытылмый. Кызның исеме дә онытылган, ә менә аркага-арка терәп яту — хәтердә.

Мин аны беренче мәртәбә 44 нче елның көзендә очраттым. Госпитальдән чыгып, запас полкта элемтәче һөнәрен үздәштергәч, мине 3 нче Белоруссия фронтының 184 нче укчы дивизиясе карамагындагы аерым элемтә батальонына җибәрделәр.

Ул вакыт безнең гаскәрләр Белоруссияне тулысы белән азат итеп, Көнчыгыш Пруссия җирендә оборонага туктаганнар иде. Мин ул кызны батальонга килгән көнне үк күреп алдым. Андый чибәр кызлар бик тиз күзгә чалыналар. Күңел дигәнең, сугыш дип тормый. Бигрәк тә оборонада утырганда.

Оборонада чакта ул кыз штаб элемтәсендә иде. Шулай да мин аны еш күрәм. Безнең батальонда нибарысы җиде-сигез кыз иде алар. Мин, аның кайчан кайтасын чамалап, траншеядә, җиң очларыма гына яшереп тәмәке тарткан булып утыра торган идем.

Билгеле инде, яныннан кызлар узып киткәндә егет кеше дәшми кала алмый. Кыз да, җавап эзләп, кесәләрен актара торганнардан түгел. Мәгънәсезрәк' сүз ычкындырсаң, шундый китереп чәпи, икенчесендә авызыңны үлчәбрәк ачарга мәҗбүр буласың. Аннан килеп, монда чишмә буе да түгел. Оборона вакыты булса да, сугыш кыры диләр моны. Баш очыннан уклар сызгырып уза, снарядлар оча. Бер адашканының траншеяңә төшеп ярылуы да бар. Шуның өстенә, бу чибәр кызның төн буе йокламыйча арып кайтып килүен дә онытмаска кирәк. Мин үзем дә бер траншеядән икенче траншеягә телефон чыбыгы тартып, катушка сөйрәп кайтып егылган кеше. Бер-ике сүз алышсам, күңел була. Шунсына да бик канәгать, бик шат. Аның сизелер-сизелмәс кенә елмайган мөлаем йөзе, ягымлы тавышы, икенче очрашканга кадәр, миңа канат биреп, очыртып йөртәчәк.

Һөҗүмгә күчкәч, безнең ул траншея артта калды, әлеге чибәр кыз да онытылган кебек иде. Һөҗүм вакытында элемтәчегә көн дә юк, төн дә юк, ял да юк, йокы да юк. Пехота, ичмаса, көндез чаба алган кадәр чаба да, караңгы төшкәч, башын яшерерлек бер чокыр уеп, шунда гырлый бирә. Ә син аркаңа телефон чыбыгы уралган катушка асып йөгерәсең дә йөгерәсең. Кайчак икешәр-өчәр тәүлек буе йокы эләкми, атларлык хәл калмый, барган уңайга түнеп-түнеп китәсең. Артык гаҗиз булган вакытларда, санинструктор җилкәсендә сөйрәлгән яралы солдатка: «Менә бу туйганчы бер йоклый инде»,— дип көнләшеп карыйсың. Бик талкыды мине сугышның соңгы кышы. Расчетта гына түгел, взводта да һөҗүмне минем белән бергә башлаган солдатлардан берәү дә калмады. Яңалар килеп тора, килгәннәр китеп тора, ә мин һаман барам, кай көнне расчетта берүзем калам.

Шундый авыр көннәрнең берсендә безнең расчетка әлеге чибәр кыз килмәсенме?! Мин аны инде онытылды дип уйлаган идем. Ә ул юк, онытылмаган икән. Күңел түрендә томаланып кына яшәгән икән. Күренүе булды, күңелемне яңадан көчле ялкын урап алды. Ару-талуны белмим дә. Яраланасым да килми, сакланып йөри башладым. Траншея белән траншея араларын үрә катып узу юк, үрмәләп яки шуышып үтәм. Үләсе дә, яраланып санинструктор сыртында да китәсе килми. Түнеп калган җирләрдә «черем итеп» алулар да юк. Тизрәк өзекне ялгап расчетка кайтырга ашкынам, чөнки анда «Зуммер» трубкасын кочаклап, ул утыра. Маңгай белән саз ерган килеш тә кайтып булмый. Траншея төбендәге болганчык су белән юынам, битемне шинель итәге белән сөртәм.

45 нче елның март ахырлары иде. Бөтен фронт буйлап һөҗүмгә күчкәнебезгә дә ике айдан артык вакыт узды. Көнчыгыш Пруссиянең буеннан-буена үтеп, Кенигсберг шәһәренә җитеп киләбез. Соңгы сулышлары якынайган саен дошман гаскәрләре котырынып, теш-тырнаклары белән каршы торып маташалар.

Ике тәүлек буе ефрейтор Кобыченко белән икәү ут астында булып, кайда йөгереп, кайда түшебез белән шуышып, расчетка кайтып егылдык. Аппарат төбендә чибәр кыз юк. Без аны мөмкин кадәр линиягә чыгармаска тырыша идек. Ләкин снаряд кыйпылчыклары кеше гомерен генә түгел, телефон чыбыкларын да өзәләр. Мондый очракта кыз, телефон трубкасын тотып, без әйләнеп кайтканны көтеп утыра алмый бит инде. Хакы юк. Элемтә өзелмәскә тиеш. Аркасына катушка асып, ул да линиягә чыгып йөгерә.

Төн иде. Караңгы иде. Ике якның да бик азга гына тынып торган вакыты. Безнең хәлебезне күреп взвод командиры бераз ятып торырга кушты. Траншея кырыендагы тар гына куышка шуышып кереп, аркабызны-аркага куеп кына яттык, йокыга китәргә дә өлгермәдек:

— Егетләр, уртагызга мине дә сыйдырыгыз әле! — дип әлеге чибәр кыз безне ике якка кысрыклый башламасынмы?!. Ял итәрлек башка урын юк. Ничек сыйдырмыйсың инде? Ул да бит безнең кебек үк арып-талып линиядән кайтып кергән. Шулай да ефрейтор Кобыченко аңа:

— Әйдә, әйдә, сержант, ят минем янга! — диде.— Ә рядовой Шәкүров башка җирдән урын табар! — дип, миңа суктырып алды.

— Юк инде! Рядовой булса да, ефрейтордан җылырак ул! — чибәрем тегенең авызын каплады да куйды. Үзе кысыла-кысыла уртабызга кереп ятты. Кобыченко аркасына тиз башларын терәде, ә минем аркага — аркасын!

Аһ, кайнар да иде соң аның аркакайлары!..

Кобыченко шунда ук гырлап йокыга китте, ә миңа йокы керми генә бит! Ничек кенә арыган булсам да, йоклый алмыйм, каһәр. Аның җылысына изрәп, кайнар сулышын тоеп, рәхәтләнеп тик ятам. Аз гына кыймылдарга да куркып ятам. Кыймылдасам, шунда ук торып китәр дә мине бу рәхәттән мәхрүм итәр төсле. Хәер, барыбер озакка бармады бу татлы минутлар. Взвод командирының: «Сержант, элемтә өзелде»,— дип кычкыруы булды, кыз сикереп торды.

— Ят, ят, үзем барам! — дим.

Кыяфәте генә түгел, күңеле дә әйбәт иде аның. Кешелекле иде ул. Безнең ике тәүлек йокламаганны белеп, безне кызганып, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төндә ялгызы чыгып йөгерде һәм... шуннан әйләнеп кайтмады.

...Без аны яктыра башлагач кына эзләп таптык. Снаряд чокыры кырыенда йөзтүбән ята иде. Сул як калак сөяге астына пычак кадаганнар. Сөяк сабы гына күренеп тора. Немец пычагы. Кайвакыт шулай, төн караңгылыгыннан файдаланып, теге яктан дошман солдаты үрмәләп чыгып, безнең телефон чыбыгын кисә торган иде. Күрәсең, бу бичаракай, шуңа тап булган.

Икәү барган булсак соң? Аһ, икәү барган булсак!..

# Хатип Госман



1945 елның январь һөҗүме вакытында бригада командиры белән политбүлек начальнигы мине үзләре белән алдылар. Команда пунктында — сугыш белән идарә итүче өлкән офицерлар, Армия, Фронт, Үзәк вәкилләре буларак катнашучы генераллар. Командалар рацияләр аша бирелә. Дошман оборонасын өзү ике көн, ике төн өзлексез дәвам итте. Дошманның ныгытмаларын артиллерия генә җимерә, авиация оча алмый — һавада куе томан тора. Мин донесение белән тылга ике тапкыр чыгып кердем. Андагы әзерлек таныш мина: урманнан соң Мазовец киңлеге башлана. Монда искиткеч күренеш. Ул танклар, үзйөрешле артиллерия бүлекчәләре, меңләгән мотоцикллар, башка төр хәрәкәтчел гаскәрләр! Киләләр, урманга сеңә торалар...

Ниһаять, дошман оборонасы җимерелде. Миңа — яңа бурыч: хәзер үк һөҗүм итеп баручы машиналарга утырырга, җирле халык безнең армияне ничек каршылый — шуны ачыкларга! Ике сәгать саен донесение җибәреп торырга!

Мин әле генә азат ителгән кыр буйлап, йөгереп барып, машиналарның берсенә менеп бастым. Тирә - яктагы ак кар кара корым белән капланган. Фашистлар корган тимер чыбык киртәләрен безнең снарядлар өзгәләп, ботарлап-ботарлап, кибән-кибән итеп, әллә кайларга атып-атып бәргәннәр. Кайберләренә фашист мәетләре эленеп калган. Әле анда, әле монда җимерелгән танк авып ята, үзйөрешле туплар яна. Алга күз ташлыйм: әйтерсең, безнең техника бөтен дөньяны каплап алган, меңләгән моторлар гөрли, техника юлдан түгел, бер эздән түгел, бөтен киңлекне тоташтан бастырып, хәрәкәт итә. Ул арада һавадагы болытлар да өзгәләнеп китте, зәңгәр күк күренде, аннан безнең йөзләгән самолетлар килеп чыкты, иң югарыда — истребительләр... Җир дә безнеке! Түбәсенә хәтле үк күк тә безнеке! Шушы вакыт күңелне иксез-чиксез гайрәт хисе тутырды: килсен хәзер безнең каршыга явыз дошманның бөтен яулары — без аларның барысын да шушы көчле корыч ташкын белән таптап, изеп-сытып, юкка чыгарып алга үтәр идек!..

Җирле халыктан беренче очратканым Конти авылы урамында (Млавадан 4 километр көнчыгышта) 12—13 яшьләр чамасындагы ике кыз бала булды. Алар шат иде: «Пан, инде безгә гимназия ачылырмы?» — дип сорадылар. «Ачылыр, һичшиксез, ачылыр»,— дидем. Якында ишеге урамга караган өй күренде. Туп-туры шунда кердем. Карт белән карчык икән. Карт мич башында ята иде. Мин кергәч, шыр сөяк аякларын салындырып, торып утырды. Аларның ике уллары булган, икесе дә 1939 елгы сугышта югалган. Карт: «Германец әйткән иде, Польша, мең ел узса да, мөстәкыйль ил була алмас, дигән иде»,— диде дә, башын тотып, үксеп, елап җибәрде.

Моннан соң мин үзебезнең батальоннарның берсенә кушылдым. Инде төн иде. Бер авылга туктадык. Тынычлана төштек дигәндә, өйгә котлары очкан ике кыз килеп керде. Берсе өлкән, икенчесе 8—9 яшьләр чамасында. Фашист пулясы кечкенәсенең кулын чәрдәкләндереп үткән. Аларга ашыгыч медицина ярдәме күрсәтелде. Ашарга бирелде. Апасы вакыйганың ничек булганын аңлатты.

Фашистлар авыллардан халыкны да куып алып китәләр икән. Боларны да куганнар. Әмма безнең танкларның һөҗүме житез барганга, бервакыт кыр өстендә өч төркем арасы бик якыная: безнең танклар — фашист танк-

лары — куылган халык төркеме. Фашист танклары, безнең утка чыдый алмагач, ике арага халыкны куып кертәләр. Безнең танкистлар утны туктаталар. Ә халык төркеме безнең танклар ягына йөгерә башлый. Шул вакыт фашистлар арттан халыкка ут ачалар. Күбесе кырыла. Бу кызларның аталары да шунда үлеп кала, кечтеки кызның кулы яралана...

Безнең хәрәкәтчел гаскәрләр инде бик алга киттеләр. Батальоннар үзара да штаб белән дә рация аша гына сөйләшәләр. Эңгер-меңгер вакыты иде. Зур юлдан уңга борылдык. Калкулык итәгеннән үтәбез. Калкулык өстендә — наратлык, наратлыкта — бик каты атыш. Бүленеп калган фашистлар төркемен бетерү бара. Авылда кирпечтән салынган өйгә керү хәерле: пуля үтми, янгын алмый. Авыл уртасындагы шундый бер өйгә керсәк, аяк басар урын юк. Авылның карт-корысы, бала-чагасы, кызлары-киленнәре, үсмерләр — һәммәсе шушында килеп тулган. Алар да пулядан саклана. Керү белән уңъяк почмакта — өстәл. Батальон командиры туп-туры өстәл артына елышты һәм радистка әйтте:

— Кор рацияне! Сәгать 18-00. Хәзер Мәскәү хәбәр бирәчәк.

Радист шундук рация сандыгын ачты, радионы көйләп куйды. Өй эче тып-тын калды. Бераздан сигнал һәм миллионнарга таныш, көтеп алына торган көчле тавыш — Юрий Левитан тавышы яңгырады. Төньяктан алып көньякка кадәр тоташ һөҗүм баруы әйтелде. Шушы көнне азат ителгән шәһәр исемнәре саналды һәм, ниһаять:

— Польшаның Радом шәһәре азат ителде. Сугышта поляк гаскәрләре дә катнашты,— дигән сүзләр яңгырап китте.

Башта безнең гимнны бирделәр. Аннан Польша гимны уйналды. Өй эчендәгеләр кинәт үзгәрделәр. Яшьләр тураеп басты, картлар колакларын рациягә таба бордылар, яшь ананың күкрәгенә кысып тоткан бәбие, уянып, ашарга әзләнә башлады, кемдер үкси иде...

Польша халкының коллыктан котыла башлау көннәре иде бу.

## Мария Елизарова



Бөек Ватан сугышы елларында мин Татарстан Язучылар союзы идарәсе, Татарстан дәүләт нәшрияты һәм Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең Баш Политик идарәсе кушуы буенча фронтка командировкаларга йөрдем. Анда мин «Бөек Ватан сугышы» күргәзмәсе өчен материаллар җыярга, якташларыбызның фронтта күрсәткән батырлыкларын өйрәнергә тиеш идем.

Беренче тапкыр юлга чыкканда мин әле фашизмның ни икәнлеген газета-журналлардан укып кына белә идем. Укыйм да гаҗәпкә калам: гитлерчыларның вәхшилекләре мине шаккатыра, аптыравымның иге-чиге юк.

Менә инде үзем — фронтта. Мине һөҗүм итеп алга баручы частька билгеләделәр. Үз ояларына кире куылучы дошманның үкчәсенә баса-баса киләбез. Фашистлар итеге таптаган авыллардан үтәбез, алар интектергән кешеләр белән очрашабыз, сөйләшәбез. Мин үземә кирәкле фактларны, документларны җыям. Чәчләрне үрә торгызырлык хәлләр. Баксаң, газеталарыбыз бу хакта бик аз язалар икән әле, дип уйлап-уйлап куям.

Берсендә, Смоленск өлкәсенә баргач, миңа комсомол егет Алексей Гусевның фаҗигале һәлакәте турында сөйләделәр. Фашистлар аны Татаринка авылында тотып алалар. Егеттән комсомол иптәшләре, аларның эшләре турында сөйләтмәкче булганнар. Алеша бер сүз дә әйтмәгәч, аны ат койрыгына бәйләгәннәр. Атны Нащекино авылына кадәр чаптырганнар. Кыш. Карлы-бозлы түмгәкләрдән сөйрәлеп үткән егет аңын җуйган. Нащекинода, өстенә салкын су коеп, аны яңадан аңына китерәләр. Тагын сорау алулар башлана. Егет бер сүз дә әйтми. Фашист, тиресенә сыеша алмыйча, аңа төбәп, атып җибәрә.

Зайчики авылында, партизаннарның кайда яшеренгәнлеген белү өчен, фашистлар бөтен халыкны бер абзарга тутыралар да берәм-берәм сорау ала башлыйлар. Кирәкле мәгълүматка ирешмәгәч, барысын да шәп-шәрә калганчы чишендерәләр дә төрлечә җәзаларга тотыналар. Әмма һичкем партизаннарның серен чишми. Шуннан соң фашистлар кеше тулы абзарны бикләп алалар, ут төртеп, барысын да терелəй яндыралар.

Ржев районындагы Брехово авылында мин бер өйгә кердем. Алты хатын каршы алды. Алар туган якларының дошманнардан азат ителүенә шатланып бетә алмыйлар. Фашистлар оккупациясе чорында кичергәннәрен сөйлиләр. Хәер, әллә ни сөйләмәсәләр дә, өсләренә күз салу белән үк, алар башыннан нинди коточкыч хәлләр узуын чамаларга мөмкин иде. Арада берсе бөтенләй урында ята, шешенгән, телен дә тибрәтә алмый. Үзенә — нибары 21 яшь.

Ул да түгел, хатыннарның Екатерина Ивановна Ивановская дигәне: «Каршы яктагы бикле бер амбарда балалар сыкранып ята,— дип хәбәр итәргә ашыкты.— Сез коткара алмассыз микән? Мин төннәрен аларга, немецлардан кача-кача, бодай илткәли идем. Тәрәзәдәге бер ярыктан бирдем. Башка төрле ризык таба алмадым...»

Амбар янына без подполковник Савельев, шәфкать туташы Мария Бровко белән өчәү бардык. Кереп-чыгып йөрердәй, яктылык төшәрдәй урыннар бөтен яктан томаланган бу абзарны көчкә ачтык. Ишектән күңел болгаткыч ис килеп бәрелде. Идәндәге, әвеш-түеш кенә иттереп ясалган сәндрәләрдәге салам арасыннан хәлләре тәмам беткән балаларның башлары кыймылдый. Подполковник кесә фонарен яктырткан иде, сабый килеш картайган йөзләрне күреп хәйраннар булдык.

Бровко белән мин аларны барлый башладык, ә Савельев ярдәмчеләр алып килергә йөгерде. Озак та үтмәде, ул бер төркем солдатлар белән кире килде. Шинельләр, плащ-палаткалар күтәргәннәр.

— Шуларга сак кына төрик тә, күтәреп, күршедәге өйгә ташыйк!— диде подполковник.— Ул өй җылы.— Үзе балаларга аңлата башлады.— Әйдәгез, балакайлар, анда сезне юындырырлар да, аз-азлап ашатырлар да. Хәзер сезгә берьюлы күп ашарга ярамый...

Без үлем хәлендәге балаларны җылы өйгә күчерү эзерлеген күрә башладык. Подполковник үзе дә арада бик бетерешкән кеп-кечкенә бер кызчыкны кулларына алды. Шинель чабуын әйләндереп, баланы җилдән сакларга тырышты. Солдатлар да, плащларга төрелгән балаларны күтәреп, аның артыннан киттеләр. Без калганнарны барлап, абзардан алып чыгарга әзерләп тордык. Берәр сәгать үттеме-юкмы, тәнендә җаны сакланган балаларның барысы да җылы, чиста өйгә урнаштырылган иде инде. Анда аларны шәфкать туташлары, врачлар кулына тапшырдылар. Миңа, бу сабыйларны монда гына калдырмаячакларын, бераздан госпитальләргә, ә аннан балалар йортларына озатачакларын әйттеләр.

29 баланы коткардык без. Бишесе инде дөньядан кичкән иде. Шул ук ярдәм мин Егорова өендә иң башта очраткан хатыннарга да күрсәтелде...

Фронт юлларында күргәннәремнән, алып кайткан фотоларымнан, документлардан файдаланып Казанда «Бөек Ватан сугышы» дигән күргәзмә оештырылды. Андагы 20 экспонат фашистларның ерткычлыгын фаш итә иде.

Фронтта алган тәэсирләр миңа «Ватан кызы», «Музейны коткаручы», «Йолдызчык», «Каһарманнар эзеннән» кебек әсәрләр язарга да этәргеч бирделәр.

# Баян Гыйззәт



Ул көннәрдән соң 40 ел вакыт узып китте. Әмма алар бүгендәй хәтердә, әле дә күз алдында, әле дә аның шатлыклары, сөенечләре, горурлыгы күңелдә яшь. Шундый зур вакыйгаларда катнашу бәхетенә ирешкән кешеләрдә була торган кичерешләр торган саен яңара кебек.

1944 елның июнь таңы.

Явыз дошман сугыш башлаганга, безнең илгә чиксез күп газаплар, авырлыклар китергән, үлемнәр һәм кан-яшьләр алып килгән, миллионнарны ятим һәм тол иткән канлы сугыш уты кабынганга өч ел. Шушы өч ел эчендә фронтларда ниләр булды соң, фашист илбасарлар нинди максатларына ирешә алдылар, өч еллык сугыш сабаклары нидән гыйбарәт? Бу таңда һәркем әнә шул турыда уйлый, үзенчә йомгак ясый, киләчәккә карый.

Мәскәү юлында Гитлер армиясе тарихында беренче тапкыр көчле удар ала һәм тукталып кала, ул гына да түгел, 100—200 чакрымга чигенергә мәҗбүр ителә. Сталинградта безнең армия аның умыртка сөяген сындыра, Курск дугасы сугышларында башын миңгерәтә, һәм шуннан соң ул аңга килә дә алмый. Моңа кадәр җәйге һөҗүмне дошман башлый иде, димәк, инициатива алар кулында булган. Ә хәзер? Июнь ае узып бара, ә гитлерчыларның тыны да чыкмый — сукыр тычкан кебек җирне казып, окоп төпләренә посканнар — һөҗүм башларга көч юк. Һөҗүмне дә хәзер инде без башлыйбыз. Без! Июнь урталарыннан алып, тау-тау сугыш припаслары ташый башлагач та бу инде мәгълүм булды.

Әлбәттә, һөҗүмгә күчәчәкбез. Тик кайчан, кайда, нинди күләмдә? Шик тә юк, дошман да тик ятмый. Соңыннан билгеле булды: безнең Өченче Белоруссия фронты алдында фашистларның бер миллионнан артыграк сугышчысы, тугыз мең биш йөз туп һәм минометы, тугыз йөз танкы һәм штурм артиллериясе, мең биш йөз самолеты каршы торган. Шуларга каршы без 1 млн. 400 мең сугышчы, 31 мең туп һәм миномет, 5200 танк һәм үзйөрешле туп, 5300 самолет куя алганбыз. Өстәвенә безгә 300 меңнән артык партизан ярдәм иткән. («Коммунист» журналы, № 16, 1984 ел. 60—61 битләр.)

Төнен мәгълүм булды — безнең фронт иртәнге сәгать өчтә һөҗүмгә күчә! Без батарея командиры белән үзебезнең күзәтү пунктында идек (беребез сафтан чыкса, икенчебез команданы өстенә алыр дигән исәптән).

Аз-маз черем итеп алырга өлгердекме-юкмы, 22 июнь таңы беленә генә башлаган иде, төрле урыннардан берьюлы кызыл әз калдырып сигнал ракеталары атылды һәм шунда ук гадәттә һөҗүм сугышларын башлап җибәрә торган «Катюша»лардан чын ракеталар очып китте, аларга меңләгән туплар, минометлар кушылды. 16 килограммлы миналар ыргыта торган безнең полковой миномет батареясы да эшкә тотынды, дошманның оборонасын туракларый башлады. Туктаусыз яуган снаряд һәм миналар дошманның траншеяләрен, ут нокталарын, блиндажларын актарып ташлады, балчык, агач, такта кисәкләре, төрле сугыш кораллары күккә очты. Кайчак җир тетрәгәндәй булып китә. Давыллы диңгездә йөзгән корабта барган кебек, үзең дә чайкаласың, сикереп-сикереп киткәндәй буласың. Фронт сызыгы бирeдә бормалы-бормалы булып, дуга ясап үтә. Безнең дивизия йөзе белән көньяк-көнчыгышка карап урнашкан, шуңа күрә кояш та безнең тылдан түгел, ә дошман торган урманнар артыннан чыга. Бүген кояшка да әллә ни булды: инде баш калкытып өлгергәч, ул шушы хәлләрдән куркып, бер урында тукталып тора сыман. Бу фашизм кояшының баюыннан хәбәр түгелме?!

Бераздан тузан-төтен арасыннан әллә нинди шәүләләр күренә башлады. Болар шул ут эчендә исән калган, үлемнән качып, безгә әсирлеккә ашыгучы дошман солдатлары булып чыкты. Алар безнең траншеяләр алдына килеп-килеп авалар. Болар арасында акылдан шашканнары да күренде. Кайберсе туктаусыз: «Гитлер капут, Сталин карош»,— дип үзалдына мыгырданып бара. Сүнгән боларның дөньяга баш булу хыяллары. Ә бит аларның бөтен эшләре-теләкләре шул максатка буйсындырылган иде.

Ул да түгел, күктән тоташ гүләү тавышы якыная башлады. Күккә карасак, күк тулы самолет! Авиация үзенең бурычын төгәл үти: ул дошманның чигенә башлаган төркемнәрен куып җитеп, бомбага тота, җанлы көчләрен, техникасын кыра, безгә юл ача. Һөҗүмгә күчкәч күрдек: безнең авиация фашистларның чигенү юлларын кискән, күпер-буаларны күккә чөйгән, кичү эзләп тупланган дошман гаскәрләрен табып, машинасын, кешеләрен, техникасын—барысын бергә турап ташлаган. Һәр урында тәртипсез, төшенкелеккә бирелеп чигенү, качу. Кыр буйлап, ияләрен югалткан атлар чаба... Безнең шатлыклар эчкә сыймый, ул хис һәр кешенең йөзенә чыккан! Чөнки бу хәл тиздән Җиңү киләчәген белдерә...

Ул да булмый, үзебезнең тылда, урман эченнән, йөзләгән мотор гүләве күтәрелә һәм күп тә үтми бөтен тирә-якны танкларыбыз каплап ала. Танк — бар нәрсәне җимереп-кырып үзенә юл сала торган ифрат гайрәтле көч. Ниһаять, әнә шул көч-куәт белән безнең урамнарга бәйрәмнәр килә! Танклар, үзебезнең траншеяләр янында тукталып та тормыйча, үкерә-үкерә немецларның оборонасын изәргә, алга үттеләр. Аларга пехота иярде, артиллерия позицияләреннән туплар алынып, барысы да алга ыргылды.

Менә шул сәгатьтән безнең Өченче Белоруссия фронты гаскәрләре, ун көн дигәндә, дүрт йөз чакрым юл узып, Минск шәһәренә керде, аннан Польша чикләренә барып чыкты, хәтта бер армиябез Пруссиянең Гольдап шәһәренә дә кереп, «сәлам» биреп чыкты. Безнең Командующий сугышны комбриг булып башлаган, зур хәрби таланты аркасында, бик тиз комкор, командарм һәм 1944 елда инде фронт командующие булып күтәрелгән, ике тапкыр Советлар Союзы Герое исемен, армия генералы дәрәҗәсен алган Черняховский иде.

22 июньдә башланган вакыйгалар бик күп әһәмиятле нәрсәләр турында уйларга мәҗбүр итә иде. Гитлер Германиясе безгә каршы сугыш башлаганчы бөтен Европаны яулап алды һәм аның көчле индустриаль потенциалын безгә каршы корал чыгаруга юнәлтте. Әгәр безнең ил хәзер шуларның барын кырып ташларга көч тапкан икән, димәк, безнең индустрия бөтен Европаныкыннан өстенрәк булып чыга түгелме?! Димәк, безнең тылыбыз нык, заводлар көннән-көн көчәя бара, оста куллы эшчеләр дә җитәрлек. Димәк, хәзер бездә, шулкадәр металлга җан кертеп, танклар белән җирне, самолетлар белән күкләрне тотыру өчен, атып бетерә алмаслык снаряд, мина, бомба, патрон чыгару өчен, йөзәрләгән артиллерия һәм миномет бригадаларын коралландыру өчен бездә көч бар!

Шушы вакыйгаларны күрү, шул хакыйкатьне аңлау фронтта рухи күтәренкелек тудыра, көчләрне бермә-бер арттыра, җиңү көннәре якынлашканын һәркем сизенә, шуны якынайтыр өчен алга омтыла. Аеруча шушы техниканы барлыкка китергән, шуның аркасында никадәр гомерләрне саклап калырга мөмкинлек биргән һәм аннан да бигрәк дошманны җиңәргә юл ачкан эшчеләргә, икмәк биргән колхозчыларга һәр солдат күңелендә рәхмәт хисләре кабына иде.

Кызыл Армиянең 1944 елдагы җиңүләренең әһәмияте дөньякүләм яңгыраш алды һәм тагы бер җитди вакыйгага сәбәп булды. Мәгълүм ки, фашизмга каршы көрәштә үзләрен безнең союзниклар дип йөрткән Англия-Америка хөкүмәтләре 1941 елда ук Германиягә каршы икенче фронт ачарга, ягъни көнбатыштан һөҗүм башларга вәгъдә биреп тә өч ел буе дөнья җәмәгатьчелеген алдап килделәр. Әмма моның бер чиге булырга тиеш иде. Ниһаять, Кызыл Армиянең бер-бер артлы ясаган каты ударлары нәтиҗәсендә Гитлер армиясенең көче бетә барганын күреп һәм безнең, союзниклардан башка да, җиңеп чыгачагыбызны аңлап, Европаның кулдан ычкынасын сизенеп,

алар Франция чигендә десант төшерергә мәҗбүр булдылар. Союзникларның баш командующие Д. Эйзенхауэр да (ул соңрак президент та булды) чынбарлыкны танырга мәҗбүр иде: әгәр без үз көчләребезне Урта диңгез тирәсенә юнәлтсәк, Үзәк һәм Көнбатыш Европаны совет гаскәрләре яулап алырга мөмкин, («Известия» газетасы, 1984 ел, 4 июнь) дигән ул. Димәк, Америка генераллары безнең армиянең бер ялгызы гына да фашист Германиясен җиңеп чыга алачагына шикләнмәвен белдергән.

Хәзер яңа сугыш турында хыялланучылар шушы хакыйкатьне бозып күрсәтергә маташалар. Бу аеруча 1984 елның җәендә, икенче фронт ачылганга 40 ел тулган көннәрдә ачык күренде.

Ә танылган генералның сүзләре, фактлар, саннар — барысы да Кызыл Армиянең нинди куәткә ия булганлыгын ачык раслый.

Дөнья халыклары да хакыйкатьне күптән аңлады инде һәм яңа сугыш уты кабызучыларга каршы көрәшкә күтәрелде. Кайчандыр безгә бөтен Европа каршы куелып, без агрессорлар белән ялгыз сугышкан булсак, хәзер инде заманалар башка, хәзер сугышка каршы дөньядагы күпчелек илләр, континентлар күтәрелә.

Без хәзер дә горурланып кабатлыйбыз: безнең көчләрнең, тынычлык көчләренең чиге-хисабы юк, яңа сугыш уты кабызучыларга каршы көрәштә алар җиңеп чыгачак!

## Тихон Журавлев



1943 ел. Алгы сызык төнлә Карачев шәһәреннән шактый ераклашты, хәтта ату тавышлары да шәһәргә ишетелмәс булды. Кешеләр тынычлап йокларга яттылар. Әмма төн уртасында бу тынлыкны гөрселдәгән туп тавышлары тагын бозды. Кайдадыр шәһәр кырыенда гына аткан снарядлар, чыелдап килеп, урамга төшеп ярыла башлады.

Иртән комендатура патруле, шәһәр читендәге агачлык араларын актарып йөри торгач, куаклык арасына яшерелгән немец «Фердинанд»ын күрде. Үзйөрешле туп яңа гына сындырылган ботаклар белән капланган, ә янында беркем юк иде. Көндез немецлар урманга китеп качып торалар да, караңгыда кача-поса туп янына киләләр булса кирәк. Комендант тупка кагылмады, якында гына секрет куйды да солдатларны засадага алып китте.

Төнлә немецларның барысын да электереп алдылар, ә тупны тарттырып шәһәргә алып кайттылар.

Шәһәр халкы инде тынычландык дигәндә, өченче төндә тагын ата башладылар. Бу юлы немецлар бөтенләй оятсызландылар — төне буе сәгать саен берәр снаряд җибәреп тордылар, төшке һәм кичке аш вакытында тәнәфес ясап, хәтта көне буе да аттылар.

— Кич җитсен әле, боларын да каптырырбыз. Кайдан тәкереп яткынын белдек без аның — яшь урманлыктан җибәрә, немецларның оборонасы иде анда...— диде комендант.

Төш җиткәндә, без артиллерия бригадасы капитаны белән, Брянск ягына баручы берәр машинага утырып китәргә дип, шәһәр кырыендагы пунктка киттек. Урамнар буп-буш: кешеләр снарядтан качып подвалларга, базларга төшеп яшеренгәннәр.

Юл күрсәтүче кыз безгә машиналарның бүген бик сирәк үтүен әйтте, снарядлар күбесенчә шушы районга төшкәнгә, шоферлар шәһәр әйләнеп башка юлдан йөриләр, диде.

— Кадалып киткерләре, тынгы бирмәделәр тәмам,— диде кыз сукраныл.— Шау-шу ясадылар да хәзер һәммәсенең телендә шул «Фердинанд» кына. Күпме кырдык инде без аларны, һаман бетмәгәннәр әле.

Шул вакыт якында гына туптан аткан тавыш гөрселдәде һәм, әче чыелдап, безгә таба снаряд килгәне ишетелде.

— Әнә ул! — дип кычкырып җибәрде кыз һәм юл кырыендагы канауга тәгәрәп тә китте.

Әмма снаряд безнең өстән узып, юлның теге ягындагы басуга төшеп ярылды.

— Кая аталар соң алар?— диде капитан сәерсенеп.

Икенче снаряд, тагы да арырак очып, аэродромның чистартылган юл тасмасына төшеп шартлады. Анда бер У-2 тора иде. Самолет снаряд куптарган тузан болыты күтәргән сыман бераз гына алга таба тәгәрәп барды да ачулы фырылдап очып китте.

— Моңа ни калгандыр, башкалары әллә кайчан качып бетте инде,— дип куйды кыз аны шелтәләп.

Без өченче снаряд килгәнне көтеп тормадык, куаклык артындагы олы юл чатына киттек.

Карачевтан ерак түгел, кечкенә генә җимерек поселок читендәге куе агачлык артыннан мотор гөрелтесе ишетелде.

Юлдашым: «Полуторка!»— дип сөенеп машина каршына йөгерде. Әмма куе таллыктан йөк машинасы түгел, буй-буй соргылт төстәге авыр танк килеп чыкты.

— «Фердинанд!»— дип ах итте капитан.

Без шул секундта ук юл кырыендагы канауга сикереп җиргә сеңдек. Немец самоходкасы иде бу. Менә ул беряк тәгәрмәчендә борылды да ачулы улап Карачев юлыннан безгә таба килә башлады. Мин җиргә тагы да сыена төшеп, үлән арасыннан аның бронясындагы кара свастикасын күрергә тырыштым. Әмма танкның бернинди билгесе дә юк иде.

«Фердинанд» безгә якынлашты, аның туп көпшәсе каерылып бер якка янтайган, тәресе сары балчык белән сыланып, өстенә бур белән йолдыз ясалган иде.

Шул вакыт капитан:

— Безнекеләр бит! — дип кычкырып җибәрде һәм юлга чыгып кул күтәрде.

«Фердинанд» туктады. Люк капкачы күтәрелеп, аннан артиллерист сержантның башы күренде.

— Нишләп үзебезнекеләрне куркытып йөрисез сез, шайтаннар?— дип шелтә белдерде аларга капитан.— Кая киттегез?

— Батареяга.

— Атаргамы?

— Юк,— диде сержант елмаеп.— Моның атарлыгы калмаган инде. Хәзер без аңа утырып батареяларга аш өләшеп йөрибез.

# Риза Ишморат



Сугыш юллары мине дә шактый талкыдылар. Бер ел танк батальонында — рядовой солдат, бераздан сержант, фронтка килгәч, өлкән лейтенант, капитан, майор... Озын һәм авыр юл үтеп, Острогожск шәһәреннән Берлинга кадәр барып җиттем.

Миңа Беренче Украина фронтында җаныя аямыйча сугышучы татар улларының, башка милләт сугышчылары белән берлектә, гитлерчы илбасарларның һөҗүменә каһарманнарча отпор бирүләре турында татар халкының фронтовикларга җибәргән хатларына җавап итеп хат язуда катнашу бәхете тиде. Без анда йөзләрчә батырлар турында сөйләдек. Курск дугасы сугышларында дошманның 6 танкын яндырган Мохтар Әмиров, фашистларның дистәдән артык танкын, самоход пушкасын яндырган лейтенант Камалетдинов, «Юлбарыс» тибындагы ике танк яндырган Хәмзә Мөхәммәдиев, кыю разведчик Әнвәр Кәлиев, Днепрелгасын кичкәндә зур батырлык күрсәткән Советлар Союзы Герое Нәкыйп Сафин, Днепрны беренчеләрдән булып йөзеп чыккан һәм күп фашистны кырган, соңыннан яраланып дошманга әсир төшкәч, никадәр җәзаласалар да, үзебезнекеләр турында сер ачмаган Хатип Хәсәнов турында һәм үзләренең подразделениеләрендә фашистларның йөзләрчә сугыш техникасын, солдатын кырган офицерлар Шәмси Бәдретдинов, полковник Сәлмән Таһиров һәм башка бик күп сугышчыларыбыз турында яздык. Хатыбызны фронтның алгы сызыгына барып, татар солдатларына, офицерларына укып, аларның һәркайсыннан кул куйдырып халкыбызга, Казанга җибәрдек. Хат 1944 елны «Кызыл Татарстан», «Красная Татария» газеталарында, шулай ук зур плакат итеп тә басылды. Аерым китап рәвешендә дә татар һәм рус телендә бастырылып таратылды. Бу хат халкыбызның намусы, социалистик Ватаныбызны саклауда күрсәткән олы батырлыгы турында тарихта калырлык бер истәлекле документ иде. Ул «Җиңү юлы» — «I нче Украина фронтында татар сугышчылары» дигән исем белән тулыландырылып китап итеп тә чыгарылды.

Кайчакларда мин үз-үземә: дөньяда эшләгән иң зур эшем кайсы? дип сорау бирәм һәм шушы хат, шушы китап түгелме икән дигән фикергә киләм.

Инде ул хәтәр елларда кичергәннәрдән хәтергә иң тирән уелып калган вакыйгалардан аерып берсен күрсәтергә кирәк икән, монда мин, һичшиксез, Берлинны алу көннәрен күз алдында тотам. 1945 ел. 24 апрель. Мин — Берлин читендә. Без анда Котбус шәһәре ягыннан, киң трасса буйлап килеп кердек. Алдагы частьлардан бераз калышыбрак барабыз. Берлин өстенә бомбалар, снарядлар ява. Пулемет, автомат, винтовкалардан атылган утлы пулялар яңгыры ява. Алар гитлерчы илбасарларның мәсхәрәләүләрен татыган кешеләрнең ачуы, нәфрәте булып ява. Безгә каршы гражданнар киемендәге меңнәрчә кешеләр килә: хатын-кызлар, күбрәк картлар, яшүсмерләр, балалар. Һәркайсы ак тукыма кисәге яки ак флаг тоткан. Йөзләрендә — курку, каушау. Болар — Берлин кешеләре, немецлар. Ак тукыма — җиңелү, капитуляция, безгә бирелү билгесе. Өйләргә дә ак флаглар, тукыма кисәкләре эленгән. Болар бар да бездә бер яктан, җиңүгә ирешүебез турында горурлык уятса, икенче яктан, шундый югары цивилизациягә ия булган немец халкының, дуамал ефрейтор Гитлер коткысына бирелеп, шундый түбәнлеккә төшүе күңелсез тойгы тудыра.

27 апрель иде. Без — Берлинның сугыш бара торган кварталларында. Полковник В. Ермилов белән икәү. Өченчегә — шоферыбыз Иванов. Мөмкин кадәр алга, сугыш бара торган кварталларга якынлаштык. Машина белән үтү мөмкинлеге беткәч, машинабызны аулаграк урында калдырып, җәяүләп кенә алга узабыз. Бу кварталларда генерал-полковник Чуйков командалыгындагы частьлар, подразделениеләр сугыш алып бара. Урам сугышлары шартында әледән-әле кварталларны, йортларны үзгәртеп торган подразделениеләрнең командный пунктларын табу гаять кыен. Безгә аларны тапмыйча ярамый. Без тик алар аша гына алга үтә алабыз һәм сугышчылар турында мәгълүмат, ничек тә бер җай табып, аларның үзләре белән әңгәмә алып бара алабыз. Ермиловның үз эше, үз бурычлары, минем үз бурычым. Миңа, газета өчен Берлинны фашистлардан чистартучы татар солдатлары, үзебезнең якташ сугышчылар һәм алар белән иңгә-иң торып сугышучы егетләр кирәк. Эзли торгач, табам мин аларны. Бик әз минутлар эчендә генә булса да әңгәмә алып барам һәм алар турында, сугыш эченнән бирелгән репортаж өчен дип, үз блокнотыма теркәп куям. Менә алар: Татарстан егетләре — рядовой Галиәхмәт Рәхмәтуллин, өлкән сержант Иван Агашин, рядовой Насыйп Тукташов, мордва егете өлкән сержант Илья Николаев. Болар — озын сугыш юлында зур батырлыклар күрсәтеп, дошманның күп техникасын кырып, солдат-офицерларын теге дөньяга озатып, Берлинга килеп җиткән баһадирлар.

Без тагын берничә өй алга узабыз. Урам артык киң түгел. Каршыдагы өй тәрәзәләреннән безнең солдатлар күренеп куя.

— Әйдә урамның аръягына чыгыйк,— ди полковник Ермилов.— Әүвәл мин чыгыйм, аннан син чыгарсың,— ди бу миңа.

Беләбез, урам сугышлары барганда, һәр почмактан пулемет, я автомат атып торганда, биш-алты метр араны да үтү хәтәр. Шуңа күрә мин:

— Мин кызурак йөгерәм, иптәш полковник,— дим.— Сез — редакциянең партком секретаре, мин — сезнең урынбасар, мондый очракта беренчелек урынбасарларга бирелә!

Өй почмагында торган җирдән атлыгып чыгам да йөгерә башлыйм. 6—7 метр атламаганмындыр, яраландым мин. Кайдандыр аттылар миңа.

— Иптәш полковник, яраладылар мине,— дип кычкырам.

— Кире йөгер!— ди миңа полковник Ермилов.

Мин аксаклап-туксаклап кире йөгерәм. Хәлем китә, җиргә авам. Ташка бәрелеп ярылган кулымнан кан ага. Каяндыр безнең медсестралар килеп чыга, ярамны бәйлиләр. Беренче ярдәм иде бу. Хәзер миңа бик тиз арада операция ясарга, ярчыкны алырга кирәк. Моны тик госпиталь шартларында гына эшләргә мөмкин. Полковник Ермилов машинабызны алып килә.

Ниһаять, мин — койкада. Доктор кушуы белән ярамны ачалар. 3—4 сәгать вакыт бирелә азапланганның соңында, операция тәмамланганны көтеп торган полковник Ермилов, мине, үтенечем буенча, Заган шәһәре янындагы госпитальгә (Заганда безнең фронт политуправлениесе һәм редакцияләр) алып кайтып урнаштырды. Зур гына бүлмәләрнең берсе. Анда барысы да диярлек Берлин өчен барган сугышларда яраланган сугышчылар. Миннән ике-өч кенә койка аша яткан капитанга игътибар иттем. Карасам, минем якын дустым, өч ел буе сугыш елларын бергә-бергә кичкән казах редакциясенең иң актив корреспонденты капитан Сугурбеков. Намуслы, кыю, талантлы журналист...

...Шулай бер төнне яхшы ук тынычлап йоклап яткан чагыбызда кинәт атышулар башланды. Фашист дивизияләре үтеп керде, ахры, дип, барыбыз да сикерешеп тордык. Киемнәребезне караштырабыз. Беребездә дә коралфәлән юк. Ул арада булмады, шәфкать туташлары:

— Иптәшләр, курыкмагыз! Җиңү! Җиңү! Фашистлар армиясе капитуляция белдерде,— дип, бүлмәдән-бүлмәгә кереп, хәбәр иттеләр.

Без инде ул төнне артык йоклый алмадык. Бер-беребезне кочаклашу, үбешү, котлау китте. Ә тыштагы атыш? Ул нәрсә? Ул зур шатлыктан,

жиңү тантанабызны бөтен кешеләргә, бөтен дөньяга белдерү өчен үзебезнекеләр автоматлардан, пистолетлардан да, хәтта пулеметлардан да һавага атканнар... Шуңа күрә жиңү хәбәре таралган сәгатьләрдә Германиянең бөтен шәһәрләре ату тавышларыннан гөрелдәп торды.

Икенче көнне — 9 нчы майда жиңүгә багышланган беренче тантана мәжлесенә безне редакциягә алып кайтырга дип полковник Жуков килде. Госпиталь начальнигы башта риза булмады. Жибәрә алмыйм, дип кырт кисте. Ләкин полковник үз сүзендә нык торгач, артык карышмады.

Редакциянең бер бинасында зур зал. Буйдан-буйга өстәлләр тезелгән. Өстәлләрдә — май чәчәкләре. Табын тулы нигъмәт. Нинди генә ашамлык юк та нинди генә эчемлек юк анда. Офицерлар иң яхшы киемнәрен кигәннәр. Күкрәкләре орден һәм медальләр белән бизәлгән. Аларның шатлыклы йөзләре, күзләре балкый. Ишекне ачып полковник Жуков һәм Ермилов белән без килеп кергәч, залга жыйналган барлык кеше аягүрә басты. Куллар чабып каршы алдылар. Тантанада минем белән бергә эшләүче — капитан Гали Хужиев, старшина Госман Бакиров, кече лейтенант Зәйни Шаһиморатов та бар. Ә капитан Мөхәммәт Садри кайда соң?

— Ул Берлинда командировкада,— диде Гали.

Шул вакыт-ап-ак тешләрен ялтыратып Мөхәммәт килеп керде. Миңа карап:

— Иптәш майор, задание үтәлде! Жиңү турында материал житәрлек булды. Ә иң мөһиме — рейхстагка күтәрелеп: «Без жиңүчеләр булып Берлинга килеп життек!»— дип яздым. Барыбызның да исеменнән кул куйдым!— ди.

— Рәхмәт иптәш капитан, булдыргансың!— дип, Мөхәммәтнең кулын кыстым...

Инде хәзер моңа кырык ел вакыт үтеп китте. Ярам ярты ел эчендә үк төзәлде. Мин моны булып узган бер авыр хәл итеп кенә искә алам. Үз хәлем шулай. Әмма Ватан сугышында миллионнар һәлак булды. Күпләр туган-үскән илләренә кайта алмадылар. Ләкин шул жанын-тәнен аямый сугышкан баһадирлар аркасында бөек социалистик Ватаныбыз жиңеп чыкты.

Бүген Советлар Союзы жир йөзендә сугыш булмасын, тыныч, бәхетле тормыш гөрләсен өчен изге көрәш алып бара. Чөнки дөньяда әле дә хәвеф-хәтәр житәрлек. Америка Кушма Штатлары Ак йортының кара эчле атомчылары үзләре исән-сау калып, Советлар Союзын, социалистик илләрне, алай гына да түгел, бөтен кешелек дөньясын кырып бетерү турында хыялланалар. Ирекле илнең бер гражданы, ветеран коммунист буларак сүземне йомгаклап әйтәсе килгәнем шул:

— Шашынмагыз! Безгә кул озайтсагыз, сезгә каршы Советлар Союзы гына түгел, тынычлык яклы барлык халыклар бердәм күтәреләчәк! Халыклар хөкеме алдында жавап бирүдән беркая да качып котыла алмаячаксыз! Беркая да!!!

## Гадел Кутуй

### Туган ил

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта,
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәрчакта.

Суың тәмле, кырың ямьле,
Шифалы һаваларың.
Сугышларда дан казанды
Синең батыр улларың.

Искә төшә җәйге таңнар...
Рәхәт иде ул чаклар,
Бүген дә әле янадыр күк
Без кабызган учаклар.

Искә төшә бәйрәмнәрең,
Табыннарың, казларың.
Бер карауда гашыйк иткән
Зифа буйлы кызларың...

И данлы ил, и шанлы ил,
Син минем туган илем,
Киткән чакта эчкән суың
Тәме авызда минем.

И туган ил, и матур ил,
Нур күмә калаларың,
Һәр иртә-кич сине, илем,
Сагына балаларың.

Безне озаткан сукмакларны
Капламасын үләннәр,
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сез көтегез, сөйгәннәр!

1944

## Нур Баян

* * *

Хат язсам да инде бармас төсле,
Ахры, ерак киттем илемнән,
Бала чакларымда уйнап йөргән,
Чия чәчәк аткан җиремнән.

Ерак киттем. Бөдрә чәчле таллар
Көтәләрдер таныш җырчысын,
Көтәләрдер кырлар, биек таулар,
Шат күңелле еллар юлчысын.

Борчылмагыз, мине белгән дуслар,
Шат җырчыгыз сезне онытмас,
Бер кайтыр ул, якты кояш сыман,
Дошманнарны җирдән корыткач.

1943

## Хисам Камалов

# БЕЗНЕ ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР

РОМАН



Караңгы төшеп килгәндә Мирхас авылга кайтты. Туры сарайга килде, әмма монда да тайларның исе дә юк. Мирхасның эченә салкын йөгерде, аркасына тир бәреп чыкканын сизде ул. Нишләргә? Тагы кайдан эзләргә? Гыйлмеяр кунактан кайткандыр инде, бу хәлне аңа әйтмичә булмый.

Әйе, Гыйлмеяр кайткан, ишегалды чирәмендә дөм булып исереп ята иде. Мирхасны күргәч, тагы да ныграк исереклеккә салынды, чөнки шулай булу егетлеккә, көчлелеккә санала, күзен дә ачмас булды.

— Малай, тор әле, тайлар югалды бит,— диде Мирхас. Тик Гыйлмеяр дөм исерекләрчә авыз эченнән нидер мыгырданды да тынды. Мирхас аның җилкәсенә төрткәләде.

— Кем миңа суга... анаңны...— дип теге исереклекнең тагы да югары классын күрсәтергә теләде.

— Ышанам инде, күп эчкәнсең, ярар, бер мичкә ачы балны эчеп бетергәнсең, ышанам, тор, тайларны эзләргә кирәк...— диде Мирхас эчтән әрнегән тавыш белән. Гыйлмеяр авыз эченнән ботка пешерде, мыгыр-мыгыр килде, кыланырга ярата инде ул. Ахырда Мирхас, берн игә ирешә алмыйча, төкереп чыгып китте. Караңгыда кардыга килде, тайлар ярата торган яланнарны, үзәнлекләрне айкап чыкты. Сыер көтүчеләреннән сорашты, алар да шул урманда йөргәннәр, ләкин күрмәгәннәр. Мирхас кыйнап ташланган кебек арыган иде, көтүчеләр куна торган келәткә кереп, әз генә ятып алыйм дип, баш төртүгә йоклап та китте.

Күпме яткандыр, бервакыт шуны сизде: аны кемдер аягыннан өстери, башы идән сайгакларына бәргәләнеп бара, әмма уяна алмый. Мирхасны ишек тупсасына хәтле өстерәп китереп: аякларын бусага аша тышка чыгарып куйдылар. Зәһәр чәрелдәгән тавышка ул күзләрен ачты. Ферма мөдире Галимҗан абзый икән, уята алмагач, каты итеп кычкыра бу:

— Тайларыгызны Кәшерләр тоткан, ә сез арт симертеп ятасыз!

Мирхасның кинәт йокысы качты, ул бусагага торып утырды.

— Тотканнар, имеш, куркытмасана,— диде Мирхас кулын селтәп.

— Идарәгә шалтыратканнар. Закуан абзыегызның бик яман ачуы купкан анда. Авансы исемлегеннән дә сызган...— дип Галимҗан аларны җәлләгән кебек әйтте. Ул шүрләтергә уйламый иде.

---

Дәвамы. Башы 4 нче санда.

— Тайлар югалуга минем катнашым юк!— Гыйлмеяр да өйалдыннан аваз салды, ул да килеп җиткән икән, Мирхас аны хәзер генә абайлады. Аның бәлане бик тиз үз өстеннән шудыруына хәтере калды Мирхасның, ачуы килеп, тешләре кысылды. Аванстан мәхрүм иткәнгә Гыйлмеяр шыр җибәрде, бичара, дип мәсхәрәле итеп уйлады. Аның ягына карарга җирәнсенеп, өйдән чыкты. Запас атын тотып иярләде дә урман юлыннан чаптырып китеп барды.

Эчендә нинди-дер ачу, кемгәдер рәнҗү дөрләде. Бигрәк тә Байкалны тотып бер нык кына камчы белән пешерәсе килде. Мие киеренке эшли иде, бу тәбедән ничек ычкынырга? Эшнең ничек-ничек булуы ихтималын күзаллап карады, бәладән нинди юллар белән котылып булыр икән, дип баш ватып барды. Кәшер авылына барып җиткәнче бернинди хәйлә дә уйлап таба алмады.

Тайларны авыл кырыендагы фермага япканнардыр, дип уйлаган иде, нәкъ шулай булып чыкты. Каравылчы тәбәнәк буйлы, киндер күлмәк кигән бер карт, аны кинәнүле елмаю белән каршы алды.

— Ә-ә, чибәр егет синмени ул?— диде.— Син, малай актыгы, бик күп бодайны таптаткансың анда...

—Мин тайларның эзләреннән килдем, алар басу кырыеннан гына үткәннәр, шыттырма,— дип Мирхас битараф кына каршы төште. Капкага игътибар итте, ул зур йозак белән бикләнгән иде. Карт эндәшмәде, димәк, тайларны үзе тотмаган. Капка төбендәге зур таш өстенә утырган да самосад төтәтә.

— Идарәдән килеп акт төзегәнче, һәр тайга 20 тиеннән бир дә алып ычкын?— диде карт, бер күзен йома төшеп Мирхаска карап алды. Гүя бу сүз ничек тәэсир итәр моңа дип сыный иде.

—Андый акчаның нәсел-ыруда булганы юк, әй, абый, үзең акыллы гына кеше...— Мирхас мескен, гозерле тавыш белән үзен кызгандыртмакчы булды. Ләкин карт кинәт кабынып китеп, Мирхасны сүгәргә тотынды. Бөтен ачуын аның өстенә түкте, әшәке телле кеше икән.

— Әнә анда бер чирле тай бар,— дип куйды Мирхас иплә кенә. Ул аның белән әрепләшергә теләмәде.— Әгәр ул зыянласа, актык сыерыңнан колак кагарсың, белдеңме?

Карт сүгенүдән, акча даулаудан кинәт туктады, бер Мирхаска, бер эче-эчкә ябышкан чырайсыз тайга карап алды. Ләкин ул кулга керергә торган төшемнән чигенергә теләми иде.

— Мин ашап киләм, ә син бар, акча алып кил. Болай гына ни, коры кашык авыз ерта.— Картның тавышы бераз йомшаган сыман иде, әзрәк бирсәң, шуңа да риза булачак шикелле. Ул чалбар кесәсендәге ачкычын капшый-капшый таш өстеннән купты, ферма киртәсе буйлап кайтып китте. Мирхасның башында берничә план шытты. Берсе: картны йөгән белән бәйләп ташларга да ачкычын алырга. Аңа гына көче җитәр Мирхасның... Болар берничә кеше тайларны куып алып кайтканнар һәм үзләренә эчәргә акча әмәлләргә маташалар. Идарә берни белми... Икенче бер мөмкинлек табарга уйлап, Мирхас утарга, киртә аша тайлар янына төште. Тайлар, аны шунда ук танып алып, башларын аңа таба суздылар. Барысының да эчләре бушаган, эчкә батып тора. Байкал икенче почмактарак иде. Мирхаска муены белән борылып, башын торгызды, күзләренең агы белән карады. Акылсыз, тинтәк, менә кешене нишләттең, дип тиргәде аны Мирхас. Теге, аңлагандай, башын бер аска, бер өскә чайкап, ялагайланган кебек итте. Мирхасның аңа ачуын кыяфәтеннән сизенеп, туры лапас эченәрәк атлады, якын килергә курыкты. Әмма Мирхас аның артыннан барды һәм бер тайлар кысрыкланган җирдә тегеңә бик каты итеп камчы белән сыдырды. Әй, тыпырчынды Байкал, нишләргә белмәде. Текмә читән өстенә сикереп җимерә язды. Читәннең казыклары начар гына иде. Шунда ук Мирхасның башында тәвәккәл уй туды. Сәндерәдән озын чыбык суырып алды да — бер ку-

лына камчы, икенчесенә шул чыбыкны тотып, тайларны текмә читән буена өерелдереп китерә һәм кысрыклый башлады. Шәп кенә тамызгалап та алды. Байкал шул читән буенда булсын, бүтән тайларны аның өстенә кысрыклап тегенең тайпылыр җире калмасын. Һәм менә шундый момент туды, Мирхас берничә тайга бик каты үткәреп сукты, тегеләр бәргәләнә-суккалана килеп Байкалны читәнгә кыстылар һәм айгыр алгы аякларын читән өстенә күтәрергә мәҗбүр булды. Бер торым читән аның авырлыгыннан шатырдап җиргә авып төште. Кысрыкланган тайлар басымына чыдый алмаган Байкал ачыклыкка ыргылды һәм аның артыннан тайлар, арыкны ваткан бозлы ташу шикелле, алга атылдылар. Мирхас өздереп сызгырып җибәрде. Бер минут эчендә тайлардан тузаннар гына очып калды. Мирхас утардан чыгып, атына атланып торганда каравылчы күренде, йөзе һаман кинәнүле, әле берни белми, чөнки капкадагы йозагы исән-сау иде.

— Ну, малай актыгы, күпме акчаң бар, бир дә элдерт моннан,— дип сөйләнә-сөйләнә килә карт. Аның нык йомшаган икәне күренеп тора иде. Теге чирле тай куркытты инде аны. Мирхас, ат өстенә менә биреп:

— Әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмага килсен!— диде кинәнүле тавыш белән атына селтәнде һәм бер минут эчендә тегенең күз алдыннан юк булды.

Тайларны ничек коткару хакында Гыйлмеяр күпме төпченсә дә, Мирхас сөйләмәде, кулын гына селкеде. Икенче көнне авылга кайтты. Яшереп ике-өч дистә йомырка әзерләгән иде, чабыш алдыннан Очкынга шуларны эчертергә кирәк. Ләкин председатель вакчылланган, Очкынны идарә атлары сараена алып, бикләтеп куйган иде. Мирхас тизрәк аның янына керде. Закуан аны көтеп кенә торган икән, Мирхаска бик кискен ябышты. Тайларның тотылуы бары сылтау гына иде.

— Җыелышта вәкилгә ниләр әйттең? Имеш, утынга ат сорый башласаң, иң элек председательнең көен табарга кирәк? Синең мине кейләгәнең бармы?

— Бар,— диде Мирхас. Теге аның сүзен, ишетмәмешкә салынып, колак артыннан уздырды.

— Панимаеш, менә телең озын, шуңа бәхетең кыска. Нәселегез белән колхозны өнәмисез. Әтиең дә колхоздан качып читкә китте дә бетте.

— Качып түгел, вербовать ителеп, законно.

— Әниең дә колхозда эшләүдән йөз чөереп Ленинградка сыпырган.

— Ул кунакка гына барып кайта.

— Панимаеш, вәкил каршында туган колхозыңның яман атын сатасың, ә үзең кем? Лодыр, йоклап, тайларыңны тоттыргансың...

— Мин дөресен әйттем.

— Бүгеннән тайлар кәтәргә Шәрифҗан малае чыгар. Бетте!

— Ә миңа ни эшләргә?

— Әнә сабанга йөрерсең,— диде Закуан, сүз тәмамлануны белдереп йөзен икенче якка борды. Мирхас бер мәл тынсыз калды, уйларын бер ноктага җыя алмый азапланды. Тайлардан аерылса да, әйдә, ярар инде, әмма Очкын белән чабышка барасы бик килә. Елдан артык шуның белән хыялланды. Инде нишләргә? Ул мескен кыяфәткә керде, ялынып карыйм әле, бәлки, миһербаны килер дип уйлап, председатель каршына торып басты.

— Очкын белән чабышка барыйм инде, Закуан абый, һәр сүзеңне тыңлар идем?

— Юк, юк, өмет тә итмә. Чабышка Фәррах малае Талип бара,— дип, тәмәке төпчеген көллеккә басып сүндерде. Ниндидер папканы ачып кәгазьләренә иелде, янәсе, синең белән эш бетте, ычкын моннан... Мирхасның эченә ачы ут җыела башлады, ачудан борын яфраклары селкенде. Бигрәк тә Фәррах исеме аның бәгыренә барып тиде. Ул адәм тегесен әләкләп, монысын чагып, идарә тирәсендә тәлинкә ялап йөрүче бер ялганчы хөрәсән иде.

— Очкынны да Фәррахка саттыңмыни инде, әй, Закуан абый! — диде Мирхас, кешеләрнең кайчак нинди вак җанлы һәм җирәнгеч булуларына рәнҗегән тавыш белән. Закуанның какча йөзе агарып китте, озынча битендәге җыерчыклар югалгандай булды.

— Бу сүзләрең өчен сине милиционер Кузьминга биреп җибәрергә кирәк,— дип кычкырды ул.— Кара фикерле булып үсәсең, чамала аны...

— Дөреслек күзеңә төртеләме? Чынын әйткәнне кара фикерле дип гаеплисең...

— Гаеплим, чөнки син колхозны яратмыйсың...

— Ә син бик яратасың инде, колхоз атын сатып кәефләнеп йөрисең. Шуңа күрә син ак фикерле...

— Мин колхоз өчен көн-төн чабам...

— Син нәфсең артыңнан чабасың. Кичә Әсәнҗанда кәеф корып утыргансың...— Мирхас идарәгә керүчеләрне күреп туктады. Закуан аларны берни булмаган кебек елмаеп каршы алган булды һәм алар көлешә-көлешә сөйләшә башладылар. Мирхас, кулын селтәп, чыгып китте. Идарә атлары сараена барып, кечкенә тәрәзәсеннән Очкынны күзәтеп тора башлады. Ат боек иде. Мирхасны танып колакларын ике кайчы җәбе кебек торгызып карады. Аның шәмәхә күзләрендә җанны уеп ала торган моң бар иде. Әллә шул моңнан, әллә кулыннан бүтән бер эш килмәүдән гарьләнеп, Мирхас өйләренә кайтып китте. Абзар артларына керде дә үксеп-үксеп елады... Ул саф күңел белән йөри иде, кешеләрнең вакчыллыгына бик нык рәнҗеде һәм үзен тыеп кала алмыйча яшь койды...

Өч көннән соң сугыш чыккан хәбәр бөтен дөньяны дер селкетте. Бар нәрсәнең асты өскә килде. Район үзәгендәге җыеннан ук китәргә повестка алучылар булды. Урамда елаган хатын-кызлар һәм кызмача ир-ат тавышы яңгырап торды. Кыңгыраулы тройкаларга төяп, алынганнарны Келәүлегә озаттылар... Мирхаска байтак вакытлар олаучы булып станциягә кешеләр ташырга туры килде. Аннары киткән кеше урынына ат карарга куйдылар. Очкын авырый, көннән-көн сүнә барган кебек иде. Эш шунда, теге чабышка барасы Талипны, егылыр дип куркып, әнисе тыйган. Шулай итеп Очкын чабышка бара алмый калган иде. Сабан туе көнне аны сарайда бикләп тотканнар. Очкын тумыштан чабышкы иде, үткен, зиһенле иде. Кыңгырау, гармун тавышлары ишетеп, нишләргә белмәгән, әрле-бирле суккаланган. Сикереп тәрәзәгә алгы аякларын куеп торган, башын өрлеккә бәргән. Айлар буе дәртләнеп, чабышка ымсынып яшәгән Очкынның үз ишләре белән узышасы килгән инде. Чабышта узып, башына матур яулыклар тагасы, шул зәңгәрле-аллы яулыклар белән мәйдан әйләнәсе, алкышлар ишетәсе килгән. Үзенең бүтәннәрдән алдан чыгуы белән горурланасы килгән. Ул өзелеп-өзелеп кешнәгән, әмма аны сабан туена алып чыгучы булмаган. Шул хәлдән соң эчендә нәрсәдер өзелгән кебек калган. Очкын тамагына ашамый иде инде. Аяк өсте йокымсырап тик тора. Ветсанитар дәвалары да ярдәм итмәде, ике ай дигәндә Очкын үлде. Шунда гына аның чын чабышкы булганын төшенделәр, андый анты ярышка чыгармый калырга ярамый икән, диештеләр.

Мирхаска төрле яклап бәла яуды. Әнисе Ленинградтан кайтырга чыккан, ләкин эшелоннарын немецлар бомбага тотканнар. Бик күп кеше үлгән. Рокыя апаны үзебез җирләдек, дип, күрше авыл кызлары хәбәр иттеләр. Мирхас елый алмады, тәмам бәгыре каткан иде. Сеңелесе Рәзинә елап, шешенеп бетте... Болай яшәү мөмкин түгел иде. Мирхасны әтисенең энесе Һазлый абый үзенә алды, Рәзинәне Әкълимә апасы сыйдырды. Сугышның беренче айлары ук Мирхасның тормышын бөтенләй пыран-заран китереп ташлады. Кешедә торуы авыр иде. Һазлый абый итек басучы. Мирхаска эштән соң төннәр буе йон тетәргә туры килә. Иртән кара төкерек төкерә иде. Һазлый абыйның үз балалары юк, че-

регән бай, әмма үтә чыккан сараннар. Бары ике ашау белән генә торалар. Казанга бәрәңгене санап салалар...

Кырык икенең кышында Мирхасларга да хәбәр килде. Китканда гармун белән урам әйләнделәр. Кай егетләр, сөйгән кызлары өе турында, җырлаудан туктап, арадан чыгып кала иде. Югары очка менеп җиткәндә егетләр бары өч-дүрт кенә калды. Мирхас бер өй турында да туктамады. Аның күңелендә Рифа иде...

— Зәйнуллин, энпега дежурга!— дигән Мөслимов тавышына Мирхас уянып киткән кебек булды. Теге алгы сызыктан элемтә сузып кайткан иде.

## 7

Батареяның күзәтү пункты кечкенә тау өстенә, ачык урынга эшләнгән иде. Сул якта ниндидер куаклар белән капланган чокыр сузылып китә. Блиндажга тик шул төштән генә килергә була. Бүтән юл юк. Көндез күзәтү эшләре белән бик сак кыланырга туры килер. Разведчиклар начар урын сайлаганнар. Нишлисең, төнлә күп нәрсәне шәйләп булмый шул.

Идрисов, бүген көне буе күзәтү пунктында ятып, шундый нәтиҗәгә килде. Көндез элемтәчеләр дә сырт буенча сузган чыбыкларын ялгый алмый газапландылар, әз генә баш калкыттыңмы, немец атарга тотына иде. Бигрәк тә снайперлары хәтәр, башны мушкага алырга гына торалар.

Ниһаять, кич булды. Шул чак блиндажга җан керде. Ашарга, эчәргә алып килделәр. Кайберәүләр, алышынып, батареяга кайтып китте.

Идрисовка алмаш юк иде. Ул хәзер укчылар янына барырга тиеш. Алар белән бергә килешенәсе эшләр күп. Кайсы квадратта немецның нинди ут короллары урнашкан, беренче траншея безнең окоплардан нинди ераклыкта... Һәм башка бик күп шуның ише тәгәллекне сорый торган нәрсәләр. Әйе, бу юлы алны-артны шәйләбрәк эш итәргә кирәк, укчылар зарланырлык булмасын, дип үз-үзенә боерык биргән кебек уйлап, ул блиндаждан чыкты. Караңгы төшкән, ә карлы-бозлы яңгыр һаман сибәләп тора. Солдатның тәмам җилегенә төште бу салкын яңгыр... Немец исә, серле дөм караңгылыктан курыккан кебек, ракета чөя. Кинәт якын-тирәне зәңгәр яктылык сара, ракетаның һавада уты мөлдер-мөлдер килеп бераз тора да сүнә. Тагы шомлы кара пәрдә шикелле караңгылык каплый. Кайдандыр немец пулеметы, ток-ток килеп, атарга тотына. Колак кырыеннан гына выжт-выжт итеп, пулялар узганы ишетелә һәм ул тавышка башыңны кинәт иясең, үзең дә сизмәстән пуляга сәлам бирәсең.

Ул укчыларны көчкә эзләп тапты. Парольне әйткәч, часовой командирларының блиндажын күрсәтте. Блиндаж авызында баскыч тырпаеп тора иде. Идрисов шуннан аска төшеп китте. Бу — өсте юка гына ябылган, стеналары цемент белән катырган дүрт почмаклы тирән генә баз икән. Берәр хуҗаның чөгендер базы булгандыр инде, солдат шуны бик шәп блиндаж иткән. Бер почмакта сукыр ут яна, идәнгә салам түшәлгән.

Укчылар командиры капитан Мамак киң каратут битле, ягымлы кеше, кырын яткан җиреннән калылт кына торып, Идрисовны озак көткән сыман каршы алды.

— Килдеңме?— диде ул, күрешергә кул сузып.

— Безне энә белән җеп иттеләр, ә?— дип, Идрисов чыраена бернинди ризасызлык чыгармыйча Мамакка карады. Теге исә, нишлисең инде, бүтәнчә чара юк, дигәндәй, кулларын ике якка җәеп җибәрде.

— Бу юлы кесәгә пес итмәссезме соң?— дип, шаяртулы-төртмәле итеп әйтеп куйды Идрисов. Теге вакыттагы дәгъваларын искә төшереп, бер-ике сүз әйтте.

— Күзегезне ачыбрак эшләмәсәгез...— Мамак сүзен әйтеп бетермәде, битендә елмаю нурлары яктырды.

— Кесәгездә һаман безгә таш йөртәсез, ә?— Идрисов та тамак төбе белән генә көлгән итте.
— Өлешеңә ни тия, шуны аласың инде.
— Юк, бер-беребезгә таш ыргытышмыйк.
— Ә ташны ташка бәрмәсәң, очкын чыкмый бит! — Мамак көлемсерәп, ачык чырай белән карап торды.
Алар карталарын алып, лампа кырыена, салам өстенә җәйгән плащ-палаткага утырдылар. Фикерләр чарпылышты, икесе дә немецның хәйләсен төшенергә теләп, үзенең гөманын әйтә иде, немец оборонаны өч катлы итеп төзегән булса кирәк, һөҗүм җиңел булмаячак. Әгәр дә менә коры үзәннән килеп бәрсәк, көтәме ул аннан безне, көтмиме? Һәрхәлдә, немецны үзеннән ахмак санарга ярамый. Аннары Мамак үзенекен сөйли башлады.
— Миңа яңа рота тактылар бит әле,— дип, тирән итеп көрсенде. Йөзен борчылу күләгәсе каплады.— Авырткан башка тимер тарак! Командирларын кичә снайпер чүкеде.
Әкрен генә баскычтан өскә күтәрелделәр. Позицияне икәүләп тикшерергә кирәк иде.
Буй күмелерлек тирән казылган траншеядан көчкә-көчкә атлап бардылар. Яңгыр тәмам чылатып бетергән мәте балчыгы аякка тышау кебек булып урала иде. Анда-санда пулемет ояларында сугышчылар күшегеп басып торалар. Кайсы җирне куыш кебек тишеп кереп, шунда ышыкланып утыра. Бер-ике җирдә бик каты ютәллиләр. Шул тавышка немец кул миномётыннан атарга тотына. Ютәлләү тавышы — һәм берадан выжылдап килеп, окоп кырыенда гына миналар шартлый башлый. Мамак бу тәртипсезлекне бик тиз чамалап алды. Бер бөгелә-бөгелә ютәлләүче солдат янына барып туктадылар.
— Отставить! — диде Мамак басынкы тавыш белән. Ләкин солдат ютәлен баса алмады, траншея төбенә чүгәләде. Шул арада немец миналары килеп житмичәрәк шартлый башладылар. Зарядлары дымлы, шуңа килеп житми, дигән уй килә иде. Теге бияләе белән авызын каплап йөткерә, тыела алмый.
— Немецның нервысын кузгатасың! — диде Мамак, сугышчы янына чүгәләп. Бу яшь кенә, яңаклары ике якка калкып торган егет иде.
— Нишлим соң, иптәш капитан, ботинкам тишек.
— Старшинага әйттеңме?
— Әйттем.
Мамак эндәшмәде, шул мәл күккә чөелгән немец ракетасының тоныклыктысы аның борчулы йөзен яктыртып алды. Пулеметтан ату тынгач, ул торып басты, сугышчының җилкәсенә орынып, аны үзе артыннан барырга кушты. Аннары Идрисов янына ук килеп ым какты: кире борылырга туры килә бит әле...
Алар теге базга кире төшкәндә, старшина яңа гына термос белән ботка алып килгән иде. Үзе шактый кәефләнергә өлгергән күренә. Мамакка нәрсәдер сөйләп куштанлана, бер күзен кысып-кысып алгалый. Ләкин командирның йөзендә болытлар куера башлады, кашлары сыңгалап алды. Старшина, сизенеп, аның җаена ятарга теләп, бөтерелде.
— Ялагайлануны отставить! — диде Мамак коры гына һәм салам өстенә утырды. Старшина тынды, йөзенә: ни боерасыз, дигән буйсынучанлык чыгарып, текәлеп тора башлады.
— Әнә Ермаковның ботинкасын алыштыр! — Мамак һаман ютәлләп азапланучы теге сугышчыга ымлады.
— Юк бит, иптәш капитан. Складта булмады.— Старшинаның тавышы бик төче, ә күз алмалары ничек ярарга белмичә, әле болай, әле тегеләй әйләнделәр.
— Алайса үзеңнекен салып бир! — диде Мамак, тегеңә карамаска тырышып. Старшинаның йөзенә ишарәле елмаю җәелде, иптәш капитан, шаяртасызмы, дигән кыяфәткә керде.

— Тишек ботинка белән йөреп кара, шарикларың әйбәтрәк эшли башлар. Бик файдалы!

— Иптәш капитан...

— Приказны үтәгез!— дип Мамак кырт кисте. Старшина базның теге башына китте, шунда мыгырдана-мыгырдана күн итекләрен салды.

— Ялагайларны жаным күтәрә алмый!— диде Мамак, Идрисовка таба борылып. Аның чыраенда үзенең бу әмереннән риза түгеллек чагылды. Идрисов эндәшмәгәч өстәде:— Куштанлыкта хыянәт орлыгы бар!— үзенең әлеге катгыйлыгын ничектер аклыйсы һәм нигезлисе килгән кебек иде.

Ул арада старшина итекләрен киеп алган Ермаков, сөенечен күрсәтмәскә тырышып, килеп басты. Мамак аңа сержант Хәбировны бирегә чакырырга, ә үзенә аның урынына калып торырга кушты. Теге бик риза булып, тизрәк моннан ычкыну ягын карады.

Старшина йөзе бүртенгән, карага коелган килеш йоклап ятучы сугышчыларны дежурга уятып чыгарып җибәрде. Аннары термосны беләгенә асты, ипи буханкалары тулы капчыкны җилкәсенә элде дә баскычка таба атлады. Ул икенче блиндаждагыларга аларны илтергә тиеш икән.

— Тамчысын да кыйшайтмыйча сугышчыга бир,— диде Мамак, аңа җилкәсе аша башын борып.

Старшина нәрсәдер мыгырданды һәм әйберләрен җилкесенә җайлап селкенде дә баскычтан менеп китте.

Икесенә дә ничектер күңелсез булып калды. Буш сүз сөйләшә башладылар. Идрисов шаярткан булды.

— Старшина белән бозылышмасаң, хәзер авызны чөйгә элеп утырмас идек,— дип кызгану белдерде. Бу шаяртуда дөреслек бар, күшектерә торган юеш салкында патшалар ризыгы бер дә зыян итмәс иде.

— Ул шундый ялагайлануы белән җаныңны оккупацияли,— диде Мамак, эчке иреген саклаганга канәгать калып.— Аннары аның ихтыяры белән йөрергә туры килә. Юк, мин алай булдыра алмыйм.

Капитанның бу сүзләре Идрисовка бик аңлашылды. Дөрес кеше икән бу, туры тукран икән, әмма андый кеше белән яшәве бик авыр.

Бераздан Хәбиров кайтты. Мамак аны күрүгә сизелерлек йомшады, йөзенә нур бөркелде, ачуы эреп юкка чыкты. Бая әйткән үткен сержант шушы инде, дигәндәй Мамак Идрисовка ымлады. Бәлки ул аның татар булуына ишарәләгәндер.

— Ну, ничек анда??— дип, елмаеп, Мамак Хәбировны иңеннән ярым кочып алды, үзе янына саламга утыртты. «Казбек»ны кабы белән чыгарып алдына куйды. Хәбиров үзен иркен тота иде.

— Немец бик нервылы, иптәш капитан,— дип, Хәбиров берне кабызды да сөйләп китте. Сөйләгәннәре бик мәгънәле һәм эшлекле булуы сизелеп тора иде. Немецның ике-өч җирдә тозагы булу ихтималын сурәтләде ул. Ышандыру өчен: мин немец урынында булсам, шулай эшләр идем, дип тә өстәде. Мамак аңа болай да ышана иде. Чынлап та Хәбиров булдыклы күренә, бер-ике минутта әллә никадәр сорауларга ачыклык кертте. Киңәшләрен әйтте.

— Ә үзеңнекеләр ни хәлдә?— диде Мамак, тактик мәсьәләләрне «чәйнәп» бетергәч. Хәбировның ябык, озынча чыраенда, аш өстендәге өре кебек кечкенә күзләрендә жылылык тибеп чыкты.

— Һөҗүм кайчан, диләр, бирешмиләр,— дип, тәмәкесен яңаклары эчкә батканчы суырды.

— Ну, молодец, Хәбиров, мең рәхмәт!— дип, Мамак Хәбировның җилкәсен, чын күңелдән яратып, чәбәкләп алды. Үзе сокланып аңа карап торды.— Син бит мин эшлисе эшләрне башкарасың!— Аннары Идри-

совка таба башын күтәреп өстәде:— Менә шундый мировой кешеләр белән эшләргә һәм уларга дә җәл түгел!

— Сез миңа ышандыгыз, иптәш капитан...— Хәбировның тавышы калтырангандай булды, ләкин ул сер бирмәде, йөзендә канәгатьлек нуры яктырып торды.

— Мин сиңа ярдәм итәрмен, Хәбиров!— Мамак аның кулы белән һаваны ярды, сүзе нык шикелле иде. Ләкин Хәбиров тыныч калды, ул сүзләр аңа бөтенләй кагылмаган төсле тоелды.

— Сүземне җилгә очырмам,— дип өстәде Мамак.

— Беләм,— диде Хәбиров өзеп кенә. Нигәдер күзләре моңсуланды, йөзенә сөенеч нурлары чыкты. Әллә шул уңайсызлыктан качар өчен, әллә эчтәге шатлыгын ялгыз гына кичерергә теләп, ул китәргә кузгалды. Бер папирос алды да, кабызып та тормыйча, Мамакны бик олылыклап саубуллашып, баскычтан менеп китте.

Ул киткәч, Идрисовның сораулы карашы Мамакка төбәлде. Аны Хәбиров шәхесе бик кызыксындырган иде.

— «Тарихын» бераз сөйләгән иде, матавыкка эләккән бугай. Бәла солдат башыннан йөри инде...— Мамакның тавышында Хәбировны кызгану ишетелде.

— Хәлләр корбаны булган мәллә?

— Шулайрак шикелле.

— Әллә озын теллелек бәласеме?

— Ихтимал. Ну булган кеше дә инде үзе! Аңарда әллә нинди практик сәләт бар.

— Солдатларының җаен тапкан бит, ә? Башлы кеше!

— Шундыйларның сәләтен тыныч тормышта файдалансаң иде?

— Байлык инде, байлык.

Якында гына авыр снаряд төшеп шартлады, түшәмнән балчык койды, сүз бүленде. Берничә сугышчы өшеп, күшегеп, дежурдан кайтып керде. Ничек җылынырга белмичә таптанып йөрделәр дә саламга бөрешеп яттылар. Мамак та торды, плащпалаткасын җыйды. Сугышчылары янына, алдагы окопларга барырга кирәклеген әйтеп, тыштагы тавышларга ымлады. Анда туптан һәм пулеметтан аткан авазлар кинәт кенә шикләнерлек куерып киткән иде...

Бер блиндаж турыннан үткәндә, эчтән шаян җыр ишетелде.

Бу — Хәбировныкылар иде. Самокат белән Хәнҗәров сугышчыларның күңелен күтәрә...

## 8

Нишләдем мин, ходаем, нишләдем? Бу бит үз-үзеңә хыянәт итү белән бер. Ничек шулай ихтыярымны җуйдым? Бер дә болай булганым юк иде. Нинди хәлгә төштем мин? Биргән антларымны җиргә салып таптадым, бурычларымны оныттым. Абыйның ачулануына үч итеп шулай эшләдемме? Майорны үзеңә каратырга тырышма, ул безнең кеше түгел, диган иде. Урмандагылар белән дә белешмәскә кушты. Кем яклы соң ул? Әберкем дә яклы булмыйча яшәргә мөмкин түгелмени? Абый әйтә, һәркем иң элек үзен кайгырта, ди. Чынлап та мин үземне кайгыртам икән, бу начармыни? Ачык шуны тәгаенләргә кирәк: кайсы як ярга чыгарга? Абый отыры икеләнә, хәзер «урман кешеләренә» ярдәм итсәң, кызыллар җиңгәч, җәзасыз калдырмаслар дип курка. Әярдәм итмәсәң, алар үзебезнекеләр, җиңә калсалар, шулай ук баштан сыйпамаслар. Шуңа күрә бер якка да катышмау иң яхшысы икән... Әмайор мине ярата, минем сөелергә хакым юкмыни? Мисез хатын-кыз гына моңардан баш тартыр. Минем дә бөтен тойгыларым аңарда бугай. Нишләдем мин, ходаем, нишләдем? Мин аны дөрестән дә капкынга эләктермәкче булган

идем, ләкин киресенчә килеп чыкты, мин үзем аның «капкынына» эләктем шикелле. Әйе, әйе, моны танымыйча мөмкин түгел. Юк инде, миңа үз-үземне алдарга һәм ялганга ышанып яшәргә ярамый. Майор ачык әйтте: безгә хәрби хезмәткә кер, диде. Туктале, нишләп мин аңа шул чаклы ышанам? Син аның киткәнен дә белми калдың бит? Китте — бетте инде ул, каян син аны таба аласың хәзер? Юк, ул әйберләрен дә алмаган, һичшиксез киләм, дип киткән. Әмма моның бары сүзләр генә булып калуы ихтимал бит? Шушындый вакытта вәгъдәләргә ышану, бер уйлаганда, чын ахмаклык инде. Ләкин мин аңа шул кадәр ышанам, нигә икәнен үзем дә аңлатып бирә алмас идем...

Кызыллар Риганы алганнар, шунлыктан айзсорглар да акылга киләчәкләр. Буш эш белән йөргәннәрен аңлаячаклар инде. Әмма фанатиклар бар икән әле. Петермуйжада бер офицерны төнлә үтергәннәр, ди. Шуны ишетеп, абый безне тизрәк шәһәргә озатты. Биредә тынычрак. Бар төштә тәртип урнашып бара. Инде Башкарма комитетлар төзелгән. Алар бар эшне җайга сала башлаганнар. Митава нык җимерелсә дә, безнең фабрика исән-имин калган. Кайбер ватык станокларны ремонтлап, фабриканы эшләтергә керешәләр икән...

Зитта шулай уйлана-уйлана немецларның «аус-вайс»ларын совет документына алыштырырга бара иде. Кыяфәте күз кунарлык түгел, махсус начар киемнәр киенгән, чөнки бу иң ышанычлы саклану әмәле. Аны танырлык та түгел шикелле. Ләкин бер урам почмагыннан борылганда кемдер арттан килеп Зиттаны култыклап алды. Зитта, эсселе-суыклы булып, беләген тартты.

— Иple генә,— диде ниндидер калын тавыш — Туктама!

Зитта исен җыеп тегеңә борылып карады һәм беркөн аларга килгән егетне танып алды. Ул аны фабрикада да күргәләгәне бар иде. Кемдер аның хакында русларга сатылган, дигәне хәтерендә. Немецлар килгәч, аны немец шымчысы, дип әйтүчеләр дә булды. Имеш, ул да айзсорг, бичара ватаныбызның мәнфәгатен кайгырта.

Алар тар гына ярым караңгы ишегалдына кереп, бер кеше йөрми торган баскычтан икенче катка менделәр. Зитта инде үзен бераз кулга алып өлгергән иде.

Бу кеше таза гәүдәле, чи ит кебек кызыл йөзле, кечкенә күзләре нык эчкә баткан, шуннан тишәрдәй булып карыйлар. Ул Зиттаны кеше яшәми торган бүлмәгә алып керде, бердәнбер креслога утыртып, үзе бер кырыйдагы хәчтерүш кенә өстәл артына урнашты. Ул ничектер сорау алучы прокурорны, ә Зитта гаепләнүчене хәтерләтә, дөресрәге, аның кыяфәте хөкем итүче кебегрәк кырыс иде. Кулларын өстәл өстенә куеп, Зиттага сорау тулы караш белән чекерәйде. Нәрсә сораганы билгеле инде. Зиттаның төгәл мәгълүматлары юк, шуңа күрә чарасыздан алар утары тирәсенә урнашкан частьлар турында инша кылырга тотынды. Башта шома гына чыкты, дөрескә охшаш итеп сөйләде, ләкин бер-ике җирдә зиһене, елгырлыгын җуеп, төртелде, бутала башлады. Зитта берни булмаган кебек дәвам итте, әмма агент өстәлдә бармакларын бармакка үреп куйган кулын кинәт язып җибәрде, идән астыннан килгән кебек тонык, калын тавышы яңгырады:

— Алдыйсың!

Зитта сискәнеп китте, керфекләрен тырпайтып агентка карады. Аларның күзләре очраштылар, Зитта озак чыдый алмады, күзен читкә борды.

— Ни, белә алдым...— дип, Зитта берни булмагандай тотынган иде, тегенең чәнечкеле елмаюын күреп, туктады. Ул исә, мине «утырта» алмассың, дигән кыяфәттә һаман елмая, гүя үзенең сизү сәләте белән масая иде. Аннары күзләрендә ригая нуры беленде һәм ул мәрхәмәтле тавыш белән сорады:

— Сиңа нидер булган, яшермә?— диде.

— Каян чыгып шулай әйтәсең?— Зитта шәл кырыен маңгаенарак тартып куйды. Әллә әби әйткән сүз дөресме, ул бар җиреңнән нур бөркелә, дигән иде...

— Мин барын да беләм,— дип, агент тагы җитерәк итеп карады.

— Ташлагыз, чокчынып маташмагыз!— Зитта үзен тәмам кулга алырга өлгерде, шуңа тавышы ышанычлы чыкты.

— Кызый, әйдә, күз буышлы уйнамыйк!

— Уйлаганым да юк!

— Син ихлас сөйләшмисең. Бу — зарарлы!

— Сез ышанмагач, мин нишлим инде! Ну?— дип, Зитта аның күзенә кирәрлек булып тавышын күтәреп әйтте. Теге тагы кулын өстәл өстенә куеп бармакларын бармакка китереп үрде. Тынып, күзен читкә төбәде. Эчтән ниндидер карарга килергә азаплануы маңгаендагы җыерчыклар хәрәкәтеннән беленә иде.

— Хәзер һәр нәрсәгә ышануы кыен, шуңа бер-беребез алдында хәрәмләшмик! Намус бурычыңны онытмагансыңдыр бит?

— Онытмадым,— диде Зитта. Эчтән тагы уңайсызлану сизде, йөземә чыгар инде дип тәне эсселе-суыклы булды. Агент аның сөйләгәннәрен берәм-берәм ялганга чыгарып,битенә бәрер дигән шик һаман аны сагайта һәм аның җаенарак ятарга, энәләрен тырпайтмаска мәҗбүр итә иде.

— Шулай булгач?

— Ышанмаган кешене ничек ышандырырга? Белмим...

— Бу заманда үзеңә дә ышанып булмый,— дип зарланган кебек әйтте агент. Аның ничектер аяу сораган сыман булган тавышыннан Зитта кыюланыбрак китте.

— Үзеңә дә ышанмагач инде...

— Менә бит, ышанып йөргән кешең ышанычыңны акламый? Аңа тагы бер мәртәбә ышаныргамы?

Зитта бу сорауның үзенә төбәлгәнен бик яхшы сизде һәм, аңа әһәмият итмичә, сүзне бүтән эзгә борырга тырышты.

— Дөнья бер-береңә ышаныч белән тора...

— Без ышанып йөрибез, ә ул күптән безгә хыянәт иткән?— дип агент тирән итеп күрсәнде, үзе тагы ригая белән елмайды, бу сөйләшү аңа ошый иде булса кирәк. Зитта да тагы үзенә ишарәләп әйткәнне колак яныннан уздырып җибәрде, елмайды, чәчләрен шәл эченә тыкты. Агент нәрсәдер суза, нигә ул аны фаш итми? Әллә Зиттаның сүзләренә аз булса да ышандымы? Әллә бу дипломатиянең артында берәр төрле әшәке мәкер бармы?..

— Бәлки сезгә үзегезне кайгыртырга кирәктер?

— Мин үземне дә кайгыртам, сине дә...

— Ни өчен мине?

— Милләтебезнең аңлы вәкиле булган өчен...— диде агент йомшаган тавыш белән. Зитта аңа шәле астыннан күз сирпеп алды да уйланып калды. Һаман шушы милләт дигән сүз белән какшатмакчы булалар аны. Аңлы вәкиле, имеш. Шушындый шартларда нәрсә генә эшли алсын ул? Хәзер аерым бер кеше берни дә эшли алмый... Ә бу егет ни дә булса майтара алуына ышана микәнни? Нинди балалык! Ул фабрика идарәсендә эшли иде. Кызлар бер дә яратмый иде үзен. Бик ялагай, начальниклар алдында палас булып җәелергә торуыннан көлеп йөриләр иде. Ялагай ир-аттан да күңел кайтаргычрак нәрсә юктыр дип сөйләнәләр иде. Хәзер ул бик нык үзгәргән, шактый нык таушалган күренә. Әллә битлек кенә кигәнме? Күпме хәзер битлек кигәннәр?! Ә бу адәмне нәрсә йөртә икән? Чынлап та ватанын сөюеме? Ничектер ышануы читен. Әллә элеккеге түрәләре кушуы буенча гына йөриме? Мөгаен, шулайдыр, ялагай кеше бүтәнчә булдыра алмый ул. Шулай да бу кискен хәлләр кешене курчакка әйләндерә шул. Кеше көч ягына чыгарга мәҗбүр була. Кем көчле, шул хаклымы әллә?

— Нигә уйга калдың? Яшәргә телисеңме?— дип, агент тагы аның уйларын бүлде.

— Телим, билгеле.

— Соң шулай булгач, тормыш шартлары сиңа нинди роль бирә, шуны башкарасың инде. Бездән генә калмаган...

— Мин ул рольгә ярамасам, ничек?

— Рольләр бүленеп беткән, бәхетеңә тигәне шул. Бөтен кеше дә үзенә төшкән рольне башкара, син генә ник кәҗәли torгансыңдыр.

— Мин ул спектакльне күз алдына китерә алмыйм.

— Кеше үз роле турында гына кайгырса, әйбәт була.

— Бәла шунда, рольнең мәгънәсен аңламыйм,— диде Зитта ачынып. Сүз көрәштерү аны туйдыра башлады.

— Димәк, яшисең килми?— дип агент кинаяле тавыш белән әйтеп куйды.

— Кемнең инде яшисе килмәсен!— диде Зитта ачуланып.

— Алайса «рольне» башкарырга тиешсең! Мондый шартларда башкача булалмый.

— Ну, нинди эш кушасыз?— диде, кабат шәленнән чыккан чәчләрен тиз-тиз рәтләп.

— Менә рәхмәт,— дип, сөенгәндәй итте агент.— Минем өчен дә әйбәт. Тәк, эш болай: Ауце шәһәрчегенә ничек тә барырга, бу яктан килгәндә сулдан өченче ике катлы йортка керергә һәм сорарга: минем яралы братым монда ятамы?— дип. Ул кеше безгә кирәкле мәгълүматлар бирер, син шуны безгә кайтарып җиткерергә тиеш... Пүчтәк кенә эш...— Агент өстәл өстендә ике кулын җәеп, ниндидер канәгатьлектойгандай, хәрәкәт ясады. Зитта ансат кына ризалашып, аның шиген кузгатмас өчен генә заданиены шактый тәфсилләп сораштырган булды. Бу эш теге Балта кушаматлы агент кушуы буенча эшләнәмe?— дип тә төпченгән иде, егет исә: ансы синең рольгә керми, синең рольгә кергән сүзләр әнә шул, шуны ятла, диде дә әңгәмәне бетерде.

Киткәндә Зиттаның бу кешегә һәм үз-үзенә ачуы ташыды. Нигә аның башын тинтерәтәләр бу мәгънәсез эшләр белән? Нигә аны шикле эшләргә бутыйлар? Һәркемгә роль бирелгән, имеш, ул шуны башкарырга мәҗбүр, телиме, юкмы, барыбер..

Әгәр агент кушканнарны эшләсәм, мин майор күзенә бүтән күренә алмыйм инде! Бу тәгаен шулай. Минем аңа юлларым өзелә. Ягъни үз юлымны үзем өзәм булып чыга... Юк, юк... Ул китте, ә мин аның турында гына уйлый башладым, ә монда чакта алай ук түгел иде. Аерылу яратуны көчәйтеп, аңа ут өстәп җибәрәме? Аерылу яратуны сүндерә, бетерә диләр иде, ә минем киресенчә килеп чыкты... Ничек тә майордан бер хәбәр булырга тиеш! Булмавы мөмкин түгел. Шуның өчен тизрәк абый утарына кайтырга кирәк...

## 9

Үз командалыгындагы дивизион тупчы батареяларның корал-ярак белән тәэмин ителеше турындагы отчет өчен Мостафинны полк штабына чакырдылар. Төрле бүлек интендантлары җыелган иде. Мостафин җитешмәгән нәрсәләр турында, аларны табу кыенлыгы һәм шунда килеп туган бюрократизмны әйтеп бирде. Шунлыктан кайбер үшән, озак мыштырдый торган начальникларга полк командиры Кимбр тарафыннан каты эләкте. Тәртипсезлек булганда беркемне дә аяп тормый иде... Бик каты кызып китә дә барысын яра да сала. «Болай син нигә ярыйсың?! Таяксыз нуль!»— дип, шәхсеңә дә кагылып үтә. Шуңа күрә ничек булса да аның теленә эләкмәскә тырышалар иде. Әнә шулай ачуы кайнап ташыган көннәрне үзеңә дә авыр була икән. Көн буе урынына утырмый,

читлеккә ябылган җанлек кебек әрле-бирле йөренә, имеш. Үзенең күкерттәй кабынуына әчтән үкенеп, шуны кичереп изалана, ди. Ул көнне аның сакал-мыегы да тизрәк үсә икән, ике мәртәбә кырынырга туры килә икән үзенә. Моны инде белеп бетергәннәр. Кимбр пешекләве булган киңәшмәдән таралганда, үзара сөйләшәләр: бүген Нил Хачатурович ике тапкыр кырыначак диләр. Шуңа карамастан, Кимбр гаҗәп гадел командир. Үзенә тапшырган эшне башкармаган кешене генә кызган табага бастыра ул. Һәм бу аның тарафыннан бик дөрес тә. Мостафинны уңганлыгы өчен ярата иде, очраганда — күрешкәндә йөзе нурланып китә, сөйләшүеннән үк аның хәерхаһ икәнен тоясың. Ләкин теге киңәшмәдә чыгыш ясаганнан бирле, Мостафин үз командиры йөзендәге ул нурны очратмый башлады. Шуннан инде минем сүздән моңа да эләккән ахры, дигән уй килде аңа. Тик Кимбр үзе моны ни тел белән, ни эш белән белгертмәде. Менә хәзер аның үзен генә алып калып, Кимбр сүз башлауга нәкъ шуңа ишарә иткәнлеген тиз аңлап алды Мостафин.

— Тәнкыйтьләргә без барыбыз да оста, ә менә эшкә... Артык йөгерергә иренәбез, телефон төбендә утырабыз. Ай-һай, сез тегендә матур сайраган идегез, эшегез алай матур түгел икән...

— Мин дөресен әйттем, Нил Хачатурович.

— Синең ул дөреслегең беркемгә дә кирәк түгел, беләсеңме шуны,— диде ул «син» гә күчеп һәм шуның белән йомшаруын, эчкерсез сөйләшүен аңлаткандай.

— Әйтә белмәгән авыздан... нәрсә яхшы? Шуның кебек.

— Менә үзең дә аңлагансың. Безнең пушкалар самоходкаларны җимерә алмый дип ник кычкырырга? Аны кем белми?

— Өстәгеләргә тизрәк җитсен дигән идем.

— Өстәгеләр аны күптән белә. Син дөреслек дисең, дөреслекне аны өстә эшләп чыгаралар...

— Беркатлылык караклыктан яман, ди.

— Нәкъ шулай. Безнең эшләрнең уңайлары кызыл тактага, гөнаһлар исә кара тактага язылып бара бит. Синең менә кара тактага языла торганнары күбәеп китмәсен дим. Ярый әле, сине кай чакта Баграков яклап аралый.

— Рәхмәт, Нил Хачатурович.

Сөйләшү шулай дусларча тәмамланса да, ничектер Мостафинга авыр тәэсир итте. Баграков каршында да уңайсыз иде. Үз-үзенә кимсенгән кебек булды. Шушы пошаман уйлардан бераз арыну өчен ул батареяларга чыгып кайтырга булды. Идрисов батареясы биләгән позиция аны һаман борчып тора иде. Иң элек аңа сугылды. Икәүләп тагы бер кат карап чыктылар, ябык позиция өчен пушкалар әйбәт урнашкан, әмма немец танклары һөҗүм итә калса, хәл шәптән булмаячак.

— Танклар оборонаны өзсә дим. Пехота ул куян тиресе инде?— дип, Мостафин бик дустанә итеп Идрисовка карады.

— Ул хакта мин дә шикләнәм ансы...— Идрисов сүзен әйтеп бетермәде. Бу участокта немец артын кысып тик торыр, гомумән, хәзер безнең гаскәрләр Германиянең үзенә кергәч, алар моннан чигенерләр, бары сабыр итәргә генә кирәктер дип уйлый иде. Мостафинның тиздән һөҗүмгә бару нияте белән хәстәрле сөйләшүе аны аптыратып калдырды.

— Соң?

— Аның белән кара-каршы атышу хәтәр икәнен беләбез, шуңа гранаталарны күпләп әзерләдек.

— Сугышчыларны шуңа хәзерләдеңме?

— Көн-төн шул эш инде. Әмма картлар белән бик авыр.

— Тиздән сугыш бетәсен сизенәләр булыр...

Алар пушкалар янынннан тылга табарак атладылар. Бу позицияне ничектер җайлыйсы килү икесенең дә уен борчып тора. Әмма җай табылмый әле, шуңа юк-бар сөйләшергә мәҗбүрләр.

— Сиңа йолдыз өстәү мәсьәләсен тагы кузгаттык,— диде Мостафин һәм, бу сүз ничек тәэсир итәр икән дигәндәй, Идрисовка күз кырыен төбәде. Ләкин комбатның йөзенә берни дә чыкмады.

— Рәхмәт,— дип, исе китмәгәндәй кулын селтәде.— Элегрәк йолдызга кызыга идем, ә хәзер ничектер барыбер.

— Кеше арасында аңсы да кирәк инде.

— Бәлки шулайдыр да.

— Сине «йолдыз» бозмый, картлар әйтмешли, кальбеңне үзгәртми.

— Бозылучылар да бармыни?

— Ничек кенә әле! Дәрәҗә өчен әтисен сатар, валлаһи. Кешене сыныйсың килсә, дәрәҗә бир, диләр бит?

Бер блиндаж янына килеп, яшел чыршы ботаклары түшәгән баскычтан аска төштеләр. Блиндажның эче иркен генә икән. Снаряд әрҗәләреннән әмәлләнгән өстәлдә сукыр лампа яна, бер кырыйда чыршы түшәгән сәке китә. Өстәлгә карта җәеп, икесе дә шуңа иелделәр. Мостафинның калын йөнтәс кашлары бер җыерылды, бер язылды.

— Тупларны урман алдына чыгарып булмыймы?— дип ымсынып Идрисовка карады. Идрисов бер бит кәгазьгә нәрсәдер сызгалый, үз уйларына йотылгандай иде.

— Әх, юк шул!— диде үртәлеп.— Снайперлар...

— Авызын корт чаккыры!— Мостафин шулай карганып өстәлдән башын күтәрде. Идрисов сызымлы кәгазен уртагарак китерде, йөзенә ниндидер яктылык чыккан иде.

— Менә монда нейтралькада бер зур лапас бар, стеналары кирпечтән,— дип күп мәгънәле итеп карады.— Бер-ике пушканы шунда яшереп куйсак, ә?

Мостафинның күзләре кызыксыну очкыны белән чаткыланып китте.

— Соң шулай диләр аны! Артхәзерлек вакытында алар үзләрен белгертми торсыннар?

— Анысы дөрес. Менә алар өчен кем ут яудырыр?

— Өстәмә гаубицалар куярбыз. Һи, анысы пүчтәк.

— Ә мин шуннан куркам, моны сезгә әйтмичә генә эшләмәкче идем.

— Ни өчен инде?

— Тегенди-мондый хәл килеп чыкса, сезне буямаска...

— Анысы зрә... Иң элек ул лапасларны разведчикларың капшап кайтсын.

— Үзем барып карыйм әле...

— Юк, үзеңә рөхсәт итмим.— Мостафин, карта өстенә иелеп, чокыр, урман билгеләрен карый башлады.— Ә танклар сулдан килсә?

— Анда коры үзән бар бит?

— Менә яшеренеп килергә ясап куйган кебек...— Мостафин торып басты һәм шинель каптырмаларын эләктерде. Аның нишләргә теләве ачык иде. Комдив нейтраль зонаны үзе күзәтергә уйлый. Идрисов картасын җыеп куенына тыкты да сәкедә яткан касканы алып аңа бирде һәм үзе дә киде. Алар чыктылар. Тегендәрәк Тафтиловның ашыга-ашыга китеп барганы күренеп калды.

— Инструкторны каршы алырга барышы,— диде Идрисов шул якка таба карап.

— Ничегрәк соң?— дип Мостафин замполит хакында нидер белергә теләгәндәй сорады.

— Ярыйсы. Солдатлар белән дә ипләнеп килә.

— Ә синең белән?

— Башта үз кубызына биетмәкче иде, мин салкын кан белән генә үз эшемне эшли бирдем, чәүчәләкләнмәдем. Бер-ике мәртәбә үзе «галошка» утыргач, җайланды. Кеше белән сүзгә килмә икән, авыз-борынын җимергәч үзе үк рәтләнә...

— Сүзгә килсәң, ул да сиңа карулаша, шуннан башлана инде.

— Безнең эти әйтә иде: тормышта иң төшемле нәрсә, ул — килешү,— ди торган иде.

— Ызгыш беркемгә дә файда бирми, хәтта талашта җиңгән кешегә дә.

— Ә адәм баласы талаш-ызгыштан туктый алмый?

— Акыл җитми, акыл. Аннары кытлык та бар бит әле.

— Әнә шул акыл җитмәү харап итә. Их! Кеше дигәнең озак балигъ була алмый азаплана, егерме бишкә кадәр күп ялгышлар ясый, ә егерме биштән соңгы тормышы шул ялгышларны төзәтүгә китә.

— Укымаганлык бетерә безне...— дип Мостафин кызгану белән әйтеп куйды.

Урман эчендә юл бар иде, шул эздән атларга җиңел булды. Әмма урман тиз бетте. Ачык урынга чыгу белән пулялар колак төбендә генә выжт-выжт итеп сызгырып үтә башлады. Үзеңнән-үзең башыңны иясең, сәлам бирәсең. Мостафин пуляларга да исе китми барды. Идрисов аның янында «пуляларны сәламләп» оялып бетте. Бераздан бер куак төбенә ятарга мәҗбүр булдылар. Мостафин трофей бинокле белән алгы сызыкны күзәтергә тотынды. Идрисов әйткән лапаслар калку артындарак икән, башлары гына күренә иде. «Бу таудан төшкәндә безнекеләр уч төбендә кебек була инде аңа»,— дип ачынып һәм үртәлеп уйлады Мостафин. Күзәткән урын бер дә күңеленә ятмады. Ул корылмалар немецларга якынрак шикелле. Ничек булыр икән соң? Нейтраль зона ниндидер афәт белән өртелгән сыман, шомлы, куркыныч булып тоелды. Әмма Мостафин эчендә уянган шикләрен Идрисовка белгертмәскә тырышты. Икеләнү исә үзен тагы да ныграк уйларга этәрә иде.

Пулялар выжылдавы күбәйде. Ботаклар сыңгалап, күзгә агач сүле чәчрәштергәли, ботакларда пуля «тешләп» алган ак нокталар күренгәләде.

— Оптика белән ата,— диде Идрисов пышылдап һәм борылырга ымлады. Торып басарга мөмкин түгел иде, алар кирегә үрмәләделәр.

Батареяга кайткач Мостафин тупларны карап йөрде. Ничегрәк утыралар, көпшәләре дөрес юнәлгәнме? Күренеп торган «мишень»гә ничек төзәп атарга? Прицелны кай якка таба күчерергә? Моны ут кебек тиз эшләргә өйрәнергә кирәк. Солдатны тыгызлап, бимазалап тормасаң, бик тиз үшәнләнергә ярата ул. Кешенең мөмкинлекләре зур, шуңа күрә ялкауланырга, йөзен югалтырга ирек бирергә ярамый. Дошман белән бәрелеш вакытында солдатның физик яктан көчле һәм елгыр зиһенле булуы бик мөһим нәрсә. Бар эшне шул хәл итә.

Мостафин кайбер расчетларга команда биреп, «ут ачтырып» карады. Сугышчылар бар көчләренә тырышалар иде. Идрисовка кызарырга туры килмәде. Бигрәк тә Маламишкин, Гыйльманов һәм Кардәшев, Дүртмөхәммәтов расчетларының төгәл эш итүе һәм буш хәрәкәт ясамаулары, үзләрен һәрчак кулда тотулары күзгә ташлана иде. Маламишкин белән Кардәшев аеруча өтәләнеп алдан чыгарга тырыштылар. Соңыннан Мостафин саф алдында аларны мактады, алардан үрнәк алырга кушты, рәхмәт әйтте. Тегеләрнең дулкынлануы йөзләренә чыкты, күзләрендә очкын кабынды. Болар бик рыясыз солдатлар булса кирәк, дип уйлады Мостафин. Шундыйларга ышанырга була. Бу хәлдән үзенең дә кәефе күтәрелде.

Идрисов теге мәсьәлә буенча аның сүзен көтә иде, ә ул берни әйтә алмый әле. Башында әвәли дә әвәли, тик тәгаен бер фикерне эшләп чыгара алмый, Ул лапаслар ничектер өметсез күренде шул аңа... Киткәндә әйтте:

— Ярдәмгә ышанычлы ике разведчик бирәм, синекеләр белән бергә барып кайтсыннар әле...

— Рәхмәт!— дип сөенде Идрисов. Мостафин, кабат-кабат подкалибрлы снарядлар турында кисәтеп, тылга бара торган сукмакка борылды.

Тафтилов политзанятие уздырганда дивизиядән килгән инструктор да катнашты. Сугышчыларның кайбер сорауларына җавап биргәләде. Әмма сорауны яудырып кына торучы Маламишкин һаман канәгатьләнми. Берәр начальник килсә, аның үзен күрсәтәсе килепме, яки тегенең ялгышын тотарга теләпме, украсы котыра торган гадәте бар. Бүген дә шулай булды.

— Ни өчен аш сыек? Анда ит валчыгын лупа белән эзләп тә таба алмыйсың?— диде. Дөрестән дә бу көннәрдә карабодай оны туглап пешергән шәмәхә төстәге сыек аш бирәләр иде. Инструкторның йөзе җитдиләнде, озын борынының ике ягында көрән тимгелләр беленде. Ачуы килгәнлеге күренеп тора, әмма сер белгертми, үзе елмайгандай итә иде. Тафтилов исә Маламишкинның соравын шаяруга борырга теләде.

— Суворовка да шундый сорау биргәннәр,— дип сөйләп китте.— Ул болай иткән: солдатларны сафка тезгән дә, бер йомарлам кар алып, саф башында торучыга биргән. Кар тубын ары җибәр, дигән. Кулдан-кулга күчеп, кар шары сафның теге башына барып җиткәндә, бик кечерәеп, бармак башы чаклы гына калган. Суворов солдатлардан: аңладыгызмы инде ашның ни өчен сыек булганын? дип сораган.

— Аңлашыла,— дип кемдер көлеп куйды, аңа бүтәннәр дә кушылдылар. Тафтилов бу сорауга җавабының мач чыгуыннан канәгатьләнеп елмайды.

Занятиедән соң Тафтилов инструкторны озата барды. Шул чакта гына аның теле ачылгандай булды.

— Нинди кара фикерле кеше ул Маламишкин?— дип, тимер тавыш белән замполитка төбәлде.

— Юк, иптәш капитан, ул болай...

— Яклыйсың?..— инструкторның аскы мәгънәле сүзе Тафтиловны бүлде.

— Характеры шундый аның, чын,— диде Тафтилов, тыныч, дустанә итеп.— Әйбәт сугышчы, тыңлаучан...

— Ни өчен төрттерә торган сораулар бирә?

— Төртмә телле адәм инде ул, уенда ни булса, телендә шул.

— Уйда әллә ниләр булыр, барысын да чыгара башласаң...

— Нишләтәсең аны, ни уйлаганын әйтә дә бирә, эчендә саклап тота алмый... Әмма күңелендә начарлык юк...

— Ну-ну, син бигрәк, каян беләсең син аның эчен?— Инструкторның тавышы һаман йомшамый иде.

— Соң туры холыклы кеше ул. Һәркемнең үз характеры бар бит. Бернине дә эченә яшереп тота алмый...

— Ә син аңа ышанасыңмы?

— Менә, ничек инде!— дип, Тафтилов гаҗәпләнгән кыяфәт белән кулларын җәеп җибәрде.

— Мин аңа ышанып җитмим?

— Дөрес. Чөнки сез аны белмисез. Мин дә башта шулай уйлаган идем. Ул астыртын түгел. Нәрсә бар, шуны шартлатып әйтә.

— Ул безнең кимчелекләргә сөенә?

— Киресенчә, көенеп бетә алмый.

— Юк, патриот кеше алай сөйләнми!

— Туктагыз әле, иптәш капитан. Димәк, безнең кимчелекләрне күргән, шул хакта әйткән кеше ватанчы түгел? Кимчелекләргә битараф булган, шуңа кайгыртмаган солдат патриот була сезнеңчә?

— Мин алай дип әйтмәдем ич!

— Сезнең сүз сөрешеннән шул килеп чыга бит.— Тафтилов ягымлы елмаеп инструкторга карады. Теге аска төбәләп бара, йөзендә ниндидер таркаулык сизелә. Әллә ул Тафтилов белән килешә микән, әллә таныырга кыюлыгы гына җитмиме?

— Ашыгам, бүтән вакытта сөйләшербез,— дип туктап, Тафтиловка кул бирде ул. Бу — бүтән озата барма, дигән сүз иде. Алар бик җылы аерылыштылар. Тафтилов инструкторның әйбәт кеше булуы турында уйлады, юк, ул биредә сөйләнгәннәрне таратып йөрмәс, дип ышанды...

Ә сугышчылар әңгәмәдән соң таралашылары килмичә, хыялларын худка җибәрделәр.

— Анда безнең братлар Берлинга таба баралар, ә без мәте балчыгына буялып ятабыз. Нәрсәгә ярый бу?— дип, кайсыдыр бик нык үртәлеп куя. Замполит безнең гаскәрләрнең Пруссиягә керүләре, Варшава өчен сугышулары турында сөйләгәч, солдатларның герман җиренә туры килмәүләре өчен бигрәк тә эчләре пошты.

— Юкка хафаланмагыз, баш исән булсын,— диде кайсыдыр үзен дә һәм бүтәннәрне дә юатып.

— Болай булса безнекеләр Берлинны ала,— дип, Кардәшев ниндидер горурлык һәм мактану белән әйтте.

— Бүре бурычын тиресе белән түли, ди.— Маламишкинның кыяфәтендә дә кинәнү бар иде.

— Бу ничәнче мәртәбә алу була инде?

— Өченче мәртәбә.

— Ай-вай, ничек алай?— дип ышанмады арадан бер солдат. Кардәшев аның томаналыгына игътибар итмичә, җайлап аңлатырга тотынды.

— Беренчесе мең дә җиде йөз ничәнчедер елда, икенчесе — мең сигез йөз унөченчедә, Наполеонның коерыгына басып барганда. Ләкин сез шуны белмисез әле: мең сигез йөз ундүртенче елда Парижга беренче булып татар-башкорт атлы гаскәре керә. Аларның командиры генерал Муратов була. Аның кабере хәзер дә бар, Ленинградның мөселманнар зиратында. Ә ак патша Александр, татар-башкортларның батырлыгын искә алып, шул походта катнашучыларга Урал даласыннан күп җир бүлеп бирә. Менә безнең авыл шуннан барлыкка килгән. Авылның исемен дә шушы вакыйганы истәлек итү өчен Париж, дип атаганнар...

— Китсәнә, шыттырасың, Кардәш,— дип, мыек астыннан елмаеп куйдылар татарлар.

— Париж исемле авыл, имеш. Тузга язмаганны,— диештеләр. Кайсы башын чайкый, берсе тезенә суга-суга көлә. Кардәшевнең бөрчек-бөрчек күгәрекле ягымлы йөзенә елмаю җәелде, тегеләрнең ышанмауларыннан көләсе килә иде. Ул куенына тыгылды да кызылармеец кенәгәсен алды, Маламишкин сизелерлек кызыксыну белән аңа сузылды. Кечкенә кенәгәнең битен ачып укый башлагач, Маламишкинның йөзендәге менә хәзер ялганы фаш булыр дигән масаю сызыклары сүнде. Бераз укыгач, ул күзләрен уып алды, тагы кенәгәгә кадалды. Кардәшев авылга язган хатын икенче бер сугышчыга бирде. Мә, укы! Теге укый, күзләренә ышанмыйча, як-ягына каранды.

— Чынлап та Париж исемле авыл икән,— диде Маламишкин, кенәгәне иясенә кайтарып. Кенәгәне кулдан-кулга йөрттеләр. Бу гаҗәп хәлгә исләре китеп, башларын селкеделәр.

— Безнең бабайлар әнә Парижны да алганнар!— дип куйды Мирхас.

Маламишкин белән Гыйльманов һәм тагы берничә рус үз туплары янына кайтып киткәч, биредә төрки сугышчылар гына калды. Алар Кардәшевтән шундый кызыклы авылы турында тыкырдатып сораша башладылар. Кардәшев үзләренең таулары, болыннары, Кыйгы инешенең әкияттәгедәй матур булуын авыздан сулар китерерлек татлы итеп тасвирлады. Әмма бер тау астыннан чыккан зәңгәр чишмә турында әйт-

кәндә тавышы калтыранып китте, күзе дымланып, сүзе өзелде. Бу чишмә аның бик кадерле һәм үкендерә торган истәлекләре белән бәйле булса кирәк. Мирхас сүзне икенчегә бору өчен әйтә куйды:

— Шәкүрә апаның хаты килде бугай, шигырьләр язмаганмы?— дип, аңа таба борылып утырды. Башкалар да аның сүзен куәтләп җибәрделәр. Кардәшев тамак кыргалады, эчендә кузгалган дулкынны җиңеп, күзләрен түбәнгә төбәгән килеш торды. Шунда ук йөзенә тагы нур чыкты. Ул хатыны Шәкүрәнең шигырьләрен сугышчыларга укырга бик теләп тора һәм шуның белән горурлана иде. Сугышчылар да аның хатынының җыр-шигырьләрен яратып өлгерделәр. Ул җырларда каядыр еракта калган туган җир авазы ишетелгән кебек була. Сагыну хисләрен кузгатып куя, сугыш әшәкелеге белән күмелеп барган нечкә тойгылар тагы күңел тирәнлегеннән калкып чыга һәм кабынып китеп бер ачы-татлы рәхәтлек белән йөрәкне телгәләп-телгәләп ала. Бу юлы да укытучы Шәкүрә апа күңелгә үтә торган җырлар язган иде. Кардәшев тавышын җырдагы моңга туры китерергә тырышып укыды. Җыр озын, өч бит иде, ләкин азагы тагы да моңлы иде.

Без аерылышкан шыксыз җилле кичне
Кан кызарып кояш баеды.
Яңгын төсле офык янды, янды,
Гомерлеккә әллә аерды?
Бирелмә син моңга, сагышларга,
Дошман угы тия күрмәсен.
Күкрәгемдә фәкать гел син генә,
Мин үлсәм дә мәңге үлмәс ул!

Сугышчыларның кайсы тирән итеп көрсенеп ала, кайсы исә уе белән бөтенләй туган җирләренә, туган йортына кайтып киткән шикелле уйга чумып утыра. Һәрберсенең күңелендә юксыну дулкыны кузгалган, әллә ниләр исенә килеп төшкән. Яхшы, бәхетле минутлар һәм начар, бәхетсез вакытлар. Күпме акылсыз эшләр эшләнгән, әх, хәзерге акылым ул чагында булса иде... Күңел шулай уйчанланып, бер төшенкеләнеп алгач, нииндидер күтәрелеш тоя, тагы да күбрәк өметләр белән тула. Шигырьләр укылып беткәч, барысы да тынып тордылар.

— Шәкүрәгә җавап итеп үзем дә бер җыр чыгардым әле,— диде Кардәшев һәм нәрсәгәдер уңайсызланыбрак торды да укып бирде.

Зәңгәр күлдә йөзгән гүзәл аккош
Җилгә каршы канат кагынып...
Язмыш белән җир астына керсәм,
Сөякләрем сине сагынып...

Кайберәүләр башларын ия биргән килеш, җилкәләрен селкетеп уфылдап куялар, «сөякләрем сине сагынып», дигәне бигрәк тә җанга кагыла, моңсуландыра. Мондый минутларда кеше үзен барлаган кебек була. Үз-үзенә сорау бирә: нинди кеше ул? Кыска гына гомерендә нинди яхшылыклар эшләгән, нинди ялгышлар ясаган? Кемнәр аны искә алырлар? Әллә бөтенләй онытырлармы? Аның үлеменә көенүчеләр булган кебек, сөенүчеләр дә булмасмы? Дуслары күп иде, әмма дошманнары да табылды. Чөнки тормыш гел яхшылык белән генә бармый бит. Кырысланырга, кансызланырга да туры килә... Намусың сафмы? Кеше күзенә туры карый аласыңмы? Төрле чак булды, кай моментта, намусның бугазына басып, эш башкарырга мәҗбүрсең... Ни өчен, дигән беркатлы сорау бирмә...

Гыйльманов бер дә туган авылын теленнән төшерми инде.

— Безнең Әлмәтнең бар ягы да килгән,— дип мактый башлый.— Җирләр шәп, майлы җирләр. Болыннары үзе бер хикәя. Әмма бер нәрсә теңкәгә тия, ул да булса, тәмле суы юк. Кая гына кое казысаң да тозлы су чыга. Зәй буенда ташу баса торган урында бер-ике рәтле кое бар.

— Бездә чишмәләр күп анысы.— Маламишкин блиндаж мичено утын өстәде дә гимнастерка якасына ак тегәргә кереште. Гыйльманов каяндыр ат ите юнәткән, котелогын утка җайлап маташа.

— Чишмә дә байлык бер караганда.

Шул чак Мөслимов төшке ашка кухняга җибәрелгән котелокларны кертеп чыкты. Гыйльмановка хат та алып кайткан иде. Гыйльманов, сөенеченнән кабалана-кабалана, ашын ут янынарак куйды, ашарга җыенмый иде. Иң элек хатны укырга кирәк. Ул шинелен төймәли-төймәли тышка ашыкты. Хатны бары ялгызы гына, озак итеп укырга ярата ул. Шуңа күрә кая булса да кача. Хәзер урман эченә таба китте, анда өелгән чыбыклар бар, шулар өстенә кырын ятып, рәхәтләнеп укырга була.

Әмма шундый тәмләп тотынган хатыннан баштарак берни дә аңлый алмады ул. Кинәт маңгаена гөрзи белән китереп суккан кебек булды. Хатны дүрт мәртәбә күздән кичереп чыккач кына анда язылганнар төш түгел, чын икәне зиһененә барып житте. Сүзләр ничектер һәрберсе, сыек чыбык белән суккан кебек, укыган саен җанын ачыттыра, йөрәген чеметтереп-чеметтереп алалар. Каяндыр тирәннән шуңа каршы сукыр ачу дулкыны күтәрелә, куллары йомарлана башлый. Шул дулкын канны кыздыра, бөтен тәненә ут капкан кебек итә... Ничек инде бу? Аның укытучы кызы Рәхимә законсыз бала тапкан. Ул Камы-елга авылында укыта иде, кем шулай мыскыл иткән аны?! Әй, бала! Ничек шулай ялгыштың? Үзең укыган, авторитетлы кыз. Безнең нәселебездән дә бер укыган кеше чыкты, дип чиксез горурланып, мактанып йөри идек. Моның хурлыгына ничек чыдарга? Әниең кеше күзенә ничек күренер? Син аның һәм минем йөземә корым яктың бит! Ничек анда кайтырмын, ничек кеше күзенә күренермен?! Кызының хурлыгы атага мең оят! Бер дә шуны уйлап карамадыңмыни, әй, бала! Бөтен нәселебезгә тап төшердең бит, ыруыбызны пычраттың! Син арада иң яраткан балабыз идең. Мин бигрәк тә сине ярата идем. Әни, мәрхүм, әйтә иде: баланы өзелеп яратма, бәхетсез була, ди иде. Минем сине яратуымның кайчак хәттин ашканын күреп шулай акыл биргән инде. Ә мин һаман сине генә күрдем, исемдә гел син булдың. Өскә-башка юнәткәндә дә иң элек син. Ашаганда-эчкәндә иң тәмле калҗа — сиңа... Барысы өчен менә шушы хурлык...

Блиндажга кайтып кергәндә ул бөкшәйгән, әллә ничә елга картайган кыяфәттә иде. Яңаклары эчкә баткан, күзләрендә тере очкын сүнгән.

— Гилман, ни булды?— дип,һәрчак кешегә игътибарлы Маламишкин күреп алды аны. Гыйльманов өметсез рәвештә кулын селтәде, котелогына барып тотынды. Ләкин тәмам ачыккан булса да, тамагыннан аш үтмәде. Ашын Маламишкинга бирде. Теге тагы да гаҗәпләнә калып, хәленә керергә теләгән карашын аңа текәп торды. Гыйльманов: берни дә сорама, дигәндәй тагы кулын гына селкеде, учактагы ахак күмерләргә карап тынып калды. Ә бит аның бәгыре дә менә шушы күмерләр кебек көйри, эче тулы ут кына, хәтта сулыш алуы авыр. Ничек шуны кешегә сөйләп аңлатып булсын, юк, бу мөмкин түгел. Кайгы үз эчеңдә генә ята да сине күмергә-көлгә әйләндереп бетерә, дөнья шулай корылган ул...

Берничә көннән соң Гыйльманов чыдый алмады, кайгысын Маламишкинга да әйтте. Үзе һаман күзләрен сөртә, күз яшьләре ихтыярсыз тәгәриләр бит, хәерсез.

— Әй, юләр, гел пүчтәк өчен ватыласың икән!— диде Маламишкин һәм, чынлап торып, тегене тиргәргә тотынды. Беренчедән, болай изаланып бәлаңа булышасың гына. Икенчедән, булганны барыбер кире кайтара алмыйсың. Реаль фикер йөртергә кирәк...

— Бездә андый эш бик хурлык санала, нәсел пычрату дип карала,— дип, Гыйльманов үз өстенә төшкән кайгының зур булуын аңлатып маташты.

— Куйсана, нәрсәсе хурлык, дөньяда, булмый торган эшме?
— Ничекләр итеп кайтырсың ул өйгә?
— Әй, тиле дисәң хәтерең калыр. Бик шәп кайтыр идең әле! Безнең үзебездә дә бар шундый җилдән туган малай...
— Ничек?!—Гыйльманов, колакларына ышанмагандай, Маламишкинның күзләренә карады. Ничектер үз баласе ишенең бүтәннәрдә дә булуы аңа җиңеллек бирер төсле иде. Өе янган кеше үзе кебек өе янган кешене якынрак күргән шикелле. Маламишкин шуны сизгәндәй, үз башыннан кичкән хәлне сөйләп, дусты кайгысын йомшартмакчы иде.
— Күптән булды бу,— диде Маламишкин.— Ләкин аңа бер дә кайгырмадым. Теге колхозлашкан елларда, кызымны районга хисапчылар курсына җибәргәннәр иде. Шунда үзе ише егетләр белән шаяргандыр, күрәсең. Тегесе алам дигәндер, унҗиденгәге кызны ышандырыр өчен күпме кирәк. Аларга бар дөнья алсу бәхет төсендә күренә ул чакта. Кызның бик күңелсезләнеп, сөмсере коелып йөргәнен хәтерлим. Бала тугач, бары да онытылды. Малай иде, барыбыз да аны шундый яраттык. Мин бигрәк тә аңа нык ияләнеп киттем. Үзе дә гел минем куенымда гына булды. Бик акыллы бала булып үсте. Бар балаларымнан артыграк шуны яраттым, валлаһи менә! Хәзер әнә бар йортны шул алып бара. Нинди генә хатлар язмый үзе! Син, Гилман, зрә кайгырасың, шул малайдан да якынрак кешең булмас әле, әйткән иде диярсең...
— Хурлыгы бит аның...— дип уфылдады Гыйльманов, учы белән тезенә суккалап.
— Хурлыкны күкрәккә такмыйлар ла.
— Артында сөйләүләре тагы...
— Кеше сөйли инде ул. Артта кеше бер-берсенә һаман хөкем чыгара. Аннан сиңа ни зыян?— диде Маламишкин, учакка утын өстиөсти. Ул бар нәрсәне шулай гадиләштереп караучан иде. Гыйльмановның кашлары җимерелде, йөзе тагы да караңгыланып китте. Озак кына уйланып торганнан соң:
— Эх, Кирюша,— диде ачынып.— Син андагы хәлләрне белмисең. Районда бер дошманым бар иде, бу әшәкелектә шуның кулы уйнаган булырга тиеш. Теге адәмне минем кызны алдарга шул котырткан, төгәл беләм мин моны. Шулай кызымны хурлап, миннән үч алган ул имансыз! Эх, егетләр...
— Юк, алай булмас, Гилман. Син моны бик куертып карыйсың. Һәр нәрсәгә ансат кына карау хәерле...
— Син белмисең, Кирюша, белмисең.
— Ул чаклы алама итеп уйлама әле!
— Бүтәнчә уйлый белмим, нишләргә соң?
— Аның белән дөнья кителеп төшмәс. Баш исән булса, ул бала үзеңә бер бүләк кебек кенә булачак...
— Кызымны хурлап, миннән үч алганга ничек чыдарга, моңа нинди дәлил табарга? Юк...
— Сабыр бул, Гилман! Барысы да үтә торган нәрсәләр. Үтә ул, үтә, юкка алай нервыңны туздырма...
Ләкин Маламишкинның юату сүзләре Гыйльмановка керми иде, үч алганнар дигән уй миенә кечкенә чүкеч кебек сугып тора.
— Ата өчен баладан үч алалар, кая китә бу?— диде Гыйльманов һәм төргән тәмәкесен атып бәрде.
— Нишләп алай булсын, юләрләнмәсәнә,— дип, Маламишкин ачулана башлады. Ул Гыйльмановның һәр нәрсәнең кире ягын уйлап, үзенә кирәкмәгән каршылыклар тудырырга итүен белә иде. Гаҗәп кеше, гади генә итеп уйлыйсы урында, эшне катлауландыра һәм үзенә дә, бүтәннәргә дә авырлыклар китереп чыгара. Кызына да әле ул начар хат-

лар язып, әллә нинди кайгыларга төшереп бетерер. Шуның өчен Маламишкин аның кызын яхшырак итеп күрсәтергә тырыша, бар гөнаһын яшьлегенә сылтап калдырырга итә иде.

— Кызыңны ачуланма,— диде.— Ул гаепле түгел монда.

— Ничек гаепле булмасын, һе!

— Аңлыйсыңмы, кыз кешегә дөнья ал төстә булып күренә?! Алдану турында уйлый алмый ул, табигате аның шулай. Менә җирдә балкып чәчәк үсеп утыра. Аның нектарын эчәргә ана корт килеп куна. Чәчәк шунда кортка каршы тора аламы? Юк, чөнки ул аны үзе тели. Табигать шулай яраткан аны...

— Табигать дип инде үз-үзеңне онытырга ярамый,— дип сузып әйтеп куйды Гыйльманов.

— Ярамый да бит, нишлисең. Хатын-кызның ышанычыннан явызларча файдаланучы ир-ат әшәкенең дә әшәкесе инде...

— Ул яктан ир-атта эгоистлык бар шул...

— Менә үзең дә аңлыйсың икән,— дип, Маламишкин дустының кызына карата йомшый баруын тойгандай булды. Алар әле шул темага озак сүз көрәштереп утырдылар.

Гыйльманов кайгырырга ярата торганрак кеше иде, һаман эчтән генә сызып йөрде. Кызына авыр сүзләр язып җибәрмәде, язмыш шулайдыр инде дип кенә әйтте. Шулай да элекке кебек ачылып сөйләшми башлады. Ниндидер кимсенгәнлек билгеләре аның һәрчак ачык чыраена соры сызыклар булып сызылып калды. Ни әйтсәң дә бала кайгысы бәгырьдә шул...

...Таң атып килә иде. Төне буе эшләп, күзәтү пункты блиндажының ике ягына да траншея казып бетерделәр. Мирхас блиндаж сәкесенә якын урманнан үзе алып килгән чыршы ботакларын ташлаштырды да, хәл җыярга дип утырды. Бүреген салды, маңгаендагы кара тирне учы белән сыпырып атты, аннары бүреген киеп, хәзер тылга китәсе иптәшләренә иртәгә нәрсәләр алып килергә кирәген әйтеп маташты. Тегеләр ашыгалар иде, хәзер комбат үзе килергә тиеш, аның күзенә чалынганчы шыларга кирәк. Блиндаж ишегеннән әз генә баргач та тирән чокыр башлана иде, китүчеләр, шул чокырга чумгандай, кинәт күздән юк булдылар. Мирхас блиндаж матчасына стереотрубаны җайлады, комбат килүгә әзер булсын. Ләкин Идрисов һаман күренмәде. Көн инде тәмам яктырып җитте, бирегә килү хәзер бик куркыныч инде. Мирхас стереотрубадан немец ягын күзәтә башлады. Немец траншеясы урман буендарак икән, бик уңайлы калку җирдә, авызын корт чаккыры. Мирхас кыштырдау ишетеп, артына борылды. Караса, җиргә бик нык иелеп, Хәбиров менеп килә. Кичтән бирегә, Мирхас янына сугылып киткән иде. Стереотрубадан күзәтергә тели микәнни?— дип уйлап алды Мирхас. Ул арада Хәбиров дөп итеп тамбурга килеп төште, шул минутта немец пулялары выжт-выжт итеп очкалап үттеләр. Күрделәр, шайтан.

— Комбат юк ахрысы?— диде Хәбиров, еш-еш сулыш алып.

— Килеп җитмәде әле,— дип, Мирхас комбат нәрсәгә икән моңа дигән уй белән Хәбировка карап алды. Очрашуга сөенгәндәй елмайды. Аның чынлап та Хәбиров белән бер озак кына сөйләшеп утырасы килә иде. Шуны алдан юрап һәм бер җай табарга тырышып йөри иде. Җай чыкса дип кызыл балык та әзерләп куйган иде. Хәбиров блиндаж эченә узды, Мирхас та, күзәтүен ташлап, аның артыннан керде. Хәбировның вакыты иркен иде бугай. Янчыгын алып, ашыкмый гына тәмәке төрде, Мирхас аның чиста кулларына, пөхтә өс-башына игътибар итте. Нинди генә шартларда да үзен бик җыеп йөрергә өйрәнгәне турында уйлап алды. Кунакка ниндидер хөрмәт күрсәтергә кирәк иде. Ярлырак булса да, капкалап алырлык ашамлыклар чыгарды. Бер бөтен ипи, балык консервасы ачты, термоста тәнлә алып килгән чәй дә бар икән әле, ул кайнар иде, әйбәт кенә булды. Кружкаларга салды.

— Утлы су хәзер шәп була иде, юк каһәр!— дип уфтанды Мирхас.
Ул теге очрашуда Хәбировның әчмим дигән сүзенә тамчы да ышанмаган иде. Хәбиров аның эчке уен чамалаган кебек:

— Мин аны авызга да алмыйм, чын!— дип, кружкасын күтәреп чәен эчте, пәке очы белән балык кисәген әләктереп капты.— Солдат үзенең командиры шундый икәнне сизсә, аны санламый башлый. Командир бер кабым да артык һәм тәмләрәкне кабарга тиеш түгел. Командирның иң беренче сыйфаты гаделлек булсын! Солдат гаделлекне ярата, шуның өчен утка керә. Кечкенә нәрсәдә дә аның ышанычын бетерергә ярамый. Һич! Тупчыларда, бәлкем, бүтәнчәрәктер, пехотада кече командир белән солдат мөнәсәбәтендә ара булырга тиеш түгел!— Ул тагы бераз капкалады да тәмәке кабызды. Мирхас күбрәк тыңлап утырды. Хәбиров үзенең нинди частьта булуын белгертергә теләми кебек иде. Мирхас шул кызыксынуы тел очыннан ычкынмасын дип сагайды. Мирхас укытучысының күңелен күрәсе килеп, кыстаган булды. Хәбиров исә кул ымы белән ашыкма, көн озын, диде, кинәт эчтән яктырып китте. Йөзенә канәгатьлек һәм мөлаемлык нурлары чыкты.

— Мин синең әтиеңнең егет чакларын беләм,— диде ул, ниндер бик озын итеп сөйләргә теләгәндәй.— Ярулла абзый көрәшче иде бит, билгеле кеше. Әй, екты да инде өрлектәй егетләрне. Көчле иде...

— Карталыда шахта ярамады аңа,— диде Мирхас үкенеп. Алар дүрт ел шунда торып кайтканнар иде. Мирхас русчага да шунда малайлар белән сугыша-сугыша өйрәнде. Ләкин әтисе бераздан каты чирләде, шул ятудан тормады.

— Колхозны өнәмичәрәк киткән булгандыр инде,— дип, Хәбиров та кызгану белдерде.

— Өнәмичә түгел, Хәбиров абый, бәхет эзләп,— диде Мирхас. Өнәмичә дигән сүз алар хакында чыккан авылдагы гайбәт сүз иде, председатель дә Мирхасны шуның белән еш кына шелтәли иде. Бу сүз шуңа күрә аның күңеленә барып кагылды. Ләкин Хәбиров Мирхасның төзәтмәсен ишетмәгән дә кебек иде.

— Син инде, Мирхас, уйлыйсыңдыр, сугыш башында ук лейтенант булган кеше ничек кече сержант дәрәҗәсенә калган дип. Әйе, уйламый мөмкин түгел,— диде ул, күз кабакларын аска салындырып, тәмәкесенә төбәлгән килеш. Аннан тирән генә суырды да төтенен борын тишекләреннән чыгарды...— Озын булса да җентекләп сөйлим әле, юкса аңлашылмавы ихтимал. Акланыр өчен түгел, ә гыйбрәт өчен. Элеккеге укытучының тарихын син белергә тиеш. Бәлки исән калырсың... Ә эш менә ничек булды, кырык өченең кышында Великие Луки шәһәре тирәсендә оборонада тора идек. Ләкин бүген оборонада торсаң, иртәгә һөҗүмгә приказ килә. Алгы сызыкның тормышы шулай. Шәһәргә ике тимер юл керә иде. Рельслар бер-берсеннән шактый ерак торган тирән чокырлар эченә салынган. Алдагы бер кечкенә калкулыкны юллар икесе ике төштән кыска гына туннель ясап үтә. Туннель өстендә калкуның сыртлары тоташа да озын гына дамба сыман булып әллә каян күренеп тора. Немец имансыз шул биеклеккә оялаган да безгә баш күтәрергә дә ирек бирми. Сугыш теле белән әйтсәк, бөтен тирәне ут белән контрольлек итеп тора. Нишләргә? Бик теңкәгә тиде бит бу. Болай булмый. Сугышчыларның да тәмам ачулары кайный башлады. Командирларның да түземе бетте. Кыскасы, бер төнне шушы калкудан фрицны бәреп чыгарырга безгә приказ килде. Сержантларым белән уйлаштык, исәп тоткан нәрсәбез шул: һава бик салкын, немец бөрешеп блиндажда ята. Сизмәстән генә барып капларга...
Солдатларга тиешле күрсәтмәләрне бирдек, әйбәт булып китте. Бик ышанычлы ике сержантым бар иде, берсе Шалин, икенчесе Нужин. Әй, зирәк, үткен егетләр дә иде инде. Шуңа күрә бу операциянең уңышлы булуына шикләнмим.

Төнге сәгать унбер, иплап кенә алга таба кузгалдык. Йөрәк дөп-дөп тибә, барабаң кагаларымны, хәтта колакка ишетелә. Бераз баргач, чирканчык алган кебек булдык, йөрәк тынычлана төште, уяулык артты, тәнгә кыюлык, ышаныч керде. Пулялар безнең баш очыннан узалар, һәм ачык күрдек, немецлар дүрт ноктадан гына аталар икән. Димәк, тоташ оборонасы юк шикелле. Көрт ярып мышкылдый-мышкылдый барып, немец траншеясының бер очына килеп чыктык. Шул чак пулеметлар тагы ут сибеп алдылар, ә окопта беркем кыймылдаганы күренмәде. Хикмәт нидә? Шалин белән Нужин, траншеяга төшеп, шуннан бара башлаганнар иде, тагын немец атарга тотынды. Нужин яраланды, немецлар блиндаждан аталар икән. Шалин шунда граната ыргытты, мин сугышчылар белән өске якка чыктым, блиндаж ишегенә автоматтан бер сиптереп алдым. Шалин: «Стой!» дип кычкырдып җибәрде. Безгә тел алырга да приказ бирелгән иде. Шуны искәртеп, атмый торырга куша. Шалин блиндажга үрмәләп якынайды да немецларга кычкырды: «Сдавайся!» Бераз тынлык булып торды, аннан кинәт бер немец килеп чыгып, автоматы белән ут сиптерергә тотынды. Тик безнең егетләр аны шунда ук тончыктырдылар. Калган икесе, кулларын күтәреп, блиндаждан чыкты. Яраларын бәйләгән Нужин аларны тылга алып китеп тә барды... Блиндажга кергәч кенә немецның хикмәтен шәйләдем. Алар пулеметларны төрле җиргә урнаштырып, тәтеләренә кабель бәйләп куйганнар, атарга кирәк чакта шул баудан гына тартып яталар икән... Блиндаждан чыксам, күрәм: Шалин җиңү дәрте белән кызышкан сугышчылар белән алга таба китеп бара. Башлы егет шул, монда ныгып тору өчен бик җайсыз булуын күреп алган. Ә аксыл кыр уртасында бер җир карамчыкланып тора иде. Шалин шуңа таба бара. Ләкин мин аларны куып җитүгә, немец шул төштән атарга тотынды. Яттык. Шалин минем кырга килеп ауды. Сөйләшәбез. Нишләргә? «Уң флангка авышыйк»,— ди Шалин. Бу фикерне немецның ул тирәдән атмавы раслый иде. Шунда таба шуышып, чокыррак җирдән киттек һәм тагы фрицларның флангысына барып чыктык. Фрицлар чигенеп, урманга таба чаптылар. Берничә кешеләре кар өстендә аунап калды. Бу хутор урыны булган икән. Немец йортларны сүтеп алып бетергән, блиндажлар төзегән. Ә андагы кешеләр уңдарак, тирән чокыр буена землянкалар казып, шунда урнашканнар булып чыкты. Бичаралар бары да хәерче хәлендә иде. Бала-чага, карт-коры... Оборонаны элекке хутор булган җирдә ясарга карар иттек. Анда өй базлары бар иде. Төн урталарында элемтә булды. Комбат рәхмәт әйтте. Туплар җибәрәбез, немец иртәгә килми калмас диде. Ә минем нигәдер үлеп эчем поша башлады,үземне кая куярга белмим генә. Пушкалар көтәм...

Ләкин артиллеристлар килеп җитә алмады, иртән немецлар өч танк белән атакага ябырылды. Тизрәк тылга шалтыраттык, тупчылар киртәли торган ут ачтылар. Без дә бөтен кораллардан атабыз. Немец артка тибәрелде. Бу беренче дулкын иде. Аннан икенче дулкын килде. Тупчылар күрмичә аталар, сукыр ут танкларны зарарлый алмады. Тагылып пехотасы килә. Безнең рәт сирәгәя башлады. Яраланучылар ярдәм сорап кычкыралар. Пулеметчылар һәлак булды. Мин кул пулеметын үземә алдым. Шалинның ике кулы да яраланган иде, ул иелеп тылга таба китеп бара, бер мәл яралысы да, ярасызы да аңа ияреп сыпырта башладылар. Аны яраланган дип белмәгәннәрме, әйтә алмыйм, факт шул: саф сирәкләнде — чигенмичә бүтән әмәл калмаганлыгы көн кебек ачык иде. Мин, кул пулеметы белән чигенүчеләрне ышыклап, аттым да аттым. Бер окоптан икенчесенә күчә-күчә йөрдем. Шуңа немецлар тиз генә якын килә алмадылар. Караңгы төшкәндәрәк искә килдем, безнең тыл дигән җирдә дә немецлар икән. Мин теге землянкаларга таба шуыша, чаба киттем. Бер хатын мине үзенең базына яшерде. Курыкма, немец авыру ияртүдән курка, монда килми, диде. Базда гына муеным нигә юеш дип карасам, яраланган булган икән. Аны бәйләп

куйдым. Немецлар керми калмаслар дип пистолетымны әзерләдем, ике патроны бар икән әле. Ә күкрәгемне эчтән хурлык, җинелү ачысы пычак кебек кисә генә. Бөтен җирем дер-дер калтырый. Төрле шикләр умарта күчедәй мине сарып алды, җанны гына чагалар. Нәрсә булды инде бу? Нишләдем мин? Комбат нәрсә әйтер дә, минем хакта нәрсә уйлар? Мин булмагач, ярый әле үлеп котылган диярме? Юк, алар иртәгә үк һөҗүмгә килерләр, бу биеклекне кире алырлар, дим. Өмет учагы дөрләп яна. Бүтәнчә булуын башыма да китереп карамыйм... Бер көн үтте, ике көн. Юк. Нигә? Безнең операция ни өчен генә булды соң?— дим. Ну, ике «тел» алдык. Дошманның бу турыдагы көчен капшап карау өчен дә булуы ихтимал, дим, узган уңышсызлыкны акламакчы булам. Тагы ике көн үтте. Шомланып, үз-үземә ачуланып, бөтен гомеремне җиз иләктән үткәрдем...

Хәбиров, сөйләүдән туктап, сүнгән тәмәкесен кабызды. Мирхас аңа тагы чәй салып бирде, ләкин Хәбиров кулын селтәп: юк, бетте, тамактан үтми, дип куйды. Кичерешләре бик авыр булып, чыраена да чыкты. Ул кинәт картаеп киткән шикелле тоелды. Кайдадыр авыр туптан аттылар, башта донк иткән тонык тавыш, аннан бик каты шартлаган тавыш ишетелде. Мирхас ишек төбенә чыгып стереотрубадан бераз күзәтеп торды да тизрәк эчкә керде. Хәбиров һаман тирән уйга чумып утыра иде.

— Үткәннәрне баштан уздырганда бик күп хәлләр искә төште,— диде Хәбиров, кулы белән тыңла, дигән ишарә ясап.— Аянычлысы да, куанычлысы да. Ул заманда бит бөтен тәрбия эше безнең җилкәдә иде. Заем, налог — кеше белән дошманлаштыра торган нәрсәләр. Колхоз эшенә салкын караучылар белән матавыклану. Мужикны хак юлга инандыру иң авыр эшләрнең берсе... Мин гел шул көрәш сандалында идем, ләкин күбрәк үзем чүкеч булдым. Кемнеңдер кушуы буенча түгел, шөкер анысына, үземнең заманым шундый иде. Яңа тормыш төзү кирәклеген аңлап, җан белән ышанып, шул эшкә риясыз җигелдем. Мине күрәлмәүчеләр дә бар иде. Хәзер немец кулына эләксәм, алар ничек сөенерләр иде, дим, чигәмә терәгән пистолетымның салкынлыгын тоеп, кире алам. Әле өмет бар дип, үземне-үзем юаткан булам.

Бары җиденче көнне генә, кайсыдыр флангтан һөҗүм итеп, безнекеләр бу төшләрне азат итте. Ләкин ни аяныч, бу безнең часть түгел иде. Шул моментта ук хәлемнең мөшкел икәнен чамаладым, әмма нишли алам мин хәзер? Землянкага яралыларны тутырдылар, сестраларга мин дә булыша башладым. Яралылардан сорыйм, безнең частьтан берәү дә юк. Мине билгесезлек бик нык борчый иде. Контроль-үткәрү пунктына — КППга киттем. Мине каптырып кына алдылар. Анкета тутырттылар. Миңа мәрхәмәт күрсәткән хатынны да допроска чакырдылар. Монда бик кырыс кыланалар. Шунда эчемне ут алды. Ничек акланырга? Ләкин шул чак капитан минем муендагы бинтка дикъкать итте. Яраң бармыни, ди. Әйе, дим, кечкенә яра, ләкин башны бора алмыйм... Нигә госпитальгә китмәдең?— ди. Һи, мондый яра белән тылга китәргә оят, дим. Капитан уйга калып торды. Аннары иртәгә килерсең дип, кайтарып җибәрде. Шунда кинәт миемне бер уй яндырып узды: соң санитар кызлардан ярамны бәйләткәндә «Алгы сызыктан» дигән карточка тутырып, госпитальгә генә китәсе булган бит! Яраланганмы-яраланган! Ә минем канга сеңгән: сүздә ватанчы булып сөйләшкәч, гамәлдә дә ватанчы булу, эз генә дә икейөзләнә алмыйм мин... Капитан минем шушы мөмкинлектән файдаланмавымны дөрес аңлады һәм миңа чиста документлар биреп, үз частемне эзләп табарга кушты. Ике күземнән кайнар яшь тама башлады, рәхмәт яше! Капитан кисәтеп әйтте: телеңне йозакта тот, чамала!— диде. Яшем тамагыма тыгылган иде, бары башымны гына ия алдым һәм чыгып киттем.

Мин чиксез бәхетле идем. Частьны эзләп киттем. Аны тулыландыру өчен ерак тылга күчергәннәр икән. Мәскәү янына. Частьта мине үлгән дип белгәннәр, әлбәттә, хәзер теге дөньядан кайткан кебек каршы алдылар. Ләкин командирым юк иде, күчкәндә төнге бомбежкага эләгеп яраланган. Кайбер иске танышлар аша әйбәт кенә урнаштым. Мине җанлы көч туплау вәкаләте белән Казанга җибәрделәр. Моннан да артык бәхетнең булуы мөмкинме? Мин күзгә күренми торган канатларда гына очып йөрим. Шунда ук шәһәргә Зәлилә апаңа шалтыраттым. Иртәгә үк янына барырга юлга чыгам дип шатланды. Китте эшләр худка. Миңа йөкләтелгән эшне көн-төн ял итми башкарам. Зәлилә килүгә буш көн әзерлим. Кабанның аргы башындагы кызыл казармаларда тора идек. Тәмугның үзеннән исән чыккан кеше бу бәхетнең бик кыска икәнен белә, хозурдан файдаланып калырга тели. Без дә иптәшләр белән, бер эшне уңышлы гына эшләп чыккач, кәеф-сафа корып алабыз. Ләкин арада дары иснәмәгәннәр дә бар иде. Шулай сәрхушләнеп, ял итеп утырганда, шуларның берсе бик патриот булып сөйләнә башлады. Кызмача баштан мин моңа каршы төштем, тегенең серкәсе бер дә су күтәрми икән, кинәт ачуланды, шартлардай булып бүртенде һәм миңа: син куркак!— дип кычкырды. Мин кинәт айнып киттем, йодрыкларым йомарланганын сизмәдем дә. Ләкин тыелып калдым, теге дә үзенең гаебен тоеп, тизрәк чыгып китте. Әмма аның сүзенә гарьләнүем бетмәде. Мин тынычланып, иптәшләргә үземнең әле күптән түгел генә фронтта алгы сызыкта нинди мажарага эләгүемне һәм аннан ничек котылуымны сөйләргә мәҗбүр булдым, Ә ул, тыл күсесе, берни белми бит, ватанчы булып кылана гына, дидем...

Ике көннән мине комендатурага чакырдылар һәм сорау алырга тотындылар. Дошман тылында җидетәүлек булдыңмы?— диләр. Мин яшермәдем, әйттем. Ә бит кәгазьләрдә минем ул юк, тикшерәләр. Дошман ягында калу дезертирлык санала икән. Мине кулга алдылар. Утыртып та куйдылар. Эшне янадан карагыз дип гариза яздым. Җибәрмиләр. Зәлилә килә алмады, аны юлдан кире борганнар. Менә шулай кинәт упкынга мәтәлдем дә киттем. Капитанның телеңне йозакта тот, дигән сүзе шул чак искә төште, ләкин терсәкне тешләп булмый инде. Әмма дөньяда әйбәт кешеләр бар бит! Үзем белән бергә килгән безнең часть кешесе, өлкән лейтенант Корнейчук бик каты йөрде. Алгы сызыкта бер һөҗүмдә булганнан соң ук үзебезгә кире алам диде. Бу минем өчен зур уңыш иде... Беренче һөҗүмдә уңышлы хәрәкәт иттек һәм мине акладылар. Әмма партбилетны кайтармадылар. Сержант дәрәҗәсе биреп, мине тагы шушында эшләргә куйдылар. Монда мин югалткан нәрсәләремне тизрәк кайтара алачакмын...

Хәбиров сөйләүдән туктаганны гына көткәндәй, немец минометтан атарга тотынды. Ике-өч мина якында гына шартлады. Пулеметтан тырттырт итеп ата башладылар. Хәбиров борчылып урыныннан торды да ишек төбенә чыкты. Тыңлаган, күзәткәләгән итте. Тоташ болытлы булганга ничектер көн караңгыланып эңгер-меңгер булып тора иде. Атулар көчәйде, безнекеләр дә аталар. Хәбиров, ниндидер хәтәр сизенгәндәй, тиз генә бүреген киде һәм: «Бигайбә!»— дип, Мирхаска кул бирде, түбәнгә төшә торган сукмактан иелә-иелә китеп тә барды...

## 11

Фәимә өчен Идрисов белән һәрбер очрашу үзенә күрә бер кечкенә бәйрәм сыман булып тоела иде. Ничек ул аңа шул тикле якын булып киткәндер, хәзер Фәимә үзе дә моңа шакката. Эч серләрен аңа барып сөйләсә, ничектер берьюлы җиңел һәм рәхәт була, хезмәтенә дә яңа дәрт белән тотына. Ә үзе белән бергә эшләүче кызлар белән ул нишләптер якыная алмады. Бәлки Идрисовның якташ булуы да күңелен нык тарткан-

дыр? Алгы сызыкта һич тә кәтмәгәндә очрашуга икесе дә тирән мәгънә бирделәр. Югыйсә бу бик очраклы хәл иде. Ләкин якынаюның сәбәбе болар гына түгел иде. Хикмәт шунда, Фәимәнең хезмәте бик авыр һәм четерекле иде. Эштә төрле каршылыклар булып тора. Кайбер нәрсәләрне аңлап җитми, ә иптәшләреннән сорарга тарсына. Әллә горурлыгына көч килер дип куркамы? Ничек кенә булмасын, эштә туган борчуларын ул Идрисовка тәяп бара һәм түкми-чәчми аңа бушата. Командирның бик рәсми булуыннан да зарлана иде. Аның шактыйн коры кеше булуын аңлый һәм аны аклый да ул. Чөнки аларның часте секретлы санала, командирның бүтәнчә булуы мөмкин дә түгелдер. Тик Фәимә үзен аның янында ничектер бик уңайсыз тоя, каушап кала. Әллә нинди киеренке, эчтән борчый торган һәм шул хакта уйларга мәҗбүр итә торган мөнәсәбәт урнашты. Фәимә, бәлки, моңа үзе гаепледер, нәрсәнедер ул командир теләгәнчә эшләмидер? Командир аңа артык дикъкать белән карый шикелле. Һәрбер хәрәкәтен, хәтта аның кәефен дә барлап тора ул. Фәимә чыраендагы кечкенә үзгәреш тә аның күзенә чалынмый калмый. Нишләп бүген кәефең начар?— дип, кинәт сорап куя ул. Нәрсә дип әйтергә дә аптырап каласың. Фәимә үзе дә аптырый инде: аның кәефе еш алмашынып тора. Иртән яхшы гына булса, кичкә начарлана да куя. Нәкъ биредәге һава кебек. Фәимә моны сизеп, үз-үзе белән көрәшеп яши. Ләкин иң читене тагы шул әле: рациядә аның белән бергә эшләүче солдат аңа игътибарлы булып, ухаживать итсә, командир моны бик тиз сизеп ала. Тегеңә бәйләнә башлый. Ә эштән гаеп табу бик ансат ул. Менә Фәимә аркасында ул солдатка җәфа чигәргә туры килә. Дөрес, аны гына түгел, башка кызларны да солдатның нечкә дикъкатеннән «саклый» командир. Аның нияте, билгеле, яхшыда инде, кызларның саф күңеле тапланмасын, яшьлеккә бирелеп, бәлагә юлыкмасын. Кызлар арасында үпкән-кочкан җилгә очкан, яшьлек бер генә килә, дип йөрүчеләр дә бар шул. Фәимә алай булдыра алмый. Шулай да командирның бу кайгыртулары аның өчен ничектер уңайсыз, күңелендә ниндидер шыксызлык тоеп йөри ул. Бервакыт шул хакта Идрисовка зарлангач, теге каударланып: мин сине үзебезгә алам, безгә радист кирәк, дип әйтеп ташлаган иде. Шул җәһәттән берәр эш эшләмәде микән? Ләкин бер көн ул үзе белән хезмәт итә торган кызларга очраган, бер сүз дә әйтмәгән. Кызлар кайткач шаяртып: синең «запалыңны» күрдек, дип көлешеп алдылар. Алар егетләрне «запаллар» дип йөртәләр иде... Эх Идрисов янында аңа әйбәтрәк булыр иде. Мондый киеренке мөнәсәбәттән котылыр иде...

Бу өмет аның күңелен бик ымсындырды, шуңа күрә Фәимә бүген, сменасыннан бушагач, ял итәсе урында, Идрисов янына барырга булды. Яңа позициягә күчкәч, Идрисов аны үзе эзләп табып, кайдалыгын әйткән иде. Урман буеннан үтә торган юл туры аларның пушкалары янына китереп чыгара иде. Барып җитәрәк, туктап, Фәимә бер агач артына керде һәм көзгесен чыгарып, күзен-башын төзәтеп алды. Яшькелт төстәге шинель, кара берет. Алгы чәчләрен маңгаена чыгарыбрак куйды. Маңгае зур булып күренеп тормасын...

Ул аның блиндажын эзләп йөргәндә, Идрисов үзе әллә каян гына килеп чыкты. Кулында өсте капкачлы, яссы алюмин котелок иде. Фәимәне күрүгә кашлары язылып, нурланып китте.

— Ә-ә, кунак килә, кунак килә!— дип, сөенеченнән такмаклап куйды.— Менә хәзер чәй эчәрбез...

Блиндаж эче ярым караңгы иде, күз ияләнгәч, болай ярыйсы икән. Идрисов, снаряд әрҗәләре өстенә кружка куеп, чәй агызды. Элемтәче солдат үзенең кружкасын алды да, ары почмакка китеп, аппараты янына ылыс җәйгән идәнгә кырын ятты. Идрисов Фәимәне сыйларга кәгазьле конфетлар да куйды һәм бер-берсенә ияләнеп беткән кешеләр шикелле чәй эчәргә тотындылар. Шыпырт тавыш белән, икесе аңларлык кына итеп сөйләшәләр иде.

— Нәчәлнигең берәр сүз әйтмәдеме?— дип кызыксынды Идрисов. Фәимә аңа, яратып, күз сирпеп алды, ә эчтән: ир-атка ышанмам дигән тәүбәм бар иде, ни өчендер менә аңа бөтенләе белән ышанам бит, хәерле булсын, дип уйлап алды.

— Нәрсәгәдер йөзе чытылып йөри әле, әллә шелтә биргәннәр. Мине «сорарга» бармагансыңдыр бит?— диде.

— Теге атнада киңәшмәдән бергә кайттык, шунда кылын тартып карадым.

— Соң?

— Булмый торган эш, дигән була. Секретлы шифр ачкычын белүче радистны алгы сызыкка күчерергә ярамый, имеш... Радист дошман кулына эләксә, белмәссең, анда сезнең төрле хәл булуы ихтимал, ди. Бер кодның сере бер полк гаскәргә тора икән...

— Әй, секретны ярата да инде, һәрберегезгә чын мәгънәсендә йозак элеп куяр иде.

— Секрет белән масайганы сизелә шул.

— Шуны үзенә патша тәхете итеп күрә инде.

— Секреты да ташка үлчимдер әле, «үлгән каргадыр»?

— Каян беләсең безнең сүзләрне, ә? Секреты беткән әйберләрне без «үлгән карга» дип атыйбыз.

— Колак ишетә бит...— диде Идрисов елмаеп. Аның алдагы әз генә китек бер теше күренеп калды. Шул теш тә Фәимәгә ягымлы тоелды.

Сүз сөреше бер нәрсәдән икенче нәрсәгә сикерә иде. Кемнең кайда, нишләп йөрүе хакында сөйләшеп киттеләр. Сүз Фәимәнең туган яклары Баулы турында иде.

— Булганым бар,— диде Идрисов.— Анда гел таулар да таулар.

— Әллә сызгыртасың инде, малай?— дип, Фәимә аңа карап елмайды, әмма Идрисов дөресен әйтә иде. Кырык икенче елның кышында госпитальдән аңа әзгә генә ял биргәннәр иде. Шуннан туры Баулыдагы туганнан туган апасына кайтты. Теге ат сату вакыйгасыннан соң байтак вакыт узса да, авылына кайтырга оялды. Әтисе күптән вафат иде инде, әнисе ул хәлләрне онытып, аны бик күрәсе килеп яза иде. Барыбер эчтән нәрсәдер тыйды, җибәрмәде.

— Чын, шунда Долорес Ибаррурины күрдем,— диде Идрисов. Фәимә тагы да аптырабрак аңа карады. Ышанып җитмәве дә йөзенә чыккан иде.

— Чын менә. Әллә ышанмыйсыңмы? Сталинградка малае Рубен янына баруы булган аның. Ул көннәрдә буран бик котырды. Самолетлары адашкан да, ягулыклары бетеп, Баулы басуына төшкәннәр. Долорес Ибаррури ниндидер бер хатын-кыз белән иде, райком секретаренда яшәделәр. Летчикларын безнең апага куйдылар. Буран тагы биш көн котырды. Долорес Ибаррури бер тапкыр райкомга барып килде. Куксел мамык шәлдән, күк каракүл якалы пальто кигән иде. Озынчарак битле, матур калын кашлы, бик ягымлы, нур бөркеп тора торган йөзле...

— Әллә малае сугышта һәлак булгач, шуны күмәргә барды микән?

— Бәлки шулай булгандыр. Ә син каян беләсең аның малае турында?

— Безнең капитан Испаниядә булган кеше. Кайчак кәефе килгәндә, сөйләп алгалый. Испаниядә сугыш вакытында Ибаррури малаен, ятим балалар белән рәттән, безнең илгә озаткан булган икән. Шуның өчен аны гаепләгәннәр, үз улын сугыштан качырды, дип язганнар. Ә малае батыр йөрәкле булган...

— Шул гаепне юар өченме әллә малае сугышка киткән?

— Фашистларга нәфрәттәндер.

— Әйе, немецлар Франкога ярдәм иттеләр бит. Шулай да бик гыйбрәтле хәл, чит җирләрдә үскән малай безнең ил өчен башын сала...

Алар уйланып калдылар. Идрисов бу хәлне сугышчыларга сөйләргә кирәк булыр, дип хәтеренә төйнәде. Аннары Фәимәнең хәл-әхвәле белән кызыксынды.



Т. Хажиәхмәтов рәсеме

— Энеңнең берәр хәбәре юкмы?— диде Идрисов чын кайгыртулы рәвештә. Фәимә аның ихлас күңелле мөнәсәбәтен тоя һәм шул нәрсә җанына ниндидер рәхәтлек бирә иде. Бөтен кичергән авырлыклар аңа җиңел булып китә, алдагы хезмәт, сугыш хәвефләре алай куркыныч булып тоелмый башлый. Чөнки аның якын кешесе, ышыкланыр, таяныр дусты бар.

— Димескәйдән хат килде, әнидән юк,— диде Фәимә моңсу гына тавыш белән.

— Сугышка алганнардыр аны да? Гаҗәп, нигә үзенең бердәнбер туганыңнан кача икән?

— Мин аңлый башладым шикелле аны,— дип, Фәимә көрсенеп куйды.— Ятимлектә әченә ачу җыйналган аның... Шул ачуын миннән ала.

— Юк, Фәимә, дөрес әйтмисең. Нишләп ул ачуын синнән кайтарсын?

— Ачулы кеше ачуын туганнарыннан ала шул. Мин моны үземнән чыгып әйтәм,— диде Фәимә. Идрисов, моңа каршы ни әйтергә белмичә, уйланып калды һәм үзенең теге чакта әтисенә бик нык ачуы килүе, шул ачудан акылсызланып бердәнбер атларын станциягә алып китеп сатуы кинәт исенә килеп, миенә китереп суккандай итте. Бу уйлардан тизрәк арынырга теләгәндәй, чәен шөбердәтеп эчте дә, кружкасын читкәрәк этеп куйды. Фәимә эсселәгәндәй шинель каптырмаларын ычкындырып җибәрде. Ул тома яшькелт йон гимнастерка һәм шундый ук матур юбка кигән иде. Гаскәри кием аның яшь, йомры гәүдәсен тагы да матурлап, ымсындыргыч итеп күрсәтә шикелле иде. Идрисов, шаяргандай итеп, Фәимәнең кулын тотты.

— Карале, кулыңнан миңа электр тогы килә,— дип көлде ул.

— Малай, электрым суга күрмәсен үзеңне,— диде Фәимә дә шаяруга күчеп. Икесенең дә шаярасылары гына килеп тора иде.

— Шулай көчлемени?

— Сиңа гына җитәр анысы.

— Әй минем сине кочагыма алып, бала кебек йоклатасым килә!

— Йоклат, әнә санбатта кызлар күп.

— Юк, мин сине генә!

— Малайлар, беләсеңме, ничек итеп кош аулыйлар? Бер иләк куялар, аның бер ягын кыска гына таяк белән күтәртеп, шул таякка озын җеп бәйлиләр. Ымсындыру өчен иләк эченә бодай сибәләр дә үзләре читкә посалар. Ач кошлар бөртеккә алданып иләк эченәрәк кергәч, җептән тарталар һәм шап! мәхлуклар иләк эчендә тыпырчына, бәргәләнә башлый. Син дә миңа әллә шундый ау кормакчы буласыңмы?.. — диде Фәимә көлә-көлә.

— Алай уйласаң, ялгышасың, Фәимә,— диде Идрисов җитдиләнеп. Ләкин йөзендәге нур сүрелмәде.

— Син әүлия түгелдер ич?!— Фәимәнең тавышы үртәүле-яратулы иде.

— Әүлия түгел, ләкин андый уй башыма килгәне юк.

— Бер килмәсә, бер килүе бар.

— Һич юк! Син миңа ышанып җитмисең бугай?

— Кайчак шикле уйлар да килә шул. Телең бик баллы...

— Сиңа гына баллы, бүтәннәргә әче борычлы,— диде Идрисов, Фәимәнең нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап бетермичә.

— Елан чаккан кеше юлдагы бауны да елан итеп күрә бит.

— Сине елан чакканы бармыни?— диде Идрисов, Фәимә сүзләренең мәгънәсенә төшенгәндәй.

— Бар шул,— диде Фәимә, кинәт сүрелеп. Идрисов ни әйтергә белмичә аңа карап алды. Сүзне дәвам итәсе килмәгән, аңардан курыккан кебек иде аның төсе. Фәимә Идрисовка астан гына карап, пышылдап дәвам итте:

— Егетләр ничек кызларны ышандыралар, белмисеңмени? Я инде, бала-чага булма. Ул да шулай простой булып уенын уйнады.
— Кем?
— Койрыклы җен...
— Мин ул җенне белмим, белергә дә теләмим,— диде Идрисов. Фәимә сүзләренә тагы да аптырап. Ул моны арада бернинди дә аңлашылмау калмасын дигәннән әйтәме?
— Алтын вәгъдәләргә кызлар ышаналар...— дип, Фәимә үзенме, әллә башканымы җәлләгән кебек көрсенде.— Ә бит кызлар егетләргә ышанмасалар, җирдә бернинди дә тормыш булмас иде...—Фәимә, эчендәге нинди-дер тирән хисне сиздермәс өчен, башын артка чөеп, чәчләрен рәтләгәндәй итте. Идрисов үзен ничектер гаепле сизгәндәй, уңайсызланып, аңа карарга кыймыйча утырды. Ә күңелендә кызга карата матур хисләр ташыды. «Карале, мескенем, ул миннән бер нәрсәсен дә яшерә алмый, шундый кешегә ничек йөрәгең эремәсен дә, ничек аны якын итмисең?!»
— Фәимә, син нигә миңа ул хакта әйтәсең? Син минем өчен саф кеше!— дип куйды ул, эчендәге уйларын аңлатырга теләгәндәй.
— Әй, тәмуг фәрештәсе! Син генә бүтән төрледер инде?!
— Минем алда, Фәимә, синең бер гаебең дә юк! Син керсез кеше минем өчен! Чын менә!
— Ышанасым бик килә дә соң...
— Синнән миңа берни дә кирәкми, Фәимә. Менә әллә нидә бер очрашып сөйләшәбез, шул бәйрәм!
— Уф, әллә нишләдем мин, үзем дә белмим,— диде Фәимә һәм, әрҗә кырыена ике учын җәеп, шуңа башын салды.
— Һөҗүмнән соң безне Дальний Востокка җибәрәләр, ди,— диде Идрисов, бик мөһим яңалык әйткәндәй.— Әгәр чын булса, мин сине үзем белән алып китәм.
— Командир бирсә...
— Ризамы? Урлап алып китәм!
— Романтично, конечно! Ләкин аның өчен...
— Юк, мин аның җаен табармын, Фәимә. Эх, исән чыгып булса...
Идрисов Фәимәне озата барды. Кыз бик шат, бәхетле кыяфәтле иде. Ул Идрисовның колагына авызын куеп пышылдады.
— Беләсеңме, мин синең хатының була алыр идем. Ләкин хәзер үк түгел. Мин сине сынар өчен генә «елан чакты», дидем.
— Минем өчен син һәрвакыт саф дип әйттем ич. Ә кайчан соң?
— Үзем әйтермен. Көт. Булдымы?— диде ул, җитди һәм ышандыра торган итеп. Аннары, «шушында кал», дип кулы белән ишарәләде дә, урман кырыендагы сукмактан кызу-кызу адымнар белән китеп барды. Идрисов ымсынып карап торды. Фәимәнең сүзләре аның күңелен кузгаткан иде. Шаярта булыр, шайтан кызый...

## 12

Дошман ягын тетү сәгатьтән ашып китте. Шул арада көн дә бераз яктыра төште. Идрисов үзенең күзәтү пунктында иде. Мирхас стереотрубадан күзен алмады. Тупларының кай төшне дөмбәсләүләрен күзәтеп торды. Аннары Идрисов белән бергә, ату таблицасыннан файдаланып, билгеләнгән ут ноктапарына үнлаган снарядлар яудырдылар. Укчылар командиры Мамак та, килеп, бик хәстәрчән рәвештә алдан шәйләнгән берничә цельгә аттырды. Снарядларның кайда, ничек шартлауларын стереотрубадан аерылмыйча күзәтеп торды. Бик яхшы күренмәсә дә, шартлауны чамалап була иде. Каракүз, Милашкин расчетлары бик төгәл ата. Мамак та: «Молодец, молодец!»— дип, берничә мәртәбә шатланып кычкырды.

— Ну, ярадымы?— диде Идрисов төртмәле тавыш белән, аның тупчыларны гаепләргә генә торуына ишарәләп. Мамак сәгатенә карап алды, җавап бирмәде. Тизрәк каскасын киеп, башына иплэп маташтьы да, траншеядан җәлт кенә сикереп, өскә күтәрелде, куакларга ышыклана-ышыклана, үзенекеләр янына чапты.

Башта сул флангтагы ике ротасына килеп, күрсәтмәләр биреп узды. Командирлар һәм сугышчылар бик ышанычлы иде, анда озак тормады. Иң мөһим, җаваплы участокка, Хәбиров взводы янына ашыкты. Ул күренүгә, траншеяга сөялеп боегыбрак торган сугышчылар, дәртләнеп, башларын күтәрделәр. Хәбиров исә теге башта сугышчыларның рухын күтәреп йөри иде. Траншея казып маташучы бер сугышчыга:

— Көчеңне әрәм итмә, кузгалабыз,— дип әйтеп узды. Аның артыннан: эш белән вакыт узганы сизелми, дип, кычкырдылар. Уйга чумган икенче бер сугышчыга Хәбиров:

— Күп исәпләмә, Бикиев!— дип әйтүне кирәк тапты. Теге исә сискәнеп киткәндәй итеп карады да:

— Ләхетемә кермә әле, иптәш командир!— дип кулын селтәде.

«Ут сүрелгәнче күтәрелергә кирәк!»— дигән уй Хәбировның миен бораулый иде. Капитанны күрүгә сөенеп куйды, аның дулкынланган чырае да вакыт җиткәнлеген аңлатып тора иде. Капитанның иреннәре дәһшәт белән кысылган, ул Хәбировка соңгы күрсәтмәләрен бирә башлады: кай төштәнрәк үрмәләргә, иң элек дошман траншеясының кайсы төшенәрәк бәреп керергә...

— Ну, с богом!— диде ул ничектер йомшап һәм аның исән калуын аталарча кайгырткандай. Хәбиров та дулкынланды, борчылу булып эчендә күтәрелгән каушавын басар өчен тамак кырды. Аннары траншея стенасындагы уемга сул аягын куйды. Бу минутны үзе 'озак сузган шикелле тоелды һәм, шуңа ачуы килгәндәй, автоматын өскә күтәреп кычкырды:

— Минем арттан, алга!— Тавышы карлыкканрак чыкты, тагын бер мәртәбә шул ук сүзләрне көчлерәк итеп кычкырды да бруствер өстенә сикереп менде, артына борылып карады. Сугышчылар барысы да окоплардан чыгып, җиргә иелә биреп, алга баралар иде. Немец атмый иде әле.

Уң флангтан Самокат белән Хәнҗәров шактый алда баралар. Һич куркуны белмиләр, шайтаннар. Молодецлар. «Самокатка сержант званиесе бирдереп дөрес эшләгәнмен»,— дип, сөенеп уйлады Хәбиров. Әнә хәзер бөтен взводны әйди. Ярый әле, пуля яңгырына каршы күтәрелергә туры килмәде, хәзер инде сугышчы чирканчык алды, беренче шурләү бетте. Ничә метр үтелде икән инде, нишләптер бик озак барабыз? Бу араны үткәндә һәр сантимер бигрәк тә озын тоела. «Әйдә, каян килеп, кая китмәгән!— дигән уй башка уйларын бүлде Хәбировның.— Үлсәм дә җәл түгел, үземнең хаклы булуымны исбат итеп китәм. Миннән әйбәтрәк кешеләр дә үлә әле...» Бу — аңардагы һич тә үләсе килмәү хисе шулай әрепләшә иде.

Кинәт колакка выжлаган тавышлар ишетелде, һәм шунда ук күз алдында снарядлар шартлый башлады. Димәк, немец поскан җиреннән чыгып атарга керешге... Хәбиров югалып калмады, бар көченә:

— Ложись!— дип кычкырды. Шул команданы тагы кабатлады. Сугышчы командирның барлыгын белсен, бу кискен моментта үзен ялгыз тоймасын. Ялгыз кешенең куркуы көчәя һәм аның паникага бирелүе мөмкин... Яралanучылар кычкыра башладылар. Хәбиров аларның тавышын басарлык итеп, һаман командалар биреп торды. Сугышчыларга бу тавыш мәлҗеп калмаска ярдәм итәргә тиеш иде...

Немец тәмам исенә килде, баш күтәрергә бирмәслек итеп атарга тотынды. Алданрак бер коры елга чокыры сузылган иде, сугышчылар шуңа шуышып төштеләр. Һөҗүм тукталды. Хәзер тупчылар яңадан

немецның ут нокталарын бастырырга тиешләр, шунсыз алга бару мөмкин булмаячак.

Ләкин командирның куркуы юкка иде: Самокат белән Хәнҗәров, песи кебек бик сак шуышып барып, пулеметның тылына чыктылар һәм кинәт тегеләрнең окопларына арттан шуышып төштеләр. Төтен, корым белән караңгыланган һавада финкалар ялтырап китте. Немецның берсе, бик каты акыра-акыра, шундук җан бирде. Самокат нәкъ шулай теләгән иде, шул тавышка бүтән немецлар да куркып качарга тиешләр. Мондый моментта үлем авазы бик каты тәэсир итә ул... Үзе сөйләвенчә, бервакыт Самокатны күселәр мыжлап торган тегермәнгә эшкә куйганнар. Күселәр шундый әрсезләнгәннәр, өскә сикерәләр икән. Самокат тимер сәнәк алган да бер күсене эләктергән һәм тегене сәнәк җәбе белән сыртыннан идәнгә кадаклап куйган. Әй, шырыйлаган күсе. Шул тавышка тегермәндәге бар күселәр качып беткәннәр... Немецны да шулай итәргә кирәк, дип бик кызыга иде Самокат, менә бүген теләгенә иреште. Хәбировны шиккә калдырган тавыш һөҗүмне туктатып торучы немецның тончыгу авазы иде.

Хәбиров моны шундук дошман пулеметы тынудан сизеп алды. Җанында кузгалган шатлык өермәсе аны җирдән күтәрде. Торып баскач та күзенә снарядлар чыра кебек телгәләп бетергән сирәк урман кәүсәләре арасында чигенүче зәңгәр гәүдәләр чагылып китте. Хәбиров «Урра»,— дип, бар тавышка акырып җибәргәнен сизми дә калды. Аның тавышына тагы берничә сугышчы кушылды һәм алар алга таба йөгерделәр. Пулялар сирәк оча, тияр дип бер дә уйламыйсың, өмет каядыр алда, аякларыңны сизмисең, бары гәүдәңне һәм башыңны гына тотасың. Бер ыргым, ике, өч...

Иң алдан Хәбиров, аның артыннан берничә сугышчы немецның әрлән оясы кебек тармакланып казылган траншеяларына сикерделәр. Һәрберсе берәр тармак булып сузылган чокырны чамалап, шуның буенча чапты. Траншеялар тирән казылган, бөтен буй белән иелми йөрерлек. Хәбиров траншеяның сул тармагына кереп китте, тыны бетсә дә һаман йөгерде. Траншея таугарак күтәрелде һәм ниндидер ачык урынга килеп чыкты. Шул минут алдында ни күрсен, Самокат белән Хәнҗәров! Икесе каракаршы утырганнар да фауст-патрон мылтыгын карыйлар.

— Әй, шайтаннар!— дип, көчкә кычкырып җибәрә алды Хәбиров. Хәнҗәров җиңел гәүдәле, шундук пружинадай өскә калкынды. Самокат тыныч, кымшанмады.

— Бу шайтанның патроны юк икән, иптәш командир,— дип, фауст көпшәсен читкә томырды да бик каты сүгенде. Шунда ук тишекле кожухы юха еланны хәтерләткән немец пулеметын алып брустверга җайлады да атарга кереште. Хәбиров та, траншеяга сөялеп, бинокле белән алны күзәтте. Аннары кинәт:

— Алга!— дип кычкырды һәм үзе дә траншеядан сикереп чыкты.

Әмма ерак китә алмадылар, бер шәрә, ышыксыз җиргә килеп җиткәндә немец бик каты ут ачты. Миналар адым саен шартлады, байтак сугышчыларны кырып салды. Бу ут стенасы иде. Буталыш китте. Хәбиров команда кычкырып торды. Паника кузгалудан курыкты. Паника бер кузгалса, ул ташкын кебек була, аны туктатырмын димә. Мондый чакта ышыкланмый чара юк. Хәбиров шулай боерырга мәҗбүр иде. Бәхеткә каршы, немец траншеялары ерак түгел иде, шунда төшеп ышыкландылар. Вакыт тар, обстановканы билгеләргә кирәк иде. Хәбиров траншея буйлап тагы чапкынлап йөгерергә тотынды. Ак бинт белән чорналган баш, куллар күзенә чалынды, алар шактый күп иде. Нишләргә? Мамак белән элемтә һаман юк. Хәбиров, бер калкурак урын сайлап, бинокле белән немецларны күзәтә башлады. Бер үк вакытта сугышчыларга тиз генә ут ячейкалары хәстәрләргә приказ биреп, әледән-әле шуны кабатлап торды. Дошман утны алар өстенә күчерде. Контрһөҗүмгә әзерләнә, ахры, дип уйлады Хәбиров. Бу инде көтелгән нәрсә иде, ләкин шактый ерактан

болайга таба шуышучы сары төстәге немец танкларын шәйләп алгач, каушап кала язды. Уттай кайнар елдырым аркасын пешереп узды. Ул танклар килер дип үк уйламаган иде. Нишләргә? Бик тиз бер карарга килергә кирәк иде. Өч чакрымлап алга киттеләр: капитаннан бернинди хәбәр юк... Ул бруствердан кәгазьдәй агарынып төште. Сугышчылар аның йөзеннән барын да аңладылар.

— Танклармы?!— дип кычкырып сорады Самокат.

Кардәшев окуляр аша танкларның күплеген шәйләп алды, эченә салкын йөгергәндәй булды. Әх, нигә гаубицалар атмый, дип, әрнеп үртәлде.

Кардәшев, ике снаряд җибәреп чирканчык алган кебек булды. Зиһене тиз эшли башлады. Снарядларның берсе танкның бер ягында, икенчесе икенче ягында шартлады. Бу исә пушканың холкын белеп төзәргә ярдәм итте. Өченче снаряд танкның нәкъ алгы өлешенә барып тиде.

— Подкалибрный!— дип кычкырды ул казенникка снаряд куючы Кылычбайга. Аның йөзе җимерек һәм җанварныкыдай зәһәр иде. Дүртенче, бишенче снаряд танкның нәкъ алгы күкрәк өлешенә, аскарак тиде. Һәм бу чыннан да бик мач булды. Аскы өлешендә «Тигр»ның бронясы юкарак иде, подкалибрный снаряд аны җимерә алды. Танк туктады. Кардәшев прицел окулярыннан моны күреп алды һәм, үзе дә нишләгәнен белештермәстән: «Әтә-тә, ә-тә-тә», дип, тезләрен куллары белән чәбәкли башлады. Кылычбай казенникны шалт итеп япты, Кардәшев икенче танкны прицелга ала башлады, әмма үзе сөйләнә, «әйдә, әйдә, җаныкаем, әйдә, әйдә, әйдә, җаныкаем», ди, танкның мушкага керүенә кинәнгәндәй итә иде. Ләкин шул минут күзенә ялкын чалынып китте һәм чигәсенә ниндидер авыр нәрсә белән суккан кебек булды. Прицелга тотынды, әмма кулы аннан да шуып ычкынды. Тезләнгән әрҗәсе әллә кая очкан иде, ул башы белән җиргә бик каты бәрелеп барып төште. Шунда ук аңына килеп:

— Кылыч, Кылыч!— дип кычкыра башлады. Ул дәшмәгәч, өченче номерга кычкырды. Алардан да җавап ишетә алмагач, хәле китеп, тынып калды. Ниндидер салкын караңгылыкка очып барганын тойгандай булды ул. Аңында чагылган иң соңгы нәрсә шул иде...

Пушка белән лапас стенасы арасында немец снаряды шартлаган иде, шул аларның өчесен дә сафтан чыгарды. Кылычбайның бер кулы гына яраланган иде, ул Кардәшев янына үрмәләп килде, аның йөзенә учын куеп торды да пушкага юнәлде. Прицелдан күзәтергә кереште. Кардәшев аңа: «Мин сафтан чыксам, менә болай, тегеләй итәрсең»,— дип колагына киртләп куйган иде. Шул әйткәнчә хәрәкәт итте. Шул мәлдә ярдәмгә бер тупчы да килеп җитте. Кардәшевның хәлен белмәсә дә, Идрисов аны булышырга җибәргән иде.

Лапас артындагы телефонда Идрисов берни дә майтара алмады. Немец еш атканлыктан чыбык гел өзелеп тора иде. Бераздан пушка тагып килә торган үз машиналарын күреп алды. Шатлыгыннан аны тизрәк лапас артына тартып алмакчы булып җилкенде. Ләкин килеп җитәрәк, машинаның алдында диярлек снаряд шартлап балчык фонтаны күтәрде. Идрисов, хәтәр сүгенеп, җиргә төкерде. Әмма кешеләр исән калган иде, шофер белән Мирхас кабинадан чыгып, мотор өстен ачтылар. Шофер башын селкеде, тиз генә төзәтерлек түгел. Мирхас кузовтан расчетны төшереп, пушканы тәгәрәтеп алып барырга кушты бугай. Барысы да пушкага килеп ябыштылар. Тик алып бара алмаслыклары шунда ук аңлашылды, көч әз шул. Мирхас Идрисовны күреп алды, йөгереп килде. Алар кычкырып-кычкырып нишләргә кирәклек турында сөйләшә башладылар. Ә немец снарядлары баш түбәсеннән кот алырлык тавыш белән сызгырып үтәләр иде...

...Бөтен тирә-юнь, җир һәм күк ике яктан да аткан снарядлар выжылдавыннан, аларның коточкыч шартлавыннан тоташ гүләп тора иде. Шушы үлем улавы эченнән Идрисов үз пушкаларының атуын чамалады, игътибары гел шуларда булды. Бераздан Кардәшев орудиесенең

тынып калганын абайлады. Һәм бөтен тәненә кайнар ут йөгергәндәй булды. Телефоннан бик мөһим сөйләшүне көтеп торырга түземлеге калмады. Шунда аңардан күрсәтмә алырга килгән Мирхасны аппарат янында калдырды да лапасның аргы башына чапты.

Орудие янына җиткәндә ул алга күз ташлады һәм бары өч-дүрт йөз метрга болай таба шуышучы танкны күреп алды. Тиз генә орудие кырына килеп тезләнде, лафет артында кемдер замок белән маташа иде.

— Огонь!— дип кычкырды Идрисов, теге йөзен күтәреп карады. Әһә, бу кичә генә килгән солдат икән, аны үзе бая гына шушында җибәргәнен ул онытккан иде.

— Замок ябылмый, иптәш комбат!— диде сугышчы бик тыныч кына. Аның бер дә исе китмәгән төстә булуы шаккатыргыч иде. Кыяфәтендә бернинди курку әсәре юк. Идрисов замок рычагына үзе килеп тотынды, ул ябылмый иде. Кабалана-кабалана кай төшендер борып карады, юк, булмый гына. Ахырда, кулын селтәп, ачынып төкерде.

— Гранаталар әзерләргә!— дип, ерткыч тавыш белән үкерде ул. Сугышчы тиз-тиз хәрәкәтләнә башлады. Аның гранаталары әзер икән инде. Сай гына казылган, ике метр озынлыгы гына траншея бруствериына тезеп куелган иде. Икесе дә шул траншеяга сикереп төштеләр.

— Ничек фамилияң?

— Иван Могила,— диде калын, йомры иякле, зур гына авызлы сугышчы. Аның ярты йөзен һәм күзләрен каска каплаган иде. Элеккеге фронтовик бугай, шуңа күрә үзенә бик нык ышанган кыяфәт белән тора. Аның тыныч булуы Идрисовка да йокты, ул да тынычлана төште. Хәзерге моментта нәкъ шулай кирәген аңлап алды. Орудиенең икенче ягында да нәкъ шушындый ук окоп бар иде, Идрисов, уйлады да, Могилага шунда шуышырга кушты. Танкның шул якка таба килүе дә ихтимал иде.

Ул траншея стенасына сыланып иелгән килеш, гранатаның сабыннан тотып, кулында үлчәп карагандый итте: «ничә метрга атып булыр икән, ераграк ыргыта алмасаң, үзеңә эләгүе мөмкин... Танкка нигә беркем дә атмый», дип җаны үртәлде аның. Күңеленә үч һәм кыжрау тулды. Бөтен уйларын, тойгыларын нәфрәт хисе туплады. Я гомер, я танк, бүтән хисап юк иде... Танк үзенең зур гәүдәсе белән җирне селкетә, траншея стенасыннан балчыклар ишелгәләп төшә. Ул башын күтәргәндә танкның куркыныч гәүдәсе шактый якынлашып өлгергән иде; Идрисов каушый язды, ләкин бик тиз үзен туплап, кулына кыскан гранатаны җан көче белән танкның тегермәненә турылап атты. Гранатаның шартлавын ишетмәде, шул минутта күкрәгенә ниндидер бик көчле дулкын килеп бәрелде. Траншея стенасы өскә ишелеп төште дигән уй миендә чагылды һәм күзе танк тәгәрмәченең һавада әйләнеп торуын шәйләде. Ул ике куллап траншея идәненә таянмакчы булып карады, ләкин өстән ниндидер авырлык аны басып төшерде. Кайнар битенә салкын балчык тигәнен сизде ул, чигә турысын нәрсәдер бик каты авырттырганын тойды: шул мизгелдә уй җепләре кинәт өзелеп кадылар...

Немец авыр туплардан бик еш ата иде. Шулай да безнең танклар яшеренгән ояларыннан чыгып ике флангтан да дошман танкларының икенче дулкынына каршы ут ачтылар, алга таба хәрәкәт итә башладылар.

Хәбиров үзенең сугышчылары белән, дошманның беренче траншеясында теше-тырнагы белән ябышып, немец танклары һөҗүме вакытында бүленеп калган иде. Алар өстенә үзебезнең миналар да, дошман снарядлары да төшкәләп торды. Әмма немец блиндажлары һәм окоплары аларны бәла-казадан ышыклады, бер-ике яраланучыдан башка зыян булмады. Ләкин үзләре немецларга шактый зыян ясадылар, танклар артына ышыкланып килүче немец пехотасының юлын кистеләр. Самокат бер кул пулеметын бик җайлы урынга көйләгән иде, Хәнҗәров белән икесе шуннан атып яттылар. Немецлар нишләргә белмичә, берни-

чә мәртәбә үрмәләп якын ук килеп, гранаталар белән һөҗүм иттеләр. Ләкин егетләр бик уяу һәм житез булып чыкты. Флангтан безнең бер танк күренгәч, Хәбиров сөенеченнән «ура» кычкырып җибәрде. Барча сугышчыларга дәрт кереп китте. Бу танк аларны үлем упкынынnan чыгарырга сузылган кул кебек иде. Димәк, танклар һөҗүмгә кергән дип, ышаныч белән уйлады Хәбиров.

Траншеядан ерак түгел бер зур бомба чокыры бар иде, безнең танк шуның янында туктап калды. «Әллә немец снаряды тидеме? Нәрсә булды икән», дип, борчылып, Хәбиров танк эченнән кемнең дә булса чыгуын көтте: ләкин шул мәл танкка таба әллә кайдан гына пәйда булган немец танкы якынлашып килүен күрде. Танкның арт яктан үрмәләве, аның чигенеп барганлыгын күрсәтә. Тукта, безнекеләр нигә шәйләмиләр аны? Немец танкы, качып котыла алмаслыгын, бүтән чара калмаганлыгын белеп, моңа төбәлеп килә иде. Якыннан граната ыргытырга уйлыймы? Әллә таран ясап измәкчеме? Мотор жалюзиена тәгәрмәче белән китереп бәрсә, зарарлавы мөмкин. Ләкин немец килеп җитте дигәндә, безнең танк кинәт яны белән борылды да куйды. Дыңк иткән аваз ишетелде һәм очкыннар чәчрәде. Танкка зыяны булмады. Безнекеләр немецны алдан шәйләп, көтеп торганнар бугай. Менә безнең танкның моторы көчле гөрелдәргә тотынды. Ул җәлт кенә чигенеп китте һәм немец танкының артына килеп чыкты. Теге исә бик әкрен кыймылдый иде. Чөнки аларның танклары бензин белән генә эшли һәм шуңа күрә купкә көчсез дә. Немец безнекенең ниятен чамалап өлгергәнче, безнең утыз дүртле үзенең көчле күкрәге белән тегенең мотор корпусына китереп орды. Тагы хәтәр очкыннар чәчрәде. Немец танкысы чайкалып куйды, арткы трагы җирдән кубып торды, аннан кире төште. Ул яны белән борылырга итә иде. Безнекеләр аның янтыгына якын ук килеп бастылар. Һәм тиз генә тагы артка таба китеп, тегенең жалюзи почмагына алгы трак белән китереп ордылар. Бу бәрү бик мач булды, ахры, немец танкының моторы кинәт тынып калды. Димәк, моторны имгәткәннәр. Хәзер ул бер өем тимер генә иде. Безнең танк аны бөтен гәүдәсе белән бульдозер шикелле теге тирән чокырга табан этеп китерә башлады. Немец танкысының моторы кабынмады. Ул берничек тә каршы тора алмый иде, ләкин немецлар, өске люкларын ачып, безнең танк тәгәрмәченә ике-өч граната ыргыттылар. Танк туктады. Шулай ук зарарладылар микәнни? Әһә, юк икән, танк хәрәкәткә килде, ул үлмәгән, тере иде. Немец танкысын чокыр ярына ук китереп җиткерде, танк чүмәлеп китәргә тиеш иде. Кинәт немецлар, люкны ачып, чокырга сикерешә башладылар. Бу күренешне карап торган Хәбиров, кыҗрап, нindидер рәхәтлек белән автоматын шул немецларга төзәп торды һәм, ышанычлырак булсын өчен, күкрәген тутырып сулыш алды да тәтесенә басты. Немецлар өчесе дә, чалгы белән чапкан сабак кебек, кыелып төштеләр. Берсенең каскасы башыннан ычкынып, чокырның төбенә хәтле тәгәрәп барды.

Шул мәлдә, әле тегендә, әле монда безнең танкларның алга хәрәкәт иткәне күренә башлады. Кинәт Хәбировлар яныннан гына узып баручы бер танктан Мамак сикереп төште. Аның чырае-башы корымга, дегеткә буялып беткән иде. Кул астындагылар югалган этиләре табылган малайлар кебек чиксез шатландылар. Мамак үзе дә күтәренке кәефле иде.

— Ну, бөркетләр, молодцы!— диде.— Куркып калмадыгыз! Югалтулар бармы? Хәбиров кая?

Немецның пулеметтан атуы туктаган иде, Мамак траншея кырыена баскан килеш барысын да белеште. Шул минутта ук йөгерүдән ухылдыйухылдый Хәбиров килеп җитте. Мамак аңы чак кына кочаклап алмады, ашыга-ашыга рәхмәтләр әйтте. Сөйләшеп торырга вакыт юк иде, Мамак тиз-тиз күрсәтмәләр бирде.

— Егетләр, алга!— дип кычкырып, кул болгады ул. Хәбиров та: «Алга! Алга!» ди-ди, траншея кырыеннан солдатларны әйдәп чабып китте. Сугышчылар окоплардан чыктылар, автоматларын күкрәкләренә

терәп торкан килеш, Хәбиров артыннан алга таба йөгерделәр. Немецлар бары авыр туплардан гына аталар иде. Танклар һәм сугышчылар ниндидер бер көчле дулкын булып баралар. Бу дулкын шактый киң кырны тутырып һаман алга ыргыла. Кыр уртасында кайчак танклар һәм сугышчылар янында ук снарядлар шартлап җир фонтаны күтәрәләр. Монда инде очраклык үз көченә керде, ул барысын үзенчә хәл итә. Була-бәхетле очраклар, була фаҗигале очраклар. Бәхетсез очракка туры килеп, кайберәүләр мәңгегә шул кырда ятып кала иде. Үлем уены бик рәхимсез бит, монда ул күбрәк җиңә, кеше җиңелә. Дөнья яктылыгының тере чаткысы булган кеше кинәт сүнеп кала...

Алда төтен, актарылган балчык тузаны аша карамчыкланып ниндидер урман күзгә чалынып китә иде. Барган саен төтен эченнән әйберләр калкып чыга барды. Каралып күренгән сирәк урманлыкта шалаш кебек текә түбәле йортлар пәйда булды. Барысы да бериш кызыл кирпеч япкан, стеналары яннан күренми, түбә стена итеп җиргә хәтле диярлек кыеклап төшерелгән иде. Ләкин йортлар күп түгел, ниндидер хутор кисәге булса кирәк. Кырыйдагы бер йорт җимерелеп, кызыл кирпечләре көл булып чәчелгән. Хәбиров Самокат белән Хәнҗәровны күздән ычкындырмаска тырышып бара. Өйләргә керергә омтылсалар, шунда командир булуын күреп, тыелып калачаклар... Ләкин алар өйләргә таба карамый гына узып киттеләр. Инде йөгерә-йөгерә хәл бетте, эчләргә кату төште. Хуторның аргы башында ниндидер таш юлга килеп чыктылар. Бер як канавында танк изеп киткән өч немец гәүдәсе аунап ята иде. Шул юлның ике ягыннан тезелгән шикелле ара саклап һаман алга омтылдылар. Немец миналарны шактый еш төшерә башлады. Ләкин бу алга баруны туктата алмый иде. Ачык кырдан баралар, алда тагы офыкка элгән кара пәрдә сыман ниндидер урман тора иде. Шактый араны үткәч, немецның пулемет уты сугышчыларны җиргә аварга мәҗбүр итте. Ут көчәйгәннән көчәйде. Кырыйда гына ике танк сафтан чыкты. Немец болванка ата, ул авыр, зур көч белән җирдән тәгәрәп килә дә танкның я тәгәрмәчен җимерә, я бронясын тишә. Флангтагы танклар да, көчле каршылыкка очрап, алга баруларын туктатканнар бугай... Юл янындагы танклар исә, иңкү җиргәрәк чигенеп, шуңа ышыкландылар һәм дошман ягына нык кына атарга тотындылар. Шунда ук каяндыр тылдан «Катюша»лар залп бирделәр. Алар тынганда Хәбировка Мамакның приказы килеп җитте: «Алга!»

Хәбиров, карлыккан, шыксыз тавыш белән бар көченә кычкырып, сугышчыларны атакага күтәрде. Йөгереп алга киттеләр. Ләкин озак барырга һич тә мөмкин түгел иде, тагы җиргә аудылар. Яраланып кычкыручылар кинәт күбәйде. Немец уты һаман кимемәде. Инде караңгы төшеп килә иде. Сугышчылар снаряд чокырларына төшеп, шунда урнаштылар. Кичке эңгердә каскалары гына чак-чак шәйләнә. Оборонага урнашудан башка чара калмаганлыгын һәркем сизеп тора иде. Ләкин приказ юк. Шуңа күрә Хәбиров, алга тагы бер омтылыш ясарга теләп, үрмәләп, дүрт аяклап, чокырдан чокырга кычкырып, боерык биреп йөрде. Тәмам этләнеп, арып бетте. Сугышчыларны берничек тә атакага күтәрә алмады. Караңгылык шактый куергач кына Мамак килде һәм оборонага урнашырга приказ барлыгын әйтте. Исән калган сугышчылар, иркен сулыш алып, үзләре поскан чокырларын казырга керештеләр. Биш йөз метр чамасы арттарак, тирә-ягына чаука үскән бер чокырга кухня килгән иде инде. Шуннан термос белән аш һәм икмәк алып кайттылар. Окоп тирәләре тагы җанланып китте... Ләкин немец цельсез булса да һаман өстән төшереп тора иде. Тагы берничә кеше яраланды.

«Инде аз калдык, пополнениегә чыгарырлар», дип, өметле уйга бирелеп, Хәбиров белән Самокат кечкенә бер блиндаж кисәге әмәлләп маташа иде. Бер сугышчы килеп, Бикиевның яраланганлыгын һәм ни өчендер үзе янына Хәбировны чакырганлыгын әйтте. Бармыйча ярамый иде,

чөнки командирның әз генә игътибарсызлыгы да сугышчыларга беленми калмый, алар сиңа ышанмый башлыйлар. Хәбиров, казудан туктап, сорады:

— Кайда әле ул?

— Санпунктка илттек.

«Балык кебек бер дә сөйләшми, аралашмый торган ул егет нигә дәшә икән», дип уйлап, Хәбиров күрәсе теге сугышчыга бирде һәм санпунктка китте.

Санпункт дигәне кухня янынарак куелган палатка-чатыр икән. Бер кырыйда тимер мич яна. Шәмнең яктысы зәгыйфь кенә иде. Бикиевны бөтенләй танырлык та түгел. Яңаклары суырылып эчкә баткан, иягe алга калкып чыккан, саргылт ал тешләре ыржаеп тора.

— Ни булды, энекәш?— дип, Хәбиров чыршы ботаклары өстендә яткан Бикиев янына барып тезләнде. Бикиев күзләрен ачты, әсәренеп карап торды.

— Менә үләм, иптәш командир,— диде ул, сүзләрен көчкә әвәләп. Ә үзендә бер дә үртәлү, үкенү, ачулану галәмәте юк. Ул үлүенә канәгать сыман иде.

— Шуны гына әйтмәкче идем, иптәш командир,— дип, бик авырлык белән сүзләрен өзек-өзек әйтә башлады ул.— Минем чын фамилиям Бикиев түгел, ә Нәбиуллин. Әтием дә, әнием дә юк, ачлык елны үлгәннәр. Тик бер Фәимә исемле туган апам булырга тиеш. Мине әтинең туганнары тәрбиягә алганнар иде. Мин аларда бик газап чиктем. Рәнжетүнең чиге булмады. Ахырда мин качтым, җылы якка. Анда приютка эләктем. Аннан да качтым. Термезда яшәдем. Аннан тагы Ташкентка кайттым. Эшли башладым. Миндә нинди-дер заем кәгазьләре бар иде, шуларның берсе илле мең отты. Мин ул акчаны үзем квартирда яшәгән өйнең нигезенә яшердем. Җай чыгуга Рәсәйгә кайтып, апамны эзләп тапмакчы идем... Челанзар урамы, 13 нче йорт, уң як нигез...— Ул хәле бетеп туктады, күзләрен йомды.

— Ник син моны миңа әйтәсең?— диде Хәбиров. Аның мондый хәлләрне күп күргәне булды, күпләрнең соңгы сүзләрен ишетте ул, моңа бер дә исе китмичә генә карады, шулай да сүзенең мәгънәсен беләсе килә иде. Бикиев бераздан соң гына, сүзләрен авызыннан вак ташлардай этеп чыгара-чыгара:

— Чөнки син чын кешегә охшагансың,— дип куйды. Кулын авыр гына селтәде, күзләрен йомды. Бүтән берни әйтә алмады, хәле киткән иде. Санитар кызлар килеп, аның яра бәйләвечен сүтә башладылар. Эче бик хәтәр актарылган икән. Бикиев аңын җуйды. Санитарлар дарулап, яхшылап бәйләп бетергәндә сулыш алуы кинәт туктап калды...

...Граната шартлаудан окоп стенасы җимерелеп, балчык астында контужен булып калган Идрисов бермәлне бик каты өшеп исенә килде. Күзләрен ачты. Тирә-ягы дөм караңгы иде. Кайда мин? Нишләдем мин? Ничек болай булдым? — дигән сораулар миен энә белән чәнечкән кебек итеп авырттырып үтәләр. Ул башын кыймылдатып карады, юк, кымшанмый, аны зур бер кантар бик каты кыскан иде. Маңгаен шулай ук кантар баскан. Шул кантарлар арасында һава керерлек ярыклар барлыкка килгән, бары шуннан гына исән калган икән. Кулларын балчык астыннан җиңел алды, әмма аякларын «коткарырга» күп көч түкте, сантиметрлап үзенә таба тартты да тартты. Буыннары өзелеп кала язгандай иде. Ул моны бик шыпырт эшләде, бәлки тирә-якта немецлардыр дип сагая, үзенең кай төштә ятканына әле ус белән барып җитә алмаган иде. Аякларын алгач кына башын кантарлар астыннан чыгаруга иреште. Куллары белән тирә-юнен капшый башлады, кулы гел тимергә барып тия иде. Бераздан шуны белде: аның баш өстендә ниндидер танк гәүдәсе сузылган. Кем танкы икән бу? Әйе, ул окоп тирән булу аркасында гына сытылмый калган... Кинәт шул мәл баш өстендә нәрсәдер

чырк итте, аннары тимергә-тимер бәрелгән аваз килде. Идрисов хәтәр сагаеп, аякларын үзенә таба бөкләде, бер йомарлам булып йомарланды, колагын торгызды. Әһә, менә тагы нәрсәдер дырк итеп ачылгандай булды һәм Идрисовның борынына үлек өстенә сибә торган төче хушбуй исе килеп бәрелде... «Немец!»— дигән уй бик каты миенә китереп сукты. Шул аның бөтен җегәрлеген, карарсызлыгын капылт алып ташлады, кулларына хәтәр көч тулып кайнарланды; ут булып кызышты. Зиһене тәмам ачыкланып, гаҗәп үткер эшләргә тотынды. Нәкъ шул минутта өстәге тишектән әкрен генә төшүче үкчә дагасы елтырап китте. Моның немец икәненә Идрисовның инде шиге калмады, һәм куллары яшен тизлеге белән үзен-үзе капшап корал эзләде. «Немец мине сизенеп төшә икән, монда хәзер я мин, я ул», дигән уй бар көчен кулларына туплады. Бәхеткә, чалбар каешындагы финкасын табып алды, пистолеты кабурасыние белән юк иде. Финка җайлы гына иде, хәзер аның куллары, акылына буйсынмагандай, кискен хәрәкәтләнә иде. Менә Идрисов үзенең бите янында гына кыштырдый-кыштырдый юан бер арканың түбән таба төшүен җан күзе белән күреп, сизеп алды. Ул ничек итеп кизәнгәнен сизмәде дә, бары финкасының ниндидер бер, тыгыз әйбергә кытырдап кереп батканын гына тойды һәм «ык-ык! ыһ-ыһ!»— иткән авазлар ишетелде. Аннары шатыр-шотыр килеп, бик авыр бер нәрсә аның өстенә ишелеп килеп төште. Бар гәүдәсен кантар кебек басты, окоп стенасына китереп кысты. Колак турына ниндидер салкын әйбер тиеп, бик каты авырттырып алды һәм шунда берни тоймас булды. Тагы исен җуйды. Ул ниндидер күктә очып йөри башлады... Бераздан тагы нәрсәгәдер бәрелеп ул һушына килде, ләкин аягын да, кулын да кымшата алмады. Тагы аны: «Нишләдем мин? Кайда соң мин?»— дигән уйлар биләп алды, әмма хәрәкәтләнергә, кычкырырга бер хәле дә юк икәнен тойды...

...Һөҗүм барган вакытта Фәимәнең җаны кыл өстендә булды. Ул Идрисов турында гына уйлый иде. Рациядә эшләгән чакта бары Идрисов белән бәйләнешле тавышларны гына ишетә иде. Үзләреннән ерак түгел озын-озын лапас кебек яшел палаткаларга урнашкан санбатка яралыларны китергән саен, барып карап килде. Эх, язмышны белеп булса, әллә ниләр бирер иде. Бу бит соңгы сират күпере инде, исән калса, барысы да алар теләгәнчә генә булыр иде! Икесе корган татлы планнар чынга ашар иде. Эх, исән генә калса... Ничек кенә яратмас иде ул аны. Фәимә кичне көчкә-көчкә җиткерде. Сменасын тизрәк тапшырып, тагы санбатка килде. Операция бүлмәләренә чаклы кереп тикшереп чыкты. Түзәр хәле калмагач, Идрисов батареясын эзләп китте.

Батарея өч чакрым чамасы гына алга күчкән икән, ниндидер урман буена урнаша башлаган. Тафтилов Фәимәне шундук танып алды. Кызның күзләре: «Идрисов кая?»— дип сораганын да күрде. Ләкин аны һаман бүлдерәләр, әллә кемнәр әллә нинди таләпләр белән керәләр һәм Тафтилов алар белән сөйләшә. Алар чыгып өлгерми, икенчеләре килә, шау-шу куптара. Тафтилов бер ара табып, Фәимәгә утырып торырга кушты, үзе янындагы снаряд әрҗәсен тәкъдим итте. Сукыр ут мелт-мелт килеп яна иде. Идрисовның юклыгын, һаман кайтып кермәвен күреп, Фәимәнең бөтен тәне эсселе-суыклы булды, иреннәре калтырый иде.

— Комбатыбызны югалтып торабыз әле,— диде Тафтилов моңсу гына.— Бар төштән эзләттек, тагы эзләргә җибәргән идем...— Аңа сүзен әйтеп бетерергә бирмәделәр, тагы урап алдылар. Фәимәнең кинәт күзен томан басты, тамагы тыгылды, башы зең-зең итеп чыңлый иде. Шиге зураеп, җанына сарылды. Зиһененә әллә ниләр килеп буталды да бетте. Иртәдән бирле җанына урын таба алмыйча, борчылган, эче пошкан иде. Күңеле сизгән икән. Ул арада урта буйлы, мәһабәт чырайлы Мөслимов ах-вах килеп, кайтып керде.

— Ни тереләр, ни үләләр арасында ул юк,— диде көчкә аягында басып торган хәлдә һәм Тафтиловның җавабын да көтмичә блиндажның

җир сәкесенә янтаеп төште. Телефон шалтырады, анда нәрсәдер боералар иде. Тафтилов шул эш белән Мөслимовны тагы чаптырды. Әмма югалган комбатны эзләү белән шөгыльләнергә һич мөмкин түгел сыман иде. Киселгән-беткән, бөтен эш исәннәрдә, һәркемнең үзенеке көчле иде.

— Мин аны эзләргә чыгам,— диде Фәимә, битенә аккан күз яшьләрен учы белән сөртә-сөртә урыныннан торды.

— Туктале, кызым,— дип, Тафтилов тагы элеккеге мөлаем-ягымлы хәленә кайтты. Берничә җиргә шалтыратты, боерды, кемнәрнедер таптырды, ләкин берниндн дә нәтиҗә булмады.

— Танк бортына утырып, штурмовиклар артыннан барганын күргәннәр, шуннан эз югала...— Тафтилов таркау зиһен, нишләргә дә белмәгән йөз белән трубканы куйды.

— Эзләмичә булмый!— дип, Фәимә кыю җәнлек кебек тагы кузгалды. Аның артыннан Тафтилов та чыкты. Кызга ым кагып, эзләшергә үзе бер үткен сержант бирәчәген әйтте. Алар бөгелмичә йөреп булырлык, әйбәт, иркен блиндажга керделәр. Бүлемтек-бүлемтек сәкеләргә печән түшәлгән, ишек төбендә юынгыч та бар. Немец, имансыз, комфортта яшәгән.

Тафтилов бүреге белән күзен каплап, сәкегә чалкан сузылган сугышчы янына килде. Ул фуфайка кигән, трофей итекләрдән, ихтыяр көчен белгертеп торган киң иякле иде. Фәимә аны шунда ук таныды. Идрисов һәрчак сокланып һәм беразкызганып сөйли иде аның турында. «Тормышта бәхете юк, әмма сугыш бәхете бар», ди иде. Чөнки Мирхас бик риясыз егет, бар эшен дә риясыз эшли, кешегә дә тиз ышана. Бар кеше дә аның кебек артык ихлас түгел шул. Мирхас алдана. Үзен бәхетсез саный, бизенә. Әмма берәр эш башкарырга тотынса, элеккеге риясызлыгы тагы үзенекен итә. Алтын егет, мин аны саклабрак йөрергә тырышам... Ә Тафтилов Мирхасны уятмакчы була, әмма теге бик каты йоклаган, эндәшкәнне ишетми дә шикелле иде.

— Улым, тор әле,— ди Тафтилов. Мирхасның уянмавын акларга иткәндәй өсти:— Бүген ул ун кешелек эшләде, ике немецны плен алды...

Бер элемтәче килеп, Мирхасның иңеннән тарткалады, аны икенче якка әйләндерергә маташты. Мирхас кымшанмады да, кулларын гына як-якка җәеп куйды, берни булмагандай мышный бирде. Мөслимов та, аны уятырга тырышып, тегенең башын ике учына алды һәм колакларын уа башлады. Мирхас һаман уянмады, әмма, калкынып, Мөслимов кулыннан башын ычкындырды, бер кулы белән аны селтәп җибәрде. Мөслимовның зур гәүдәсе чайкалып китте. Мирхас Мөслимовны бер дә өнәми иде, аның командир алдында куштанлануын сизде ахры, шуңа бик хәтәр кизәнде бугай.

— Эх, аракы булсын иде,— диде Мөслимов Мирхаска бер дә ачуланмыйча. Ул үзенең чослыгын күрсәтәсе килгән кебек иде. Фәимә «аракы белән нишли аласың», дигән караш белән шинель кесәсеннән ак алюминий баклашка чыгарды. Тафтилов Мирхасның башын тотты, аны юмалый торган сүзләр әйтте, «уян», дип ялынды. Мөслимов Мирхасның авызын кашык сабы белән шак-шок китереп ачып, баклашкадан аракы койды. Ниһаять, Мирхас телгә килде, тик күзләрен һаман ача алмый иде.

— Нәрсә эшлисез, сволочьлар!— диде карлыккан тавыш белән. Тагы күзен ача алмыйча изри башлады. Мөслимов тегенең авызына тагы утлы сыекчаны койды. Мирхас шуннан соң гына күзен ачты. Тафтиловны күрүгә йөзендәге ачу, канәгатьсезлек шундук бетте. Ул торып утырды. Тафтилов аңа эшнең нәрсәдә икәнен аңлатырга тотынды. Шунда Мирхас Фәимәне танып алды һәм үзенең шулай рәтсез булуыннан уңайсызланды, йөзендә аны аңлау, мәрхәмәт, хөрмәт чаткылары чыкты. Тафтилов сөйләп бетермәстән үк, ул сәкедән сикереп төште, ятагында яткан мөгез кебек озынча магазинлы автоматын алды.

— Үзем генә барам,— дип, Фәимәгә таба борылды ул. Ләкин кызның кыяфәтендә катгыйлык күрде.

— Юк, сез аны таба алмассыз,— диде кыз нык итеп, әйтерсең лә ул Идрисовны табуның бер серен белә иде.

— Кызым, син йөрмә!— Тафтилов Фәимәнең җиңенә аталарча кайгыртучан рәвештә кагылып куйды. Ләкин кыз тагы да кискен итеп баш селкеде. Тафтиловның йөзе уйчанланды, кызлар балигъ булгач шулай әтиләренең сүзләрен тыңламый башлыйлар инде, дигән бер мәгънә күзләреннән беленеп калды.

Алар чыгып китүгә телефон зуммеры пипелдәде. Алтынчы батарея командиры икән. Тафтилов аның тавышыннан таныды. Ул коры гына приказ тоны белән әйтте: «Хәзер үк пехотачылар катында күзәтү пункты булдыр. Әгәр үзеңнең көчең җитмәсә, анда минекеләр барып урнашты, шунда дежурга бер элемтәчене җибәр. Чыбык сузылган, хәзергә безнеке аша хәбәрләшеп торырсыз.»

Идрисовның югалуын белгәч, «штабтан шулай кушканнардыр инде», дип уйлады Тафтилов трубканы куйгач. Шунда ук чыршы ботакларына күмелеп яткан Мөслимов янына килде. Тагын монысын да күзгатып булмас кебек тоелган иде аңа, әмма Мөслимов көтмәгәнчә тиз торды. Запаслы кеше буларак, йокысын да запас йоклап куйган диярсең. Кеше белән кешенең аермасы бар шул. Мөслимов бер эштә дә, беркатлы Мирхас кебек, үзен азагына чаклы салып бетерми, көчен саклап калдыра иде.

Алтынчы батарея кырыйда гына иде, караңгы булса да элемтә чыбыгын тиз тапты Мөслимов. Һәм шул кабельне җирдән алып, учы аша шудыра-шудыра, алгы сызыкка таба йөгерде. Күзгә төртсәң күренмәс дөмдә немец ракеталары ярдәм итте: вакыт-вакыт юлны яктырталар һәм алгы сызыкны төгәл күрсәтәләр иде.

Элемтәче күз күргән кеше икән, бик тиз аңлашып алдылар. Блиндажы да ярыйсы гына: уртадан юл, ике яклап ылыс җәйгән тар гына җир сәке, түрдә бик зәгыйфь кенә сукыр ут теле тибрәнә. Шулай да элемтәче, каешланган адәм булса кирәк, үзенең биредә хуҗа булуыннан файдаланды: Мөслимовны телефонга куеп, үзе ятып йоклады. Линия болай тыныч иде әледән-әле парольне әйтеп, штабтан тикшереп торалар, немец турында сораштыралар. Башкача борчучы сизелми.

Мөслимов та бик арыган иде, күзен йокы әчеттерә, кыра башлады. Күзен йоммыйча һич мөмкин түгел. Күзне йомасың да йокылы-уяулы утырасың. Шул чак блиндажга капылт кына ике кеше килеп керде. Мөслимов, куркып, янындагы автоматына тотынды. Йокысы кинәт юып алгандай ачылды, тегеләргә:

— Пароль!— дип кычкырып җибәрде. Берсе старшина погонлы иде, шул парольне әйтте дә өстәде:

— Ә-ә, мин сине беләм, егет,— дип, аңа төбәлде. Мөслимов та тегенә тасрайды, әмма танымады. Старшина телефоннан сөйләшергә рөхсәт сорады. Мөслимов аңа трубканы биреп, һаман хәтерен эшләтте. Бу матур йөзле кешене кайдыр күргәне бар бугай шул. Тукта, теге тылда торган чакта тәртип бозган өчен Мостафин штабка алып килгән старшина ич бу! ЭРЭС расчеты командиры. Асоев аның эшен зурга җибәрмәкче булган икән, әмма Мостафин җәлләгән, документларын кире кайтарып бирдергән. Мөслимов белән Мирхас старшинаны үз частьләренә чаклы озатып куйганнар иде. Теге трубканы биргәндә, Мөслимов шул хакта әйтте, ләкин аның бу сүзгә бер дә исе китмәде, ишетмәгән кебек итеп:

— Боларның начальниклары шәп кеше,— дип, иптәшенә төбәлеп әйтте дә бетерде. Иптәше дә гранаталар тутырган противогаз сумкасын җилкәсеннән бушатып янәшәгә куйган, үз эченә төбәлеп утыра. Тышкы берни дә аны кызыксындырмый шикелле иде.

— Командирны әйтәм, ничек тиз үзен бездән аерды! Тфү! Мин аны әйбәт кеше дип йөри идем,— диде чак ишетелерлек тавыш белән. Алар үзләре генә аңларлык рәвештә быдыр-быдыр сөйләшә башладылар.

— Ярар, Петя, куйсана,— дип куйды старшина. Күрек кебек кин күкрәгеннән селкетеп бик тирән итеп көрсенде.— Ничек шулай килеп чыкты, авызын корт чаккыры, һаман аңыма килә алмыйм.

— Мин дә машина яныннан ничек киткәнемне һич белмим. Әллә нәрсә булды шунда!

— Шул-шул, сизмичә дә калынды. Пехота чигенеп чаба иде, шул дулкын безне дә йомычка урынына алып киткән, күрәсең...

— Тфү!— дип, Петя бөтен йөрәге белән үз-үзенә рәнҗегән кебек әйтте.

Мөслимов боларның бик зур бәлагә эләгүләрен дымык сөйләшүләреннән, иелгән баш һәм төшкән җилкәләреннән чамалый башлаган иде. Һаман аларга сораулы карашын төбәп торды. Ахырда старшина шуны сизеп, бер-ике сүз белән сөйләп бирүне тиеш тапты. Эш болай булган: һөҗүм вакытында, ашыгып, «Катюша» белән ялгыш юлга кереп киткәннәр һәм немецлар арасына барып чыкканнар. Хатаны аңлап кире борылганда, шоферны пуля тиеп үтергән. Карасалар, төрле яктан ата-ата нәрсәдер кычкырып немецлар ябырылалар. Болар машинаны ташлап, кырыйдагы урман эченә кереп киткәннәрен дә гоймыйча калалар. Ә ЭРЭС-ны дошман кулына калдырырга ярамый. Бу хакта махсус приказ бар. Дәүләт сере... Менә хәзер «Катюша»ны немец җыйганчы без барып шартлатырга тиеш...

— Гариф, син гранатаны ничә метрга ата аласың?— дип, иптәше аны бүлдерде. Үзе, сумкасындагы «лимонка»ларны алып, аларга запалны борып бетермичә генә куя да учына кысып карый. Гариф эндәшми, аңа текәлеп тора, чырае бу хакта сөйләштек бит инде дигән сыман. Теге гранаталарны куя да, үзалдына караган килеш, тагы уйга чума.

— Беләсеңме, Гариф,— ди ул, бераздан кинәт уянып киткәндәй,— ни өчен ярканатлар төнлә күрәләр? Әйбергә бәрелмичә очалар? Белмисең. Бу тирән сер? Менә караңгыда күрә торган прибор ясасаң иде, ә?

— Әх, Петя, ничек шушындый минутта бүтән нәрсә турында уйлый аласың?— диде Гариф аңа соклану һәм ярату тавышы белән.

— Минмени, баш үзе шулай уйлый бит.

— Петя, син минем адресны, ничектер хәтереңә сеңдермәдең шикелле,— дип, старшина сәгатенә карап алды.

— Борчылма, Гариф, шикләнмә: Чистай шәһәре, К. Маркс урамы.

— Мин синекен ташка язган кебек истә тотам. Мәскәү, Первая Мещанская, 7.

— Минем ут кебек сеңелем бар, фотосын син бик ошаттың. Әгәр исән калсаң, шуңа өйлән. Башлы кыз ул. Ә синең холкың әйбәт, сабыр. Ишетәсеңме?

— Туктале, Петя, син ничек мине исән калыр дип башыңа китерәсен. Бәлки андый бәхет сиңа төшәр?..

Петя җавап кайтармады, тирән итеп көрсенде генә, тагы түбән карап уйга чумды. Ул эчтән бик мөһим нәрсәгә җавап эзли, әмма һич тә таба алмый, шуңа гаҗиз сыман иде. Гариф ашыга-ашыга сәгатенә карап алды да торып басты. Петя да кузгалды. Гариф иптәшенә таба бер адым атлап, аның җилкәсенә учын куйды.

— Ну, Петя, анда хушлашырга вакыт тимәс, бәхил бул, брат,— диде, ике куллап кочаклап, ике тапкыр битеннән үбеп алды. Петяның зәңгәрсу күзләре мөлдер-мөлдер килде, ул да дустын ике куллап кочты, аркасына суккалый-суккалый үпте.

— Сугыш башыннан ук бергә яшәдек, рәхмәт сиңа, бәхил бул!— дип, кулын ычкындырды да читкә карады. Күзләре яшьләнгәнен яшерергә теләде. Алар сүз әйтергә базмый басып тордылар. Тагы бер сүз ихтыяр-

сыз күз яшьләрен агызып төшерергә тиеш иде, шуңардан куркып, дәшмәделәр. Бер минуттан икесе дә хәрәкәткә килеп, граната тулы сумкаларын җайладылар, кулларына автоматларын тоттылар. Чыгып киткәндә Гариф Мөслимовка таба борылды. Чыраенда ниндидер салкынлык һәм читләшкәнлек, йөзендә сылулыктан килә торган ягымлылык бар иде.

— Безнең «Катюша» моннан биш йөз метрда гына, шартлау тавышы ишетсәң, «Лайне» дигән пароль белән шалтырат. «Лайне»— латышча кояш дигән сүз,— диде, ә үзе Мөслимовның бу гозерне үтәвенә ышанмый иде. Аннары икесе берьюлы диярлек бер кулларын күтәреп саубуллаштылар да, борылып, чыгып киттеләр.

Бик моңсу булып калды, Мөслимовның күңеле тулды. Шушы риясыз егетләр хакында, үзе турында уйлады. Нәрсәдер бик жәл, йөрәген телемтелем итеп кисә, ачыттырып тора. Кемгәдер, нәрсәгәдер булган ачуы ташып чыкты.

Ул гаять зур дикъкать белән шартлау тавышын көтте. Юк, болар хәрәмләшә торган егетләр түгел. Бернинди зарлáнусыз, беркемгә рәнҗемичә, үз антларына турылыклы булып, үлем авызына киттеләр бит. Үз гаепләрен кеше җилкәсенә аудармыйча үзләре йолалар. Нинди акыллы егетләр, үз-үзләренә баш була беләләр, шуңа күрә иң кискен минутта да югалып калмыйча, кирәк эшне башкарып чыгачакларына ышаналар.

Байтак вакыт үтте, әмма шартлау тавышы һаман ишетелмәде. Мөслимов чын күңелдән борчыла башлады. Блиндаждан чыгып, озак-озак алгы сызык ягына карап торды. Инде офык артына сызык кына яктылык җәелгәне сизелә иде. Тынлык. Таң алды вакыты. Сер һәм шом белән тулы. Кинәт ул илаһи тын серлелекне пулемет тавышы ярып үтте. Аның тырылдавы шәрә урманнарга бәрелеп кире кайтарыла һәм әллә ничә корал аткандай ишетелә. Аннары тагы тынлык урнашып тора.

Шулай тың торганда кинәт җир селкенеп куйды, аннары «гөрс!» иткән каты тавыш яңгырады. Мөслимов җиңел сулап: «Шулар бу!»— дип, чиксез сөенде, ләкин икенче яктан, йөрәген нәрсәдер әрнетеп алды. Блиндажга кереп, теге пароль белән шалтыратырга тотынды. Аларның соңгы теләкләрен үтәргә кирәк бит инде. Ләкин берничек тә теләгенә ирешә алмады. Ул пароль белән аңа беркем дә җавап бирмәде. Күчкәннәрдер, диделәр. Тик Мөслимов барыбер өметен өзмәде. Тереме, яралымы килеш алар бирегә барыбер үрмәләп чыгарга тиешләр, дип көтте. Әмма күпме генә көтсә дә егетләр күренмәде...

## 13

...Алар блиндаждан чыктылар. Төн бик караңгы һәм шыксыз иде. Алгы сызык ягыннан аталар, снарядлар ярылган тавыш сискәндереп, тәнне чиркандырып куя.

— Сез йөрмәгез инде,— диде Мирхас, комбатны яратканга күрә бу кызга да хөрмәт белән карап.

— Юк, юк, әйтмә!— дип, кыз үзенең ныклыгын белгертәсе итте. Плащ-палаткасын рәтләп кигән арада Мирхасның күзе караңгыга ияләнеп өлгергән иде инде, кызның чигенмәслеген кыяфәтеннән чамалап алды. Бу риясызлык шактый сәер тоелды аңа. Әмма комбатны эзләү кирәклеге, бар уйларны чигереп, аны эчтән куалап тора иде. Ул, алгы сызык ягына таба борылып, эре-эре атлап барды. Кыз аңардан бер дә калышмый иде.

— Син Идрисовны кай вакытта күрдең?— диде ул, борчуын эчкә яшерсә дә иплəп кенә. Тавышы ничектер йөрәккә ятышлы, аңа хәерхаһ буласы килү сизелә иде.

— Мине ул пушкаларны алга күчерергә дип әйтергә җибәрде. Элемтә өзелгән иде. Без өйләдән соңрак килеп җиттек. Комбатны беркайдан

да таба алмадык...— Мирхас алга иелә биребрәк атлый иде, кызга таба башын борып, шыпырт кына әйтте.

— Ул берүзе генә булмагандыр бит?

— Янында бер солдат булган, яраланган, шул аның алга кузгалган пехота артыннан бер танкка утырып киткәнен күргән, имеш...

— Артиллерия командиры пехотага ияреп алга барырга тиешмени?

— Әйе, без пехотага беркетелгән...

Киеренкелектән сөйләшү өзек-төтек кенә чыга иде. Һәм шулай байтак юл үттеләр. Мирхас уенча, бу тирәләрдә миналар булмаска тиеш иде, ник дисәң, немец яңа чигенгән җирләр. Аннары Мирхас хуторны да читләтебрәк үтүне кирәк тапты. Чөнки анда солдат аягы күп йөри. Идрисов яраланып-нитеп егыла калса, аны тиз күреп алачаклар. Шулай фикер йөртте Мирхас. Үз гоманының нигезле булуын ул кызга да аңлатып барды. Кызның аңа ышаныч белән каравын тели иде.

Ракеталар яктырткannан файдаланып снаряд чокырларын барлап бардылар. Инде озынчы, адашкан пуляларның очуы күбәя. Ракета яктысы да көчәя башлады. Алгы сызыкка якынлаштылар. «Шушы төштән бик нык эзләргә кирәк», диде Мирхас. Берничә җимерелгән танкның очравы өметне тагы да дөрләтеп җибәргән кебек булды. Ракета күккә күтәрелеп яктырткан арада һәр бүлтәймәне шәйләп алалар һәм барып карыйлар иде. Кыз гаҗизләнеп җиргә тезләнде дә, басынкы йөрәк тавышы белән: «Идрисов! Идрисов!»— дип суза-суза ялвара. Аның йөзе шул чаклы тирән газап белән җыерылып, үз эченә төбәлгән, Мирхас кызны җәлләп имәнеп китте. Ул баласын югалткан бәхетсез ана кебек, инәлеп-инәлеп кычкыра иде.

— Идри-сов! Хә-лил!

Әллә шуңа күрә, үзенә янаган куркынычны абайламый да. Мирхас аның якындарак кына мина шартлаганда яки пулялар күпләп очканда да сакланырга онытуын күреп алды. Берсендә Мирхас кызның җиңеннән тартып снаряд чокырына алып төште дә каты гына әйтте: «Бу ахмаклыгыгызны куегыз», диде. «Үлем белән шулай шаяралармыни, тиле!»

Эзләгән саен Мирхас монда йөрүнең мәгънәсезлеген ныграк тоя башлады. Алгы сызыкка да якынайдылар. Куркыныч артканнан-арта бара иде. Элеккеге нейтраль зона булган җирдән яхшылап карарга бушка шикелле тоела иде. Ул кызга якын ук килеп, аны җиргә иелергә кушып җиңеннән тарты да әйтте: «Кире борылыйк, бик куркыныч бит», диде. Фәимә, тыңлап бетермәстән үк, җиңен ярсулы тартып алды.

— Куркасыңмы?— Караңгыда күзләре пыяла кыйпылчыгыдай ялтырап китте.

— Юк. Соң ни бит...

— Мин санбатта яралылардан сораштым, алар да...

— Яралы сүзенә ышансаң...

— Идрисов синең хакта шәп фикердә иде, ялгышкан икән,— диде кыз рәнҗегән сыман.

— Соң өметлерәк җирдән эзләргә кирәк,— дип, Мирхас кызның ачулануына игътибар итмичә җиргә ауды һәм шуның белән бүтән алга бармаячагын белгертте. Нәкъ шул мәлдә якында гына караңгылык эчендә өч-дүрт мина шартлады. Немец миналардан залп биргән иде. Кызны мәгънәсезлектән айнытырга тиеш иде бу. Әмма ату тынуга Фәимә:

— Үзем генә эзлим!— дип сикереп торды.

— Юләрләнмәгез!— диде Мирхас, аның җиңеннән эләктереп.— Комбатның кайда ятканын мин хәзер точно беләм...

— Юк, юк,— дип, кыз алга талпынып куйды.

— Сез ник миңа ышанмыйсыз?— Мирхас каты бәрелергә шикләнеп, фикерен аңлата алмаган гаҗиз тавыш белән гозерләнде.

— Син куркасың...— диде кыз өзеп кенә. Мирхас бермәл ни әйтергә белми аптырап калды. Бүтән берәү шундый сүз әйтсә, җене чыгар иде, әмма кызга ачуы килмәде.

— Мәгънәсезгә нигә йөрергә? Шул куркумыни?— дип, йөрәк ачынуы белән әйтеп куйды. Кыз җиргә тезләнеп утырды да уйга талып торды. Сулышы ешайган, мышылдап чыга иде.

— Мика ул балам кебек якын. Син аңлыйсыңмы шуны!— дип, Мирхаска нык кына төртте һәм еламсырап: — Аңлыйсыңмы?— дип өзгәләнде. Мирхас аны аңламый иде, шулай да кызның чын өзгәләнүе күңеленә барып тиде.

— Хикмәт минем аңлау-аңламауда түгел бит,— диде, ниһаять, ачуы кабарып.— Сез дә хәлне аңлагыз!

— Юк, таш йөрәк син, таш йөрәк,— дип, кыз, тузынып, тагын урыныннан сикереп торды. Мирхас: «Сыер дуласа, аттан яман», дип уйлады. «Моны офицерлар иркәләп үзсүзлеләндереп бетергәннәр икән...»

— Ну, ярар,— диде, чигенеп. Ул торып басты. Белмәссең, замполитка әйтер, «куркак икән», дияр, комбатка да җиткерә белер. Кызның үҗәтлегенә буйсынуын үзенә-үзе шулай нигезләде ул.

Тагы алгарак китеп, эзләнә башладылар. Шунда бер җимерек немец пушкасына юлыктылар. Лафет янында ике үлек ята иде. Кыз мәетләрдән чирканмыйча, курыкмыйча кат-кат карады. Немецлар нигәдер пулеметтан һәм кечкенә миналардан бик еш атарга керештеләр. Мирхас, кызны бер чокырга урнаштырды да, үзе алдарак күренгән карамчыкларны карап килергә китте. Аңа урыннан тайпылмаска кушты. Кыз исә басынкы, йөрәк тавышы белән:

— Идри-сов! Идри-сов!— дип, караңгыга үзенең авазын яңгырата, ялвара иде. Мирхас аны җәлли башлады. «Шул чаклы да бирелеп яратыр икән, бәлки ул Идрисовның хатыны булырга да өлгергәндер. Күп кирәкмени», дип уйлый-уйлый чокырдан-чокырга үрмәләп, кармаштырып, тикшереп йөрде. Әмма бераздан кызның тавыш бирүе тынып калды. «Арыгандыр, бичара, шул тикле өзгәләнүгә соң ничек чыдамак кирәк», дип уйлап, ул кире борылды. «Инде булмады, кайту ягын чамаларга вакыт», диде ул үз-үзенә. «Кызның, билгеле, тәҗрибәсе юк, мондый эштә аның сүзен тыңларга ярамый, харап кына булуың бар», дигән ныклы карарга килде ул. Кызны калдырып киткән чокырны тиз тапты, аның аксылланыбрак беленеп торган гәүдәсен күреп алды.

— Хәзер моннан китәргә кирәк!— диде ул каты гына, кыз янына тезләнде. Кыз дәшмәде. Игътибар беләнрәк караса, нигәдер кызның башы бер яккарак авышып төшкәнен күрде һәм, тәненә кайнар су сипкәндәй, кинәт сискәнеп куйды. «Тукта, нәрсә әле бу? Ә-ә, эһе, йоклап киткән икән ләбаса! Ничек дәшәргә аңа? Әллә әз генә, черем итсенме, тәмам хәлдән тайган, бичара. Юк, уятырга кирәк. «Иптәш сержант, ялыктыгызмыни?»— диде йомшак кына. Ләкин кызда бер хәрәкәт тә сизелмәде. Берни булмагандай, башын җиргә төртебрәк ята бирде ул. Ниндидер зур бәла барлыгын аңлау Мирхасның миенә китереп сукты, чигәсендә нәрсәдер дөп-дөп итеп тора башлады. Үзе дә абайламаган хәрәкәт белән ул кызның башын ике учына алып кысты: «Иптәш сержант! Иптәш сержант!— дип кабатлады. Әмма кызда тере җан әсәре юк иде. Шунда аның бармаклары кыз беретындагы юешне тоеп алды... Юк, Мирхас бу хәлгә һаман ышанмады, беретын салдырып, күпереп торган чәченә бармакларын батырды һәм кинәт барысын да аңлады... Пөгерешкән уйларыннан башы умарта күчедәй гөжли... «Тукта, ничек була соң әле бу?— ди ул үз-үзенә, фикерләрен җайга сала алмыйча.— Миңа сиңа кирәк .булса! Ул хәзер нишләргә тиеш? Шуны хәл итәргә кирәк, әйе, әйе! Аһ, шайтан алгыры, болай каты утырганы юк иде әле. Тафтилов нәрсә әйтер? Аңа ышанмыйча караулары да бар бит... Тукта, миңа хәзер нишләргә? Әллә яктырганчы шушында ятаргамы? Юк. Яктыргач

моннан шәүлә дә үтә алмаячак. Димәк, хәзер үк сызырга! Ләкин ничек? Кызны бит ул бу чокырда калдырып китә алмый. Күмеп калдыру да һич мөмкин түгел. Коры кул белән анда ничек күренерсең!

Озак юанырга ярамый иде. Мирхаска аны һәрчак бәладән коткара торган аек акыл килде. Ул тиз-тиз эшкә кереште. Кызны җилкәгә күтәрү авыр иде, шуңа ул аны плащ-палаткага җайлап төрде. Үзенең бил каешыннан, автомат каешларыннан иңгә эләктерергә элмәк ясады.

Өстерәп ярты чакрым да китә алмагандыр, тәмам хәле бетеп, җиргә ауды, җан ачысы белән үзен-үзе каргады, язмышын каргады, кызны тиргәде. Кап-караңгы төндә, тирә-юнендә миналар шартлый, утлы пулялар башы тирәсендә күч кебек гөҗләп очып тора, ә ул шушы авыр йөк белән япа-ялгызы, бернинди ярдәмчесез, бернинди өметсез. Ләкин гәүдәне тагы җайлабрак төргәндә, Мирхасның кулы ниндидер каты нәрсәгә тиде. Ул кызның кесәсеннән баклашка тартып чыгарды. Анда спирт бар иде. Юк, язмыш аңардан көлми икән әле, аны бөтенләй ташлап бетермәгән икән. Бу сыекча, утлы күмердәй яндырып, бугазыннан төшеп китте. Буыннарына яңа көч тулганын сизү аңа рәхәт иде. Ул тагы яши башлады. Аңа өмет кайтты. «Чынлап та бик уңган кыз булган икән бу», дип, мактап уйлый иде. Идрисовны эзләргә чыкканда иң кирәкле нәрсәне ала белгән бит! Нинди акыллы, зирәк зат булган ул! Ул кабат алга таба атлады. Пулялар очканда, миналар шартлаганда артык сакланмады да. Чөнки монда бар нәрсә очраккa бәйләнгәнен яхшы аңлый иде... Бер артына борылып караганда, кызның тезләре бөкләнеп, эчке күлмәгенең ак челтәре чыкканын күреп алды һәм, чиксез оялып, аны тиз-тиз итәге астына яшереп куйды.

Таң беленеп килгәндә, көчкә-көчкә генә үзләренең батареялары урнашкан урынга кайтып җитеп, җиргә ауды. Җеп өзәр хәле дә калмаган иде. Бер блиндаждан чыгып, каядыр ашыга-ашыга баручы Тафтилов аны күреп алды да янына килде.

— Зәйнуллин, бу синме?— диде.

Мирхасны танырлык түгел иде. Сөйләргә хәле дә юк. Тиргә һәм балчыкка буялып беткән йөзендә аның тере икәнен белгертеп бары күз аклары гына елтырый иде. Шулай бер-берсенә карашып тордылар. Тафтилов ни булганын сүзсез дә аңлады. Башын як-якка чайкады, тәмам аптырап калган иде. Мирхасның карашы: «комбат табылмадымы, ничек?»— дип аңа төбәлгән. Ләкин Тафтилов аның соравын кабул итмәгән йөз белән, кире борылып, якындагы блиндаж ишегеннән кемнәрнедер дәшеп чыгарды. Ике сугышчы килеп чыкты. Болар яңа килгәннәр иде, Мирхас аларны белми иде. Тафтилов сугышчыларга плащ-палаткага төрелгән гәүдәне санбатка илтергә кушты. «Анда күмү командасы бар», диде.

Алар киткәч, Мирхас санын көчкә күтәреп җирдән торды. Шунда үзенең өс-башына күзе төште. Фуфайкасының бөтен җиреннән мамык кисәкләре тузгып чыккан иде, тәмам эт талаган шикелле булган. Моны узгынчы пулялар шулай тишкәләп, ертып бетергәннәр инде... Мирхас, өметсез рәвештә кулын гына селтәп куйды. Нәрсә булса да әйтер, дип, карап торган Тафтиловка да шулай үк кул гына селти алды. Һәм аякларын авырлык белән сөйри-сөйри блиндажга кереп китте...

Инде өйлә җитеп килә иде, сугышчылар кухнядан «аш булды» дигән хәбәр көтеп йөриләр. Ләкин шул чак батарея тылындагы куе урман эчендә бик каты пулеметтан аткан тавышлар ишетелде. Сугышчылар моның немец пулеметы икәнен бик тиз белделәр. Агачлар арасыннан үткән пулялар алар янына ук килеп җитә башлады. Сугышчылар, шаулашып, кайсы окопка төште, кайсы җиргә ауды. Карабиннарына тотындылар. Тафтиловны чакырып чыгардылар. Ул, пулялар очканын күреп, «тревога», дип, команда бирде, коралланырга боерды. Бер траншеягә урнашып, урман ягын күзәтә башлады. «Нәрсә булыр бу тагы?»—

дип, борчылып уйлый иде. Ул арада урманнан ике солдат килеп чыкты. Бик нык жиргә бөгелеп, башларын ике куллап тотып, болай таба йөгерәләр. Пушкаларны һәм сугышчыларны күргәч:

— Немецлар! Анда немецлар! — дип, кычкырырга тотындылар. Үзләре укчылар иде, нәрсәдер эзләнеп, урманга кергәннәр, ахрысы. Алдан килгәне яшел чолгаулы, иске ботинкалы, иске шинельле өлкән яшьтәге җыерчык йөзле солдат окоп алдына килеп ауды. Уң кулының бармаклары гел кан иде.

— Анда ике зур таш йорт бар, шуннан аталар, — диде, тыны-өне бетеп.

— Диверсантлар бугай, — дип өстәде икенчесе. Ул бик тыныч иде, пулялардан куркып жиргә дә ятмады, берни булмагандай, гамьсез генә басып торды. «Кичә чигенә алмый калган фрицлар түгелме», дип фикер йөртте Тафтилов. «Кайчак алар бик исереп йоклыйлар һәм иртән айныгач кына безнең тылда калганлыкларын шәйләп алалар. Еш кына әнә шулай җәнжал куптаралар. Шаккатырлык нәрсә түгел, күргән бар... Ләкин нишләргә? Штабка шалтыратыргамы, әллә үзебез генә барып карыргамы? Күп уйларга вакыт юк, сугышта бик тиз берәр карарга килергә кирәк», дип, сугышчыларга өйрәтүе исенә килде һәм окобыннан күтәрелде. Немец атуын туктатты. Алты-жиде сугышчыны туплап, Тафтилов урманга китте. Бу куркыныч ничектер ымсындыра иде.

Агачлар арасыннан байтак баргач, аксылланып йортлар күренде. Тафтилов атарга әзер булып барырга боерды. Алар йортларга якын ук килделәр, шулчак немецлар ата башладылар. Сугышчылар яттылар һәм тәрәзәләргә төзәп ут яудырдылар. Немец пулеметы астан, каяндыр подвал тәрәзәсеннән ата иде. Ләкин бераздан ату туктады, өстәге тәрәзәдән ак җаймә җилфердәп күренде.

— Биреләләр! — дип кычкырды кайсыдыр һәм, яткан жиреннән торып, алга, ялангa ыргылды. Ләкин шунда ук чабылган сабактай жиргә ауды.

— Провокация! — дип акырып куйды кайсыдыр һәм бик каты кыжрап сүгенде. Шул минутта немецларның эт өргәнгә охшаган тавышлары ишетелде. Алар рупордан нәрсәдер кычкыралар иде. Тафтилов агач артына яткан килеш сугышчыларга күз салды. Берсе дә немецча аңламый. Шулай да кызык: нәрсә әйтәләр икән бу фрицлар. Үзләре якын жибәрмиләр, аталар, нәрсәдер аңлатмакчы булалармы? Нинди әкәмәт бу? Шул, исергәннәрдер дә айнып житмәгәннәрдер, мөгаен...

— Пушкаларны китереп куярга да... — диде кайсыдыр. — Немец бүтән телне аңламый ул.

Тафтиловның уе буталды, бу хәлне ул төрлечә куеп карады. Юк, пушкалар белән маташасы түгел, әнә ак флаг күтәргәннәр, ничек атасың инде. Без атсак, алар да атачак. Нәрсәгә артык кан коярга... Шул мәл немецлар тагы кычкыра башладылар. Безнекеләрдән кемдер автоматын худка жибәреп алды.

— Отставить! — дип кычкырды Тафтилов, агач артында утырган килеш. Ул автоматын култыгына кыскан, йөзендә эре тутлар тагы да күбәйгән, нинди дә булса бер карарга килгән шикелле иде.

— Сержант Каракүз, штабка чап, тәрҗемәче алып кил, — диде Тафтилов каты гына боерып. Теге исә бернечә адымда гына иде, шунда ук каскасын рәтләп киде һәм агач кәүсәсенә ышыкланып кына торып басты. Аннары агачтан-агачка поса-поса китеп барды. Куркыныч беткәч, чабып китте.

Ул озак йөрде, штабны эзләгәндер инде. Немецлар тагы эт өргәнгә охшаган рәвештә кычкырып карадылар, әмма бездән җавап булмагач, тындылар. Кай сугышчылар сүгенеп, кайсы сүз белән батырланып ятты. Берсе исә: «Без шулай инде ул, немец белән тәкәллефләнеп торабыз, тфү!» — дип, бар йөрәгеннән үртәлә иде.

Ниһаять, тәрҗемәче килде. Тәбәнәк кенә буйлы, озын борынлы, ике якка чыгынкы яңаклы, чырае ничектер төлкене хәтерләтә иде. Ул агачлар арасынапоса-поса килде дә Тафтилов кырына барып чүгәләде. Замполит аңа берничә сүз белән хәлне аңлатырга тотынды. Теге йөгерек зиһенле икән, тиз төшенде, булды, дигән мәгънә белән кулын селтәде дә урыныннан кузгалды. Бер агачтан кинәт икенче агач артына алга таба ыргыла иде. Немецлар күзәтеп тора икән, аңа аттылар. Тәрҗемәче бер юан нарат артына басып, учларын авызына куйды да немецларга кычкырды. Тавышы трубкадан чыккандый калын иде. Бер үк сүзләрне берничә мәртәбә кабатлап торды. Бераздан немецлар да телгә килде. Шул арада Тафтилов тәрҗемәче артына барып басты. Ул бары «ахтунг» дигән сүзне генә аңлый иде. Немецларның сүзләре тынгач, тәрҗемәче Тафтиловка таба борылды.

— Биредә бик секретлы радиостанция урнашкан, ди. Без шуны шартлатырга калдырылган кешеләр. Бу бик кыйммәтле техниканы безне исән калдыру бәрабәренә, руслар кулына тапшырыр идек, диләр. Аннары без бары зур начальникка гына биреләбез, дип таләп куялар...

Шул сүзләрне әйткәч, тәрҗемәче Тафтиловка күз сирпеп алды: кыяфәте зур начальникка торырлыкмы, янәсе. Әмма замполитның шинеле бик иске, погоннары ямьшәеп беткән, кай йолдызлары «ите» белән йолкынган иде. Ә немецларга тышкы кыяфәт шәп кирәк, шунсыз кешене дә зур начальник дип белмәячәкләр.

— Кара, ничек сатулашалар, эт еккан нәмәрсәләр!— дип сүгенде Тафтилов.— Бу берәр хәйлә түгелме?

— Шайтан белсен,— диде тәрҗемәче уйга калып.— Немец техниканы күз карасы кебек күрә инде. Анысы бар.

— Аларда хәзер баш кайгысы!— дип, Каракүз дә ачуын белдерде.

— Моннан алгы сызык ерак түгел, контрһөҗүм көтеп, вакытны суздыйлармы?— Тафтилов баядан бирле эчен кырып торган шиген чыгарды.

— Бик ихтимал,— дип куйды тәрҗемәче, ләкин үзе гаять тыныч иде.

— Тизрәк бирелегез, юкса пушкалар белән атабыз, дип әйтеп кара әле!— Тафтилов, бөтен ышаныч синдә, дигән сыман, тәрҗемәчегә төбәлде. Теге учы белән нигәдер авызын-борнын сөртеп алды да, агач артыннан гына немецларга тагы кычкырып алды. Тегеләр җавап кычкырганда, колагын агач кәүсәсеннән алгарак чыгарып тыңлады.

— Юк, бирелмибез, зур начальник килсен диләр,— дип, агачка аркасын куеп, Тафтиловка борылды. Ул тагы Тафтиловның кыяфәтен күздән кичерде. Юк, немецлар моны зур начальник итеп күрә алмаслар, дип уйлады бугай, карашын читкәрәк алды. Тафтиловның йөзендә ашыгу күренеп тора иде, шуны чамалап, тәрҗемәче: «үзем штабка барып, берәрсен алып килим», диде һәм җәлт кенә кузгалып, кызу-кызу атлап китте. Тафтилов тагы пошынып калды. Алгы сызык ягын күзәтте, ракеталар чөймиләрме? Немецларның хәйләсеннән бик күп авыз пешкәне бар... Юк, немецлар тыныч кына көтәләр шикелле...

Ерактан ук агачлар арасыннан Тафтилов тәрҗемәче белән Мостафинның килүен күреп алды. Мостафин Асоевның елкылдап торган кара күн пальтосын кигән иде. «Асоевка бу затлы киемне ординарецы Зангир каяндыр юнәтеп биргән»,— дип сөйлиләр иде. Дивизионда андый пальто бер Асоевта гына. Шулай да Мостафинга да бик киләшә икән. Мостафин бу куркыныч эшкә үзе теләп риза булгандыр инде, югыйсә, бүтәннәрне дә җибәрә алыр иде... Ә кыяфәте чынлап та нык тәэсир итәрлек, итекләре дә ялт-йолт итеп тора, фуражкасының текә маңгаенда әллә нинди нәкышле бизәкләр.

— Нигә алар безгә шарт куялар? Без диктовать итәргә тиеш!— диде Мостафин килеп җитүгә. Тәрҗемәче дә шул юнәлештә немецларга

сүз кушып сөйләшә башлады. Ул рупор алып килгән, шуның аша сиптерә.

— Алар үзләре безгә килергә тиеш!— диде ул, фикерен Тафтиловка да аңлатып. Бераздан тәржемәче Мостафинга таба борылды.

— Совет командиры килсен, без атмыйбыз, диләр.

— Ник үзләре чыкмыйлар?— дип ачуланды Мостафин.

— Чыга алмыйбыз, дип кабатлыйлар.

— Алар ничәү анда?

— Өчәүме-дүртәүме — өзеп кенә әйтмиләр.

— Димәк, араларында бер эсэс бар,— диде Мостафин һәм уйга калып торды. Аның янындагылар да куркыныч артуын сизделәр. «Немецка ышанып булмый инде»,— дип уйлады Тафтилов һәм, Мостафин янына ук килеп, «әллә башта бер-ике солдатны гына җибәреп карыйбызмы»,— дип сүз кушты. Мостафин үз уйларына йомылган, аның сүзләрен ишетмәде дә кебек. Ниндидер бер житезлек белән сугышчылардагы коралларны барларга тотынды. Кул пулеметы булган сугышчыны аерым алып, аны бик җайлы позициягә урнаштырды. Әгәр немецлар ата башласа, ул бик каты ут ачарга, ышыкларга тиеш иде. Тагы хәстәрлек эшләре күргәч, үзе белән барачак сугышчыларны күзәтеп алды.

— Зәйнуллин юкмыни?— диде ул, Тафтиловка төбәлеп. Теге үзенең фамилиясен ишетүгә, агач артыннан килеп чыкты.

— Ну, сержант, тәвәккәлләдекме?— диде Мостафин, гади кешеләрчә Мирхасны тин күреп. Мирхас боек иде, кинәт ачылып китте, «була ул» дигәндәй, дәртләнеп, башын селкеде, автоматын күкрәгенә ипләбрәк кысты. Мостафин тагы бер мәртәбә сугышчыларына карап алды да, беренче булып, агачлар арасыннан яланга атлады. Атармы немец, юкмы? Бөтен тәне, вөҗүде шул ышанычсызлык белән гүли, газаплана иде. Берничә адым киткәч, чирканчык алган кебек булды, тәндәге кабарган вак бөрчекләр бетте. Артына борылып, тагын бер кат сугышчыларга күз төшерде. Менә шушындый куркыныч моментта, пуляга күкрәкне куеп барганда кеше беленә дә инде. Кайсы кеше аркасына ышыклана, адымын юри вак итеп атлый, арткарак кала. Бик әзгә генә. Ул белә: барысын да шушы унбиш сантиметр ара хәл итә. Алдагыга беренче пуля эләгә. Тик унбиш сантиметр ара... Мостафин Тафтиловның кеше ышыгында бармавын һәм барырга теләмәвен күреп сөенде. Үзе турында гына уйламый икән... Ә Мирхас, немец атса, пуля кайданрак киләсен чамалап алып, Мостафин алдынарак чыгып бара иде. Мостафин тыштан берни сиздермәде, әмма эчтән ул егетнең үз-үзен җәлләмәвенә, фидакарь йөрәкле булуына сокланмый кала алмады. Аның турында матур уйлады. «Үз яныма алырга кирәк, әллә кайда мәгънәсезгә әрәм булуы ихтимал. Аннары чинын лейтенант дәрәҗәсенә күтәрергә дә вакыттыр... Моны ничек тә онытмаска иде... Фриц атармы, юкмы? Элек куркыныч минутларда мин болай һич тә уйламый идем. Гел штабта утырып, күнекмәләр чыгып бетеп бара икән бит! Пуляга каршы барган чакта башны каядыр яшерәсе килә иде, хәзер дә ул хис миндә бетмәгән икән әле... Мостафин шунда каска кияргә онытуын абайлап, үкенде, ләкин соң иде инде, аны беркемнән дә алып булмый... Йортның астагы тәрәзәсеннән бер дә күзен алмый барды ул, чөнки шуннан гына атулары мөмкин иде...

Шушы өч йөз метр араны бик озак барган кебек тоелды. Баралар, ә вакыт узмый кебек иде. Ниһаять, килеп җиттеләр. Сөзәк баскыч подвалга төшеп китә икән. Анда тимер ишек. Бераздан ишек шалтырап ачылып китте. Зәңгәрсу мундирлы һәм шундый ук төсле пилотка кигән ике немец солдаты күренде. Тәржемәче алга чыгып, аларга дәште. Сөйләшә башладылар.

— Коралларыгызны ташлагыз!— диде Мостафин каты гына. Немецларның йөзләре куркыну белән тулды, тәржемәчегә төбәлделәр. Теге,

Мостафинның боерыгын аларга җиткергәч, кулларын як-якка җәйделәр: «бездә корал юк», диләр икән. Аннары берсе алгарак чыкты, аңлатырга тотынды.

— Бу — бик секретлы радиостанция. Биредәге приборлар бары да техниканың яңа сүзе. Без шушы станцияне шартлатырга дип калдырылган солдатлар...

— Нигә шартлатмадыгыз?— дип аны бүлдерде тәрҗемәче.

— Шул чаклы кыйммәтле әйберләрне җимерергә кызгандык,— диде немец.

— Әгәр моны исән килеш сезгә тапшырсак, шуның бәрабәренә безне дә исән калдырырсыз, дип уйладык,— диде икенчесе.

Мостафин җирәнеп карады, йөзе чытылды. Бер сүзләренә дә ышанмый иде. Менә ул мең-мең газап китерүче кан коючылар. Нәрсә йөртә аларны? Тамак өчен шулай ерткычланаламы? Юк, аларны идея йөртми, аңардан түбән алар. Тере җан итеп карарга күз карыша. Тыштан адәм затына охшаганнар бит, ләкин күзләре капкынга эләккән бүре күзләре кебек бик тынгысыз һәм чәнечкеле. Сунарчы капкынга эләккән бүрегә ничек карый икән? Кинәнәме? Мостафин үзендә чиркандыра торган хис кенә уянуын тойды.

Беренче немец кулларын бутый-бутый сөйли, ышандырырга тырыша бугай... Биредә өлкәнрәк, ахрысы. Кулларын эчкә таба сузды, керергә әйдәде. Мирхас, песи кебек сак басып, аның артына төште, автоматы тәтесенә бармагын куйган килеш алга атлады.

Подвал караңгырак иде. Озын коридор сузылып китә. Ике яклап бүлмәләр. Бер ишекне ачып керделәр. Карасалар, ухылдый-ухылдый идәндә аягы бәйләп ташланган немец ята. Иптәшләрен күргәч, нәрсәдер ырылдап кычкырырга тотынды. Болар аңа карамадылар да.

— Ул шартлатырга итте, без ирек бирмәдек,— дип, аңлатырга ашыкты өлкәне.— Йоклагач, икәү сүз берләштек тә бәйләп куйдык...

Бүлмәләр аптека кебек пөхтә, ак приборлар бик күп, һәрберсе тәртип белән куелган иде. Ләкин алардан ниндидер шыксызлык, йөрәккә салкын йөгертә торган хәтәр нәрсә бәреп тора иде.

Аннары, өйнең өске катын тикшереп йөрделәр. Анда бүлмәләр буш, идәнендә чүп-чар кәгазьләр, ватык урындыклар аунап ята. Ниндидер штаб булган инде бу.

Кире аска төшкәч, икенче немец: «Теге бәйләнгән фрицны ычкындырыргамы»,— дип, рөхсәт сорагандай итте. Мостафин Тафтиловка карады. «Әйдә, чишсен»,— диде Тафтилов кул ымы белән.

Инде китәргә кирәк иде, Мостафин Тафтиловка күрсәтмәләр бирде. Мин штабка барып, тиешле кешеләрне җибәргәнче солдатларың белән саклап тор, диде. Үзе белән бу немецларны конвойлар өчен өч сугышчыны аласын әйтте. Ул иң әлек Мирхасны күрсәтте, аннан тагы ике солдатны. Мирхас, немецларны бер почмакка аерып алып, өчесен дә тентеде, алардан коралише әйбер табылмагач, ишеккә күрсәтте. Мостафин алдан чыгып бара иде.

Өлкән немец тәрҗемәчегә һаман да бу радиостанциянең әһәмияте, аның яңа техника булуы турында сөйли иде. Дивизия штабына чаклы байтак атларга туры килде. Бары караңгы төшеп килгәндә генә, Мостафин махсус команда туплап, трофейны барларга җибәрә алды. Алар килүгә, Тафтилов үзенекеләр белән кайтып китәргә тиеш иде. Бу группаны теге йортка кадәр Мирхас алып барырга булды.

Дивизия штабы каршында антифишистлар группасы бар иде. Алар безгә кайчандыр әсир төшкән немецлар. Германиянең гаделсез сугыш алып барганлыгын аңлаган, фашизмның кешелеккә бары газап кына китерүен төшенгән немецлар бик тырышып аңлату эшләре алып баралар. Алгы сызыкка радиодан гел чыгыш ясап торалар. Мостафин бу фрицларны шуларга тапшырды. Сөйләшеп киттеләр.

Тагы ниндидер вак-төяк турында сөйләшеп алганнан соң, ул кайтып китте. Төн караңгы иде. Әле генә кичергән күренешләргә капма-каршы буларак, аны Зитта турында уйлар биләп алды. Нишләргә? Ничек аны табарга, күрергә, сөйләшергә? Караңгы төндә эчтән яп-якты, нурлы уйлар белән яктырып кайтты. Аның күнелендә Зитта беркем дә, бернинди газап та томаламый, күмеп китә алмый торган урын били икән бит, дип бер рәхәтлек белән уйлый иде ул...

Ә икенче көнне трофей командасы, немец танкын зур тракторга эләктереп алып киткәндә, окоп төбеннән Идрисов гәүдәсен тартып чыгарды. Ул исән иде, бары сөйләшә генә алмый һәм аяклары йөрми.

## Икенче бүлек

### I

Асфальт юл кырыеннан бер төркем солдатлар үтә. Аларның, госпитальдән чыгып алгы сызыкка баруларын әллә каян чамаларга була. Өсләрендә иске, юылган шинель. Кайсыларының итәгендә, күкрәк турында сабын да ала алмаган кан таплары беленеп тора. Элек шинель иясенең кай төшенә пуля яки ярчык тигәнлеген хатасыз әйтергә мөмкин. Болар төрлесе төрле җирләрдән җыелган кешеләр юл уңаенда бер-берсе белән танышып баралар. Бәлки бер, яисә ике көннән солдат язмышы аларны тагы төрле җиргә таратыр. Шуңа күрә арадан бер сөйләргә яратучысы, башыннан кичкәннәрне сөйләп, юлны кыскарта, икенчесе шаян сүз кыстырып көлдереп ала.

Бераз алдарак солдатларның вакытлы башлыгы — чибәр йөзле, яшь кенә Сөенчалин фамилияле лейтенант һәм кечерәк буйлы, күпереп торган кара чәчле, башына саргылт берет кигән, яшел шинельле бер кыз атлый. Кыз алар төркеменә бүген генә килеп кушылды. Юлдаш кыз очраганга лейтенантның бик кәефе килгән, аңа нәрсәдер әйтә дә елмая, шулай да солдатларын да истән чыгармый. Борыла да:

— Зарипов, артка калмагыз,— дип әйтеп куя. Янында кыз булганга мөгамәләсе йомшаганлыгы тавышыннан ук сизелеп тора.

— Борчылмагыз,— ди аңа старшина Зарипов. Янәсе, читкә сугылучылар булмаячак.

Шунда ук өзелгән сүзне ялгап китә:

— Сез Сталинградта булмагач, белмисез инде, и-и андагы җәһәннәм тәмугын сөйләсәң, кеше ышанмас. Биредәге сугышлар андагы белән чагыштырганда сәхрә генә...

— Ну әйттең — сәхрә!— дип бүлдерде кайсыдыр.

— Юк, ихлас менә! Андагыдай мәхшәрне күзалларга мөмкин түгел...

— Кырылыш каты булган инде! — диде берсе раслагандай һәм Зарипов тагын фикерен куәтләп сөйли башлады.

— ...Кырык икенең көзе иде, ул көз бик коры килде. Без даладан әллә ничә көн поход белән бардык. Шулай бер көнне кичен привалга туктадык. Алдыбызда кып-кызыл булып офык яна иде. Без аны кояш баеый дип уйлаган идек, ә ул Сталинград икән. Донк-донк иткән тонык шартлау авазлары ишетелә. Караңгыда шул ерактагы кызыл ялкын шәүләсе сыек кына булып солдатларның йөзләренә килеп куна, күзләрен ялтыратып куя һәм ниндидер хәтәр шомлылык җилекләргә хәтле үтеп керә. Без вулкан кебек актарылып-актарылып янган менә шул ут эченә барып керергә тиеш...

Ләкин башта Идел аша кичү күпере эшләргә кирәк икән әле. Безгә шундый приказ бирелде. Дөм-караңгыда Иделнең аскы як агымыннан ике катер менде, андагы саперлар озын чылбырлы якорьга бер-

кетелгән буш мичкәләрне су өстенә ике рәт тезеп чыктылар. Без исә юан, озын бүрәнәләрне җилкә белән китереп, шул мичкәләрне аркылыга бастырып куябыз, аннары матчаларга такта тезәбез. Бөтен полк белән төне буе эшләдек, тик күперне теге ярга алып барып җиткерә алмадык. Яктыруга, тәмам хәлдән таеп, яр кырыендагы блиндажларга кереп аудык. Немец самолетлары килеп күперне бомбалавын да ишетмәгәнбез, тик үзебезнең өскә төшерергә тотынгач кына уянып киттек. Бернichә блиндаж бомба балчыгы белән күмелеп калган иде. Тизрәк казып, коткармакчы булабыз. Әмма киемнәрен ерткалап бетергән, битләре тырналып канаган, ишек янына кат-кат булып өелгән үле гәүдәләрне генә таба идек.

Күперне барыбер төзедек. Сталинградка бик күп гаскәр һәм пушкалар чыкты. Безнең часть тә шунда китте, ә мине кичүнең коменданты итеп калдырдылар. Взводымда — сакчылар. Немец бомбага тотса да, күперне ремонтлыйбыз, хәрәкәт өзелеп тормый. Бер төнне бездән алдагы кичүне немец җимергән булган һәм безнең күпергә яралы атлар, дөяләр, арбалар агым белән килеп буылдылар. Нишләргә дә билмибез. Атларның судан өскә ыргыла-ыргыла йөрәк өзгеч кешнәүләренә, дөяләрнең акыруына һич чыдап булырлык түгел. Җитмәсә суны тоткарлап күперне агызулары да мөмкин. Шул чак атларны, дөяләрне автоматтан атып, су төбенә җибәрергә мәҗбүр булдык. Тамакка ашь тыгыла, сөйләшеп булмый. Һәр төнне нинди дә булса бер көтелмәгән хәл килеп чыга. Миңа көндез дә тынгы юк. Йокламаганнан тәмам миңгерәүләндем. Үзем аяк өстендә, үзем йоклап йөрим, аңгы-миңге. Күп нәрсәләргә дикъкатем бетте, ишетмим дә, уйламыйм да. Башым бөтенләй эшләми шикелле. Мине бары өстемә йөкләтелгән бурычны үтәү хәрәкәтләндерә, берәр приказны үти алмаудан курку йөртә. Әнә шул курку көч бирә миңа. Әмма болай бик авыр, тамакка да ашап булмый башлады, бернәрсәнең тәме юк, салам тек салам. «Я тизрәк яраласын иде, я булмаса үтерсен иде,» дип эчтән теләп йөрим. Миңа хәзер бөтен нәрсә барыбер. Бары приказны гына аңлыйм, бүтән нәрсәләрне аңлый да, кабул да итә алмыйм... Йокламаудан да авыр нәрсә юк икән...

Бер төнне кичүгә командирлар киемендә ике-өч кеше килеп туктады. Караңгыга күз ияләнгән инде, шәйләдем,ниндидер частьнең башлыклары. Шлагбаумга таба килүчегә: «Пароль?»— дип кычкырдым. Теге: «Карабин»,— дип җавап бирде. Бу кинәт башыма китереп суккандай тәэсир итте, чөнки килүче парольне дөрес әйтмәде. Әллә диверсантлармы, дип бик нык шикләнеп калдым.

— Ач!— диде берсе приказ биргән кебек.

— Юк, тукта! Пароль алай түгел! Рөхсәт итмим!— дип кычкырдым мин һәм шлагбаумга таба арт белән чигенәм, ә кулым үзеннән-үзе кабурадан пистолетны тартып чыгарды.

— Безгә частьне ярты төнгә чаклы теге якка чыгарырга боерык бирелгән,— диде берсе һәм кискен кыяфәттә миңа таба атлады.

— Юк, пароль?!— дип тагы да катырак итеп кычкырдым.

— Отставить!— диде икенчесе мичкәдән чыккан бас тавыш белән һәм башы белән ымлады. Шунда ук артымнан килеп кулымнан тоттылар, көчле матрослар, буйлы тельняшкаларыннан шәйләдем.

— Блиндажга кертеп бикләгез!— дип, юан тавыш кулын селкеде. Мин кычкырам, «башбаштаклык өчен җавап бирерсез», дип, әле болайга, әле тегеләйгә ыргылам, ычкынмакчы булам. Әмма кулларны тимер кебек каты кысканнар. Бер блиндажга кертеп ыргыттылар, ишекне тыштан терәтеп, сак куйдылар. Шунда гына «әллә парольне үзем ялгыштыммы», дип нык баш вата башладым, ми буразналарым буйлап кабат «сөреп» чыккандай иттем. Һәм икенче минутта кинәт аркамны пешереп кайнар елдырым узды, маңгаемнан салкын тир агарга тотынды: үзем ялгышканмын икән! «Нәрсә булыр, нәрсә булыр, нишләдем мин?»— дия-дия, башымны ике кул белән учлап, идәнгә аудым... Шуннан соң берни белмим,

йоклап киткәнмен... Күпме шулай ятылгандыр, әйтә алмыйм, бервакыт блиндаж селкенүгә һәм битемә салкын балчык кисәкләре төшүгә уянып китсәм, мәхшәр — бөтен тирәне немец самолетлары бомбага тота... Шунда ук бик каты шартлау колакны тондырды һәм ишек тактасы каерылып төшкәне күренде, аннан яктылык кереп күземә бәрелде. Яктырып килә икән инде. Мин тышка ыргылдым, траншеяга ауган часовой матросның буй-буй тельняшкасы гына күземә чагылып калды. Тегенең мылтыгын табып култыкка кыстым, тизрәк күпергә таба чабам. Барган шәпкә ук чамаладым: атлар, арбалар, солдатлар күпергә кереп тулгач кына, немец самолетлары бомба ташларга тотынганнар.

Су өсте яралы сугышчылар, атлар һәм якореннән өзелгән буш мичкәләр белән тулган. Атларның һава ярып кешнәгәне, солдатларның: «коткарыгыз!»— дип өзгәләнгәне колакны яра. Әллә шул коточкыч күренештән минем колакка шулай тоеламы? Белмим. Әмма бомбаларын ташлап бетергән немец самолетлары сиреналарын яман кычкыртып һаман баш очында пикировать итәләр иде. Ни өчен шулай эшли? Куркытыр өчен генә. Аның сере шунда: кешене бер куркытсаң, аны җиңү җиңелләшә. Очрашканда инде ул синә куркып карый, ягъни рухи көчен бераз югалткан була. Әнә немец, паразит, ничек эш итә! Ерткыч түгел диген син аны!

Мин күпергә җиткәндә, немец самолетлары киткән, берсен безнең зенитчиклар яндырган, теге як ярдан кап-кара төтен күтәрелә иде. Шунда кемдер миңа кычкырды:

— Кая монда комендант?— ди һәм аты-юлы белән сүгенә бу. Борылып карасам, алдымда ниндидер полковник тора. Тегенең каршына атылып бардым да кулымны козырекка куеп:

— Мин комендант,— дидем һәм йөзенә карадым. Аның киңчә чыраенда шул чаклы ачу тупланган иде, минем тез буыннарым шунда ук бушап китте.

— Кем полкны кичүгә кертте?— дип, тагы ике-өч катлы итеп сүгенә башлады, авызыннан төкерекләре чәчелә иде. Мин төнге хәлне аңлата башлаган идем, ул, тыңларга теләмичә, куйын селтәде, һәм мин шунда гына аның янында автомат тоткан берничә матросны күреп алдым.

— Кулга алырга һәм трибуналга тапшырырга!— диде полковник, миңа карарга да теләмичә, кулын һавага күтәреп кискен генә төшерде дә блиндажларга таба атлады.

Мине тагын тоткын итеп алып киттеләр. Бераз баргач, кинәт туктап калдым һәм кычкырып җибәрдем: бер блиндаж янында төнлә мине яптырган командирның берсе үлеп ята. «Менә кем гаепле!»— дип, акырган булдым, ләкин мине беркем дә тыңламый иде, часовой: «Атла!»— диде һәм штыгын җилкәмә тидереп алды.

«Беттем!»— дип уйладым, башым урталай ярылган кебек булды. «Бетүем шушы ахрысы!» — дип уйлый башымның бер яртысы, әллә каян өмет күтәрелә дә: «Юк!»— дип тагын аваз сала.

Тикшерү ике көн барды. «Парольне онытып, син күпер аша үтүне тоткарлагансың, шуңа күрә частьләр бомбежкага эләккән»,— дип китереп кыстылар. Ә ничек киресен исбат итәсең? Гаебем бар — факт. «Биш елга ирегеннән мәхрүм итәргә» дип хөкем чыгардылар да бер зур землянкага китереп яптылар. Анда минем кебек кискен хәл капкынына эләккәннәр бар иде. Бер-ике сүз белән белешеп алалар да үз эчләренә бикләнәләр. Һәркемнең үзенеке көчле.

Бервакыт кинәт: «Зарипов!»— дигән тавышка сискәнеп киттем. Төн яктырып бара икән инде, мине алырга конвой килгән иде. Кулларым-аякларым дер-дер килә, көчкә ишеккә барып җиттем. Шунда ук үз-үземне

кулга алып, тирән итеп көрсендем дә бусаганы атладым. Конвой миңа кая юнәлергә кирәген: «сулга, уңга, турыга», дигән сүзләр белән арттан әйтеп бара. Тиз-тиз атлыйм. «Бу газап тизрәк бетсен»,— дим эчтән, ашыгам. Конвой мине ике яклап блиндажлар тезелеп киткән урамнан алып бара башлады. Кай блиндажның ишеге өстенә төрле төстәге уннлаган телефон чыбыклары килеп кергән. «Болары штаблардыр инде»,— дип уйлап куям. Алда ниндидер саргылт полоса күренде. Ныклабрак карасам, урман икән. Күз үтеп баруга карамастан, нигәдер агачлар яфракларын коймаган, имәнлек бугай, имәннең шулай яфраклары соң коела... Кинәт зиһенемә ток китереп суккандай булды: «димәк, шул урманга алып барып...» дигән уй пычак йөзе ышкылгандай кисеп узды мине... Әле урманга җиткәнче байтак бар. Урманга кергәч, «конвойны сугып егарга да качарга һәм Сталинградка чыгып, бер частька кушылырга», дип мине эчтән ниндидер иблис котырта башлады шунда. Уйларым яшен тизлеге белән йөгерешә. Әйе, иң элек менә болай итәм: туктап, конвойның штык белән җилкәгә төрткәнен көтеп торам һәм ялт кына борылып мылтыгына ябышам. «Атса шунда ата, төрмә хурлыгыннан котылырмын, пуля тигәнен дә сизми калырмын... Әгәр мылтыгын каерып алмасам, мин аңа атмаячакмын, бары куркытыр өчен генә һавага җибәрермен дә урман эченә шыларммын. Аннары инде мин ничек Сталинградка чыгарга белермен... Димәк, беткән баш беткән...» Ләкин шул мәл команда тавышы ишетелде:

— Стой! Стой!— дип, кемдер кычкыра иде. Безгәме, түгелме? Карасак, бер блиндаж янында ниндидер командир эчке ак күлмәкчән көе юынып маташа, ординарецы аңа котелоктан су салып тора иде. Мин моның кыяфәтеннән кичә трибуналдагы майор икәнен танып алдым. Ул, кулын болгап, үзенә таба килергә кушты. Үзе ординарецы җилкәсендәге ак сөлгене алып, тиз-тиз битен, кулларын сөртә башлады. Аннары ординарецы аңа кителен сузды. Без килеп җиткәндә, ул тулы формада иде.

— Син нинди милләттән?— дип, миңа таба борылды ул. Мин аптырап калдым, «кичә минем кәгазьләрне күргәндер бит инде, әллә берәр ялганымны тотар өчен сорыймы», дигән уй башымда чагылып китте.

— Татар,— дидем мин, майорның йөзеннән нәрсәдер эзләп.— Казан татары.

— Ышанычлы халык!— дип, ул ботындагы планшетына үрелде һәм, аны шыртлатып, тез өстенә куйды. Конвой сузган кәгазьне алды да, тезенә куеп, нидер язды.

— Фәлән ротага взвод командиры булып барырсың, ризамы?

— Бик рәхәтләнеп!— дидем кинәт җанланып. Шунда капылт кына күк капусы ачылгандай күз алларым ятырып китте. Шул моменттагы бәхетемне белсәгез иде! Конвойны кочаклап үбәсем килә. Майорга рәхмәт тә әйтергә онытканмын. Аякларымның җиргә тигәнен дә сизмим...

Конвой мине шул саргылт урманга таба алып китте. Урман дигәнем урман түгел, ә саргылт салам түбәле землянкалар булып чыкты. Әйткән ротаның блиндажлары шунда икән, аннары Сталинградка баргач, ну, немецларның иманнарын кикерттек инде...

Зарипов, «барыбер аңламассыз» дигән мәгънә белән кулын селтәп, тынып калды. Арада күпне күргәнрәк солдатлар аның погонына күз төшергәләп алдылар. Элек лейтенант булган, хәзер сержант кына. Ә бит сөйләве буенча, командир итеп җибәргәндә, аның чинын төшермәгәннәр. Димәк, шуннан соң тагы ниндидер бәлаләргә юлыккан һәм алардан болай гына котыла алмаган, шактый кыйбат түләргә туры килгән ахрысы, әмма бу хакта сүз кузгатып төпченү ничектер уңайсыз иде. Зариповның көмеш куна башлаган чигә чәчләрендә, яшенә караганда

бик нык картайган чыраенда ниндидер кызгану кузгата торган чалымнар бар иде. Шулар ниндидер хөрмәт уята. Бу кеше беткәнче риясыздыр. Үзенә тиешлене бер дә кеше җилкәсенә салмыйдыр, бүтән хәйләкәр риялылар үз йөкләрен аңа такканда да Зарипов һич авырсынмый күтәрәдер...

Көн кичкә авышып бара иде инде. Солдатлар төн куну турында кайгыртып сөйләнә башладылар. Зарипов адымын тизләтә-тизләтә алгарак элдерде. Аннары шактый гына йөгерде, тик шулай да лейтенант белән кызны көчкә куып җитте. Зарипов әйткәч, лейтенант сәгатенә күз төшереп алды да шунда ук күнде. Әйе, вакыт икән инде... Юлдан читтәрәк күренгән утарларны күзәткәләргә тотынды. «Якын-тирәдәгеләрендә рәт булмастыр,»— диде Зарипов, кызгылт чирәп түбәләргә ымлап. Чистарткаңнардыр, эчкәрәк керергә кирәк... Лейтенантның кәефе әйбәт иде, бу фикер белән ризалашып ияген какты.

Бераз исәп корып алганнан соң, сул якка борылып, камыллы басуга кереп киттеләр. Биредә ызаннар да ызаннар, шунда үскән үлән сабаклары басуны тәбәнәк рәшәткә белән уратып алган кебек итәләр. Урманнар да шулай кишәрлекләп бүленгән, бер ягыннан икенче ягы күренә. Шундый урманнарны үткәч, урылмаган бодай җиренә килеп чыктылар. Ярлы көлсу төстәге туфракта бодай бик сыек, башлары да бик вак, буйга да тәбәнәк иде. «Эх, ипи әрәм була,» дип уйларга өлгермәделәр, җирнең теге башында атлы кеше күренде. Ул кечкенә генә жатка белән бодайны урдырып маташа икән. Жатканың әвернәләре кулларын болгый-болгый каршыга килгән озын бер кеше шикелле иде. Менә ул килеп җитте, жаткада бер өлкән генә латыш бөкшәеп утырган, бар дикъкате чабылган учмага төбәлгән. Учма шактый җыелгач, утыргычы кырыендагы ниндидер сапны этеп куя һәм әвернә жаткадан учманы сыпырып төшерә. Солдатлар: «Алла ярдәм бирсен!» дигән булдылар, әмма латыш аларның сүзен ишетмәде һәм күз дә салмый узып китте. Аның бөтен кыяфәте: «туйган инде сез ачәрвахлардан», дигән шикелле иде.

Бәрәңгесе, чөгендере алынган, сөрелгән җирләр буйлап шактый баргаяннан соң, бер урман кырыендагы тыштан төзек күренгән бай хуторга керделәр. Хуҗа, юка гына чырайлы, озын буйлы сары латыш, кочак җәеп каршыламаса да, кире борып чыгармады. Аның сөйләшүеннән укыган кеше икәнлеген чамаларга була иде. Бер дә өркеп, каушап калмады, бер-ике сүзеннән үк үзенең кырыслыгын сиздерде.

Алар туктаган йортка кайтып кергәндә, өстәлдә бер табак әрчеми пешерелгән бәрәңге буларын чыгарып утыра иде. Солдатларның йөзләре ачылган. Лейтенантлар икенче якта җайланганнар икән. Бусы да әйбәт. Лейтенант Сөенчалинның үзен солдатлардан аерымрак тотуын беләләр иде, шуңа күрә үзләре янына дәшмәделәр. Түгәрәкләнеп утырдылар. Кайсыдыр Ляшковны мактарга кереште.

— Сиңа, егет, бу үткерлегең белән начпрод булып эшләргә кирәк.

— Наркомга ярарлык уш бар икән үзендә!

— Ә нигә, баш җитмәстәй эшмени ул?— дип, Зарипов та көлгәндәй итте.

— Сугыш кына бетсен, оҗмахта яшәрбез әле,— диде икенчесе, җитди тонга күчеп, һәм тирән итеп көрсенде.

— Юк, оҗмахны сөймим мин, анда тончыгып үләрдәй күңелсез булачак,— дип, Ляшков тагы сүзне шаянга борды. Зур гына бәрәңге алып әрчергә тотынды.

— Ну, малай, кеше дигән затка оҗмах та ярамый...

— Оҗмахта бәрәңге юк бит,— диде Ляшков.— Ә мин бәрәңге яратам. Бәрәңге булмаса, шайтанымамы оҗмахың?

— Иң мөһиме, анда сугыш булмас, тиле!— дип, кемдер чәйни торган авыз белән каршы төште.

— Юкка өметләнәсең, брат,— диде Зарипов.— Әгәр оҗмахта кешеләр яшәсә, барыбер сугышмыйча чыдамаслар...

— Ник алай дисең? Анда фашистлар булмас, шунлыктан сугыш та чыкмас!

— Юк, ышана алмыйм,— дип, баш селкеде Зарипов.— Һич булмаса оҗмах белән оҗмах сугыша башлар... Кеше дигәнең бик акыллы да һәм бик ахмак та бит ул...

Ул арада әчке бүлмәдән хуҗа үзе чыкты. Биек маңгайдан, озынча йөзле, сары чәчле, аркасы бөкшәебрәк тора иде аның, нәрсәдәндер тәэсирләнгән, күзләрендә кызыксыну, битендә дә җылы сызыклар күренә. Офицерлар белән анда бераз сыйланганга охшый. Ляшковның күңеле шат булып, хуҗаны күрүгә, аңа кружка сузды.

— Җиббәр, без сине блат белән колхозга беренче яздырырбыз,— дип шукланды Ляшков. Хуҗа елмайгандай итте, кружканы алып, ике-өч тапкыр йотты да кире борды. Закусканы да капмады, кулын селкеде, авызына учын куеп, тамагын гына кыргалады.

— Мин колхозны теләп көтеп торам,— диде җитди тавыш белән. Солдатлар аңа ышанмыйча карашларын чекрәйттеләр.

— Чын менә! Чөнки җиремне эшкәртер кешем юк, әрәм булып кына ята!— Ул ышандырырлык итеп әйтә иде.

— Колхозның шул ягы шәп шул аның!— диде Зарипов.— Бер тәмен белеп алсагыз әле...

— Белмим, биредә ничек төзерләр ул колхозны,— диде кайсыдыр.

— Анысы хак,— диде хуҗа, аннары теге бүлмәгә таба ымлады, янәсе, «анда да кунакларым утыра» һәм, бер кулын күкрәгенә куеп, рәхмәтен белдерде дә, күрше бүлмәгә кереп китте. Аның бу хакта сүз куертасы килмәгәнлеге сизелә иде.

Лейтенантлар кечкенә кухня өстәлендә хәзинәдә бары белән сыйланып утыралар, плитәдә чәйнек чыжылдый... хуҗа иң элек шуны караштырды. Аннары мич буендагы урындыкка аякларын чалыштырып утырды да үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Кеше һәркөнне нинди дә булса яңалык белә,— дип, авыр итеп бер көрсенде. Биек маңгаенда җыерчыклар, ниндидер фикергә төбәлеп, гармун күрегедәй җыерылып килде. Өстәл янындагылар аны аңламаган кебек карап алдылар. Хуҗа сүзен дәвам итте:

— Шуңа күрә әйтәләр: кеше һәрвакыт караңгыдан яктыга бара, диләр.

Юлчылар дәшмәделәр, хуҗаның сүзләрен миләрендә әйләндерәләр иде шикелле, йөзләренә шул чыккан. Бераздан Сөенчалин, селедкасын ашап бетереп, кулларын газетага сөртергә торды.

— Фәлсәфәңнең төбе тишегрәк, бабай,— диде.— Без алгы сызыкка — караңгыга таба барабыз.

— Юк, чибәр егет, барыбер яктыга...— дип, хуҗа капкачын шалтырата башлаган чәйнеккә иелде. Сөенчалинның кыяфәтендә картның сүзләрен чынга алмау, бары әдәп өчен генә тыңлау сизелә иде. Капчыгыннан бер төргәк чәй алып хуҗага сузды. Теге бердән яктырып китеп, канәгатьләнүдән кулларын угалап, чәйне мул гына итеп чәйнеккә салды, уттан алып куйды. Шкафтан стаканнар китерде. Үзе һаман нәрсәдер әйтер сыман иде. Шул арада чәй дә пеште. Сирәк очрый торган һинд чәе икән, хуш ис бөркелде, стаканнарга чия суыдай кызгылт чәй тулды. Шикәр бар иде, өчәүләп чәйнең рәхәтен тоеп эчә башладылар.

— Әх, күңелләр күтәрелеп китте,— дип, хуҗа чәйне мактады. Ул бая лейтенантка каршы төшүен йомшартырга теләгәндәй, яраргa тырыша, ләкин моның әмәлен таба алмый гасабилана сыман иде. Ниндидер

эчке уйларын кире каккандай, учы белән тезенә суккалап ала. Ахырда чыдамады:

— Кешенең юлы караңгыдан яктыга бара дип, шуның өчен әйтәләр иптәш лейтенант,— диде.— Чөнки кешеләр бер-берсеннән сәясәт һәм нәфес нәтиҗәсендә аерылганнар. Кеше кешегә таба юл ярырга мәҗбүр. Үзендәге нәфсене, гуҗлыкны җинеп,— яхшы кешегә таба омтыла ул. Ә тормышта яхшы кешегә очрасаң, караңгыдан яктыга килеп чыккан кебек буласың...— Хуҗа чәен уртлап алды да тынып калды. «мине аңларга теләмиләр, түбәнсетеп карыйлар,» дигән кимсенү бар иде йөзендә. Сөенчалин хуҗаның күңеле төшкәнлеген абайлап, тагы шаяртырга теләде.

— Һай, бабай, бик акыллы сүз әйттегез бит әле,— дип, үзләренә килеп кушылган теге кызга күз кысты, чырае мутланды.— Менә бүген иртән бу кызны очраткач, күңелемдә кояш чыккан кебек булды, валлаһи!

Кыз ашаганда түшенә куеп торган ак кулъяулыгын сыпыргалады, аларга карамаска тырышты, ул лейтенантның сүзләренә бөтенләй әһәмият бирмәде, аңа бу сүзләр каз өстенә коелган яңгыр тамчылары кебек кенә иде. Аның кыз белән генә сөйләшәсе килә иде. Әмма карт торып өстәл өстен җыештыра башлады, кыз аңа бик теләп булышырга тотынды. Мич арасындагы юынгыч янында савыт-сабаны, стаканнарны учактан көл алып чистартып юды, аннары бик әйбәтләп шкафка тезде. Лейтенант кыз белән аулакта калу җаен эзләп, бүлмәләрне караштырып йөрде. Кыз исә бая якында гына госпиталь урнашканын чамалап алган иде, төн кунарга шунда барырга булды. Лейтенант эчкәре бер бүлмәгә кереп яткан арада, ул өйдән чыкты, ачык болдыр баскычларында солдатлар тәмәке тартып, тел чарлап утыралар икән. Кыз баскычтан төшеп килгәндә, Ляшков аның каршына торып басты.

— Безне ташлап китәсезмени?— дигән булды, үзенең авызы колакка җиткән.

— Әйе, күз яшеңне сөртергә кулъяулык бирим ме?— Кыз аның шаяруына шаяру белән җавап кайтарды, солдатлар көлешеп куйдылар. Кыз да елмайды, ләкин Ляшков югалып калмады.

— Сез үзегез дә, әнә медальләрегез дә минем өчен табышмак,— дип, кызу-кызу сөйләнде.— Шул медальләрегезнең нинди батырлык өчен бирелгәнен әйтеп бирә алмассызмы?

— Үзегездә булгач сөйләшербез,— диде кыз һәм кулын селтәп китеп барды. Аның кул селтәве, аяк атлаулары шул тикле ягымлы иде, беркем дә көләргә базмады, ничектер эчтән тынып калды. Ни тапкыр Ляшков та сүз таба алмады.

Кызның киткәнен белгәч, Сөенчалин да моңаеп калды, күңелендә үз-үзеннән каңгатьсез хисләр баш калкыта иде.

— «Нинди кеше бу?» — дип уйлады Сөенчалин карт турында.— «Мине ничек тә төп башына утыртмакчы буламы? Нәрсәгә ирешергә тели ул? Солдафонлыкта гаепләргә җыенамы? Немецлар безнең турыда «варварлар», дип гайбәт саталар, шулмы аның аңына сеңеп калган?»

— Тыңлагыз,— дип дәвам итте карт сүзен, берни булмагандай.— Шушы елның маенда мин урманнан яралы бер очучыны табып алып кайттым. Ионов фамилияле рус иде. Өч ай яшереп тәрбияләдем...— Карт сөйләүдән туктады, ул Сөенчалинның ышанмаган карашын тойган иде. Шунда ук каядыр мич астына үрелде, аннан бер планшет алып лейтенантка сузды.— Менә карагыз!..

Сөенчалин кәгазьләрне эчке шик белән караштырырга мәҗбүр булды. Укыган саен шиге кими барды. Ионов Кенигсберг шәһәрен бомбага тотарга барган, әмма кире кайтканда зениткага эләгеп яраланган, ә диңгездән исә торган көчле җил аның парашютын фронт сызыгыннан бик еракка алып киткән... Летчик: «Совет органнарына бирерсең»,— дип язып калдырган язуында картны «чын кеше», дип атаган. «Мине үлем-

нән коткарды, мин аңа мәңге бурычлымын», дигән... Сөенчалин, очучының эш бланкаларына язылган саннарны, номерларны чагыштырып, хата эзләде. Әмма һәр нәрсәнең очы-очка ялгана, фальшь юк шикелле иде. Шуннан соң Сөенчалин картка тагы бер мәртәбә сыный төшеп карады.

— Нигә фрицларга барып әйтмәдең? Бүләк алган булыр идең.

— Латышлар кеше сатмыйлар, иптәш лейтенант.

— Хәзер кайда соң ул?

— Бер көнне кинәт кенә юкка чыкты. Тазарып җиткән иде инде. Үзенекеләргә китте, ахрысы. Юк, немецларга эләксә, мине дә тартырлар иде, болай калдыралармы соң?

— Рәхмәт, бабай, рәхмәт,— дигәнен Сөенчалин сизми дә калды, картның тәрбия алган итагатьле кеше булуына шушы минутта гына ышанды.

— Һи, башта ачуланган идегез, хәзер рәхмәт әйтәсез!— дип, хуҗа кеткелдәп куйды. Аңарда нииндидер усал шатлык һәм үзен өстен итеп тою бөтен кыяфәтенә чыккан иде. Сөенчалин да кушылып көлде дә бетерде. Ул бик арыган иде, картка шуны ым белән белгертте, башын ия төшеп, сый өчен рәхмәт әйтүен сиздерде, аннары икенче бүлмәгә чыгып китте. Почмакта каты диван сыманрак бер урын бар иде, чишенми-нитми генә шунда сузылды.

Ярты төн авышып барганда, пыяла зыңгылдаганга ул кинәт уянып китте. Кай җирнедер бомбага тоталар иде, шуның тонык тавышы ишетелде, өй ревматизмлы тез буынындай шыгырдап куйды. Аннары — тынлык. Ләкин Сөенчалин, күпме тырышса да, кабат йоклап китә алмады. Башына килгән төрле уйлар арасыннан кичәге әңгәмә калкып чыкты, аннан соң әтисе күз алдына килеп басты. Ул районның җәмәгать эшеннән кайтып кермәс иде. Дөньяны тигезләмәкче булып чапты. Колхозга баргач, күпме тапкыр аны кулаклар кыйнап кайтардылар! Бервакыт авылга колхоз оештыру эше буенча уполномоченный булып киткән иде, кайтмады. Өч көннән соң иртән тарантас җиккән атын капка төбендә күреп алдылар, үзе юк иде. Камышлы милиционерлары ике көн, ике төн эзләделәр, тапмадылар. Шул авылның бер кулагын тотып бик каты кыскач әйткән: уполномоченныйны капчыкка салып тирән яр астына ташлаганнар. Табышлы да, исән калышлы да түгел. Ярый кесәсендә пәке булган...

Әйләнеп кайтканда бите кәгазьдәй агарган, сакалы җиткән иде. Үзе беркемгә дикъкать итми, ләм-мим, бары чәй эчә дә чәй эчә, аннары урынына барып ята. Әби кинәше белән әни аның яра тулы тәненә бурсык мае сылады, үләннәр кайнатып эчерде.

Терелгәч тә һаман шул РИКта эшләде. Иң инициативалы, нык куллы активист булып, абруе бик зур иде. Үзе өчен түгел, эш өчен яна иде, үз тормышын кайгыртуны коммунистка тап төшерә торган нәрсә дип карады. Шул мәсьәлә нигезендә әни белән икесе арасында сүз дә булгалады. Әби дә: «үз гамәлен кайгыртмаган кеше — уңмаган зат», дип тәнкыйть сүзләрен кыстыргалый. Йорт хуҗасы кеше барысын да колагы яныннан уздырып җибәрә. Сүз кайтарып тормый. Кулын селти дә бетерә: янәсе, «сез нәрсә аңлыйсыз?»Шуңа күрә аның өйдә абруе һич калмады.«Кеше өчен кояш чыгарып йөрисең, үзеңә берни юк, тагы капчыкка салырлар әле», дип әни дә мыгырдана. Әти җавап урынына үзенең китапларына тотына. Өйдә ул бик аз сөйләшә, әйтерсең бөтен сүзләрен эштә сарыф итеп бетерә дә — сүзе калмый.

Әбиләре Сөн буенда ук яшиләр иде, Бату җәй көне гел аларда. Анда су коенырга бик шәп, ат йөздерерлек тугайлар күп. Тик су коенуның бер күңелсез ягы була иде. Эш шунда, Бату сөннәткә утыртылмаган, шуңа күрә чалбарын салып суга кергәндә малайлар аны үртәргә тотыналар. Бату бик гарьләнә иде. Шулай әйткән өчен ул бер-ике малайның борын тирәсенә дә менеп төште, әмма үзенә дә каты тондыралар. Бату әбисенә елап кайткалый башлады.

Бер көнне әбисе аның башын күкрәгенә кысты да озак ютатып, юмалап маташты, аннары:

— Сөннәткә утырырга телисеңме?— дип куйды. Бату моның нәрсә икәнен малайлардан ишетеп белә иде, шулай да иркәләнәсе килде.

— Авырттырамы соң?

— Авырттырмый, шөпшә тешләгән кебек кенә була да бетә.

— Ә сине тешләгәне бармы соң?

— Булмый ни, мин аны сизмим дә!

— Авыртыр шул, ә?

— Энә очы тигән сыман була да шундук онытыла.

— Ә минем онытылмаса нишләрмен?

— Нинди егет син шөпшә тешләгәнгә дә чыдамагач?

— Ничек итеп чыдарга соң?

— Тешеңне кыс та бүтән нәрсә турында уйла.

— Әйем лә!

— Ату һаман үчекләрләр бит. Сөннәтләнсәң, үзеңә дә әйбәт булыр, кызлар да күбрәк яратыр.

— Нигә кирәк ул чикылдыклар?

— Егет кешегә дөньяда кирәкмәс нәрсә юк,— дип сөйләнде әбисе.

«Малаен сөннәткә утырткан», дигән сүз этисе эшләгән җиргә барып ишетелгән иде. Анда аны гүя көтеп кенә торганнар, шунда ук элеп алып, тикшерә башлаганнар. Очкын төшкән күмер булса, тырышып өрүчеләр күпләп табыла инде. Әтисен эшеннән алалар. Горур җанлы кешегә шул җитә кала, ул бик каты эчәргә тотына. Бату әле дә хәтерли, гел мунчада исереп ята торган иде. Әнисе, әбисе быжылдый калмаган нардыр, әтисе өйдә бер дә күренмәде. Ә бер иртәне ул үлгән иде...

Батуның аңы этисенең язмышы тәэсирендә формалашты. Чоры шундый, артык бөгеп җибәрә торган булган һәм әтисе белән бергә эшләүче иптәшләре бик тәкъваланып кыланганнар. Әлбәттә, ярарга тырышучылар да табылгандыр. Алар барысы да яхшы эш эшлибез, дип уйлаганнар инде. Соңыннан үзләрен гаепле сизделәрме икән? Әнисе әйтүенчә, бармакларына шырпы кадалган кебек тә булмаган, «ул безгә турысын ярып сала иде, без дә аңа чынын әйттек», дигәннәр. «Без түзә идек, ә ул күтәрә алмаганга без гаепле түгел», дип акланып маташканнар. Батуның аларга каршы нинди дә үче кузгала иде. Бер үк вакытта шул хис аңа һәрчак тәртипле, намуслы булырга һәм яхшылыкка омтылырга этәргеч тә булды. Әтисен рәнҗетүчеләрдән өстен чыгасы килә, «зур дәрәҗәгә ирешеп, күпме тырышсагыз да, дөньяда хаклык җиңә ул», дип әйтәсе килә иде. Иң авыр вакытларда шул хис аңа егәр өсти һәм күңелен «мин сугышта исән калырга тиеш», дигән ышаныч белән тутыра. Ә иң мөһиме — әтисенең хатасын кабатламаска: кешеләргә йомшак, гадел, кимчелекләренә түзем булырга...

Ул йоклап киткәнен сизми дә калды. Иртән торып, коры-сары гына капкалап алгач, юлга җыендылар. Сөенчалинның күңелен нәрсәдер бимазалый иде, тәгаен карарга килә алмыйчарак аптырады, ашыкмыйча гына кырынды, юынды. Ниһаять, чыгып киткәндә, кинәт кенә борылып, карт бүлмәсенә барып керде һәм өстәленә йөзлек кәгазь акча китереп салды. Тегесе «кирәкмәс» дигәнне аңлатып, кулларын болгады, йөзен чытты, ләкин акча өчен сөенгәнлеге күзләрендә очкын булып бии иде. Шуны күрүгә, Сөенчалинның күңелен чәнчеп торган төере бетеп киткәндәй булды, җаны иркенләп сизде. Бу минутта ул картны җиңде. Шул рәхәтне тоя-тоя Сөенчалин солдатлары артыннан йөгерде. «Апага җибәрәсе акча иде, ярар, табылыр әле»,— диде ул һәм аңа җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй җиңел булып китте.

Ул юл кырыеннан барганда, кинәт бер машина килеп туктады. Кабина ишегендә теге кыз күренде.

— Сау бул, лейтенант!— диде кыз.

— Сине кем дип истә калдырыйм инде, ә?— диде Бату елмаеп.
— Хәбирова Рифа,— дип көлде кыз, һәм шунда ишек шапылдап ябылды, машина газ бирде. «Кара, татар кызы булган икән, бер дә белә торган түгел», дип, ничектер үртәлгән кебек уйлап калды Сөенчалин.

## 2

Октябрь бәйрәме уңае белән дивизия частьләрендә хезмәт итүче кызлар слеты булды. Җыелышны зур бер костелда оештырганнар иде. Бу шыксыз, соры төстәге гыйбадәтханә эченә кызлар җыелуы һәр тарафка ямь, нур өстәгән. Алар үзләре дә кырыс солдат киемен бик матур итеп киенгәннәр. Кыяфәтләрендә горурлык һәм көязлек бар. Кайберләренең текә күкрәкләрендә медальләре дә күренә. Аякларында кирза итекләр дә ничектер бик ыспай, елкылдап тора. Бигрәк тә очучы кызлар төскәбиткә тазалар, орден, медальләре дә күбрәк, алар барысы да офицерлар. Госпиталь врачлары, шәфкать туташлары аксыл ягымлы йөзле булулары белән үк күңелдә йомшаклык уяталар. Зенитчы кызлар, элемтәчеләр, снайперлар тыйнак, басынкы тоелалар, аларның күбесе сержант һәм рядовойлар. Киемнәре һәм үз-үзләрен тотышлары чиннарына туры килеп тора. Ә очучы кызлар бик гаярь, ирләрчә булырга тырышалар, һәрбер хәрәкәтләрен ирләргә ошатып эшлиләр, хәтта алардан уздырып та җибәрәләр. Зал уртасындагы юлдан ир-ат офицер узганда күзләре шуңа төбәлсә, ирләрчә шаяртып алалар:
— Натка, ул цель күптән атып алынган, ялгышма,— дип куя берсе.
— Үзе егылган еламас,— ди икенчесе.
— Егылгач, эш уза ул. Компос урынына акылыңны җик.
— Бер төшсәң ул чоңгылга, чыга да алмассың,— дип өсти өченчесе.
— Ә минем ул чоңгылдан чыгасым да килми.
— Аһ, мәхәббәтем — минем һәлакәтем, дип елау романтично!
— Ә нигә, бик рәхәт бит күз яшьләре...
— Кара әле, нишләгән бу, гел кирле-мырлы?
— Штопорга эләккән ул — шуңа кәефе кырылган...
Снайпер кызлар башкачарак сөйләшә, алар һәрвакыт алгы сызыкта, үлем белән көн дә очрашалар, диярлек. Көннәр буе юеш окопта кымшанмыйча яшеренеп ятарга, үткен җәнлек кебек күзне дошманга төбәп, тын да алмый көтәргә кирәк. Монда күбрәк нервы сугышы — кемнең нервысы ныграк — шул җиңә.
— Кызлар, кая безнең Грунябыз?— дип сорады арадан бер кыз.
— Бәй, ишетмәдеңмени, немецның Берлиннан махсус китертелгән снайперы белән дуэльдә һәлак булды.
— Нинди гүзәл кыз иде, әрәм булган!— дип, берсе уфылдап куйды.
— Әйтмә дә инде!
— Гүзәлләрнең гомере кыска була, диләр шул...
— Бер лейтенантны елатып йөртте ул, бәлки шуның күз яше төшкәндер.
— Егетләрнең күз яше кызларга төшми...
— Төшә...
Ул арада залның сәхнә кебек күтәртеп эшләнгән урынына куелган өстәлләр артында президиум урнашканы күренде. Анда зур орденлы очучы кызлар һәм бер генерал бар иде. Җыелыш башланды, бер лейтенантка сүз бирелде. Ул дивизия частьләрендәге кызларның немец фашистларга каршы сугышта күрсәткән батырлыклары турында сөйләргә кереште. Теле бик йөгерек, шома иде. Бер очучы кызның немец самолетына каршы ничек оста көрәшүен һәм мессерны качарга мәҗбүр итүен тасвирлады: аны бу тәвәккәллеккә партия рухландыруын әйтеп, залны кул чаптырды. Аның доклады шундый алкышларга исәплә төзел-

гән иде. Ул бетергәч, кызлар сөйләде. Бер сузан гына буйлы, йөзендә нур балкып торган очучы кыз үзенең батыр дус кызы турында бик күп матур нәрсәләр әйтте. Егетләр белән мөнәсәбәткә керми, әхлагын нык тота, шуңа күрә хәрби заданиеләрне үтәгәндә уңышка ирешә... Без аңардан үрнәк алабыз, оккупантларны бетерми торып, ир-ат халкына әйләнеп тә карамаска ныклы сүз куештык, һәм без үз сүзебездә торачакбыз!.. Аңа да дәртле кул чаптылар. Аның сүзләреннән шул аңлашылды: сугышчанлыкны күтәрә торган иң зур нәрсә, ул да булса, ир-ат белән берниндй дә бәйләнешкә кермәү иде. Әмма икенче бер кыз сүз алып (ул штаб әлемтәсендә иде булса кирәк) үзенең бөтен серен ярып салды. Багырена төшкәндер, ахры. «Без,— диде,— бергә эшли торган сержант белән бер-беребезне яратабыз. Арабызда берниндй исәп-хисап юк. Чиннарыбыз тигез. Юкса кайбер кызлар ялтыравыклы һәм эре йолдызлы погоннарга үреләләр. Өйдә хатыннары булуларына да карап тормыйлар. Бездә андый нәрсә юк. Шулай да безне никахламыйлар. Штабка килдек, полковник Кимбр кырт кисте: «мин поп түгел», диде. Без нишләргә тиеш? Һаман да шушы подпольный мәхәббәтне дәвам иттерергәме?»— дип, кыз сүзен бетерде. Президиумдагы кырган башлы генералның йөзенә ачу сызыклары чыкканы күренде. Моның өчен кемгәдер эләгәчәк, билгеле.

Чыгышлар тәмамлангач, генерал батыр кызларга бүләкләр тапшырды. Биек зал алкышлар белән шаулап торды. Аннары тәнәфес игълан ителде, залдагы урындыкларны бер кырыйга җыйный башладылар. Банкет буласы икән.

Кызлар шау-гөр килеп, төркем-төркем тышка агылды. Костел белән янәшәдә генә зур парк бар иде. Биек чаган, юкә агачларының сары, кызгылт яфраклары сукмакларга төшәлгән. Сирәк күренә торган кояш та бүген җылы нурларын коя. Шуңа көн суык түгел иде. Карасаң, көзнең бу чагы да үзенә күрә матур, моңлы икән. Бу — яңадан очрашу өмете тулы саубуллашу моңы. Ләкин кабат очрашып булырмы-юкмы, инде берничек тә белер хәл юк... Мостафин, искәрмәстән, башына шундый уй килгәнгә пошынып, сукмактан атлый. Ул биредә эш буенча бик кирәкле кешене күрергә дип килгән иде. Һич урынында тотып булмый. Монда да очрата алмады. Шома балык шикелле кулдан шуып ычкына торган кеше булып чыкты... Бу көн янды инде. Нишләргә? Асоевка гына кушасы калган моны, әмма ул кичә «эшем күп, йокы тими», дип зарлангач, үзе алынган иде.

Мостафин кайтып китәргә ниятләнеп мотоциклы янына таба атлады. Шоферы яшь кенә латыш егете Гунар (ул аны машина йөртә һәм карый белгәне өчен үзенә хезмәткә алган иде) ниндидер яшькелт шинельле, артка төйнәгән толымы өстенә кунаклаган пилоткалы бер хатын-кыз белән сөйләшеп тора. «Танышын очратты микәнни?»— дип уйлады Мостафин. Ләкин килеп җитәрәк теге хатын-кыз аңа таба борылды. Һәм Мостафин, шаккатып, баскан урынында туктап калды. Зиттаның чылтап көлүе яңгырады, шул чың Мостафинны исенә китерде. Икенче мәлдә Зитта үзе аның җиңенә килеп тотынды. Бер-беренә төбәлеп, еш-еш сулыш алган хәлдә кеше янында тору уңайсыз иде, Зитта Мостафинны читкәрәк тартты.

— Ничек таптың, Зитта?— дип, өзелә язып сорады Мостафин, аның әле гаҗәпләнүе һаман бетмәгән, сүзләре дә өзек-төтек чыкты. Зиттаның ӧс-башыннан ул аның хезмәткә кергәнлеген аңлады, ләкин сорамады. Хәрби кием аңа килешеп тора, тагы да ягымлылатып җибәргән.

— Күңелем эзләп тапты,— диде Зитта серле генә, аннары «сорама», дигән мәгънәдә кулын селтәп куйды. Ул үзгәргән, битләре тулыланып, сылуланып киткән, әлеккеге үзенә тарта торган битараф-моңлы карашына ниндидер ачыклык, кызыксынучанлык кергән шикелле. Мостафин аңа сокланудан бер сүз әйтә алмый бара. Бөтен җилекләре белән сагынды ул

аны, газапланып бетте, каршылыклы уйлар аның йөрәген пәрә-пәрә кисқәләде. Беренчедән, Зитта белән саубуллашып китә алмавы (ул нигәдер өйдә булмады) аны бик каты пошаманга салды. Киткәндә әйтермен, дип әзерләнгән икесе өчен дә мөһим сүзләре әйтелмичә калды. Мостафинның якын көннәрдә китәсен белеп тә, аның капылт кына югалуы бик күп нәрсәләр юрарга юл ача иде.

«Икенче эшелонга чыккач, мин аны барыбер эзләп табам», дип нык-лы карарга килде һәм шушы көннәрдә мотоцикл белән алар утарына барырга җай эзли иде Мостафин.

— Ничек мине таба алдың, Зитта?

— Йөрәгем тапты...

— Йөрәкне сукыр була, диләр тагы...

— Йөрәгемнең зиһене ачылды, аны син ачтың,— дип, хис белән ярым пышылдап әйтте Зитта.

— Шулай диген, ә үзең мин киткәндә кайда булдың?

— Син әйтмәдең, шуңа кимсендем, миңа ышанмый икән, дип уйладым, әй, ул чагындагы кичерешләремне белсәң...

— Мин дә әллә ниләр уйлап бетердем,— диде Мостафин, Зиттаның күзләренә төбәлеп. Зитта карашын читкә алды, елмайды, әйдә, сөйләсен, дигәндәй, сагаеп бара башлады. Мостафин исә, Зиттадагы үзгәрешнең нинди булуын белергә тырышып, эчтән уйланды. Ул да чын күңелдәнме? Әллә минем белән уйныймы? Менә юләр, тансыклаган бәхетең алдыңа килеп басты, ә син кирле-мырлы уйлыйсың...

— Сине шундый сагындым, әйтерсең, син минем ирем...— дип көлеп әйтте Зитта.

— Чынлапмы?— диде Мостафин. Аның күңелендә, төрле уйлар белән бергә, шатлык фонтан кебек ургый иде. Бу уйлар ансат кына килеп эләккән бәхетне гел үзенеке итәргә, кулдан ычкындырмаска тырышудан туа иде.

— Әллә ышанмыйсың?

— Ышанам, әмма син мине онытырга җай эзли идең.

— Кара әле,— дип, барудан туктап, Мостафинга йөзе белән борылды Зитта. Аның киң каратут маңгаендагы нәзек кара кашлары матур булып җыерылдылар.— Син аны каян сиздең?

Мостафин берни дә сизмәде, бу сүзне бары Зиттаны сынар өчен генә әйтте. Айга якын аерылып торуның һәм алданасы килмәүнең авазы иде бу. Мостафин аны үзе дә белеп бетерми иде.

— Әллә синең кеше уйларын белә торган сәләтең бармы?

Зитта сүзен шулай дәвам иткәч, Мостафин көлеп куйды:

— Әйтәсең бит, яратуның күзләре күп була, дисең.

— Син үзгәргәнсең, Даут,— диде Зитта, бик якын итеп, үз итеп. Мостафинның сынаулы сүзләреннән ниндидер нәтиҗә ясагандай әйтте ул моны.

— Юк, син үзгәргәнсең, ә мин картайганмындыр. Һәрбер һөҗүм безне бер-ике елга картайта.

— Әлек син эчкерсез ышана идең, хәзер алай түгел сыман.

— Әйтәм бит, картайдым, дип,— Мостафин кызның кулын кысты да көлеп җибәрде.— Олыгайган саен кешенең ышанычы сагая бара, ахры.

— Онытырга теләгән идең, дисең. Менә онытмадым, мең бәла белән эзләп таптым.

— Сиңа рәхмәтемнең иге-чиге юк, Зитта,— диде Мостафин.

Алар кире мотоцикл торган якка таба борылдылар. Каршыга төркем-төркем кызлар килә, Мостафин хәзер аларның .берсен дә күрми иде. Үзе Зитта белән сөйләшә, үзе эчтән план корып бара: хәзер үк аны үземә кунакка чакырырга, блиндаж әйбәт, ашарга-эчәргә бар. Тик менә Асоевның күзенә чалынмаска иде. Әллә якындагы берәр утарга барып кунаргамы? Юк, ярамый. Госпитальдәге дус хирургның аерым бүлмәсе

бар, әллә шуңа әлдерергәме? Юк, бу да күңелгә ятмый. Әһә, Идрисовка барырга, аның кузовына тимер мич куелган, студебеккеры ярга казып кертелгән. Бераү дә белми, күрми. Асоевка шуннан шалтыратырмын. Тәк...

Ләкин шул чак узып киткән төркемнән бер кыз аерылып калды да:

— Иптәш комбат?! — дип дәшеп, аларга таба килде. Мостафин аңа текәлеп, зиһенен җыйды. Һәм, бәхеткә каршы, кызны шунда ук таныды, бу аның элекке санинструкторы Хәбирова иде.

— И-и-и, Рифа, бу сезме? — диде аңа кулын сузып. Кыз әллә майор погоннарын күреп уңайсызланды, кызарды, Зиттага да күз салды. Мостафин ике ут арасында калган кебек иде, аның да аксыл йөзенә кызыллык йөгерде һәм ул шушы кыен хәлдән чыгу өчен тиз-тиз сөйләргә тотынды.

— Мине газраил кулыннан йолып алган фәрештә менә шушы инде, — дип, Зиттага карады. — Сөйләгән идем бит. Старшина мине үлгән дип белеп, окопка күммәкче була, ә ул күмдерми, «тылга алып чыгыйк, шунда җирләрбез», ди. Юл буе шулай әрепләшеләр, мин кайчак аңыма килеп, аларның тарткалашуын ишетеп бардым... Ну, ни хәлләр?

— Менә тагы фронтта... — диде Рифа көчкә генә, аның баягы өмете сүнгән, йөзенә ниндидер үпкәләү чыккан иде. Рифа берничә минут эчендә күп нәрсәне тоеп өлгерде: Мостафин янында басып торган кыз аңардан чибәррәк һәм аның якын кешесе булырга тиеш. Аның майор өстеннән власте барлыгы сизелеп тора. Ригая белән елмаеп, Рифага теләктәш-мөлаем караса да, кыз- аны өнәми иде. Чөнки ул күпме айлар җанында иркәләп, йөрәк бәгыре белән яраткан, хыялларын, өметләрен шуның белән бәйләгән кешесенә ия булган бит! Биредә аның юклыгыннан файдаланган, үзе бик затлы күренә, шуның белән алдыргандыр, күзен томалагандыр, билен биетеп, кашларын сикертеп, тәмам сихерләгән, ахрысы...

Рифа Мостафинның сорауларына беркатлы җаваплар биреп торды. Бик кадерле нәрсәсе тартып алынган баланыкыдай, иреннәре турсайган иде. Мостафин да аның кәефе төшкәнлеген сизде һәм сүзне тизрәк бетерү ягын карады:

— Мин сезне эзләп табармын әле, — диде, башын ия төшеп, хушлашты һәм Зиттага таба борылды. «Бу кыз аны тәмам үзенеке иткән икән», — дип уйлады Рифа, йөрәге сыкрый-сыкрый иптәшләре артыннан йөгерде. Мостафин бу очрашудан җанында купкан ниндидер җайсыз тойгыны яшерер өчен елмайды, Зиттаның кулыннан тотты. Кызның күңеле бу минутта ярату хисләре белән тулган иде.

— Әйдә, безгә киттек, — диде Зитта, Мостафин чиксез сөенер дип ышанып. Әмма теге аңа күтәрелеп карады да «чын әйтәсеңме?» — диган төсле елмайды, күзендә моңсулык чаткылары тибрәнде, ул уйлана иде.

— Озак уйлама, юкса кыюлыгың бетә, — дип, аның холкын белгәнлегенә ишарәләп, үзенекен тукыды Зитта. Култыклап алды, теге кыз салып киткән уйларыннан арындырырга теләде. Ничек итеп тиз буласын әйтте: олы юлга чаклы 50 чакрым, аннары бер сәгатьлек ара...

— Минем сиңа әйтәсе сүзем бар, Зитта, — диде Мостафин, шуның белән барысына да риза икәнен белгертеп.

— Минем дә сиңа бик әйтәсе килгән сүзләрем бар.

— Ихласмы, Зитта?

— Мин ике төрле сөйли белмим, сүзләр ялган булса, эшләр дә чын була алмый.

— Син бүген бик серле, Зитта. Мин сине бөтенләй белмим бугай.

Мотоцикл янына килеп туктадылар. Мостафин машинаның кай җирендер җиргә тезләнеп төзәтеп маташучы ординарецына: «Менә бу туташны эшли торган штабына илтеп куярга кирәк», — дип ялганлады. — Мин үзем генә барырмын инде, ә син кайта тор...» — диде.

Зитта бишеккә утырып, алдына брезент ябынды. Трофей мотоцикл өр-яңа иде, өч сәгать дигәндә утарга килеп тә җиттеләр. Таныш ишегалды, баскыч күңелгә якын, ягымлы булып тоелды. Зитта ишекне берничә ачкыч белән ачты, димәк, өйдә кеше юк. Мостафин хуҗаның кайдалыгын сораштырып алды. Ул Митавага анасы янына киткән икән. Коридор буенча барып, Зитта аны үзенең бүлмәсенә алып керде. Тәрәзәсе тыштан ябылган. Күпме тапкыр Мостафин хыялында сурәтләнгән бүлмәдән таныш хушбуй исе килде. Зитта өстәлдәге лампага ут элдерде, кара калай белән төрелгән йомры мичкә утыннар салып ягып җибәрде. Каяндыр саргылт болан тиресе тартып чыгарып, аны да мич алдына җәйде. Учактан төшкән җылы нурлар мех өстендә биюләр. Ирексездән шунда авасы, талгын сынны язасы, ял итәсе килә иде. Мостафин шулай итте дә: шинелен салып, кулларын юып керде һәм мич каршына җылыга сузылды. Зитта бик житез йөренде, мех палас өстенә кәгазьләр җәеп, табын шикелле нәрсә әзерләде. Ак балык, колбаса турады, саплы кастрюльдә кофе кайнатып, сөт салды.

— Сине анда югалтмасларммы?— диде Зитта, яшел чокырларга кофе бүлеп. Ул аны кайгырта иде. Мостафин сәгатенә карап алды, «юк», дигәнне белдереп, кулын селтәде. Болан тиресенең икенче кырыена ул да аякларын сузып утырган иде. Табындагын капкалап, тәмле кофе эчтеләр.

Бер минуттан Мостафин эченең кайнарлануын аерым бер рәхәтлек белән тойды. Юлда бераз өшегән булган икән. Зитта юк-бар шаян сүзләр сөйләп көлде дә көлде, аннары кинәт кенә, эчке уйларына йотылгандай тынып торды да көрсенде:

— Ышанасыңмы, синең белән танышу тормышымны әллә нишләтте. Томан эченнән кинәт кояшлы җиргә килеп чыккан кебек, мин дә нәрсәләрнедер абайлап бетермим кебек... Ышанасыңмы?

— Зитта, син элек болай сөйләнми идең,— дип елмайды Мостафин һәм аның ак кулын бик яратып сыйпап алды. Бу сүзләр йөрәгенә май булып ягыла иде.

— Әйе, мин хәзер уйланам. Әйт әле, сугыш беткәч, нишлисең?

— Хәрбиләр язмыш кулында инде.

— Ә мин?

— Ә син минем янымда буласың. Ризамы?— Мостафин, Зиттаның кулына үрелеп, аны иркәләде, үзе шатланып көлде. Зитта учак утына төбәлеп уйга калган иде. Йөзендә эчке бер каршылыкны җиңә алмау чалымы беленеп китте. Ул, Мостафинның нурлы карашын тоеп, шунда ук башын күтәрде, елмая-елмая тузган чәчләрен рәтләде.

— Шаяртмыйсыңмы?

— Нинди шаяру булуы мөмкин, Зитта?

— Әйе,— диде Зитта, башына килгән фикергә таянып, ниндидер тынычлану тапкан кебек.— Без бер-беребезне бик аз беләбез шул әле.— Ул тагы көрсенде. Мостафин аның кырыена ук килеп ятты, аны иркәләргә тотынды.

— Мин юкта сиңа нәрсәдер булган...

— Берни дә булмады, җаным.— Зитта бармаклары белән Мостафинның чәчләрен сыйпады, иркәләп тарады. Мостафин кызның йомшак, ефәк кебек кулдан шуа торган биленнән алды да үзенә кысты, иреннәре белән кызның йомшак, кайнар иреннәрен үбә башлады. Кызның гәүдәсе тетрәнеп куйды, ә егетнең кулы, иркәләп тә, нәүмизләнеп тә, аның биленә шуыша иде.

— Бәлки кирәк түгелдер?— дип пышылдады кыз, иренен читкәрәк алып.

— Зитта,— диде егет, эчке бер ныклык белән. Бармаклары утлы күмердәй кайнар, ә йөрәгенең тибеше Зиттага да ишетелер шикелле. Кыз ике кулы белән Мостафинның муенын кочарга сузылганда, егет аның гимнастеркасын шудырып салдырды.

— Без бүген я мәңге бергә булабыз, я мәңге аерылабыз,— дип пышылдады Зитта.— Бу безнең кызыл сызык...

— Әйе, әйе,— диде егет, кызның билен тагын да коча төшеп.

— Молодец,— дип шукланды Зитта һәм үзе дә юка оек тасмаларын ычкындыра башлады. Мостафинның колагы берни ишетмәс булды, бу кыштырдау бар тавышларны томалады. Ул каешын көчкә чишеп, пистолеты белән болан тиресенә ташлады. Шунда Зитта кинәт туктап сагайды. Тышкы ишекне бик каты дөбердәтәләр иде. Зитта җәнлек кебек сискәнеп торып басты һәм агарынып тыңлады. Йөзендә шом, шик күренде. Мостафин әле берни дә аңламый иде. Зитта аңарга киенергә ымлады. Үзе дә оекларын киде. Ишеккә лом белән сугалар иде. Мостафин көчкә исенә килә алды.

— Абыең кайтты мәллә?— дип, Зиттага төбәлде, аңардан күзен алмады, күз аклары зур ачылды, гүя моңа кыз гына гаепле, бүтән беркем түгел.

— Юк.

— Әллә солдатлар кунарга фатир эзләп килгәннәрме?

— Белмим,— диде Зитта һәм, шинелен киеп, мәче адымнары белән коридорга чыгып китте. Ишеккә барып тыңлап торды да бүлмәгә атылып кире керде.

— Бандитлар!— дип, ачынып пышылдады. Мостафинның терсәге тырпайды, ул пистолетын тартып чыгарды. Зитта куркынып аның кулына асылынды.

— Юк, юк, ата күрмә! Үзеңә дә атарлар! Юк!

Мостафинга бу фикер тәэсир итте, чынлап та атулары бар, алар күбәү, дигән уй миен кайнарлатты, ләкин моның белән килешәсе килми иде. Зитта бер минут эчендә әйберләрне мич артына куйды, «әйдә, подвалга яшерәм мин сине», дип Мостафинны коридорга алып чыга башлады. Әмма шул минут тышкы ишекнең каерылып чыкканы һәм дагалы итек тавышларының коридорда дөп-дөп килгәне ишетелде. Зитта куркынып Мостафинның иңенә сарылды. Аннары кинәт битендәге курку, каушау бетте, Мостафинны мич артынарак тартты.

— Сүндер утны,— диде Мостафин пышылдап.— Бусагадан атлаучыга атам, минем биш пулям бар!

— Юк, юк, атмыйсың!— дип, Зитта аның пистолетына тотынды.— Әгәр атсаң, икебезне дә үтерәчәкләр. Аларның һәрберсендә шмайсер! Мин үзем сөйләшәм!— Ул мич алдына кадакланган калайның кирпечне каплаган кырыен каерды да пистолетны шунда яшерде. Мостафин капкынга эләккән җәнлектәй талпынды, әле алай, әле болай чайкалды, күзләре ялт-йолт килде.

— Нишлисең син?!— дип, пистолетын алырга итте. Зитта аның җилкәсеннән тотып тынычландырмакчы булды. Бандитларның коридорда ишекләрне лом белән шатырдатып каерып ачып йөргәннәре колакны ярырлык булып ишетелә иде. Менә болар ишегенә дә килереп бәрделәр. Зитта атылып барып ишекне ачты, шунда элеккеге кызылармеец шлемы кигән кызыл сакаллы, зур гәүдәле кеше пәйда булды. Шлемның сары суконына яшел ситсыдан тегелгән йолдыз аермачык булып күренә иде.

— Сезгә кем кирәк?— дип кычкырды Зитта үзләренчә. Тегенең күкрәгенә аскан озын дисклы автоматы кыймылдап куйды һәм, кызны читкә этеп, бүлмәгә немец һәм совет солдаты киемнәреннән киенгән кешеләр керер тулды. Барысында да немец кораллары иде. Зитта кызыл сакалга төбәп, үз телендә тагын нәрсәдер кычкырды. Сакалның эчкә баткан күзләре без шикелле аңа текәлделәр, ияге тартышты һәм шул минутта, ике-өч кеше килеп, Мостафинның кулларын артка каердылар, кыйный башладылар. Зитта чәчрәп барып аларның кулларына ябышты, хәтәр кычкырып нәрсәдер әйтте дә берсенең кулын тешләп алды, иреннәре, авыз

кырыйлары канга буялган иде. Аны тартып алдылар да идәнгә ташладылар.

— Тимәгез аңа!— дип кычкырды Зитта, идәннән торырга азапланып. Мостафин да теге өч бандитка бирешмичә сүгенә, чәбәләнә, тартыша иде. Кызыл сакал үзе барып аның чигәсенә бик каты итеп сукты. Мостафин кинәт аңын җуйды, башы бер якка салынып төште, шул килеш аны идәнгә ыргыттылар. Бая көче җитмәгән бандит хәзер аның касыгына күн итек белән типкәләде. Зитта шунда ташланды, Мостафинның гәүдәсе өстенә ятты.

— Тимәгез, зинһар, ул безнең яклы кеше,— дип кызу-кызу сөйли башлады һәм, үзенең дә айзсорг булуын әйтеп, лифыннан бер кәгазь алды һәм кызыл сакалга сузды. Тагы нәрсәләрдер ялганлады. Сакал кара күн перчаткалы кулын автоматыннан кубарып кәгазьгә тотынды, икенче кырыеннан Зитта тоткан иде. Укыгач, ул кулын ычкындырды. Күзләрендә ниндидер йомшару чаткысы барлыкка килде. Иягең кыймылдатып алды һәм теге бандит Мостафинга итеге белән тибүдән туктады.

— Миен![1]— диде сакал ниндидер яхшылык эшләргә җыенган сыман.— Кызыл офицерны коткарасың килсә, өстәлгә менеп чишен һәм бие!

— Браво!— дип кычкырды ишек катындагы бандит. Өйдә бернинди дә алыр нәрсә булмагач, болай гына чыгып китәргә гадәтләнмәгәнгә, шулай вәхшиләрчә кыланырга уйладылар бугай. Зитта аларны ишетәсе дә килмәде, нәрсәләрдер әйтеп янады, Мостафин гәүдәсе янына тезләнде, аның салкын тир белән юешләнгән битен кулъяулыгы белән сөртергә тотынды, ачыргаланып елый-елый, кызыл сакалның намусына тукына торган сүзләр кычкырды. Аны өстерәп алып бер кырыйдагы өстәлгә менгереп бастырдылар һәм, ике бандит аны шунда тотып торган хәлдә, калган икесе Мостафинның бавырына тибәргә тотындылар. Ул йөрәкне өзәрлек итеп ыңгыраша иде. Зитта ычкынмакчы булып сикерде, ләкин куллар нык тоткан, бары юбкасы гына аерылып төште.

— Туктагыз, үтермәгез!— дип, ялварды ул, кызыл сакалга төбәлеп. Теге ым какты, кыйнаучылар туктадылар. Зиттаның алар тәкъдименә риза булуы күренә иде. Ул үз үлеменнән бигрәк Мостафин өчен курыкты. Бу бит аны тозакка алып килгән кебек булды. Оятыңнан нишләрсең, ничек итеп аның күзләренә карарсың. Барысына да ул гаепле булып чыкты, ә бит алдан мондый хәлнең ихтималлыгы уена да килеп карамады...

— Үтермисезме?!— диде Зитта, ялварган һәм кыю тавыш белән кызыл сакалга иелеп. Ул кызыл сакалны өзгәләп ташларга тырнакларын тырпайткан җәнлеккә ошап калды. Теге исә курыкмаса да ияген кыймылдатты:

— Әйттем бит инде!

Зитта «мәгез, кадалыгыз», дигән хәрәкәт белән ерткаланган юбкасын ычкындырып, аяклары буйлап шудырып төшерде, ак ефәк трусиктан калды, тыгыз ботлары ялтырады. Икенче хәрәкәт белән гимнастеркасын салып ыргытты, толымнары чуалып тузган, күз яшеннән чыланган битенә чәч бөртекләре ябышып беткән иде. Бандитлар тынып калды, Зиттаның каймактай аксыл төз аякларына, сылу гәүдәсенә карап күзләрен тасрайттылар. Аларның күбесе авызларыннан сөт тә кипмәгән яшьләр иде, кызыл сакал ымы аларга закон. Ә тегенең яшьләр алдында үзен батыр итеп күрсәтәсе килә бугай. «Менә нинди тамашалар ясый алам мин», янәсе...

— Бие! Бие!— дип, каты итеп әйтте сакал Зиттага, кыз кымшанмыйча, бөрешеп тора иде, шунда ук ике бандит тагын Мостафинга типкәли башлады. Зитта ихтыярсыздан аякларын кыймылдатты, тегеләр кыйнаудан туктадылар. Кайсыдыр авыз гармуны сыздырып җибәрде, ләкин Зитта хәрәкәтләрен тизләтмәде. Бар кыяфәтенә яшерен зәһәрлек, ачу чыккан иде. Ул аларга үзенең матурлыгын да күрсәтмәде, йөзеннән, тәненнән нур сүнгән, бары чиксез җирәнү һәм үч кенә калды.

[1] Миен — кызым (латыш.)

Сакалның кәефе килеп, батыр кыяфәттә йөренә иде, кинәт тышта мылтыктан аткан тавыш ишетелде. Бандитлар дәррәү кубып ишеккә ябырылдылар. Бер минут эчендә бүлмә бушап калды...

Зитта идәндә ыңгырашкан Мостафин янына барып тезләнде, аның башын күкрәгенә кысып, үкереп елап җибәрде. «Нишләттеләр сине вәхшиләр, тикмәгә кеше үтерәләр бит,»— дип өзгәләнде, күлмәген күтәреп тәнен карады, бар түше күгәреп кара янган иде. Тик Зитта бу минутта бик реаль фикер йөртте: хушбуйлары белән аның битен, тәнен уды. Мич арасына яшерелгән җирдән спирт һәм мамык алып килде. Спиртка манчыган мамык белән тагы битләрен, чигәләрен кат-кат ышкырга тотынды. Бераздан Мостафин тирән итеп сулыш алды һәм кипкән иреннәренә телен тигерде. «Әчәсе килә бичараның»,— дип уйлады Зитта сөенеп һәм, башын җайлап тотып, авызына спирт агызды. Мостафинның тамак асты селкенде, авыздагын йотты, тагы сорагандай, иреннәрен кыймылдатты. Зитта тагы бер йотым йоттырды, аннары тагы... Мостафинның йөзенә җан әкрен керә башлады. Бер сәгатьтән ул күзләрен ачты. Зитта аның өстенә иелде. Мостафинның битен күз яше буразналап бетергән, чәче тузган, ирен кырыенда кан юшкыннары күренә. Ул: «нәрсә булды соң әле миңа», дигәндәй, исен җыеп торды, тик эндәшерлек көче юк иде бугай. Тагы күзләре йомылды.

— Җаным, син исән, син исән!— дип, Зитта аның башын күкрәгенә кысты. Әмма Мостафин, тирән итеп сулыш ала-ала ятса да, күзләрен һаман ача алмый иде. Зитта аңа тагы спирт йоттырырга кереште.

Төн урталары узгач кына Мостафин тәмам һушын җыеп күзләрен ачты. Кыз аның башын күкрәгенә кысып үбә дә үбә иде.

— Зитта, мин барысын сизеп яттым,— диде кабарган иреннәрен көчкә генә кыймылдатып.— Рәхмәт сиңа.

Ул бик хәлсез рәвештә учын Зиттаның чәченә куйды.

3

Госпитальдән чыгып, батареяга кайтуга, Идрисовны бик күп эшләр көтеп тора иде. Сугышта өтелеп йончылган батареяны яңадан аякка бастырырга кирәк иде. Бер яктан караганда, эш үзе әйбәт тә, үзенә йотып ала һәм авыру-сыктауларыңны, хәсрәтләреңне оныттыра. Ләкин ыгы-зыгы, хәрәкәт тынып калган минутлар була, шул вакытта Идрисовның йөрәге сулыгып-сулыгып әрнеп куя. Фәимә исенә төшеп, шулай бәгырен телгәләп ала иде. «Ник ул миңа шул тикле нык ышанды икән? Фәкать шуның аркасында гына һәлак булган», дип, үзен гаепле саный иде ул. «Бар күңеле белән шул ышанычка бирелмәгән булса, мине эзләргә барудан, бәлки, тыелып та калган булыр иде. Намусы, тугрылыгы йөрткән иде аны. Үзем дә юләр, нигә аның күңелендә ныклы өмет уяттым икән? Юк, бу үзеннән-үзе килеп чыкты. Фәимәгә йөрәгем ачылып киткәнен мин тоймадым да, акылым кайда булгандыр, белмим. Үзе дә инде бигрәк ихлас табигатьле иде шул, начарлыкка да юлыкмый калмагандыр, әмма җаны кырысланмаган, исәп-хисап, хәйлә белән тулмаган. Ничек шулай сакланган?»

Идрисов блиндажның чыршы ботагы түшәгән сәкесендә уйланып ята иде, черем итеп киткән. Төне буе диверсантлар эзләп урманнарда йөргәннәр иде. Болай да бу арада йокы бик аз эләгә, көндез төрле тикшерүчеләр белән матавыкланасың, төнен инде корал-ярак кабул итәргә туры килә.

Уфылдап, Тафтилов кайтып керде. Ул дивизион штабына летучкага барган иде.

— Яңа приказ — мунча әмәлләргә,— дип ул, бүреген салып, бер әрҗәгә утырды һәм өстәлгә таянды. Битендәге эре сипкелләре

беткән шикелле, алар вак җыерчыкларга күмелеп калганнар. Тафтилов нинди дә булса хәстәр белән уйлана башласа, сипкелләре шулай беткән кебек була иде. Идрисов торып, аякларын идәнгә салындырды. Тафтилов әйткән хәбәрне башында әвәләп, эндәшмичә генә аска төбәлде.

— Өченче көнге медосмотр вакытында бер солдаттан «жанвар» чыккан,— диде Тафтилов үкенүле тавыш белән.

— Землянка казытырга туры килер?

— Димәк, биредә озак торабыз икән әле.— Идрисов, нәтиҗә чыгаргандай, канәгатьсез рәвештә әйтеп куйды. Аның өчен мунча кирәк нәрсә, ә биредән китү-китмәү әһәмиятлерәк сыман иде.

— Шушында томаланып калырбыз, ахрысы, авызын корт чакқыры!— дип, Идрисов ачу белән төкерде.

— Фрицларга кораб белән яңа көчләр килгән, ди.

— Шуңа аптырыйм, нишләп алар шушы хәтле гаскәрне биредә тота, ә Берлинны ышыкларга алмый?

— Миңа да һич аңлашылмый бу. Анда Черняховский Пруссиягә бәреп кергән...

— Диңгезгә чыгып, диңгез буе группировкаларын чолгап алырга, и бетте?

— Әйе, безнекеләр ниндидер хикмәт әзерлиләр бугай.

— Руслар Берлинга хәтле барып җитмәсләр дип ышаналармы? Нәрсәдер бар.

— Юк, фюрер немецларда эшләнә торган бик көчле коралга исәп тота, диләр. Норвегиядә эшли башлаганнар икән, инглизләр шуны сизеп, заводны бомбага тотканнар икән.

— Юк инде, язмыш хыянәт итте аларга хәзер...

— Чыннан да, язмыш көлә алардан. Ул бер көлсә көлә инде, аннары — булмый. Язмыш аларга арты белән борылды хәзер...

Кинәт телефон шалтырады. Идрисов трубканы алды (ул үзе блиндажда булганда элемтәчене йокларга җибәрә иде). Кемдер бик катгый рәвештә батарея командирын сорый. Идрисов трубкага:

— Ул юк әле, эш белән чыккан иде,— диде. Трубканы куйгач, Тафтиловка зарланды:— химслужбадан отчет сорыйлар, противогазлар төзекме, һәр сугышчыга җитәрлекме? Тфү, нәрсәгә инде ул, баш катырып, ә?

Тафтилов та үз чиратында «стена газетасы чыгардыгызмы» дип тыкырдатуларыннан зарланырга тотынды. Ахры, ул служба бер тыловик утыра, тылдан китмәс өчен тырышамы, әллә үзе бар эшне җиренә җиткереп эшләргә яратучымы? Бик яман куыра... Сугышчының батырлыгын стена газетасы белән генә тәрбияләп буламыни? Батареяда берәр кимчелек табылса, анда стена матбугаты юк, дип, бар бәлане шуңардан күрәләр...

— Ярар, су туглап май чымас,— дип, Идрисов өстәлгә якынрак шуышып утырды, планшетын ачты.— Кичәге приказга бераз соры матдә сарыф итәргә кирәк. Нишлибез?

Тафтилов, тәмәке кабызып, шуны суыра-суыра, уйга бирелде. Идрисов исемлектән фамилияләрне караштырды. Приказ шактый баш кашыта торган: берничә рядовойны сержант званиесенә тәкъдим итәргә, аннары өч сержантны кече лейтенант дәрәҗәсенә күтәрәселәр икән, шуларга лаеклы кандидатура сайларга.

— Гадәттә, мондый чинга күтәрүләр һөҗүм алдыннан була торган иде,— диде Тафтилов, Идрисовның биредә калырбыз, дип пошынуына җавап биргәндәй. Әмма Идрисов аның сүзләрен ишетмәде дә шикелле, карандашын исемлек өстендә шудыра бирде.

— Кемнәрне теркибез? Минемчә, Каракүз, Зәйнуллин... запаска Мөслимовны кертергә була.— Идрисов башын күтәрмичә генә, гүя

Тафтиловны сынар өчен, шул исемнәрне атады. Тафтилов комбатка күз төшереп алды, кичә сөйләшкәнне исеннән чыгарды микәнни?

— Болай язсаң, кәгазьне кире кайтарачаклар, ә үзебезне политик артталыкта гаепләячәкләр.

— Ничек алай? Политик дип син тагы... — Идрисов башын күтәрде, аның күзләре: «мин биредә нәрсәнедер аңлап житкермим», дигәндәй мөлдери иде.

— Үзең яхшы беләсең бит, һәрбер исемлектә төрле милләт кешеләре булырга тиеш, ягъни интернационал.

— Ә-ә, — диде Идрисов, маңгаена сугып алып. — Истән чыккан шул элементар нәрсә! Чынлап та, исемлек ул яктан уйланган булырга тиеш. Туктале, ә лаеклы кандидатура булмаса нишләргә!

— Барыбер интернационализм рухын сакларга! Лаеклылар һәр милләттән булмый калмас.

— Аңлашылды. Алайса, кемне кая тәкъдим итәбез?

— Ляшков һәм Иван Могила ышанычны акларлар, минемчә?

— Әйе, нишләп без аларны онытып торабыз соң әле?

— Ляшков бик усал телле, хәтәр сүзләр дә ычкындыра.

— Ярар, теләсә ни лыгырдасын, әмма эшлекле булсын, хикмәт шунда бит.

— Оештыру сәләте бар аның, тик политик аңы гына аксый шикелле.

— Ә командир булдыклы булсын, тел белән тегермән тарта торганнан да алама кеше юк ул. Минем уемча, Ляшков әйбәт лейтенант булыр.

— Каракүз дә артыгын сөйләшүчән. Политикага борынын тыга. Шул минус ягы бар.

— Командир булгач, алай итмәс, дип ышаныйк. Алай фикер йөртсәк, без барыбыз да политикага борын тыгабыз анысы. Политиклар буласыбыз килә, син дә, мин дә...

Идрисовның бу сүзләренә Тафтилов берни дә әйтә алмады. Чөнки чыны шулай иде: һәрберебез политика турында сөйләшергә ярата... Тагы берничә кешене тикшереп алдылар. Идрисов фронтовикларча юмарт кылана иде, исемлеккә күбрәк кеше теркәргә тырыша. «Сугышта кече лейтенант яки сержант булып һәлак булсалар, семьяларына пенсия күбрәк чыгар —, дип кайгырта иде, ә исән калсалар, киләчәктә командирлар булырлар», дип кулыннан килгәнне жәлләми. Күпертеп, мактап яза. Тафтилов сугышчының политик карашына нык әһәмият бирә, ә Идрисов кешенең унган булуын беренче урынга куя.

— Уңмаган хөрәсән нәрсәгә ул? Нәрсә эшли аласың аның белән? — дип, Тафтиловны сүзсез калдыра. Тегесе фикерен жыеп, Идрисовның карашы дөрес түгеллеген исбатларга керешә... Алар чак кына тавышланышып китмәделәр, исемлекне яңабаштан карарга тотындылар.

— Казахлардан да кемне дә булса кертергә кирәк, — дип көрсенде Тафтилов. Бикмөхәммәт белемлерәк егет, шуны языйк.

Идрисов, аскы иренен тешләп, исемлек азагына тагы берне өстәде.

— Хәзер черки дә борынын төртә алмас, — дип, карандашын шапылдатып өстәлгә куйды. Тафтилов үзалдына уйланып калды, сары кашлары жыерылып түбәнгә төбәлде. Идрисов ниндидер канәгать чырай белән аның ни дә булса әйтүен көтеп торды.

— Ляшковны иртәрәк орудие командиры иттек бугай, — диде Тафтилов шелтәлерәк тавыш белән. Ул моның белән Идрисовның ашыгыбрак эш итүен кисәтә иде. Ник дисәң, Ляшковны ул күтәрде. — Инде ничә тапкыр: миңа һаман начар солдатларны бирәсез, ә Каракүзгә — әйбәтләрне, дип тавыш чыгарды.

— Безгә ни китерәләр, шул, — дип авызын капларга иде.

— Капларсың, бар. Ник монда йоклап ятасыз, запас полкка барып үзегез сайлап алырга кирәк, лодырьлар, дип ду куба...

— Әллә аны старшина итеп куйыйкмы, безнең Синчук бик ушәнләнде.

— Син нәрсә, аннары ул безгә баш була башлар, үз кубызына биетер. Әле хәзер дә синең Каракүз белән блатың бар, дип телләшә.

— Каракүз — аңа бирешми торган үткен егет, шуңа өнәп бетерми ул аны... — Идрисов исемлекне алып урыныннан торды, штабка барырга җыена башлады. Бөгәрләнгән погоннарын җилкәсенә яткызып маташты, гимнастерка сәдәпләрен барлады. Тафтилов та партбүлеккә чакырылган иде. Ул да, каешын тарткалап, өстен-башын сыйпаштырды, итегенә крем сөртте... Куен көзгесен чыгарып карап алгач, икесе бергә тылга юнәлделәр.

Ә бу вакытта Ляшков белән Каракүз бик тәмләп сыйланып утыралар иде. Эш шунда: Каракүзгә посылка килде. Анда ак чиләк калаеннан эшләнгән чәйнек кадәр кечкенә мичкә белән шәраб та бар иде. Соңгы вакытларда Каракүз Ляшков белән телгә килгәләде. Тәмсез сүзләр дә әйтештеләр. Шуңа күрә Каракүзнең күңеле тыныч түгел иде. Башта кызып китеп кешегә каты гына әйтә дә соңыннан шуның өчен борсаланып, йөрәк маен сыздырып йөри. Үзе дә белә, бик начар гадәт, әмма һич шуны үзендә бетерә алмый иде. Менә шул күңелдәге төерне юу өчен ул Ляшковны кунакка чакырды. Аннары шунысы да бар: Ляшков көчле егет, сүзен һәр җирдә уздыра ала, андый кеше белән дус булу шулай ук зыян итми...

— Яратам мин сине, Каракүз, синдә тач рус җаны, — диде, йодрыгын күкрәгенә бәрә-бәрә. Каракүз аның сүзләреннән бер карыш үсеп киткәндәй булды, күзләрендә рәхәтлек очкыны биеде. Ляшков тагы ихласланды.

— Бер күрүдә сиздем, син — киң күңелле кеше, синең белән бергә үләргә дә була...

— Юк, үлмик әле, — дип, елмаеп, Каракүз Ляшковның җилкәсенә учы белән кагылып куйды.

— Үлмибез, әлбәттә. Безгә диган пулялар коелмаган әле. Әнә дошман үлсен!

— Ляшков, брат, җир упсын, мин сине яратам,— диде Каракүз, йомшап, тагы да күңеле нечкәреп.

— Мин синең өчен җанымны бирәм, аңлыйсыңмы?

— Ә мин синең өчен бернәрсәмне дә кызганмыйм... Петя, брат, җир упсын...— дип, Каракүз дә ант итә башлады.

### 4

Рифа слетны ташлап кайтып китте. Эчендә әрнү, үкенү ачысы җыелды, шуңа чыдый алмады.

Өйдә беркем дә юк иде. Шушы бушлык күңелендәге рәнҗү хисләрен кинәт көчәйтеп җибәрде. Ул караватына барып, мендәренә йөзтүбән капланды да үксергә тотынды. Күз яшьләре күп җыелган икән, шушы моментны көтеп кенә торгандай, агылды да агылды.

Аны беркем дә алдамады, кимсетмәде, ул үзен-үзе алдады. Шул нәрсә эчтәге рәнҗүен тагын да көчәйтә иде. Артык беркатлы булып, артык ышанган. Нигә шулай тиз ышанырга иде? Ул бит сине ышандырырга теләп бер сүз дә әйтмәде. Госпитальдә очрашкан саен: «Мин сине мәңге онытмам», диде. Бары шул. Син шул сүзне зурга юрап, күңелеңә кертеп утырттың, иркәләдең, үзеңнекен иттең... Бәлки майор, үзе яхшы кеше булса да, тотрыксыз характерлыдыр? Бәлки йомшак, характерсыз кешедер? Андыйлар кайсы хатын-кыз кулына килеп эләгә,

шуныкы булалар да калалар... Монда аның бер гаебе дә юк... Бәлки ул кыз аның җанын биләүче түгелдер, бәлки бер дустыдыр? Юк, юк, тиле булма дип, икенче уйлары каршы төшәләр: үз күзләрең белән күрдең бит, тагы ни кирәк. Күзләре нинди очкынланып яна иде ул кызның! Майорны нурда коендыра иде. Аннары ул миннән күпкә чибәр. Тышкы яктан, әлбәттә. Тышы эченә туры килә микән соң? Ир-ат аны уйлыймыни соң? Ә ул кызый Даутны әрәм генә итмәсме? Мин аның белән авыр минутларда үземнең юатып яшәдем. Ярам әрнегән чакларда ул искә төшә иде дә, кинәт миңа җиңел булып китә иде. Аны үземә пар итеп күпме хыял сарайлары төзедем?! Бер зиннәтле сарай төзим дә никтер охшамый башлый, аны җимереп, тагы яңасын, әйбәтрәген төзим... мин аны уйлап, дөньяда әти-әни барлыгын да оныттым. Әнигә хатны бик сирәк яздым, югыйсә, көн дә язарга вакыт бар иде. Әти фронтта бәлагә юлыккач, бик нык гарьләнгән, кайгырган идем, ул да онытылды. Нәрсә бу, иң якын кешеләрем миңа ерак булып калды? Бу бит иң киме инсафсызлык! Кансызлык! Әти мескен нишләп шундый язмышка дучар булды икән? Чынлап та ул бик җәл! Районда нинди абруйлы кеше иде бит! Авылда чакта барысын дер селкетеп торды. Гасыйм шулай дип әйтте, дип кенә җибәрәләр, аның сүзе теге яки бу мәсьәләне хәл иткәндә хөкем карары урынына йөри иде. Тик кайчак масаеп китә торган гадәте бар иде, шул аңа әллә аяк чалганмы? Әни шулайрак бугай дип язды. Үзе исә сер бирдерми: «Минем болай булуда беркем дә гаепле түгел», — ди. «Кайгырмагыз, мин барыбер үз дигәнемне итәрмен», — дип тынычландырган була. Кабат фронтка бара алса, аның өчен зур уңыш булачак, имеш...

Мең төрле уйларын өйалдыннан килгән тавыш бүлде. Кемдер ишек шакый иде. Әллә сестралардан спирт сорап йөдәтүче олаучы килгәнме тагын? Әллә Таняның «ухажеры» бүген иртәләгәнме? Рифа, изү сәдәпләрен бармаклары белән барлап, ян тәрәзәгә килде. Баскычта кубанкалы һәм пөхтә шинельле, якасын торгызганга күрә йөзен дә юньләп шәйләргә мөмкин булмаган таныш түгел кеше басып тора иде. Рифа ишекне ачаргамы, юкмы, дип икеләнеп калды. Тегенең кыяфәте ничектер шикләндерә иде. Ул ишекнең биген ычкындырмый гына тавыш бирде. Теге яктан үзенең исем-фамилиясен ишетүгә Рифаның йөрәге еш-еш тибә башлады. Нинди-дер бик таныш аваз шикелле. Кем булыр бу? Ишек ачылды, һәм алар бер-берсенә төбәлгән килеш катып калдылар. Күзләр генә, очкынланып, бер-берсенең йөзләрендәге таныш, якын сызыкларны тилмерә-тилмерә эзли иде. Бусага артында басып торучының күзләре яшь пәрдәсе белән капланды, ул учы белән кабакларын сыпырып җибәрде дә калтыранган тавыш белән:

— Кызым, Рифа, әллә танымыйсыңмы? — диде.

— Я, алла! Әллә әти синме? — дигәнен Рифа сизми дә калды, куллары түбәнгә салынды, аяклары, гәүдәсенең хәлсезләнгәне сизелде. Ул, авып китмәс өчен, ишек яңагына тотынды һәм шулчак кына тәмам исенә килә алды.

— Ай-һай, сине дә күрер көн бар икән! — Хәбировның тавышы көр чыкты, керергә омтылып куйды, ләкин аягын атламады. — Ай буе эзли торгач, таптым тәки...— диде.

Рифа шаккатуын һәм чиксез аптыравын җыя алмый, ни әйтергә белми. Мондый очракта нишләргә кирәк соң? Муенына сарылыргамы, хәлен сорашыргамы? Ниһаять, теленә сүз килде, әмма мәгънәсез сүз иде:

— Ничек таптың, әти, ничек таптың?— диде.

— Күршедә генә икәнсең ләбаса, ә мин күпме газапландым,— дип, Хәбиров тагы алга омтылды, тик кызы һаман кузгалмый иде. Әтисенең бусагадан атлавын күреп, Рифа артка чигенде, үзе, каушаудан һаман бер сүзне кабатлады: «Ничек таба алдың, әти, ничек?..»

— Үзем дә ышанмыйм әле, кызым,— дип, Хәбиров шатлыклы, җиңүле тавыш белән кызына карады. Кызы да бик үзгәргән шул, тулыланып, калынаеп киткән...

Латыш өенең олы миче артында, аерымрак бүлмә сыман җирдә Рифаның караваты һәм тумбочкасы тора иде. Ул әтисен шунда алып кереп урындыкка утыртты да тагы яшеренеп кенә карап җентекләп күздән кичерде, әйтерсең, алсу түбәле кубанка, офицер шинеле кигән бу кешенең үз әтисе булуы һаман шикләндерә иде.

— Кеше ышанмаслык хәл бит, менә язмыш кая китереп очраштырды,— диде Хәбиров моңсу тавыш белән. Бүреген салды, кырган башын сыпырып куйды. Рифа аның ябык йөзен, бүрәнкә кебек эчкә батып торган яңакларын, җыерчыкланган маңгаен күрде. Тышкы яктан гына түгел, эчке яктан да нык үзгәргән, ахры. Әтисенең «язмыш»ны телгә алуы аның элеккеге хасиятенә бер дәятышмый иде.

— Бик бетерешкәнсең, әти,— диде Рифа,һәм күзләре яшь белән тулып елтырады. Күңелен нәрсәдер авырттырып, уеп алган кебек итте. Әтисен чиксез җәлләү иде бу, шул хис яңа гына кузгалып, бәгырен әрнетте.

— Һи, монда тазардым әле,— дип, бер дә исе китмәгән рәвештә кызына күз сирпеп алды Хәбиров. Аның чырае чамасыз шатлыктан нурланып тора иде.

Шунда бер-берсен бүлдереп, бер нәрсәдән икенчегә күчеп, өзек-төтек сөйләшә башладылар. Рифа сораулар биреп торды, әтисе бер сүз яки ым белән җавап кайтарды. Сөйләшүнең һич рәте булмады, күп нәрсәләр аңлашылмады. Икесе дә четрекле мәсьәләләргә кагылырга куркалар иде. Шунда Рифа капылт кына урыныннан кузгалды: «Мин бер минуттан кайтам»,— диде дә чыгып китте. Хәбиров моның ни икәнен белмәде. Рифаның исә әтисен ни беләндер сыйлыйсы килә иде.

Хәбиров кызының кай төше яралануын, ничек төзәлүен бик беләсе килә, ләкин сорарга кыймый. Болай бар җире бөтен күренә. Әмма ата кеше кыз белән ике арасына тел белән әйтеп булмый торган нәрсәдер булганын тоя һәм шуңа ярасы турында сүз кушарга кыенсына. Кызы инде тәмам балигъ булып беткән, хәзер барысын да үзе аңлый, үзе белә. «Карасана, инде лейтенант булырга да өлгергән. Әнисе күрсә иде моны! Әле семьяда чагында баланың ниндилеген белмисең, бар ягы да әйбәт булып күренә. Менә кешеләр арасына чыккач бала чын сынау үтә инде, шунда аның кемлеге, ниндилеге беленә. Биредә тылдарак, ышык җир, егетләр дә монда күз явын алырлык чибәрләр һәм үткеннәр. Мин — фронт бүресе, күпне күрдем, күпне ишеттем. Төрле хәлләр булып тора. Монда Рифага ансат түгелдер. Итәгенә салып кайтса да, берни эшли алмыйсың. Барысы да кыз баланың үзеннән инде, үзеннән. Рифа бик тәкәббер иде, менә шул холкы хәзер үзенә дә ярдәм итә торгандыр. Хатын-кызга булган биредәге игътибарга шул горурлык белән генә каршы торырга мөмкиндер. Нәфесен сузарга теләүче әтрәк-әләмнәр һәрчак табыла ул...

Әйе, уйласаң, гаҗәп бит, сугышта үлү ихтималым һәрчак исемдә иде, әмма кызымны фронтта очратырмын дип уема да килеп карамады. Хәерле булсын, Рифа бик чибәрләнгән абруе,да әйбәт булса кирәк. Карточкасын әнисенә җибәрде микән? Әх, әнисе күрсә иде моны!..»

Шатланып, Рифа кайтып керде, ул әтисен сыйларга барысын да алып кайткан иде. Әти кеше чиксез сөенеп, мең нур белән яктырып карап тора, кызының эшләре монда бик шәп икән, шул арада күпме ризык юнәткән, бераз гына спирт та тапкан. Ләкин әтисе ул эчемлектән баш тартты, «шул нәрсәне бер дә күрәлмим, каты чәй генә бир», диде. Рифа аңа гаҗәпсенеп карап алды да плитәдә өлгергән чәен алып килде. Аш янында сүз бер эзгә төшербәк, эзлеклерәк агылды.

— Минем Казаннан шалтыратканны кем барып әйтте?

— Газета редакторы Вәзиханы беләсең бит. Шул.

— Ә-ә, ул элемтә бүлегенә кергән чакка туры килгәнмен алайса...

— Әнинең ахирәте. Күлмәк, костюмнарын модалап гел әнидән тектерә.

— Шулайдыр... — Хәбиров тагы нәрсәдер әйтмәкче иде, тыелды. Йөзенә кинаяле елмаю чыкты. Ахры, ул Вәзиханың берәр хилаф ягын белә иде бугай.

— Кем әниеңне юлдан кире бордырырга кушты?

— Теге Сабирҗанов. Каргалыга шалтыраткан, авыл советы председателе әнине кире кайтарып җибәргән. Сине кулга алынган бугай, дигән.

— Ул Сабирҗанов сугышка китмәдемени?

— Һо, районның алласы шул хәзер.

— Ну, шушы бәладән генә котылыйм, иманын укытам мин аның... Тыл күсесе...

— Һаман шул әтәчләнүең бетмәгән икән әле, и эти,— диде Рифа, нигәдер ачуы килә башлап. Ләкин этисенә болай каты бәрелгәнгә шунда ук үкенде, ачуланыр, дип курыкты. Әмма этисе аның сүзләренә әһәмият итмәде дә шикелле. — Аңа беркемнең дә теше үтми. Сиңа үзең турында кайгыртырга кирәк, эти. Нәрсәгә ул Сабирҗанов? Чуан тулгач бер тишелер әле... — Рифа канәгатьсез чырай белән этисенә чәй өстәде. Хәбиров кызының бу сүзләрендә хатыны тавышын ишетте. Зәлилә дә аны шулай һәрчак гаепли, шелтәли иде.

— Мин ул куштанны барыбер бу көе калдырмыйм. Чыгышын яшергән мулла малае ул! — дип, Хәбиров чәен шабыр-шобыр эчә башлады. Эчендә кузгалган гарьчеллек ачысыннан ул чәйнең кайнарлыгын да тоймый иде кебек. Шул гарьчеллек халәтендә алдындагы тушенканы кашыгы белән умырып-умырып авызына озаткалады.

— И, эти, кешеләр белән чәкәләшмичә яши алмыйсың ахрысы! — дип куйды Рифа ягымлы, яраткан тавыш белән.

— Элеккеге дуслык өчен генә булса да әниеңне кире бормаска тиеш иде бит! Ә ул курыккан, үзенең шкурасын саклаган! Әниең килсә, миңа да җиңелрәк була иде. Әйе, ялагай кысрыкта сата дигән дөрес икән? — Хәбировның тавышы яшь төере белән карлыгып чыкты. Ул күз яшен эчкә йотар өчен тамак кыргалады, күзен читкә алды. — Үзе гел безнең түрдә булды! — дип, кулын өметсез селтәп куйды.

— Дус көлгәндә түгел, бөлгәндә беленә, диләр руслар.

— Ялагайның елан икәнен белеп булмый шул, кызым,— диде Хәбиров әрнеп, бигрәк тә Рифага сабак булсын өчен шулай әйтте.

— Сиңа хәзер үзең хакында уйларга кирәк, эти,— дип, Рифа этисенең җилдән какланган йөзенә карады. Ачуланырмы, юкмы? Юк, ул һаман үз уйларына бирелгән, кызының сүзләрен колак яныннан уздырып җибәрә. Рифа этисе эләккән бәла турында уйлап утыра, аңардан моның сәбәпләрен сораштырырга тели, әмма уңайсызлана, этисенең авыр ярасына кагылырмын, дип шикләнә һәм, үзенең сөйләп бирүен теләп, сүзне шуңа бора иде. Тик этисе шул куркак дустын һич кенә дә гафу итә алмый, төрлечә китереп тирги дә тирги. Рифа тагы аның сүзен бүләргә мәҗбүр булды.

— Моннан котылу өчен бер җай юкмы соң?

— Шул сират күпере аша гына инде, бүтән юл юк,— диде Хәбиров, кашларын җыерып. Аның бу хакта сөйләшәсе килми иде шикелле. Үзенә-үзе тамугка керергә карар иткән, бүтәнчә булуын теләми сыман тоелды. Өмете өзелү һәм бүтән бернигә ышанасы килмәү дә аның бер ноктага төбәлеп тынган күз карашыннан сизелде.

— Яшь чагында уйламыйсың икән, үзеңне дә, кешеләрне дә аямыйсың икән, кызым. Ә шулай да үкенмим... Җыен кара фикерләне җайга күндереп йөрдем...

— Шуңа үзеңне дә аямаганнар, батырганнар...

— Аңа тик үзем генә гаепле, кызым, беркем дә түгел. Әлбәттә, минем ише житәкләргә, өстә торырга өйрәнгән кешегә башта бик авыр булды. Үзем генә беләм...

Хәбировның бу сүзеннән Рифа шуны исенә төшерде, этисе бик кызыл һәм катгый булганга классташ кызлары аның белән якыннан дуслашырга шикләнәләр иде.

— Кеше үз башына төшмичә белми, диләр бит...

— Анысы шулай инде, кызым. Юк, мин бәладән сыгылып төшмәдем, шыңшымадым, шуңа эчтән әз генә булса да куанып йөрим,— диде Хәбиров тыныч, буйсынулы рәвештә. Тик кинәт ике кулын йодрыклап өскә күтәрде дә кычкырып җибәрде:

— Шалишь, мин дошманнарымны сөендермәм, бәлагә төште дип кинәнмәсеннәр! — Ул нәкъ элеккеге җыелышларда батырланып сөйләгән кыяфәтенә керде.

— И, эти, мин ул хакта әйтмим ич! — диде Рифа, этисенең һаман үзе турында кайгыртырга теләмәвенә, һаман әллә нинди элеккеге дошманнарына үчегеп маташуына борчылып. Этисе исә шушы мәхшәр эчендә җанына якын кешесен очрату шатлыгын да онытып, әүвәлге дусларының хыянәтен күтәрә алмыйча сөйләнә, гаҗәпләнә, аптырый...

— Ир типкәнгә ил тибә, дигән борынгылар, хак әйткәннәр,— дип, кулын селтәде ул. Гүя башына тулган уйларын куып бетерергә теләде. Этисенең һәр хәрәкәтен күзәтеп торган Рифаның йөрәгеннән бәгырен әрнетеп кайнар дулкын үтте. Этисен жәлләү хисе бугазына төер булып утырды. «Ничек аны коткарырга, ничек аңа бер җиңеллек китерергә,»— дип эчтән уй йөртте. Үзенең бу эштә көчсез булуын күңеленнән таныды, әмма барыбер җаны әрнүдән туктамады. «Юк, моның бер җае булмыйча булмас,» дигән фикер тагы өметен кабындырып җибәрде...

Кич булган иде инде. Рифа этисеннән:

— Кунсаң, сүз әйтмәсләрме? — дип белеште.

Этисе:

— Юк, командирлар мине бик ярата лар,— диде.

«Анда да авторитет казанырга өлгергән икән,— дип бераз сөенеп куйды Рифа. — Ул авторитетсыз яши алмый торган кеше инде».... Рифа этисен кунарга калдырды да госпитальгә дежурга китте.

Икенче көнне ул соң гына кайтты. Ягымлы чыраена арыганлык, эчтән борчылу пәрәвезе ябылган иде. Этисенә ул яңа кирза итек китереп тоттырды. Хәбиров бик сөенде, ике ботына кулларын шап-шоп сугып торды. Кызыннан шундый игелек күрү ата кешегә чиксез шатлык иде. Ул итекләрен шунда ук киеп тә алды. Куанычыннан кызына әйтергә әзерләп куйган сүзләрен дә исеннән чыгарды. Ә әйтәсе килгән сүзе шул иде: хатыны аңа ачуланып, «Рифа синең хурлыгыңа чыдый алмыйча фронтка китте» дип язган иде. Хәбиров шул хакта сорашмакчы иде. Онытып, кызын мактарга тотынды:

— Абруең, кызым, бик зур ахры, шул арада нинди әйберләр табарга, ай-ай... — дип, кызының бу уңганлыгына шаккатып, горурланып сөйләнде дә сөйләнде. — Их, әниең күрсә иде сине! Рәхмәт, кызым!

Рифа этисен озата чыкты. Икесенең дә бер-берсенә әйтәсе сүзләре күп, әмма иң кирәклесе һаман да читтә кала иде. Рифаның шуңа кәефе китебрәк бара, этисеннән үз язмышы турында кайгыртып уй йөртүен ишетәсе килә. Шуннан Рифа үзе нәрсә эшли алачагы да беленер, әз генә ачыкланыр иде кебек. Ах, этисе сүзне һаман кырыйга бора. Ул кинәт бик гаҗәпсенгәнен белгертеп әйтеп салды.

— Мин теге без торган Дәвеш авылы егете Мирхасны очраттым бит әле! — диде һәм ничек аны танып алганын сөйләде.

— Теге тыкрык эчендәгеме, ишегалларында коелары да бар иде, шулмы? — дип, Рифа бик тиз исенә төшерде.

— Бик гаярь егет булып чыккан ул. Дан орденына лаек булган.

— Директор чакта син аны яратмый идең бугай бит?

— Булгандыр. Этисе колхозны өнәмәде, бусы да кырын карый иде.

— И, эти,— диде Рифа өзгәләнгән тавыш белән. — Үзең яклы булмаган кеше сиңа гел дошман булып күренде инде!

— Заман бит, кызым. Юк, ни генә булмасын, алар кара фикерлеләр иде. Точно!

— Орден алган дисең бит,— диде Рифа, әтисенең элеккеге гадәтләрен ташламавына ачуы килә башлап. — Патриот булу өчен син әйткән «кара фикерле» булу комачауламый, димәк! — Рифа шундый үчекли торган тавыш белән әйтте, Хәбиров шым булып калды. Кызы аны элеккеге эшләре өчен шелтәли кебек иде.

— Кызым, үзең дә беләсең бит, сугыш бик әшәке нәрсә,— дип тотынды ул кызына тамчы да ачуланмыйча. Киресенчә, кызының шулай акыл иясе булып аны шелтәләве белән ул горурлана да иде. — Әнә, снаряд җирне ничек актарса, алгы сызык та кешенең бөтен җанын шулай актарып ташлый. Кемнәргәдер аң да кертә ул. Безнең элеккеге тартышлар, бер-беребезне рәнҗетүләр үлем каршысында бик вак нәрсәләр булып калалар икән. Кеше монда тәүбәгә килә, кызым...

— Син бер дә тәүбәгә килгән шикелле түгел әле,— диде Рифа һаман баягыча кискенләнеп.

— Кеше заманча яшәргә тиеш, кызым. Мин заманча булдым. Мин үз заманым кушканча эшләгәнемә үкенмим! — Хәбировның тавышы моңлы иде. Билгеле, ул күп нәрсәләрне аңлаган хәзер, кайбер эшләрне бүтәнчәрәк эшләр иде. Тавышыннан һәм күзләренең житдиләнеп китүеннән шул аңлашылды. Кызының исә әтисе алдында үзенең практик акылы белән әз генә булса да мактанасы килде бугай. Үзенең күп эшләр майтара алырлык булуын әтисе танысын, күрсен. Хәбиров та кызының бу тойгысын нык сизде, шулай да төсенә чыгармады.

— Мин тагы килермен әле, кызым, рәхмәт! — дип, урманны чыккач, башын ия төшеп, юаш кына алгы сызыкка таба китеп баруында да шул чагылды булса кирәк. Рифа аны агачлар арасына кереп күмелгәнче карап торды, тик әтисе бер мәртәбә дә артына борылып карамады... «Күңеле кителде микәнни», дип шиккә калды Рифа. Әтисен кызгану дулкыны йөрәген әрнетте. Аның хәлен җиңеләйтү өчен нәрсәдер эшләргә кирәклеген тагы да ныграк аңлады.

Ул, кире борылып кайтып барганда, үзләренең бөтен үткән тормышлары күз алдыннан узды. Алар Дәвеш авылында озак яшәделәр. Күп кенә тормыш кайгылары, шатлыклары шул авыл белән бәйләнгән. Бик чуар халыклы зур гына авыл иде ул. Әле кырыгынчы елларда да колхозга кермәүче хуҗалыклар бар иде. Бигрәк тә авылның инеш буена утырган түбән очында (ни өчендер ул төшне Пекин дип атыйлар иде) үҗәт халык, усаллар тупланып утырган.Рифа әтисенең баш бирмәсләр белән чәпәләшеп йөргәнен еш ишетә торган иде.

Әтисе белән әнисе башта да тыныч кына тормаганнар. Әтисе малай көткән, әмма, кыз тугач, әнисеннән суынып йөргән. Аннары, әнисе малай тапкач, ипләнеп киткән, шатлыгыннан нишләргә белмәгән. Биш-алты яшьтә Атласка ул шигырьләр ятлатты. Бәйрәм мәҗлесләренә аны үзләре белән алып баралар да сөйләтәләр иде. Әтисенең башы күккә тия, улының зиһене белән чиксез горурлана, масая ул. Сәрхушләнгән ир-ат, хатын-кыз баланы тотып-тотып үбәләр, иркәлиләр. Андый мәҗлесләрдән соң гына кайтып яткач, Атлас саташып, бастырылып йоклый иде. Кайчак бөтенләй йоклый алмый борсаланып чыга. Бервакыт завуч Якуповлардан аштан кайткач, Атлас авырый башлады. Һаман «башым, башым,» дип ятты, йөзе кәгазь кебек ак булып калды. Хәбиров улын ул заманда тирә-юньдә танылган Земляницын дигән врачка алып барып күрсәтте. Тегә үзе эшли торган больницага салып дәвалады. Әмма авыруы көчәя генә барды.

Бермәл Атлас сөйләшә алмас булды. «Менингит», диделәр. Шулай телсез булып калды. Ә авылның усал гайбәтчеләре ата-ананың бәгырен кисә торган сүз ишеттерделәр: имеш, директор Хәбиров малаеннан муллалардан көлә торган шигырьләр сөйләттергән, шуңа, янәсе, телсез калган...

Кара елан кебек шуышып шундый гайбәт йөрде. Билгеле, бу әтисенең дошманнары чыгарган агулы сүз иде. Бердәнбер малайларының фаҗигасе ата белән анага бик каты сукты. Әтисе нык юашланып калды. Казан врачларына күрсәтеп кайткач, әнисенә каты гына бәрелеп алды: «Нәселдән дип әйтәләр, әллә сезнең якта шундыйлар бармы?» — дигән чаклары була иде... «Юк, аның теле ачылырга тиеш», дип кемгәдер янаган кебек кычкырып куя иде әтисе. Йөрәгенә төшкән бу кайгыдан кая барып бәрелергә белми иде. Атласны телсезләр мәктәбенә шәһәргә илтеп куйгач, әтисе эчкәли башлады. Рифа да бик хурлана иде, ләкин сер бирми, төсенә чыгармый... Ахырда алар район үзәгенә, шәһәргә күчеп китәргә мәҗбүр булдылар...

Әтисе хәзер әллә бөтенләй өметен өзгән, әллә барысын эченә җыеп тышка чыгарырга теләми? Аңламассың, ул һаман элеккечә булып калган шикелле. Рифа аның Дәвеш авылы егете Мирхасны очратуына шатлануын кабул итә алмады. Ничек инде үз хурлыгына шаһит булган кеше белән очрашуга шатланырга мөмкин? Мин-минлеге аның тәмам беткәнме? Әтисенең шулай бәлагә таруыннан соң элеккеге танышлары белән күрешәсе килми Рифаның. Кайберсе тыштан синең кайгыңны уртаклашкан кебек булып күренсә дә, эчтән сөенә ул. Ниндидер ясалмалылык, икейөзлелек килеп чыга. Кешенең икейөзләнүен белеп, күреп торудан да җанга авыррак нәрсә юктыр...

Кайткач, ул тумбочкасы алдына барып утырды да көзгесенә карады. Шунда ук Мостафин исенә төште, йөрәге ешрак типте. Үз кайгысы җанын йолкыды, тырнады, бер шиккә, бер өметкә ташлады.

## 5

Асоев үзе Мостафин янына керде. Өченче көн бер эш буенча шактый гына әйткәләшеп алганнар иде, шуннан бирле күрешкәннәре юк. Нишләр икән, кичке ашка чакырса, гаеп итеп карамас микән?

Мостафин, гадәттәгечә, аны кутәренке күңел белән каршы алды. «Кинә тотмаган кеше белән рәхәт тә соң»,— дип уйлады Асоев. Әйтерсең, алар арасында берни дә булмаган — Мостафин шулай сөйләште. Асоевның тәкъдименә куанып риза булды.

— Аштан баш тарткан кешедә өмет булмый, дигәннәр борынгылар,— ди-ди, Асоев бүлмәсенә кереп, өстәл янына утырды. Асоев Мостафинның әллә ничә «фонарь» утыртылган битенә, пластырь ябыштырылган маңгаена карап-карап алгалады, ни әйтергә дә белмәде. Аннары кызлар слетына киткәнен исенә төшерде дә шунда берәр хәл булгандыр, дип шаяртуга борды.

— Кызлар ничек матурлаган үзегезне,— диде, Мостафин битендәге кутырларга ымлап. Мостафин аның шаяруын әллә ишетмәде — ул өстәлдәге ризыкны карый иде.

— Каян килгән бу күгәрчен сөте? — дип, Асоевка елмайды һәм шунда ук соравына җавапны да тапты: — Ә-ә, белдем.

— Кайда хатын-кыз, шунда бәла... — Асоевның тавышында нәрсәгәдер төрттерү бар иде.

— Юк,— диде Мостафин, каршы килеп. — Төнлә кайтканда мото белән тәгәрәдек.

— Ул латышың синең... — дип, Асоев нәрсәдер әйтмәкче иде, фикерен йомар өчен стаканга тотынды да Мостафинга ымлады.

— Бик арыганда бу ярап куя,— диде Мостафин күңеле булып. Асоев эндәшмәде, йөзе горур, үткен кеше бар эшне булдыра, дигән төс алды. Мостафин ысланган колбаса белән ак күмәчне бик тансыклап капкалагач, куе чәй эчә-эчә сөйләнеп алды:

— Хәрби мәктәптә укыганда бер бик акыллы укытучы бар иде. Елгавадагы киңәшмәдә шуны очраттым. Дисциплинаны ярата торган, үзе дә гаҗәп тәртипле, пөхтә кеше иде. Өсте-башы гына түгел, фикер йөртүе дә җыйнак. «Германиядә революция булачак, дип ышана, безгә сугыш куркынычы юк», дия иде. Хәзер шуны исемә төшердем, Иван Андреевич иде, шул башын селки, ни әйтергә белми, «нинди коточкыч алдану,— ди. — Теориягә генә таянып яшәсәң, шулай төп башына утырып каласың икән», ди Иван Андреевич уфылдап. «Ә буржуйларның иң яхшысына да ышанырга ярамый. Безгә һәм яшь буынга мәңге сабак булсын... Бу сабак артык кыйбатка төште шул», дим. Иван Андреевич үкенү, әрнү белдереп, җилкәләрен селкетеп куя, җавап урынына кулын гына селки.

— Без бераз күкрәк кагарга яратабыз шул,— дип куйды Асоев үз-үзенә әйткән кебек.

— Шул атмосфера күпләрне адаштырды,— диде Мостафин. Бу тема аны кызыксындыра иде бугай, күзләре очкынланды. Тагы нәрсәдер сөйләргә җыенган сыман иде, ләкин шул чак ишектә ординарец Гунар күренде, «хуҗа телефонга дәшә», диде. Мостафинның күзендәге чаткылар кинәт сүнде. Ул, рәхмәт әйтеп, урыныннан кузгалды.

Асоев җылынды,аңа рәхәт иде, шуңа күрә башына йомшак, төче уйлар өерелеп-өерелеп килде. Хатыны янына үзе кайта алмавына җаны әрнеде, ә бит шундый ымсынган, шундый әзерләнгән иде. Аның уңганлыгына, эшне һәрчак булдырып чыгуына сокланган начальниклар отпуска бирергә ризалыкларын белгертми калмыйлар иде. Турыдан-туры начальнигы да «отпуска бирермен», дигән сүзләр белән эшен хуплап торды. Ләкин һич көтелмәгән хәл бөтен нәрсәнең астын-өскә китереп ташлады. Бер көнне икенче эшелонда торучы бер частька секретлы киңәшмәгә барырга чыктылар. Әйбәт кенә барганда шофер юлны бутаган, читкә тайпылган, кинәт машина астында миналар шартлый башлады, чак кына өскә чөеп атмады. Ярый әле, пехота миналары гына булган. Шофер машинаны туктатты, тәгәрмәченең икесе шәлперәеп төшкән. Киңәшмәгә соңга калына иде, начальникның бик каты ачуы чыкты. «Кем бу юлдан барырга кушты?» — дип кычкырды. «Капитан Асоев!» — диде шофер. Алар киңәшмәгә соңга калдылар һәм шелтә алдылар. Моңа Асоевның тагы шундый бер эше өстәлде. Һәм чираттагы «тылны тарап» алгы сызыкны ныгыту компаниясендә Асоев та исемлеккә эләккән иде. Ул менә шулай алгы позициядә пәйда булды.

Зангир кайтып кереп, аның уйларын бүлдерде.

— Снарядлар кайтып кермәгән, ләкин бронза вексель алдым, булачак,— дип, эше уңышлы чыгу канәгатьлеге белән елмайды.

— Молодец. Ничшләп бик тиз?

— Машина туры килде.

— Әйдә, утыр. — Асоев стаканнарга яссы ак котелоктан чәй салды.

•

*Ахыры киләсе санда*

# *1946—1985*



Бу биттә сез Бөек Ватан сугышында катнашкан Татарстан язучыларының 1946 елда төшкән фоторәсемен күрәсез.

1 рәттә (сулдан)— Әдип Маликов, Мөнир Мазунов, Сибгат Хәким, Зәйни Шәһиморатов, Мәхмүт Хөсәен, Шәрәф Мөдәррис.

2 рәттә — Халикъ Садри, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Афзал Шамов, Риза Ишморат, Госман Бакир.

3 рәттә — Габдрахман Әпсәләмов, Гамир Насрый, Әсгать Айдар, Абдулла Әхмәт.

4 рәттә — Әмирхан Еники, Әхмәт Исхак, Әхмәт Фәйзи, Татарстан китап нәшриятының шул чордагы баш редакторы Х. Шабанов, Бруно Зернит, Хатип Госман.

Уң як Биттәге фоторәсем 1985 елның 19 февралендә төшерелде (фотограф Владимир Зотов эше).

1 рәттә (сулдан) — Нури Арсланов, Газиз Иделле, Мөхәммәт Садри, Риза Ишморат, Әхмәт Исхак, Гариф Галиев, Хатип Госман, Салих Баттал.

2 рәттә — Шамил Шәһгалиев, Әмирхан Еники, Мөнир Мазунов, Мәхмүт Хөсәен, Ибраһим Нуруллин, Атилла Расих, Сафа Сабиров, Әбрар Кәримуллин, Баян Гыйззәт.

3 рәттә — Нәби Дәүли, Сәет Шәкүров, Әдип Маликов, Кави Латыйпов, Мәгъсүм Насыйбуллин, Маннур Саттаров.

Бөек Ватан сугышында катнашкан язучыларыбыздан Афзал Шамов, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Нур Гайсин, Сәет Кальметов, Хисам Камалов, Геннадий Паушкин, Мария Елизарова, Мәҗит Рәфыйков, Габдулла Шәрәфи, Миргазиян Юныс төрле сәбәпләр аркасында бу фоторәсемгә төшә алмадылар.



## Шәрәф Мөдәррис

●

Күп булса да йөрәк ялкыннарым,
Чит-ят җиргә чәчәр җылым юк.
Үтсәм дә мин кургаш яңгырларын,
Сыкранырга туган җырым юк!

Килде-китте җилдә тибрәнергә
Думбырамда артык кылым юк.
Көрәш дәрте ярсый хисләремдә,
Сызланырга туган җырым юк!

1942

## Әнвәр Давыдов

●

Кулларыма
Туган кырларымнан
Туфрак алып үпсәм, көлмәгез,
Моны күңелем йомшак булуыннан,
Җаным җебегәнлектән күрмәгез.
Ят юлларның әче тузаннарын
Көнбатышка карап йотканда,
Чит җирләрдән алга үрли-үрли,
Әрем сабакларын тотканда,
Курыкмадым, дуслар, үлемнән мин,
Әмма һаман шуны уйладым,
Җылы бөркеп яткан буразнаның
Очы күренмәгән буйларын,
Туган җирләремнең
Күгәрчен түшедәй
Күпереп торган симез балчыгын
Уйладым
Һәм дошманыма каршы
Сүрелмәс үч белән ярсыдым.

1946

# БЕЗНЕҢ АВЫЛДАН ДА СУГЫШ УЗДЫ...

**9 Май көнен — Җиңү бәйрәмен бөтен дөнья бәйрәм итә. Бәйрәм колонналарында баручылар шат йөзле балаларны һәм язгы чәчәкләрне югары күтәреп баралар. Балалар — бәйрәмнең, тынычлыкның, яшәешнең таҗлары сыман балкыйлар. Әйе, балаларны югары күтәрәбез. Барлык кыйтгаларда да шулай. ГДР башкаласы Берлинның Трептов паркында корычтан коелган Азатлык солдаты да бала күтәргән. Егерменче гасырның тере тарихын үзенә иңдергән дә, әнә шулай сабый баланы күтәреп тора...**

**Тиздән 1 июнь — Балаларны халыкара яклау көне. Бу көнгә дә без тынычлык өчен көрәшеп, балаларны яклап барабыз. Балаларны яклап,— димәк, Кешелекнең киләчәген яклап.**

**Ә безнең балалар, сугышның илгә-җиргә, дөньяга нинди афәтләр алып килгәнен үзләре ничек аңлыйлар?— Аксубай районы, Яңа Дума урта мәктәбе укучылары язган сочинениеләрдән алынган өзекләрдә әнә шул турыда сөйләнә.**

Фашизм, юлында нәрсә очрый, барысын да җимерде, юк итәргә тырышты. Безнең авылдан аларга каршы көрәшкә 300 ир-егет киткән. Шуларның 139-ы ил иреге өчен көрәшеп һәлак булган. Ә күпме кешеләр гарипләнеп, гомер буе сызлап торган яралар белән кайтканнар. Ветераннарның яралары бүген дә әрни... Без аларның шул яраларына дәва булырлык матурлыклар тудырып яшәргә тиеш.

Әнис **ГАФИЯТУЛЛИН**, 9 нчы класс укучысы.

Ирләре, балалары сугышта үлгән апалар бүген дә газиз кешеләрен көтәләр. Бездә сугыш афәте кагылмаган бер генә гаилә дә юк. Сугыш китергән хәсрәтләр әби-бабайлардан — әти-әниләргә, әти-әниләрдән безгә күчә килә...

Тәнзилә **АБДУШЕВА**, 10 нчы класс укучысы.

Минем ике бабам да сугыш кырында үлеп калганнар. Әби белән бабай сугыш алдыннан матур гына тормыш корып җибәраләр. Сугыш башлана. Бабай беренче көннәрдән үк сугышка китә. Китканда: «Сез исән булсагыз, мин барлык авырлыкны да күтәрергә риза»,— дип саубуллашкан ул. 1941 елны ул һалак була. Әби бөтен гомерен колхоз кырларында уздыра. Эше дә ир-атлар гына эшли ала торган эш — урманда утын кисү, авыр йөк ташу, судан мунчала чыгару... Арыталуны белми ул, сугыштан соң да әнә шундый авыр эшләрне башкара. Балаларын шулай үстерә. Исәнлеге бик тиз какшый аның. Хәзер әбинең колагы ишетми, куллары калтырый. Картлыктан гына түгел. Алар үзләре утка-суга кереп, безнең бүгенге тормышыбызны матурлаганнар, җылытканнар.

Әлфирә **ХӨСНУЛЛИНА**, 7 нче класс укучысы.

Минем бабама хәзер 91 яшь, ул авылның иң карт кешесе. Аны 1914 елда солдатка алалар. Ул гражданнар сугышында Юденич, Деникин башкисәрләренә каршы көрәшә. 1941 елда сугыш башлангач, аны сугышка алмый торалар. Ул төрле авыр эшләрне башкара. Бабай 50 яшь булган көннәрендә сугышка китә. Ул авылга 1946 елда гына әйләнеп кайта. Әбием сугыш елларында 9 бала белән

кала. Ул елларны искә алганда, әбием күз яшьләрен генә сөртеп ала, истәлекләр сөйләргә яратмый. Балаларының иң өлкәне хәрби академия тәмамлый, тагын ике улы югары разрядлы электр белән эретеп ябыштыручы булып эшлиләр, бер улы югары белемле юрист, бер кызы — балалар врачы, бер кызы — парикмахер, бер кызы — балалар язучысы, ә төпчек кызы — шәфкать туташы. Мин әбием, бабам белән бик горурланам.

Луиза НИЗАМОВА, 8 нче класс укучысы.

Безнең авылда сугышта һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәл бар. Без каһарманнар һәйкәленә чәчәкләр китерәбез һәм тынып калабыз. Күңелләрдә шигъри юллар туа:

Тәрәзәгә җилләр бәрә —
Сәламнәре түгелме?..

Хәзер дә сәламнәр, хәбәрләр көтәләр безнең авылдагы апалар. Күбесенең ирләре, балалары сугышта ятып калган аларның...

Мин авылыбызның өч дус егете турында язасым килә. Хисам Нуретдинов, Насрулла Ногманов, Талип Сәләховлар мәктәптә бергә укыйлар. Сугыш башланганда унбиш яшьлек булган бу егетләр колхоздагы бөтен авырлыкны башкалар белән бергә күтәргәннәр. Фронтка элләгү турында хыялланалар. Унҗиде яшьләре тулу белән үзләре теләп сугышка китәләр. Өчесе дә десантчы булалар. Батырларча сугышалар. Орден-медальләр белән бүләкләнәләр. Фашистларны Берлинга куып килгән көннәрнең берсендә, Хисам абыйның сугышчан бурычны үтәү өчен сикергәндә парашюты ачылмый. Ул урман өстенә килеп төшә. Аңарга нибарысы унтугыз яшь була.

Җәүдәт ВӘЛИУЛЛИН, 6 нчы класс укучысы.

Без «Бөек Ватан сугышы елъязмалары» экспедициясенә катнашабыз. Авылыбыз батырларының сугышчан юлын өйрәнәбез. Шуларны белмичә яшәсәк, безнең тормышыбыз тулы булмас иде.

Нурия МОСТАФИНА, 9 нчы класс укучысы.

Авылдашларыбыз истәлегенә куелган һәйкәл тирәсенә без агачлар утырттык. «Сез иң бәхетле илдә яшисез, яшәү — иң зур бәхет ул», дип шаулыйлар кебек ул агачлар.

Венера МӨБАРӘКШИНА, 9 нчы класс укучысы.

Минем бабам Насрулла Хөснуллин сугышка 1941 елның 21 августында китә. Ул 1944 елның январь аенда гына II группа инвалид булып әйләнеп кайта. Бу вакытта аңа 30 яшь була.

Ул Сталинград, Витебск, Белград шәһәрләрен азат итүдә катнаша. Бернича тапкыр яралана. Яралы килеш аны фашистлар әсирлеккә алалар. Әсирлектә ул ниләр генә күрмәгән! Тере килеш коега тутырылган балаларның елашулары, ярдәм сорап кычкырулары турында бабамның сөйләгәннәрен гомерем буена онытмам. Сөйләгәндә, ул үзе дә яшьләрен тыеп кала алмый иде.

Бервакыт аның уң кулындагы ярасыннан гангрена башлана. Аңын югалткач, бабамны үлекләрне күмә торган чокырга чыгарып ташлыйлар. Төнлә аңына килеп, үлекләр арасыннан ул шуышып чыга. Урманга таба үрмәли, аңын югалта, аңына килгәч тагын алга хәрәкәт итә. Җирле халык аны үзебезнекеләр кулына тапшыра.

Госпитальдә аның җилкә башыннан уң кулын кисәләр. Шулай коткарып калалар. Гарип булса да, кайткач ул колхозда эшли. Бабам җыр ярата иде. Сугышка кадәр ул гармунчы булган. Бабамның үлгәненә быел 8 ел булды. Ул, үлгәнче, Гитлерны каһәрләде.

Әлфия ХӨСНУЛЛИНА, 9 нчы класс укучысы.

Сугыш башлангач, унбиш-уналты яшьлек кызлар тракторларга, комбайннарга утыралар. Бу һөнәрләргә алар кыска сроклы курсларда өйрәнәләр. Гыйльманова Зөһрә, Гатина Миңнегаян, Сәгыйрова Әсма апалар әнә шундый батыр йөрәкле кызлар булганнар. Алар кичергән бөтен авырлыкны, кайгы-хәсрәтне үлчәр берәмлек юктыр.

Лилия МИҢГУЛОВА, 8 нче класс укучысы.

Тол калган хатыннарны да мин батырлар рәтенә куясым килә. Алар безнең авылда 25 кеше генә калды. Гарипләнеп кайткан сугышчылар кебек үк алар да яраларының сызлавына бик күп көннәр түзделәр.

Гүзәл ЗӘЙДУЛЛИНА, 8 нче класс укучысы.

Сугыш китергән кайгы — кешегә гомер буе ияреп бара торган кайгы ул.

Илсөя ЛАТЫЙПОВА, 8 нче класс укучысы.

Фашистлар безнең халыкны үтереп бетерергә килгәннәр. Минем бабам да сугыштан кайтмаган. Әбием дүрт яшь бала белән калган. Хәбәрсез югалган бабамны хәзер дә көтәбез.

Гөлүсә ХӘМИТОВА, 9 нчы класс укучысы.

Сәүҗиһан абый Хәмитов сугышның беренче көннәреннән үк сугышка китә. Орденнар тагып исән-сау килеш кайта. Ул безнең авылда күп еллардан бирле киномеханик булып эшли. Безгә сугыш турында кинолар күрсәтә.

Альбина СӘГЫЙРОВА, 9 нчы класс укучысы.

Әбием сугыш елларында балалар укыткан. Ач балаларның күңелен җылытуы бик авыр булган аңа.

Анжелла ГЫЙЛӘҖЕВА, 7 нче класс укучысы.

Бабай сугышка киткәч, әбием өч кечкенә бала белән калган. Ул авыр эшләрдә эшләгән. Ашарга-эчәргә өйдә бернәрсә дә калмаган. Бервакыт әбине еракка эшкә җибәргәннәр. Ул бер атнадан соң гына кайта алган. «Балаларым үлеп беткәннәрдер инде», дип елый-елый кайткан. Минем әнием балаларның иң олысы булган. Ул үзеннән кечеләрне кырдан башак җыеп туйдырган. Әби балаларын исән күреп кочаклап елаган.

Ә бабам сугыштан кайтмаган. Кара язулы кәгазь килгәч тә әбием бабайны һәр көнне көткән.

Гөлүсә МОСТАФИНА, 6 нчы класс укучысы.

## Нури Арсланов

### Сугышчы төше

Иркәләнәм кочагыңда
Назлы бер төндә,
Без бәхетле бу чагында,
Без икәү бергә.
Уянам, син юк янымда...
Мин ялгыз түгел:
Автомат кулда, аңымда —
Җиңү дә син гел.

1943

## Сибгат Хәким

### Йолдыз

Үзәнлектә җилләр уйнап йөри,
Яфракларны куып түбәнгә.
Маңгаенда кызыл йолдыз яна,
Кем ул күмелеп йоклый үләнгә?

Кем ул күмелеп йоклый? Милләте кем?
Кай өлкәдән? Кайсы авылдан?
Иленә кем булып хезмәт иткән?
Бу сугышка кайчан алынган?
Балалары бардыр, бәлки, аның,
Яшь егеттер, бәлки, кем белгән.
Ләкин безгә менә шунсы ачык:
Туган җире өчен ул үлгән.
Башына ул җылы бүрек кигән,
Туңмас өчен көзге салкыннан,
Карап ята көнбатышка таба
Күчеп барган фронт артыннан.

1943

## Рәисә Ишморатова

# РӘЙХАНӘ

ПОВЕСТЬ

*Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышлыйм.*
Автор.



Сөенечле көн бүген — Рәйхананең туган көне!

Әнисе аңа: «Син, балакаем, майның тугызында иртән дөньяга килдең, әйтепләр бетергесез матур көн иде. Гомерең дә кояшлы көнгә охшар, боерган булса»,— ди торган иде.

Ярты гасырдан артыграк гомер иткәч, әйтә ала инде Рәйханә — тормышы болытлы булмады аның. Гел кояш кына да елмаеп тормады торуын.

Иртән торгач, Рәйханә Казаннан кунакка кайткан оныклары Гөлнара белән Гөлназны ашатып-эчертеп уйнарга чыгарды да, квартирасын җыештырды. Эштәгеләрнең килеп чыгуы бар. Дөрес, атап берәүне дә кунакка чакырмады ул. Гомумән, туган көнендә кунак җыярга, мәҗлес корырга гадәтләнмәгән Рәйханә. Үзләре белеп, котларга килгәннәр рәхим итсеннәр: ишек уйган, тәрәзә куйган, ачык чырай, такта чәй.

Озак еллар шушы поселокта хезмәт итеп, районда гына түгел, бөтен республикада танылган доктор-нейрохирург ул Рәйханә Гаделшовна, танылган һәм зур хөрмәткә ирешкән бәхетле кеше. Шуның өчендер, мөгаен, аның туган көнендә кемнәр генә килеп керми дә кемнәр генә кинәнеп, тәм табып сөйләшеп утырмый. Үзеннән-үзе уртак бәйрәм килеп чыга.

Рәйханә, салмак кына атлап, стена буендагы зур көзге каршына килде дә уйга калды. Еллар үзенекен итә: Гомер яңгыры аның йөзендәге матурлыкны юган, елга сулары кебек гүзәл яшьлеген агызган. Вакыт нурлы битне эреле-ваклы сырлар белән бизәгән. Ул ирен кырыендагы борчак кадәр булып үскән миңгә карап торды.

— Әнинең дә шул төшендә миңе бар иде бит,— дип авыр сулап куйды Рәйханә. Аннары көзге каршысыннан китеп барды. Язу өстәле тартмасын ачты, тартманың уң кырыенда яткан кызыл төстәге папкага күзләрен төбәде. Аннан папканы ике кулы белән кадерләп күкрәгенә кысты. Папка эчендә хатлар иде. Ул иң өстә яткан хатны кулына алды, күзләрен йомып, аны ирен читләренә китерде. Шул вакыт күкрәктән чыккан моңсу, сабыр ир-ат тавышы бүлмә буйлап йөри башлады: «Туган көнең белән, кадерлем, туган көнең белән котлыйм».

Бераздан ишектә звонок чылтырады. Рәйханә сискәнеп китте. Хатны тиз генә папкага салды. Чәчләрен рәтләде, күзләренә бәреп чыккан яшьләрен кул кырые белән сөртеп алды:

— Кирәгез, кер, ишек бикләнмәгән.

Ай-кояштай балкып, ишектә унтугыз-егерме яшьләр тирәсендәге кыз күренде. Сөембикә икән!

— Исәнмесез, Рәйханә апа! — диде ул, ишектән керә-керешкә үк. — Тәбрикләргә кичекмим әле, миннән уздырмасыннар, дип ашыктым... Котлыйм, Рәйханә апа! Дәвалanучылар бәхетенә, безнең шатлыкка озак яшәгез, авырмагыз... — Ул Рәйханә апасына чәчәк бәйләме сузды.

— Рәхмәт, Сөембикә. Бик рәхмәт. Уз әйдә, түрдән уз. Хәзер чәй яңартабыз. Улым, киленем җибәргән күчтәнәчләр белән сыйлыйм әле үзеңне.

Чәчәкләрне вазага утырткач, Рәйханәнең сүзе янә кичәге операциягә әйләнеп кайтты.

— Иртүк шылтыратып белештем. Авыруның хәле җиңеләя. Һәрхәлдә, кризис үтте дип санарга мөмкин. Нык сагайган идем, дөресен әйтим.

Креслога барып утыргач, Сөембикә Рәйханә апасына сокланып карап торды. Әйтерсең лә беренче күрүе.

— Борчылуыгызны сиздем мин, Рәйханә апа. — Сөембикәнең йөзе җитдиләнеп калды. — Төн уртасы авышмыйча кайтып китмәвегездән үк аңладым.

— Ярамый иде, Сөембикә акыллым...

Чәй өстәле янында, үзе өчен җайлырак бер мизгелне тотып, Сөембикә моннан бер-ике атна элек әйткән гозерен янә искә төшерде.

— Мин, Рәйханә апа, теге чактагы үтенечемне дә әйтермен дип килгән идем инде.— диде. Үзе никтер уңайсызланып куйды, йөзенә алсулык йөгерде. Бер дә кирәкмәгәнгә, өстәл читен сыпыргалап алды.

— Ә-ә-ә, әйе, әйе. Кичә үзем үк әйтермен дигән идем, хәтеремнән чыгып киткән. Яздым мин сиңа, сеңлем, рекомендация. Бик теләп, күңелем ризалыгы белән, чын йөрәктән ышанып яздым. Менә дигән коммунист булырыңа ышанам, сеңлем... Менә ул. — Рәйханә язу-сызу өстәлендәге кәгазьләр арасыннан ак кәгазь битенә пөхтәләп язылган рекомендацияне алып Сөембикәгә сузды. — Рәхим ит, уңыш телим!

— Бик рәхмәт инде Сезгә, Рәйханә Гаделшовна! Ышанычыгызны акларга тырышырмын...

Рәйханә кызның иңнәреннән какты.

Сөембикә китте. Рәйханә күңеленә шатлык өстәп китте. Ни генә димә, тагын бер яшь кешегә партия сафларына басу өчен хәер-фатиха бирде булып чыга бит доктор Нәҗипова бүген. Утыз елдан артык партиядә тору вакытында шактый кешегә язды бит инде ул мондый рекомендацияләрне. Горурланырлыгы бар: тәкъдим иткән кешеләрнең берсе дә аның йөзенә кызыллык китергәннәре юк.

Аның да бар иде бит Сөембикә сыман каушап, дулкынланып, өлкән коммунист Анна Захаровна алдына килгән чагы.

Доктор Рәйханә Нәҗипованың күз алдына узган тормышы, үнсигез яшен тутырган чагы килде. Күптән түгел генә булган кебек бит ул көннәр.

* * *

Райком бинасыннан урамга чыккач, ничә минуттыр әйләнә-тирәгә карангалап басып торды Рәйханә. Аның колакларында бюрода утырган кешеләрнең тавышы чыңлый иде:

— Алырга, кабул итәргә, бертавыштан!..

Рәйханә күңелендә канатланган шатлык тойгысы күкрәк читлегенә һичничек тә сыярлык түгел иде. Әлеге шашкын тойгы иреннәрендә елмаю булып калыкты, күзләрендә бәхет чаткысы булып кабынды. Һәм ул чаткылар, чык бөртекләредәй, сөенеч яшьләренә әверелделәр. Рәйханә, иреннәрен көчкә генә дерелдәтеп, «рәхмәт» әйтеп, кабинеттан тизрәк чыгу ягын карады. Куанычыннан елап җибәрүең дә бар. Әйтерләр аннары — менә сиңа мә, диярләр, партия сафларына бер елак кызыйны алганбыз бит, диярләр...

Урамдагы әче суык, Рәйхананең эченә үтеп кереп, аны калтыратып куйды. Ул кесәсеннән кулъяулык алып күзләрен сөртте, башындагы зәңгәр береткасын басыбрак киде, колакларын томаларга теләп, тунының якасын күтәрде. Ләкин баскан урыныннан тиз генә кузгалмады. Ирен-нәренә елмаю чыгарып, кар өеме баскан урамга карады. Урамда кеше күп йөри дигән сүз дөрес түгел иде. Йөрмиләр, йөгерәләр алар, салкыннан качалар. Поселокта хәзер сугыш астыннан килгән төрле милләт кешеләре яши. Алар җылы яктан эвакуацияләнеп килгәннәр монда. Салкын кыш өчен өс-башлары да аннан-моннан гына. Түбәләре калай-такта белән япкан кечкенә агач өйләрнең моржаларыннан күксел төтен чыга да тип-туры булып күккә күтәрелә — һаваның үтә салкын булу галәмәте. Аяк асты шыгыр-шыгыр килә. Рәйханә, күзләрен йомып, шул тавышны тыңлый. Госпитальдәге яралы солдатларның култык таяклары да шулай шыгыр-шыгыр итә бит. Рәйханә кызу гына алга атлады. Ул кинәт сискәнеп китте. Колагында Әмирнең тавышы ишетелгән сыман булды.

— Партия сафына аяк басуың белән чын күңелдән котлыйм. Син бүген тормышыңда бик җаваплы адым ясадың. Мин моны батырлык та, батыр булырга ант итү дип тә аңлыйм. Гомер юлын кулга-кул тотынып бергә үтик. Минем чын терәгем бул, яме. Ә үзең һәрчак миңа таян.

Рәйхананең күзләренә дә яшь бәреп чыкты. Кайнар яшь шунда ук бозга әверелеп керфекләренә сарылды.

— Әмирем, нигә син хат язмыйсың!.. Ике айдан артык хатың юк. Яз инде, бер генә сүз... Ул хат миңа яшәү көче бирер иде. Килер көннәремә өмет балкышы тудырыр иде.

Шулчак каршысына аякларына зур гына киез итекләр, башына сарык йоныннан бәйләгән шәл ябынган бер ханым килеп чыгуын искәреп алды Рәйханә. Аңа юл биреп узып китмәкче булды, әмма ханым аны туктатты.

— Рая бит Сез, әйеме? — диде ханым, күптәннән аралашып йөргән кешеләрчә якын күргәнен сиздерергә теләп. — Мне һоворили, что вы... — Ханымның украин акценты чәчрәп тора иде.

— Әйе, Рәйханә мин. Ни йомыш бар иде?

Украинлы ханым, бу суыкта урам уртасында туктатып торуы өчен гафу сораган кыяфәттә:

— Бер генә минут сабыр итегез, зинһар,— диде. — Мин Сезне өчен-че көн инде очрата алмый йөрим. Бүген менә күктән көткәнне җирдән бирде,— дип өстәде.

Рәйханә, аякларының туңуыннан гаҗиз булып, ханым каршысында сүзсез генә басып тора бирде.

Ханым шәле төсле үк сарык йоныннан бәйләгән бияләйләре белән Рәйхананең беләкләреннән тотты һәм үтә рәхмәтле чырай белән:

— Раечка, сөеклем, рәхмәт әйтергә дип эзлим мин Сезне. Кылган яхшылыгыгыз өчен, Раечка!.. — дип сөйләп китте.

— Беләсезме, Иһорек сөйләгәч, эчем бушаганчы бер еладым. Сугышны мең кат ләгънәтләдем. Мондый хәлдә идекмени без! Ә Сез мәрхәмәтле җан, кадерлем Рая...

— Мин Сездән үтенәм, аңлатыбрак сөйләгезче, мин эшкә ашыга идем,— диде Рәйханә, ничек тә ханымны рәнҗетмәскә тырышып.

— Сез минем улым Иһорекне тәмләп сыйлагансыз. Рәхмәт инде Сезгә. Киләчәктә дә, зинһарлап сорыйм, ялварам. Бала бит... Ачыгабыз. Аннан да дәһшәтле нәрсә юк. Һолод — царь! Һолод!..

Ниһаять, төшенде Рәйханә. Мәгәр фикеренең очын-очка ялгарга өлгермәде, теге малайны шушы ханымның улы итеп күз алдына китерә алмады. Пелагея Николаевна үз хәлләрен бәйнә-бәйнә тезәргә теләде.

— Киевтән, сугыш астыннан килдек без. Өч баламнан башка бернәрсә дә ала алмадык. Ярый әле монда яхшы кешеләргә килеп урнаштык. — Ул үзенең аягындагы иске генә киез итеккә карап алды, аннан өстендәге бишмәтенең җиңнәрен сыпырып куйды. — Өс-башыбызга да булды. Шулай да бик авыр, ачыгабыз, туңабыз. — Аннан житез генә

сул кулындагы бияләен салды, атсыз бармагына кигән кашлы йөзеген алып Рәйханәгә сузды.

— Арзанга гына сатам. Алыгыз. Сезгә булсын, белмәгән кешеләргә сатканчы, дим.

Рәйханәнең әле үз гомерендә мондый матур, затлы йөзекне күргәне юк иде. Күзне чагылдырып торган кашына исе китеп карады. Сокланды, кызыкты, ымсынды хәтта. Башыннан: «Алыйммы әллә?» — дигән уй сызылып үтте. Йөзекне ала алмаганлыгын кып-кыска, туп-туры әйтте. Пелагея Николаевна аның саен үҗәтләнә иде.

— Миңа хәзер берни дә кирәкми. Ирем исән-имин сугыштан кайтсын иде дә...

Сүзне сузудан мәгънә юк иде.

— Хушыгыз, Пелагея Николаевна, миңа китәргә кирәк. Хушыгыз, гафу итегез,— дип, шактый кырысланып китеп барды Рәйханә. Болай дорфалануыннан үзе үк уңайсызланды. Ләкин бит кулындагы йөзеген салып сиңа бирергә өтәләнгән ханымның өстенә карап торуы да газап иде.

Ханым белән очрашу аны янә авыр уйларга дучар итте. Үлем, кайгы-хәсрәт, күз яше, гариплләр, хәрабәләр һәм шуларның барысы өстенә ачлык!.. Ашарга житешмәүдән дә фаҗигалерәк хәл булырмы? Ашыйсың килеп өзгәләнгәндә, тамагың түйганчы ашый алма!.. Әтисе Гаделша карт әйтә бит: — Ачлык кешенең вөжданын кимереп юкка чыгара, намусын тузан итеп көлгә очыра, оятын терекөмеш кебек качыра. Ачлыктан изаланган бәндә әллә нинди яраксыз эшләр кылырга да мәҗбүр,— ди.

Егерме беренче ел ачлыгын кичергән картның сүзләренә теләсәң-теләмәсәң дә колак салырсың. Госпитальнең икенче корпусына кайтып житәрәк, дәвалау йорты персоналы гына кереп-чыгып йөри торган арткы ишекне күргәч, Рәйханәнең исенә Игорек килеп төште. Моннан ничәдер көн элек, унике-унөч яшьләр чамасы малай ишектән акрын гына атлап керде дә туктап бүреген салды. Бер урында таптанып торгач, ишек янагына сөялде. Дөньядан үткән кеше кебек иде әлеге үсмер. Йөзе сулган, көлсу чырайлы, карашында нур юк. Рәйханә, аш бүлмәсенең ишеге янында басып, малайны бераз күзәтеп торгач, аның янына килде, малайның маңгаена төшкән куе чәчләрен артка сыпырды һәм йомшак тавыш белән:

— Кем дә булса кирәкме әллә сиңа, үскәнем? — диде.

Малай бер сүз дә әйтми Рәйханәгә карап тора бирде. Рәйханә аның иңсәсеннән җиңел генә кочып алды да алга таба этәрде. Аш бүлмәсенә кергәч, аны тәрәзә кырыендагы өстәлнең бер кырыена утыртты, алдына зур гына савытка аш салып куйды. Аш бүлмәсендә берәү дә юк иде. Рәйханә ишекне япты да коридорга чыкты. Тиз-тиз атлап, үзенең эш бүлмәсенә китте. Аннан үз өлешенә тигән икмәк кисәге, берничә шакмак шикәр алып килеп, малайның кесәсенә салды.

Малай: «Рәхмәт Сезгә, апа, рәхмәт»,— дип сөйләнә-сөйләнә тышкы ишек төбенә килде. Кулын ишек тоткасына куйды, кабат артына әйләнеп карады. Тамак ялгавына сөенеп елмаямы дип торса, Рәйханә аның күзләрендә яшь бөртекләре күрде.

Рәйханә аш бүлмәсенә кереп бикләнде дә өстәленә капланып үкседе: «Каһәр төшкән сугыш! Муеның астына килгере Гитлер! Ни өчен сыңар сыныкка мохтаҗ булырга тиеш тә ни өчен тамак ялгау оятыннан яшь түгәргә тиеш кешеләр. Безнең буын илдә ачлык, ялангачлык дигән каһәрле хәлләрне белми иде бит инде. Балачакны да, яшьлекне дә урлады бу сугыш... Кайчан гына сытарлар фашист аждаһасын?..»

Уйларына бирелеп, ишек төбенә житкәч, Рәйханәнең исенә кылт итеп төшкән нәрсә Тукай томы булды. Бишенче палатадагы сержант, Гамир исемле яралы егет, Тукай шигырьләрен алып кайта алмассыңмы, дип бик үтенгән иде. Онытты Рәйханә, партия райкомыннан артык дулкынланып чыгу галәмәте иде инде. Кире барыргамы? Ерак. Чакрым гына түгелдер... Бармасаң, Гамирга ни диярга? Вәгъдә иткән иде бит. Барырга

кирәк! Моннан ярты сәгать элек кенә бюро членнары алдында барлык авырлыкларны җиңәргә бүгеннән әзер дип гайрәт чәч тә, бик кечкенә генә эшкә килеп терәлгәч, әрәмәлеккә посмы? Юк инде, монысы килешкән эш түгел!

Рәйханә госпитальгә кереп җылынып та тормады, район китапханәсенә йөгерде. Тик озак юырта алмады. Каршы җил тынны кыса, битне көйдерә иде. Ул аркан борылды, сәхнәдә биегәндәге кебек, вак-вак адымнар белән юлын үрчетмәк булып тырышты.

Бу бинада Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр мәктәп иде. Хәзер монда эвакуацияләнгән госпитальнең икенче корпусы. Хәзер монда авазларның бөтенләй икенче төрлесе. Авыр яралылар ыңгыраша, операция кичерүчеләр сызлана. Тыныч, имин чорда коридор буйлап көчләрен кая куярга, энергияләрен ничек сарыф итәргә белмәгән сау-сәламәт кызлар, малайлар тыз-быз килсә, сугыш башланган елның август аеннан бирле, (ә хәзер 1942 елның декабрь ае) монда култык таякларына таянган, кулларын гипслап муеннарына аскан, башларын кат-кат акка ураган, тәннәрендә һәм йөзләрендә әллә ничәшәр яра эзе, җөйләр булган яралылар ята. Аларның хәрәкәте дә үтә салмак, чиктән тыш сак, тавышлары да бик басынкы, уйлары да кургаштай авыр.

Элекке мәктәпнең бу классы иркен, якты. Мәгәр һич кенә дә җылытып житкерә алмыйлар аны. Бина искергәнме, ишек-тәрәзәләре кирәгенчә каралмаганмы, әллә ягу сугыш нормасы вакытынча чамалымы. Урамдагы 45-50 градус салкынлык биналардагы җылыны аямыйча суыра. Ничек кенә димә, яралыларның мамыклы җылыга тиенгәннәре юк. Шул хәл аларны одеялларына ныграк төренергә мәҗбүр итә.

Шулай да, сугыш зилзиләсен кичкән ир-егетләр тән тунуга чыдыйлар, түзәргә тиешбез дип карыйлар, зарланмыйлар. Җан өшүе тинтерәтә аларны, җан көшегүе... Кайвакыт стенадагы репродукторның кара тәлинкәсен бәреп төшерердәй булалар. Гәрчә бик анык беләләр: репродукторның да, Мәскәү радиосы дикторының да кара кайгыга сала торган хәбәрләр тапшыруда тырнак очы кадәр дә гаепләре юк. Юк, әлбәттә. Әмма нервылар шул тикле киерелгән, шул тикле тартылган, чыңлап тора. Тагын бер көчәнү була калса, барысы да шартлап өзеләчәк сыман.

Канга тоз салганы, йөрәкләрдә һичничек тә юып алалмаслык булып укмашкан нәфрәт тудырганы — фашистларның илебез халыкларына каршы эшләгән коточкыч җинаятьләре. Егерменче гасыр вандаллары тарих моңарчы белмәгән-күрмәгән ерткычлыклар кылалар. Әнә, Мәскәү тагын Совинформбюро белдерүен тапшыра:

— ...Фашист илбасарлар Смоленск өлкәсенең Снори һәм Головицы авылларында берьюлы уналты йортны яндырганнар. Бер яшьтән алты яшькә кадәр булган өч баласы белән бергә колхозчы Заболоцкаяны атып үтергәннәр...

Ишектән, сизелерлек аксый-аксый, Самат килеп керде. Ул, берәүгә дә сүз кушмастан, бүлмә уртасына баскан килеш, стенадагы кара тәлинкәгә төбәлде. Бер кулы терсәктән киселгән, икенче кулы гипска катырып иңсәсенә асылган чандыр гәүдәлле, озын буйлы, какча йөзле Гамир белән киң җилкәле, тузгып торган кара бөдрә чәчле украин егете Еременко Микола да Самат янына килеп бастылар.

— ...Иртәгә 25 декабрь — Украина Совет Социалистик Республикасының егерме биш еллыгы. Илебез бу датаны авыр һәм дәһшәтле көннәрдә билгеләп үтә. Немец-фашист илбасарлары Украинада ике миллионнан артык кешене газаплап үтерделәр. Аттылар, утта яндырдылар...

— У-у-х! — Микола йонлач зур йодрыкларын төйнәде. — Кирәк бит шундый көннәрдә аякларым, кулларым сау килеш госпитальдә ятарга! — Ул койкалар арасында ярсып йөренә иде. Аның кыяфәтендә ярсуга әверелгән нәфрәт чагыла. Әйтерсең лә читлектәге арысланның ярсуын кузгаткан нар. — Иртәгә үк госпиталь начальнигы исеменә рапорт кертәм. Подду-

маешь, кабыргалар ялганып житми! Температура, имеш! Монда ялганмаганы фронтта ялганып бетәр.

Туган республикасының, үзе туган Киев шәһәренең бу көннәрдәге аяныч хәле, андагы фажигаләр өчен Миколаның өзгәләнүен Гамир аңлый, Еременкога тулысынча теләктәш ул. Украин егетенең шашкынлыгын йөрәгенә мүк үсмәгән һәр солдат төшенә ала. Аның сугышка ырГуы, оптимизмы, көрәшкә сусап торуы күпләргә хас. Саматка килгәндә, Гамир аның үтә кәефсезлегенең сәбәбен төшенеп житми. Тиктомалдан төпченәсе дә килми. Шулай да Гамир палатадашына сүз кушмый түзмәде.

— Карап-карап торам да, Самат дус, синең кәеф градусларың түбәнрәк бит, агай, әй! — Гамир бу сүзләрен самими сөйләде, ихластан. — Төннәрен йокың шәп түгелме? Бүген төшке ашны бөтенләй ашамадың...

Саматның ачылып сөйләшәсе килми иде. Шулай да ул кулын селтәде, усал итеп әйләнә-тирәгә карап алды:

— Ашка килгәндә, ашарлык идеме соң? Бурда иде бит! Авызың тәм тоймыймы әллә синең, Гамир?

Гамир алай дип тә, болай дип тә җавап кайтарырга өлгермәде, койкасына барып утырган Микола без кадалган шикелле сикереп торды да, Саматны йолкып ташлардай булып, каршысына килеп басты. Сүзләрен теш арасыннан сыгып чыгарды.

— Син нәрсә? Профессор семьясында шоколад ашап үстеңме әллә? Ленинградта бик тәмледер ашлар! Чама югалтасың, солдат! — Кара тутлы Микола да ачудан кызарып чыкты.

— Өлкән сержант! — дип куйды Самат, Еременкога карамый гына.

— Тем хуже для тебя! — Микола ярсуын тыя алмый иде. — Сержант — тәрбияче, үзең шыңшыйсың... Сержант бул, майор бул, тагын әллә кем бул, иллә мәгәр ашны хурлама! Бурда, имеш! Блокададагы кешеләрнең хәлен күз алдына китер. Оккупациядә калганнарның язмышын уйла!

Саматның ачуы Миколага түгел, ашханәдәгеләргә, кухня кешеләренә төбәлгән иде. Шуны аңлатмак булып, ләкин пырдымсызлыгын танырга теләмичә генә сөйләнә бирде.

— Башка көннәрдә ашап туеп булмый иде. Ә бүген шулпага су кушканнар. Кайнатып та тормаганнар, просто салкын су тондырганнар...

Гамир егетләр арасында купкан күңелсез низагны туктатыр өчен үз фикерен белдермәк булды.

— Самат хаклы, Микола. Бүген аш тәмсез иде,— диде.

— Аш вакытында сестра-хозяйка юк иде, вот и вся опера!. дип Микола, җәнҗалдан баш-аяк дигән төсле, палатадан чыгып ук китте.

— Сиңа кәефеңне кырырга ярамый, Самат... — Гамир тагын иплэп кенә сүз башлады. — Савыгып житү өчен авылыгызга кайтаралар үзеңне. Тиздән жырларда жырлана торган Сарманда булырсың, авылдашларың арасында...

— Кайтмыйм мин авылга, сержант, кайтмыйм. — Ни өчендер әлеге сүзләрен Самат бик басымлап әйтте. — Фронтка жибәрүләрен сорап гариза яздым. Аңларлар, житәкчеләр башсыз түгел бит, үтенечне канәгатьләндерерләр әле.

— Медиклар дәвалануны дәвам итәргә диләр икән...

— Барыбер үз дигәнемне итәчәкмен... — Саматның карары катгый, ышанычы зур иде.

— Да-а-а! Тешләрен кысудан Гамирның яңак сөякләре уйнап алды— Да-а-а! Әгәр шушы хәлгә калмаган булсам, бер минут тормый, фронтка сорар идем, үз частемә... Өметләремне җилгә очырды шул фашист минасы!..

Самат уң кулының бармаклары белән чәчләрен аралаштыргалады, авыр көрсенеп куйды.

— Я, әйт, нишлим мин авылда? Миндәй егетләр барысы да фронтта. Бала-чага, әби-бабайлар белән...

— Колхозда кеше артык булмас анысы, иптәшкәем,— диде Гамир йомшак кына. — Бер кулыңа ике, өч эш табылыр анда.

Самат сүз көрәштермәде, тынып калды. Миендә умарта иледәй гөжләгән уйларыннан байтак кына арына алмый утырды. Аннан әченнән үз-үзенә сөйләнде: «Эх, аңламыйсыз, берегез дә аңламыйсыз хәлләремне. Үземне дә аңламый торган хәлдә мин хәзер. Минем өчен әлегә кадәр дөньяда бертөрле авырлык та, хәсрәт тә булмаган икән».

Казан төзүчеләр институтының икенче курсында укырга тиешле Самат, сугыш башланып, бер ай узуга, үзе теләп фронтка китте. Әти-әниләренә дә әйтмәде: — Сугыш бернichә айдан бетәр, фашистның муенын сындырып кайтыйк әле, әтиләрнең исе китсен,— дип көлә-шаяра сөйләнде Самат, өстенә солдат шинеле кигәндә. Чынлыкта исә тиз генә әйләнеп кайта алмады. Ике тапкыр яраланды ул. Өченче кат яралануы өч айга аны сугыштан, туганлашып беткән сугышчан дусларыннан аерды. Ут яуган, металл яңгыры яуган җирләрдән аерып, Казаннан ерак түгел район үзәгендәге шушы госпитальгә илтеп ташлады. Госпиталь койкасында аунап яткан озын көннәрдә ул бу сугышны бөтен вак-төяге белән күз алдына китерә торган булды. Төшенә кереп котың очып, йөрәгең ярылырлык хәлләрне уйлаганда, күңелен яктырткан бер нур аның тормышын, бүгенгесен, киләчәген биләп алды. Ул шул нурга сыенган саен, аягындагы авыр яра тизрәк төзәлде, йөрәге дә кысып-кысып авыртмады. Киресенчә, өзгәләнде, ашкынды ул йөрәк, әллә нинди авыр җаваплы эшләргә өндәде. Бик куркыныч булган сугыш юлларына кабат-кабат чакырды Саматны. Барысына да риза ул, тик сүнмәсен иде ул нур.

Госпитальнең шушы корпусына килеп кергәч тә аларны — унбиш яралыны — йомшак кына сөйли-сөйли, ачык йөз белән Рәйханә каршы алган иде. Өсләренә чиста киемнәр кияргә ярдәм итүче дә ул булды. Юлда төрле-төрле газаплар күргән, арыган, талчыккан яралылар җиңел итеп сулыш алдылар. Самат Рәйхәнәнең иңсәсенә кулын куеп аксаклый-аксаклый палатадагы чиста урынга килеп ятты. Бер стакан җылы сөт эчте дә шунда ук йокыга китте. Иртәгесен, йокыдан уяну белән, күзләрен ишеккә текәп, кичәге мөлаем кызны көтә башлады. Әйтерсең бары ул кыз гына аны терелтеп аякка бастыра алачак иде. Шул көннәрдән бирле Рәйханә палатага килеп керсә, Самат өчен иң ләззәтле, бәхетле минутлар башлана иде. Аягының сызлавы да, врачларның: «Кисәргә генә булмаса ярар иде»,— дигән шом тулы сүзләре дә истән чыгып тора иде шикелле. Шәфкать туташының палатада озаграк торуын, үзенә кат-кат эндәшүен, һич югында әледән-әле аңа карап куюын тели иде Самат.

Ничә мәртәбәләр Рәйханәгә ул үзенең мәхәббәтен аңлатырга тырышты: «Син минем фәрештәм»,— дигән сүзләр дә әйтте. Ләкин Рәйханә күзләрен тутырып Саматка карады да:

— Андый сүзләрегезне кабатлый торган булсагыз — мин Сезнең белән сөйләшмим дә,— диде.

Инде китәр көн дә килеп житте. Рәйханәдән аерылу аңа үлем газабы кебек авыр кебек иде. Рәйханәнең бер сүзе, бары бер генә сүзе аның хәлен жиңеләйтә алыр иде. «Сугыштан исән-сау кайтуыңны көтәрмен»,— дисен иде ул. Шуннан башка берни дә кирәкми. Әй, кырыр иде Самат фашистларны. Өрлектәй егетләрнең: «Илем өчен, анам өчен, сөйгән ярым өчен»,— дип ут эченә ташлануларын белми ахры Рәйханә... Күрсә иде шулчак егетләрнең нинди көчле булуларын. Ул, уйларыннан арынып, бер ноктага карап торды да:

— Кая югалды соң бу Рәйханә? Кич житә бит инде? — дип Гамирдан сорады.

— Үзем дә шуны уйлый идем, озак йөрде бүген сестра,— диде Гамир.

Нәкъ шулчак әкрен генә ишек шакыдылар. Гамир да, Самат та берьюлы:

— Мөмкин, мөмкин, керегез,— диделәр.

Ишектән Рәйханә килеп керде. Гамирның озын какча гәүдәсе чайкалып киткәндәй булды. Тузгыган чәчләрен рәтләргә теләгәндәй, киселгән кулын баш өстенә китерде. Самат төз, таза гәүдәсе белән алга, Рәйханәгә таба атлады. Ләкин Рәйханә аның шатлыклы, ашкынулы йөрәк тибешен сизмәде, кызу-кызу атлап, Гамир каршысына килеп басты һәм Тукай шигырьләре тупланган калын китапны аңа сузды. Саматның аркасына йөзләгән инә кададылармыни, ул сискәнеп куйды һәм палатадан чыгып ук китте.

Гамир китапка сузылмакчы булды, ләкин кулларының берничә дә ярамаганын тоеп, бите кызарып китте, башын аска иде. Рәйханә китапны тумбочка өстенә куйды. Үзе Самат караваты янына килде, бүлмә буйлап күзләрен йөртеп алды. Ул Саматның бүлмәдән чыгып китүен сизми дә калган иде.

— Кай арада чыгып китте соң әле безнең сержант? — дип, елмаеп, Гамирга карап алды. — Урамда шундый суык, шундый суык, катып үләм дип торам...

— Рәхмәт инде, сестра, мәшәкатьләдем, чыннан да суыклык илле градуска җиткән диме?.. Шундый вакытта китап дип йөрергә идеме соң?..

Рәйханә, уң кулын ишек тоткасына куйган килеш, беравык нәрсәдер уйлап алды да, кыю гына:

— Гамир абый, минем Сезгә бер үтенечем бар иде.— диде.

— Үтенеч үк дисең. Минем хәлдән килердәйме? Булдыра алсам — баш өсте.

— Булдырасыз, Гамир абый. Сез бит урта мәктәпне тәмамлагач, мәктәптә елдан артык укытырга да өлгергәнсез, математика укыткансыз.

— Хак сүз, Рәйханә сеңлем. Математика — минем сөйгәнем иде инде ул.

— Миңа шул сөйгәнегез белән дуслашырга булышыгыз. Яңа елдан читтән торып уку мәктәбенә керәм. Сугыш беткәндә, урта белемле булырга тиеш мин. Ә математикага, дөресен әйткәндә, теш бик үтеп җитми. Дәреслекләр таптым, булышырсызмы, Гамир абый?..

— Рәхәтләнеп, сеңлем Рәйханә... Үзем өчен дә искә төшерү булыр. Аннан соң, ни бит... Үземнең бер эшкә яравымны тоярмын, юаныч булыр, әй!

— Алайса килештек, Гамир абый? Иртәгә беренче дәресне башлыйбыз, ярыймы?

— Хет бүген үк, Рәйханә сеңлем... Ә син кайларга китеп югалдың соң, сеңлем?

Рәйханә бу сорауны көтеп торадыр иде сыман. Шатлыгын яралылар белән дә уртаклашасы килә иде аның.

— Югалмадым,— диде ул, сөенечен яшермичә. — Мине бүген партия членлыгына кандидат итеп алдылар, Гамир абый!

— Сине?..

— Нигә гаҗәпләндегез?..

— Бигрәк тә яшь, бәләкәй ич әле син, сеңлем!

Рәйханә үзе өчен гайре табигыйрәк горурлык белән:

— Сугыш тиз олыгайта безнең кордашларны,— дип куйды.

— Анысы хак. Хак әйттең, үскәнем. — Рәйханә куанычының бер өлешен үзенә алгандай, Гамир дулкынланып калды. — Котлыйбыз, котлыйбыз! — Кызның кулларын кысып тәбрикли алмавына Гамирның тагын җаны әрнеде. Адым саен күңел ярасына кагыла да тора бу тормыш. Ул, авыр сулап, ак боз тактага әйләнгән тәрәзә буена китте. Рәйханә аның бәгыре иңрәвен сизми калмады. Гамирга таба ике-өч адым атлады да кулын аның иңенә куйды.

— Зинһар борчылмагыз, Гамир абый.

* * *

Икенче көнне, яралылар иртәнге аштан таралгач, һич югы ярты сәгатькә дип, Рәйханә Гамир абыйсын үз бүлмәсенә чакырды. Кыз гадәттәгедән иртәрәк килеп, көндәлек мәшәкатьләрен түгәрәклап куйган, бик

аз гына булса да вакыт отарга җыенган иде. Дәреслекләрне кулга алырга кирәк, бер тотынсаң, эш акрынлап булса да үрчи ул, дип фикер йөртте.

Урын-җир, кием-салым, савыт-саба һәм башка хуҗалык кирәк-яраклары тулган бүлмә уртасында алар икәүдән-икәү калдылар. Гамир — укытучы (ул бүген үзгәреп, җитдиләнеп, уйчанланып киткән). Рәйханә — остазының авызыннан чыккан һәр сүзне анасы томшыгыннан җим алган кош баласы кебек йотып җибәрергә торган укучы.

— Вакыт тар инде, Гамир абый. Хезмәттәге кешенең чит эшкә вакыты булырга да тиеш түгел. Шулай да башлыйк әле,— диде Рәйханә.

Клеенка ябылган өстәл өстендә алгебра дәреслеге һәм мәсьәләләр җыентыгы ачылды.

— Немец снарядлары шартлавы баштан бар белгәнне бәреп чыгармадымы икән соң? — Гамир шулай сөйләнеп алды. Бик кыска вакытка гына булса да сугышка кадәрге хезмәтенә кайту аны сәерсендергән иде.— Без, Рәйханә сеңлем, квадрат тигезләмәдән башлап керешик әле. Ни генә димә, математика дигән зиннәтле дә, хикмәтле дә зур сарайга керү өчен ачкыч сыман ул тигезләмәләр.

Рәйханә ручка алды, түгелми торган кара савытына каләмен манды, ләкин маңылмады. Пыяла савыттагы язу карасы туңган иде.

— Карандашың бардыр бит, сеңлем?

— Бар, Гамир абый, бар.— Рәйханә халат кесәсеннән карандаш чыгарды.

Гамир тигезләмәнең формуласын әйтеп яздыра башлады.

— Яз әле, сеңлем! — Гамир тавышында вәкарь сизелде.— Икс тигез... Санаучыда...

Шул чак ишек шакыдылар. Җавап та көтеп тормастан, бүлмәгә бүлек начальнигы Анна Захаровна килеп керде. Озын зифа буйлы, зур зәңгәр күзле, бөдрәләнеп торган сары чәчләрен кыска итеп кистергән, кырык яше якарак кына узган бу хатынның йөзе күп вакыт кырыс, күз карашлары борчулы була иде. Ул ишек буенда туктап калды, Рәйханә янында Гамирны да күргәнгәме икән, аерата кырыслана төште.

— Мин сине бик эзләдем, Нәҗипова,— диде.

Рәйханә өстендәге халатының җиңнәрен рәтле-рәтле аягүрә басты.

— Исәнмесез.

— Исәнмесез... Сезгә эш сәгатендә корпуста булырга кирәк дип кисәтеп әйтелгән бит, Нәҗипова!

Рәйханә башка вакытларда кырыс тон белән сөйләнгән сүзләрдән югалып кала иде. Бу юлы ул үзен тыныч һәм иркен тотты. Чөнки райкомга бюрога китүе турында Анна Захаровнага әйткән иде. Оныткан, күрәсең.

Рәйханә тавышында горурлык сизелде:

— Мин райкомда булдым бит, Анна Захаровна, мине кабул иттеләр! — диде.

Анна Захаровна капылт кына башын югары күтәрде. Рәйханәгә, аны әле генә күргән кебек, күзләрен зур ачып, томырылып карап торды. Аның йөзе яктырып китте. Рәйханәнең әле кайчан гына, дежур бүлмәсенә кереп, ояла-тартына гына партиягә керергә аңардан рекомендация соравын исенә төшерде. Ул Рәйханәне кочып, үбеп алды.

— Молодец, котлыйм... Синең шундый шатлыклы көнеңдә корпуста күңелсезлек килеп чыкты. Алай дию генә дә аз. Хурлык, зур хурлык.— Анна Захаровна озын нечкә бармаклары белән өстәл кырыена шакыды. Кызга борчулы караш ташлады. Рәйханә сагая калды. Ул Анна Захаровнаның юкка-барга тавышланып, вак-төякне күпертеп-кабартып йөри торган кеше түгеллеген белә. Аның кырыслыгы мәгънәсез усаллыкка кайтып калмый.

Рәйханә, нәрсә диярга дә белми уңайсызланып, бүлмә уртасында басып тора бирде.

Бүлек начальнигы исә, сул беләгендәге алтын сәгатенә күз салып алды да:

— Ўн минуттан барлык санитаркаларны минем бүлмәгә җыегыз! — дип чыгып китте. Рәйханә формула һәм мисаллар язылган иске китапны бер читкә этәрде. Гамир аңа нәрсәдер әйтергә теләгән иде, ләкин сестра күтәрелеп карамыйча гына ишеккә юнәлгәч, егетнең Рәйханәгә иярүдән башка чарасы калмады.

Корпуста җиде санитарка. Башлыклары — Рәйханә. Алар яралы сугышчыларны көненә өч тапкыр ашатырга-эчертергә, атнага бер мәртәбә урын-җирләрен, өс-башларын алмаштырып, мунча кертергә, палата эчләрен, коридор, зал һәм башка урыннарны чиста тотарга тиешләр. Яңа килгән яралыларны тиз һәм тыныч кабул итү дә аларга йөкләнгән. Санитаркалар кулларыннан килгәнчә һәр эштә тәртип, төгәллек сакларга тырышалар. Икенче корпус госпитальдә алдынгылардан санала. Аның байтак кешесе Почет тактасында. Бу казанышта Анна Захаровна белән Рәйханәнең дә өлеше бәхәссез. Тик, никадәр тырышмасын, Рәйханә җитәкләгән участокта юк дигәндә дә эчпошыргыч күңелсезлекләр чыгып тора. Менә бүген дә төшке ашны егерме минутка соң биргәннәр. Аш сыек һәм тәмсез булган. Өстәмә ашны теләр-теләмәс кенә өләшкәннәр. Сәламәтләнеп, шушы көннәрдә кабат фронтка китәргә тиешле бер солдат бу хакта шактый чәнечкеле итеп Анна Захаровнага әйткән. Үзе өчен кайгыртудан битәр, госпитальдә әле озак дәваланасы кешеләр өчен борчылып сөйләгән. Анна Захаровна исә, Рәйханә үз урынындадыр, аңа әйтегез дип, тыныч кына үз эшләрен караган. Соңыннан — аш бүлүче Хөсниянең бер чиләк майлы куе ашны яшереп куйганлыгы ачыкланган.

Анна Захаровна Хөсниягә башта иплән кенә аңлатырга тырышты. Сугыш чоры законы буенча бер кадак икмәк өчен дә хөкемгә тарту мөмкинлеген, законның үтә кискен булуын сөйләде. «Әгәр бу җинаятең өчен судка бирсәк, балаларың ятим ка́ла бит синең!» — дип куркытып та карады. Бу караклык бүлек начальнигының канын кайнатты. Ләкин Хөсния аның сүзләрен аңламадымы, әллә, аңлап та, башын тилегә салырга маташтымы, бер дә исе китмәгән кыяфәттә:

— Биреп карагыз судка, шундук Мәскәүгә, Сталинның үзенә язам! Минем ирем — сугышта геройларча үлгән солдат. Нәрсә өчен ул анда үлеп калды? Өч балам ачка үлсен дипме? Нәрсә ашатыйм мин аларга? — дип тавышланырга кереште.

Анна Захаровна алдындагы кәгазь кисәгенә нәрсәдер язды да Рәйханәгә сузды.

— Хөснияне бүген үк палата санитаркасы итеп күчерегез. Ашханәгә Фатыйманы алырсыз,— диде.

Санитаркалар Анна Захаровна бүлмәсендәге сөйләшүдән соң эш өләшү бүлмәсенә җыелдылар. Хөснияне бик каты орыштылар, оялтырга тырыштылар. Рәйханә, нинди нахаклар ишетәсен уена да китермичә, барысыннан да бигрәк ярсыды. Ул корпустагы мондый хәл аркасында җир ярылса, җир астына төшеп югалырга әзер иде. Хөсния каршысына басып:

— Яралылар күзенә ничек күренергә? Уйладыңмы ичмасам шул турыда, Хөсния апа? Хурлык бит, хурлык! — дип өзгәләнде.

Хөсниянең үз уенча, кулында Рәйханәгә каршы торырлык «уен тузы» бар иде. Ул сөттән ак, судан пакь кеше төсле гайрәт чәчте.

— Синнән үрнәк алабыз, җанашым! Син бит украин марҗаларына ипи, шикәр бирәсең дә алардан затлы нәрсәләр җыясың! Әллә белмибезме? Без генә түгел, поселоктагылар да белә, алтыным! — дип тәтелдәде.

Рәйханә, хәйран калып Хөсниягә карады да тораташ сыман катты. Ажгырып торган Хөсниягә нәрсәдер әйтергә теләде, тик теленә үзен якларлык та, Хөснияне акылына утыртырлык та сүз килмәде. Күз яшенә буылып торгач, аның авызыннан: «Ялган!» — дигән сүз генә сытылып чыкты һәм ул бүлмәдә кала алмады.

Хөсния аның саен ярсына барды.

— Чыгып качтыңмы? Шулай була ул, чибәркәем! Дөрес сүзгә җавап юк, бәрәңгедә сөяк юк. Белмиләр дигәч тә, без барысын да белеп

яшибез. Кемнең ботинкасы эчендә аяк бармаклары ничек кыймылдаганга хәтле беләбез без, алтыным... — дип түш киерде.

...Рәйханәгә күтәрелеп карагач, Олег Михайлович китабын тумбочка өстенә куйды, җиңел хәрәкәтләнеп урыныннан торды, ике кулын сузып Рәйханәгә каршы килде. Һәрвакыттагыча хөрмәтләп, аның иңнәреннән сөйде.

— Килдеңме, сөеклем? Яхшы иткәнсең, рәхмәт! Сине көтә идем. Бер сәгатьтән операция башлыйбыз. Казаннан атаклы хирург Харитонов килде. Юлдан соң аз гына ял итеп ала да... Әйдүк, башлыйк,— дип, Рәйханәне култыклап алды, каршы стена буендагы ширма белән томалап куелган карават янына атлады.

— Тик болай килешәбез, сөеклем. Моннан чыккач та, үз бүлмәңә кереп, әйбәтләп ял ит. Мин санитаркага әйтермен, ашны бүлмәңә китерер. Теге вакытта да кан биргәннән соң чатыр чабып, авырулар кабул итеп йөргәнсең. Белми калдым, юл куймаган булыр идем. Ничәнче мәртәбә кан бирәсең, сугышчыларны савыктырасың, үзеңне кайгырта белмисең. Монысы — яраган эш түгел,— дип кисәтте.

— Зыян юк, Олег Михайлович! — дип котылмакчы иде дә Рәйханә батыраерга тырышып, хирург кистереп карады.

— Ачуланмагыз, зинһар, Олег Михайлович. Сез әйткән режимны саклармын. — Әнисенең хәтерен калдыргач юмаланган баланы хәтерләтә иде Рәйханә.

— Алайса ярый... — Хирург янә бик мөлаем булып калды. Форсаттан файдаланып, Рәйханә байтактан хыялында йөрткән нәрсәне үтенде:

— Олег Михайлович, үтенәм, бер генә мәртәбә операция ясавыгызны карап торырга рөхсәт итегез әле миңа. Үзем дә белмим, нигәдер бик-бик күрәсем килә операция барышын...

Олег Михайлович, беравык эндәшми торды.

— Үзең аңлыйсың, сөеклем, операция бүлмәсе — тамаша залы түгел. Әмма сиңа, медицина өлкәсендә җигелеп эшләүче яшь кызга, рөхсәт итәргә мөмкин дип уйлыйм. Бүгенге операция шактый авыр. Яралының үпкәсендә корыч ярчык. Шуның өчен Харитоновны чакырдык. Ярар, бар, ял ит. Вакыты җиткәч, Зөмәрә сине кереп чакырыр...

* * *

Рәйханә ак халат һәм башлык киеп, операция бүлмәсенең бер читенә кереп басты. Олег Михайлович һәм сестра Зөмәрә атаклы белгечнең һәр хәрәкәтен җентекләп күзәтәләр, ул кушканнарны шундук җиренә җиткереп үтиләр иде.

Озын таза гәүдәле Харитонов кулларын бик озаклап юганнан соң операция өстәленә килде. Аның арыганлыгы сизелә иде. Хәрәкәтләре сүлпән, йөзе сулган иде. Ул Казан госпитальләрендә төнлә һәм бүген иртән операцияләр ясаган, шуннан соң күпме вакыт поездда килгән.

Хирурглар авыр хәлдәге яралы өстенә иелделәр. Аның йөзе көлдәй. Маңгаенда салкын тир бөртекләре. Сулышы авыр ала.

Казан хирургының авызын томалаган марля аша:

— Капельницаны!.. Кан басымын күзәтегез!.. Пульс, пульс! — дигән сүзләре тып-тыныч бүлмәдә артык яңгыравыклы булып ишетеләләр иде.

Бер мәлгә Рәйханәнең башы әйләнеп китте. Үзен җиңеп, җентекләбрәк караса, Казан хирургының учында солдат үпкәсеннән алынган корыч ярчык күрде. Хирург тагын яралы өстенә иелде.

— Башлагыз, Олег Михайлович! Тегегез,— диде ул.

Олег Михайлович үзен бик тыныч тотып, зур осталык белән җөй салды. Рәйханәнең карашы Зөмәрәгә төште. Баксана, кая киткән гел шаярып, көлеп йөргән матур йөзле Зөмәрә? Ул кинәт җитдиләнеп китте түгелме соң?.. Иреннәре кысылган, куллары җитез хәрәкәтләнәләр.

Беренче мәртәбә карап торды Рәйханә кеше тәнен ярганны. Ул Олег Михайловичның хезмәтенә бик соклана иде. Госпитальгә килеп кергән ватык, сынык сөякле кулларны, аякларны ул тиз вакыт эчендә хәрәкәткә китерә. Носилкада килеп кергән яралы солдатлар бер-ике атнадан аякка басалар. Олег Михайловичка зур рәхмәтләр әйтә-әйтә яңадан фронтка китеп баралар. Нинди мәртәбәле, олы хезмәт! Вакыт-вакыт үзе дә хирург булырга хыялланып куя иде...

Юк, юк... моннан соң беркайчан да кермәс бу бүлмәгә. Артык күзәтә алмас җан тетрәткеч мондый күренешне. Чамасыз тәэсирләндерә, авыр...

— Ниһаять! — диде Казан хирургы. Бүлмәдәгеләр иркен сулап куйдылар. Елмаеп, бер-берсенә караштылар.

Хирург Харитонов, бер читтә торган Рәйханәне шәйләп алгач:

— Нигә читтән генә күзәтеп торасың, акыллым? Якынрак кил, якынрак! — диде.

Олег Михайлович Рәйханәгә дустанә елмайды һәм Казаннан килгән остага аңлата башлады.

— Карап торыйм, ди бит. Әле генә кан бирде. Донор ул безнең. Госпиталь кызы... Уңганыбыз...

Харитонов операциянең уңышлы чыгуына иман китергән иде булса кирәк, тыныч күңел белән дөнья сүзләренә кушылып китте.

— Бәлки хирург буласы киләдер аның? — Ул Рәйханә янына килеп, аның кулларын тотты. Йомшак, нәфис бармакларга беравык карап торды да: — Бу куллар, бу бармаклар, сеңелкәш, хирург була алыр дигән өмет уяталар. Тик нервылары чыныгудан бик ерак икән әле сеңелкәшебезнең. Әнә иңнәре ничек дерелдәшә... — Аннан ул салмак кына атлап өстәлдәге егет янына килде, аның өстендәге җәймәне рәтләде, егетнең коңгырт чәчләреннән сыйпады.

Шулчак Рәйханә әкрен генә:

— Үлмәсме? Терелерме? — дип сорады.

Хирург егетнең йөзенә текәлеп торды да:

— Терелер, савыгыр. — Казан белгеченең җавабы нык иде. — Ярдәм вакытында өлгерде. Аякка басарына бик ышанасы килә. Сезгә рәхмәт, коллегалар!

— Үзегезгә зур рәхмәт! — Олег Михайлович Казан хирургына ихтирам белән баш иде.

Операция бүлмәсендәгеләрнең һәммәсе күңелендә дә яз иде.

Яңа ел якынлашканда, мәшәкать ишәйми калган чак юктыр ул. Баш өстендә кара болыт булып, сугыш хәсрәте эленеп торса да, авылларга һәм шәһәрләргә хәбәрләр торган саен күбрәк килсә дә, ут эченнән гариплэнеп кайтучылар саны арта барса да, тормыш үзенекен итә. Халык — хәл-әхвәленчә Яңа елны каршыларга хәстәрләнә.

Чистарып калган күк йөзендә ай йөзә. Ул тирә-юньне көмеш нурга чумырган. Ләкин аның нурлары тәнне дә, җанны да җылытмый. Аяк астында кар шыгырдый.

Юка туны, табаны менә-менә тишелеп чыгам дип торган киез итекләре аны төнге суыктан саклый алмый. Шуңа ашыга ул. Аның күз алдында Хөсния гәүдәсе пәйда була кебек. Авызыннан сүз түгел, ут чәчә сыман ул хатын. Гайбәт чәчә, пычрак ата. Колакка, җанга ят, вөҗданга ятышмас нахак сүз тарата. «Теге көнне Игорекка ипи белән шикәр кисәге биргәнне күрдемени соң ул? Аннары Игорьның әнисе белән икесен бергә күрде бит, Пелагея Николаевнасы да сагыз булды бит. Йөзеген сузганны күргәндер... Мин аны алган дип уйлый инде Хөсния апа. Ашамаган ризык авызга ябышмый анысы. Хаклык исбатланмый калмас. Гайбәт таралуы яман. Ил авызын томаларга илле яулык кирәк дигәннәр. Гайнавал апасына андый сүз, нахак хәбәр кайтып ирешсә, бетте баш!

Тагын шау-шу башлап, этисенең миен ашар. «Адельша! — дияр мишәрчәнең дә катысы белән. — Бак, безнең Рәйханә нәстә эшли икән! Вана, гуспитальдәге Хусния әтәдер, кызың әпәй ырлап, шикәр ырлап, шыларны алтын-йөзеккә алыштырып ятадыр, дир»,— дияр. Китәр тезеп, чыдасаң чыда гына... Юк, тузан кадәр гөнаһың булмаган килеш авызга су кабып калырга ярамый! Керергә кирәк Анна Захаровна янына...

Чана юлыннан килгән ат тоягы тавышлары аны артына борылып карарга мәҗбүр итте. Төнлә кайтканда һәрвакыт диярлек очрый торган җайдак милиционер икән, поселок тынычлыгын саклаучыларның берсе.

Район үзәге булган поселок тимер юл буендагы зур станциягә орынып ук утыра. Көненә ничә состав уза! Күпме кеше кайта, күпме китә. Кемнәр килеп чыкмас та ниләр кылмас! Сугыш вакыты аерата саклык, зирәклек сорый. Шуңа төнге постлар һәрчак уяу булырга тиеш. Рәйханә күңеленнән генә иминлек сагындагы бу кешеләргә рәхмәт укый. Моны сизеп торган кебек, атлы милиционер Рәйханәне тау башына кадәр озата бара. Сүзсез генә.

Җәй көннәрендә бик матур бу тау башы. Аста Казан суы ага. Шул суга тегермән корылган. Аның буасына җыелган су ярты болынны баса. Аннары болын хәтфәдәй яшеллеккә күмелә. Шул келәм станциягә кадәр сузыла. Әмма кышларын җил-буран карны монда өяме-өя инде! Билдән кереп чумарлык итә. Салкын аяз көннәрдә сукмак шыр бозга әйләнә. Аякта басып торыр әмәл калмый. Баскыч ясаштырган булалар, алар күпмегә генә түзә?!

Бу төндә дә Рәйханә тайгак сукмак буйлап ничегрәк төшәсе дип торды да тәвәккәлләде. Тунының итәген җәеп утырды һәм, бәләкәй чакта тау шугандагыча, аяклары белән этенә-төртенә, аска таба кузгалып китте. Торды, кагынды, капка төпләренә кайтып җитте. Күтәрелеп тау башына караса, атлы милиционер әле дә шунда һәйкәл сыман басып тора иде.

Өйалды ишеген озак шакырга туры килмәде. Гайнавал торып чыкты һәм, кармалана-кармалана, ишек биген ачты. Рәйханәнең ишекне ябып, бикләгәнен дә көтмичә, тиз-тиз өйгә кереп китте.

«Йокысын бүлдем, тагын рәнҗер инде». Рәйханәгә кыен булып китте. Аяк очларына гына басып, үз бүлмәсенә үтте. Аның караваты мич кырыена ук терәтеп куелган иде. Чишенеп яткач, кулларын әле җылысы бетеп җитмәгән мичкә тигезде. Тора-бара юрган астына җылы җыелды, арыган-талчыккан Рәйханә йокыга талып бара иде, юка такта белән генә бүлеп куйган икенче яктан Гайнавалның ирена сөйләгәне ишетелде.

— Кыз ылан шылай төн кицмас, әтәсе... Якшыга тегел бу. Соңгарып каткан икән, әт үзенә берсәк. Әтәй була бел. Без, бакчи, керфеккә керфек какмый ятабыз...

Рәйханә яланаяк килеш этиләре янына чыкты, ишек янагына сөялде:

— Әти, яңа ел алды бит. Эш гадәттәгедән күп артык. Аннары мин дәрес хәзерләп утырдым. Читтән торып укырга җыенам. Җиде класс белем белән кала алмыйм бит инде.

Гаделша абзый табигате белән бик гадел, холкы-фигыле йомшак кеше, баласы — бәгырь җимеше, ничек инде орышырга, каты сүзләр әйтергә?! Гайнавалын борычлабрак тотар иде, ни генә димә, яшь хатын. Тормышын тартыша, учак җылысын саклый торган кеше.

— Алай-алай,— диде этисе, өзеп кенә ни диярга дә аптыраганнан. — Шулай да, ни, кызым, вакытындарак кайтып ирешү ягын кара инде син, әйе!

— Өйдә керосинга да кытлык бит, эти...

— Алай... алай. — Карт янә берни дә аңлатмый торган сүзләрен тәкрарлады.

Гайнавалның моңа җене чыкты:

— Алайланып ятмасана,— дип кырт кисте. — Ата булсаң, әт үзенә. Теге көнне катте дә партийный булдым дип шаккатырды, бөген

сабак өрәнгән... Иртәгә нәстә әтер? Иртәгенең арысына шындый әтер, колак сөягең ярылыр. Пачут тактасыннан пазур тактасына да ерак төгел бит, әтерләр аннары: үги ана кызына күз-колак булмаган, диерләр...

Рәйханә бакчасына ташның зурысы төшсә дә, җайлап кына сөйләшә бирде. Талаш-җәнҗал дигәнне җаны-тәне белән кабул итә алмый иде.

— Эш күп бит, Гайнавал апа. Һич кенә өлгерер хәл юк...

— Үзең тапмасаң, бар үеңә кать, дип кем генә вакыт табып бирер икән сиңа. — Шулай диде дә, сөйләр сүзем бетте, моннан ары, соңга калып йөрсәң, ишек тә ачмам, дигән төсле, иренә арка куеп әйләнде дә ятты. Гаделша, юрганын күкрәк турысына тартыбрак, торып утырды.

— Партиягә кердем диюең дә иртәрәк булды бугай, кызым,— диде ул, тонык тавыш белән.—Партиягә бит, кызым, минем белүемчә, зур эшләр башкарырлык кешеләр кирә.

— Мин, эти, үз җилкәмә төшкән эшне җиренә җиткереп эшләрмен дип кердем партиягә. Кулымнан килгәннең барысын да эшләргә тырышырмын, дип. Акыллы, тәҗрибәле кешеләрдән күп нәрсәгә өйрәнермен дип тә.

Үги кызының болай зурдан кубуын Гайнавал тыныч кына тыңлап ята алмады.

— Әй аллам, синнән килгән зур эшләргә карап торырга калса... Бу куркыныч заманда үгездәй ирләр дә пыцагымны да кыра алмыйлар, ә син кыз башың белән таулар җимерердәй булып кыланасың.

Рәйханә урынына барып ятты. Инде ничәнче мәртәбә туган әнисен сагынып яшь түгәргә кереште. Әнисе бит Рәйханәнең бәләкәй генә эшен дә зур итеп күрә иде: «Әй, кызыкаем, бигрәк тә белеп эшләгәнсең, булдыргансың,— дип мактый, шатлана иде. Күңел ярсулары ташып торган чакта, эч серләрен уртаклашырга кирәк вакытта, иркәләүгә, назга мохтаҗ бер дәвердә, киңәшләре тансыкка әверелгән бер чорда ник үлеп китәләр икән газиз әниләр?

Рәйханә бишенче класста укый иде. Кич. Әнисе җөй машинасы янында утырып, кызына күлмәк тегә. Кызчык әнисенең озын кара чәч толымнарын бер үрә, бер сүтә. Кыйгач кара кашларына, ирен өстендәге борчак кадәр булып үскән миңгә чәнти бармагын тигезеп ала да:

— Кашларың шундый матур, ә менә бу миң сине матурлыймы, ә, әнием?.. — Аннан тагын нәрсәләрдер турында әнисеннән сораштыра да, аны кочаклап: — Әнием, син бик матур, сиңа карап туеп булмый! — ди.

Ә иртәгесен... иртәгесен Рәйханә мәктәптән кайтуга әнисенең зифа гәүдәсе җансыз иде.

Балалар өчен әнине югалтудан да артык фаҗига була алмый. Абыйсы Нияз да, Рәйханә дә җир тырнап еладылар, әтиләре дә тере мәет булып калды, чыкмаган җаны гына бар иде. Ул хәтта елый да алмады, яше каткан иде.

Ана — өйнең өрлеге. Өрлек сындымы, өйнең җимереләсен көт тә тор. Гаделша гаиләсе дә җөй сүтә башлады. Нияз Казанга китеп урнашты. Заводка керде. Начармы, яхшымы, үз көнен үзе күрә. Өйдә әтисе белән Рәйханә генә калгач, күңел бушлыгы җанны изә торган бер көчкә әйләнде. Кыз бала моң, сагышка чумды. Әнисенең «Кызым бик әйбәт артистка булыр, боерган булса. Сөбханалла! Тавышына яман күз тия күрмәсен»,— дип сөенүләре татлы төш сыман гына булып калды.

Көннәрнең берендә Гаделша абзый Рәйханәгә әйтми булдыра алмады.

— Кызым, Рәйханә,— диде бичарадан ни чара калган кыяфәттә. — Өйдә тәртип кимеде, җанга җылы юк. Ашау-эчүнең дә рәте китте. Мин инде аркылыга үлчәдем, буйга уйладым да сезгә яшь әни алып кайтырга булдым...

Рәйханә бер әтисе күзләренә, бер тәрәзә төбендә әнисе кадерләп үстергән гөлләргә карады.

Әтисе аның авыр хәлен күрде, күрде генә түгел, бөтен күңеле, йөрәге аша кичерде. Аның да елыйсы килде. Ләкин олы кеше сабырлыгы аны бу

юлы да ташламады. Ул тәрәзәгә карап утырган кызы янына килде, ике кулын аңа таба сузды, тик ул куллар һавада асылынып калдылар. Рәйханә аңа үзе сарылды, җилкәсенә башын куеп, үксеп-үксеп елый башлады, ә үзе:

— Әтием, бәгырькәем!... Борчылма, мин болай гына, үзең ничек уйлыйсың, шулай эшлә, мин каршы түгел, тик... тик безнең өйгә килә торган апа, тик... әз генә, кайсы ягы белән генә булса да безнең әниебезгә охшаган булса, тик бик әз генә...

Гаделша көчле куллары белән кызын үзеннән читкәрәк этте дә аның тулган күзләренә төбәп карады:

— Я аллам, каян синә бу кадәр акыл килде соң,— диде дә кызуланып ишектән чыгып та китте.

Үги ана — Гайнавал апа — начар кеше түгел иде. Беренче көннән үк тырышып, җиң сызганып дигәндәй, тормыш алып бара башлады. Ирдән яшьли тол калган, ялгыз тормышның ачысын татыган хатын бу гаиләдә үзе дә җылынып, күңеле күтәрелеп китте. Бөтен эшне дә кызу-кызу ашыгып эшләде. Рәйханә укудан кайтканда җылы аш өстәл өстендә булды. Гаделша да якасына кер кунган күлмәк кимәде, салкын аш ашамады. Шулай да Гайнавал — Рәйханәгә «кызым» дип, Рәйханә аңа «әни» дип эндәшә алмадылар. Шулай тыныч кына, шау-шусыз гына яшәп ятканда, үги ана белән үги кыз арасында беренче үпкәләшү булып алды. Рәйханә ике-өч яшьлек чагыннан ук әнисе янында вак-төяк өй эшләре эшләргә өйрәнгән бала иде. Аның әнисе нинди генә эш башкарса да, чын күңелдән, шатланып эшли иде. Эшнең тәмен табып. Рәйханәгә әнисенең ул гадәте балачактан ук сеңә килде. Ул инде җиде яшендә үз кәрләрен үзе уа, идәннәрне ялт иттереп юып чыгара иде. Үги ана, яхшы күренер өченме, әллә үзенең гадәте шундый идеме, Рәйханәнең өс-башын да, урын-җирен дә үзе уа иде. Аның үз тирәсендә эшкә кысылып йөргән яратмый иде. Рәйханәнең бу хәлгә эче пошып йөрсә дә, Гайнавал апасына тиз генә әйтә алмады. Ә бер көнне:

— Гайнавал апа, зинһар дип әйтәм, минем керләремне умагыз, үзем уармын,— диде дә, иркәләнеп, назланып, Гайнавал апасының күзләренә карады.

Гайнавал Рәйханәнең бу сүзләрен бер дә ошатмады. Үзен кимсетү, хурлау дип аңлады. Һәм үз эченнән генә булса да «ит яхшылык, көт явызлык», дип куйды. Ул гына да түгел, усал гына итеп: «Шул булдымы рәхмәтең»,— дип җил-җил атлап өйдән үк чыгып китте. Ә төнлә ире белән бер юрган астына яткач, җылап ук сөйләде:

— Мин аңарга яхшылык эшлим, ә ул эчендә усаллык йөртә икән. Күзләремә карап әйтә бит, оялмыйча. Мин эшләгән эшләрне яратмый. Умыйм да, юмыйм да моннан соң. Күршеләр әтә, үги бала асраганчы, ди, үги бозау асра, ди... Аның әнисе дә бик тәкәббер кеше иде, диләр...

Җиденче классны бетергәч, Рәйханә абыйсы белән киңәште дә әтисенә сүз салды:

— Әти, мин укырга китәргә уйлыйм,— диде.

— Китәргә? Кая? — Гаделша өчен бик көтелмәгән яңалык булды Рәйханәнең сүзләре.

— Театр техникумына, Казанга китәргә исәбем, әти...

Гаделша чын-чынлап уйга калды. Күзләрен сагыш басты. Маңгай җыерчыклары, яңа ярган буразна сыман, тирәнәеп киткән төсле булды. Аркасында сизелер-сизелмәс кенә чыгып барган бөкресе калкып китте шикелле. Ирennәре мимылдашты, күзләрен чет-чет китереп торды. Ничегрәк керерсең, керә алырсыңмы, укып китү кулыңнан килерме дигән сораулар куеп киңәшләшәсе урынга ул дорфа гына:

— Гомереңнең буе кәмитләнеп йөрергә ниятлимсең?— диде.

Рәйханә үзе белгән кадәр артист хезмәтенең уңай якларын санап күрсәтмәк булып тырышты, әтисенең борчылмавын үтенде. Мәрхүмә әнкә-

сенең артистлык юлын сайлауга бер дә каршы тормаганын да төшендереп карады.

— Хәзер инде әтиеңне борчысаң да, ялгыз калдырсаң да ярый дип хисаплыйсыңмы?— Карт — кыз баладан ап-ачык җавап көтте.

— Әти, киләчәгем турында кайгыртырга тиешмендер бит мин? Сәхнә хезмәте миңа ошый. Белем алсам, эшләп китәрмен төсле сизәм... — Рәйханә шулай диде, бүтәнчә ни дисен?!

— Ике кулыңа бер эш таба алмаган бәндә кебек... Ярый инде,кызым, күңелем тартмаса да, юлыңа бүрәнә булып ятмыйм,— диде бераздан әтисе. — Шуны гына онытма, син дә киткәч, мин япа-ялгыз калам, кызым...

— Мин һәр атнаны кайтып йөрермен, әти, яме,— диде Рәйханә.

— Ярый, кызым, ярый...

Ата ризалыгы — Рәйханәнең һич нәрсәгә алыштыргысыз байлыгы. Шуның белән рухланып, канатланып, очынып, ул Казанга, театр техникумына килде. Кешелеккә кия торган киемнәрен кигәч, Рәйханә гөлчәчәккә охшап калган иде. Аңарда сәхнәгә сәләт бармы-юкмы икәненә ышанудан алда кабул итү комиссиясе членнары уртак бер фикерне әйттеләр:

— Бу кыз сәхнә өчен туган!

Аннары ул хәзинәдә барын — җырга, шигырь укырга, биергә осталыгын күрсәтте. Көчле дә, моңлы да тавыш имтихан алучыларны гашыйк итте. Аларда,театр дөньясының чәчәкләрен дә, чәнечкеләрен дә күргән осталарда — Рәйханә турында фикер бер иде.

— Әйбәт! — диделәр. — Өметле.

Иң соңыннан аның этюд башкарып күрсәтүен сорадылар. Таза гәүдәле, уртачадан калкурак буйлы, кабарынкы куе кара чәчле бер абый аңа күкрәп торган көр тавыш белән: «Сеңел, иң якын кешеңне ерак юлга озатып куюны уйнап күрсәт әле. Менә берничә минуттан поезд кузгала, я пароход китә... Саубуллашу минутлары, әйтик...»

Рәйханә куркынып калды. Аннары акыл килде: үзенең шул халәтен табигый санады. Якынын югалтудан курка ич ул. Аннан соң аңына аерылышуның тирәнрәк мәгънәсе барып җитте. Ерак юлга гына түгел, озакка гына түгел, бөтенләйгә озатуны кичергәне бар ич аның. Әнисен соңгы юлга озатты бит ул сабый көенчә...

Ул шуны күрсәтте. Комиссиядәгеләр бер-берсенә карашып: — Әйбә-әәт! Табигый! — диештеләр.

* * *

Театр техникумында укый башлап, Казанда, тулай торакта көн итәргә керешкәч, аның дөньясы киңәеп, күге биегәеп киткән шикелле булды. Балачактан хыялда йөргән, тартып, үзенә өндәп торган дөнья кешеләренә якынайды кыз. Әлегә һәммәсе аңлашылып җитмәсә дә, серле, томанлы, табышмаклы булып күренсә дә, техникумда укытыла торган фәннәр аның эчке дөньясы белән авваздаш иделәр. Тулай торакта матур бер гаилә кебек оештылар. Һәркемнең үзенә күрә сөйләр сүзе, уртаклашыр фикере бар. Берсе белмәгәнне икенчесе чамалый, өченчесе ачыклый. Турыдан-туры кычкырып әйтмәсәләр дә, кызларның һәркайсы сәхнә йолдызы булырга хыяллана. Академия театрының спектакльләренә йөрү мөмкинлеге — бернәрсә белән дә чагыштырып булмастай бәхет! «Сәхнә йолдызлары» күз алдында. «Шәмсекамәр»дәге баш героиняны уйнаучы Галия Булатованы әйтәсеңме, «Ромео һәм Джульетта»дагы Джульеттаны уйнаган Фатыйма Ильскаяны аласыңмы, яисә шул ук Ильскаяны Арбузовның Танясы итеп күрәсеңме — ай, җаным! — кирәкми дөньяның гәүһәр-җәүһәрләре! Бер спектакльдә булуы — бер гомер. Ромеоны башкарган Камал Өченчене, үлемсез Хуҗа Насретдинны күз алдына китереп бастырган Хәлил Әбҗәлиловны, Тукай булып уйнаган Ибраһим Гафуровны

сәхнәдә бер күрүе генә дә ни тора! Тылсымлы сәхнәнең артына үтәргә мөмкинлек чыгу, тылсымчыларга чутлап йөргән артистларың белән каракаршы очрап исәнләшү, хәтта ара-тирә сөйләшеп алу — болар һәммәсе дә Рәйханә өчен хәзинә иделәр.

Укырга керергә дип киткәндә әтисенә: «Атна саен кайтып йөрермен»,— дип вәгъдә биргән булса да, Рәйханә һәр якшәмбедә өйләренә кайта алмады. Вакыт җитмәгәннән генә дә түгел. Туып-үскән йортында Казандагы шау-гөрле тормышына капма-каршы тормыш, баз суыклыгы каршылый иде аны. Әнием дип эндәшер кешесе юк. Әтисе — аны күпме генә якын итмәсен, Гайнавал апасы тоткан тезгендәге кеше. Хезмәтенә бара (ул район җир бүлегенең атларын карый), кайткач өйдә булыша, яшь хатынны көйли. Рәйханә белән иркенләп сөйләшергә җае да юк.

Көннәрнең берсендә үз станцияләреннән Казанга килергә дип шәһәр яны поезды вагонына утыргач: «Сезнең янга утырырга мөмкинме?» — дигәнне ишетте. Күтәрелеп карса, каршысында сөйкемле генә егет. «Рәхим итегез!» — диде Рәйханә һәм үзе тәрәзә буенарак елышты.

Сүз иярә сүз чыгып, бер-берсенең кем булуын, кайда укып һәм кайда яшәүләрен сорашып өлгерделәр. Гәпләшә торгач, Казанга килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар. Саубуллашып, икесе ике якка китәр минут җитте.

— Хушыгыз, Әмир! Мин тулай торакка киттем,— Рәйханә, чынында да, бик тиз китеп барырга җыенган иде. Эңгер-меңгер җитте, көзге кич Казан каласы өстенә үзенең күгелҗем кара бөркәнчеген ябарга әзерләнә иде. Тулай торакка кайтып ашап-эчәсе, дәресләрне караштырасы, иртәгә иртүк техникумга барырга әзерләнәсе бар.

Әмирнең исә чибәр дә, акыллы да күренгән юлдашыннан аерылып китәсе килмәде.

— Юл бик кыска булды, Рәйханә. Ичмаса тулай торагыгызга кадәр озатып куярга рөхсәт итегез. Юлдашымның кай тирәдә яшәгәнен дә белеп калырмын,— дип, кызны озатырга җыенды. Рәйханә моңа каршы түгел иде, мәгәр кинәнеп ризалык бирү килешеп бетәрме дигән сагаю, өзеп кенә: «Озатыгыз алайса!» — диюдән тыеп торды. Шул кадәресе дә бар, ул бит әле үзен озатып куярга теләүче белән беренче очрашты. Моңа кадәр аны озата кайтканнары юк иде. Бүгенгә чаклы бер егетнең дә үзе белән болай якын итеп сөйләшүен ишеткәне булмады. Әмир артыгын сөйләшмәсә дә, сүз эзләп кесәгә кермәде, егетләрчә кыюлык күрсәтүдән дә тайчанмады.

Тулай торак янында да беркадәр сөйләшеп тордылар. Китәргә булып күрешергә кул сузды егет. Рәйханә дә аңа кул бирде. Йомшак җылы бармакларны учында җибәрми тоткан килеш, Әмир кызның күзләренә бик ягымлы итеп карады да:

— Мин Сезнең белән кабат очрашырга теләсәм, каршы килмәссезме? — диде.

— Белмим шул,— дип куйды Рәйханә.

Әмир, билгеле инде, форсатны ычкындырырга теләми иде.

— Аны Сез генә хәл кыла аласыз...

Әмир кулын җибәрми торганга кыз уңайсызлана башлаган иде инде, күтәрелеп карарга оялып, кыяр-кыймас кына ризалыгын бирде:

— Вакытыгыз булганда килгәләгез соң алайса...

Иртәгәсен алар спектакль карадылар.

Менә шулай башланып киткән танышу Рәйханә йөрәгендә тылсымлы ут кабызды. Бу ут Әмир күңелендәге учактан көчте. Мәхәббәткә сусаган яшьләр бер-берсен тиз аңладылар. «Сез» дип сөйләшүләр дә тарихка калды. Алар бер-берсе өчен «син» иделәр инде. Әйтеп бетергесез тиннәр, тигезләр, берсе икенчесенә терәк, рухландыргыч чыганак, дәрт чишмәсе, саф, якты хисләр кизләве... Яше белән дә өлкәнрәк (егет Рәйханәдән өч яшькә өлкән иде), тормышны күрүе ягыннан да кыздан тәҗрибәлерәк, белеме белән дә студент Әмир сабыйларча беркатлы Рәйханәгә арка терәгенә әверелде.

Көнләшерлек итеп дуслаштылар алар. Сокланырлык итеп яратыша башладылар. Һәр кичне диярлек очрашып тордылар. Авылны бик яратучы Әмир — Казанда туып үскән егет. Әтисе ягыннан әбисе һәм бабасы авылында еш була, картларга булыша. Печәнен дә чаба, утынын да хәзерләшә, хәтта бу җәйдә тракторга тагылган комбайнда эшләп, иген урдырды.

Казан каласында Әмир судагы балык сыман. Белмәгән, булмаган урыны юк. Театрларны, кинотеатрларны, музейларны, парларны айкап чыккан. Танышуларының беренче айларында ук Рәйханәне дә музейларга алып барды, рус драма театрына даими йөрергә күнектерде, үзәк китапханәнең актив укучысына әверелергә булышты.

Рәйханәнең иптәш кызлары да Әмирне үз иттеләр. Аның тулай торакка килеп йөрүенә риза иделәр. Кайчак хәтта: «Әмир абый күренми бит әле горизонтта. Рәйханә, үпкәләттеңме әллә үзен?» — дип юксына да башлыйлар иде.

Октябрьнең егерме өч еллык бәйрәме алдыннан театр техникумының беренче курсындагы кызлар Әмирне үзләренең уку йортлары бәйрәм концертына чакырдылар. Шул кичтә Әмир Рәйханәгә икенче кат гашыйк булды. Бу юлы ул аның көчле дә, моңлы да тавышына таң калды. «Зәңгәр шәл» җыры белән егетнең үзәген өзде, «Комсомолка Гөлсара»ны да бик матур җырлады.

Концерттан соң Әмир аны кат-кат тәбрикләде:

— Сандугачым да икәнсең бит әле син! — дип сөйләнде. — Сандугачым икәнсең лә, җитәр күзләр, китәрсең... Халык шулай җырлыймы әле?

Рәйханә аңа карап торды да кәефсез генә елмайды. Кызның кинәт сүлпәнләнүенә Әмир аптырый калды.

— Нишләп боектың әле, Рәйханәм? — диде.

— Халыкның ул җырында шик бар, Әмир. Ниндидер курку, имәнү бар. Күңелгә шом сала ул җырның азаккы юллары...

— Ә син шомланма...

— Ничек шомланмыйсың ди? «Җаның теләмәгәннәргә булсаң, ни хәл итәрсең?» Шуннан да зур бәхетсезлек бармы? Җаны теләмәгәннәргә булмас өчен күпме кызлар яшь түккән? «Зәңгәр шәл»дәге ятимә Мәйсәрәнең хәле генә дә бичаракаемның...

— Заман башка, җыр башка, Рәйханәм! Мәйсәрәләр язмышы беркайчан да кабатланмаслык булып юкка чыкты, акыллым!

— Азмы соң тормышның фокуслары!..

Инде Әмир үтә житдиләнеп китте. Култыклашкан килеш, карашларын алга төбәп, салмак-сабыр гына кузгалдылар.

Жуковский урамы буйлап Казанка ярына кадәр килделәр дә бакчаның аулак почмагындагы эскәмиягә утырдылар. Тик анда озак сөйләшә алмадылар. Ноябрь төне аларны урыннарыннан торгызды. Рәйханәгә суык үтә башлаганын Әмир чамалап алды.

— Кузгалдык, йөреп торыйк. Югыйсә, кыш бабайның оныклары безне чеметә дә башлады,— диде.

Якын киләчәккә планнарын ачыкладылар. Алда әле ике айдан аз гына кимрәк вакыт булса да, Әмир Яңа елны бергә каршыларга кирәклек турында әйтеп куйды. Алар бу бәйрәмне группалары белән билгеләп үтмәкчеләр икән. Шулай килешкәннәр: егетләр үзләренең дус кызларын чакыралар, ә кызлар дус егетләре белән киләләр. Группаның һәр кешесе үзенең иң якын дустын алып килә.

* * *

Бик соңлап кына йокыга китсә дә, йокысы булмады Рәйханәнең. Гайнавал апасыннан ишеткән төртке сүзләр, әтисенең кызын яклап рәтле-

башлы сүз әйтә алмавы, Әмирдән хат-хәбәр юклыгыннан зар-интизар булып тилмерүләр — саный-чутлый китсәң, чүп өстенә чүмәлә булып, йөрәкне талый торалар. Шуңадыр, манма суга батып уянды һәм өстеннән юрганын алып башлады. Авыр йөк күтәреп ерак ара узган һәм, ниһаять, шул авырлыкны җилкәсеннән төшергән кеше кебек тирән итеп сулады. Тынланып тын гына ятты. Әтисе дә, үги әнисе дә йоклыйлар иде әле.

Теге елны Әмирләр группасы белән каршылаган беренче январь белән быел җитеп килә торган Яңа елны чагыштырып карады. Җир белән күк арасы! Әй, ул чактагы күңеллелек! Җырларның нинди лләрен генә җырламадылар! Кем ничек кенә биемәде, мәзәкнең чуты булмады. Мәҗлескә Әмирләрнең Яңа бистәдәге үз йортларына җыелганнар иде. Алты почмаклы өйнең киң һәм биек алгы ягы кунаклар белән шыгрым тулы. Тальян чыңлады, мандолина уйнадылар. Музыкантлар арыгач, патефон әйләндерделәр. Патефон тәлинкәсенә язылган популяр җырга яшьләр үзләре дә кушылдылар:

...Ил читенә дошман килсә,
Каушамас безнең куллар;
Мылтык алып алдан чыгар
Яшь егетләр, яшь кызлар.
Э-эх...

Әмир ул кичне җыр сүзләренә игътибар итте. «Ил чигенә дошман килсә...»

— Чыннан да, реаль хәвеф бит бу, Рәйханә! — диде ул, җыр тәэсиренә бирелгән группадашларыннан бер читкәрәк киткәч. — Дөрес, кызыл гаскәр Халхинголда, Хасан күле буенда япон самурайларының иманын укытты, ак финнарны да тәүбәгә китерде. Ну бит шунысы да факт, болытлар тагын да куркынычрак куера бара...

Рәйханә егетнең кара күзләренә текәлеп карады, озын төз гәүдәсенә сокланды, киң, нык иңнәренә башын куеп торырдай булды:

— Куркытма әле мине, Әмир, сугыш булыр дип...

— Сине куркытудамыни эш, якыным?! Бер генә дә шомлы сүз чыкмас иде авызымнан... Ил өстенә яу килер дә, синнән аерылып китәргә тиеш булырмын дип уйлыйм. Ә сине минем һич-һич югалтасым килми. Аңлыйсыңмы, килми...

Әмирне борчулы уйларыннан Рәйханәне җырларга кыстап килгән группадаш егете аерды.

— Бик үтенәбез, Рәйханә иптәш! — дигән булып бөтерелде группадашы.

— Җырлап бир безнекеләргә, җырлап бир. Рәхәтләнеп бер тыңлыйк әле,— диде Әмир дә. Кызны якын итү галәмәтедер инде — Рәйханәнең җырлавы белән мактанасы килә иде аның. Ризалашты «иптәш Рәйханә», гармунчы янынарак үтте. Гармунчы студент, бөтен мәҗлесне балкытып торган бу чибәргә таң калган төсле, көй исемен әйтүне көтә иде.

— «Урман кызы»,— диде Рәйханә.

Рәйханә җырыннан туган ләззәт уртак бер халәткә әйләнде. Кызның үзен дә мәҗлеснең йөзек кашына тиңләделәр. Янә җырлавын сорадылар. Монысында Рәйханә «Зәңгәр шәл»не — үзенең иң яраткан җырларыннан берсен башкарды. Янә алкышлар булды.

Әмирнең әтисе аны-моны әйтмәде, әнисе шулай да чыдамады, җаен китереп, улын мактап, кызны бик ошатуын әйтте.

— Бик тә тәртипле, бик тә моңлы бала белән дуслашкансың, улым. Әүвәле-ахыры хәерле була күрсен! — диде.

Тыныч еллардагы күңелле кичәләр бүтән беркайчан да булмас кебек тоела башлады инде... Ичмасам йокысы гына йокыга охшасын иде дә ял итеп уяна идең. Җаның тыныч булмагач, тәнеңә тынгы кәтмә икән шул...

Борчылып ята торгач, тагын черем итеп китте ул. Бу юлы аны Гайнавал тавышы уятты:

— Рәйхана! Рәйхана! Сәгать бишне сукты, соңга кала күрмә! — Кызның җавап сүзен ишетмәгәч, дуларга ук керешә. — Тор дим, тор! Бульше уятып каняшмим да... Хуть вувси барма, миңа димягәең...

Рәйхана сикереп торды, юына-җыена башлады.

Корпус ишеген шакып торырга да туры килмәде. Бик иртә булса да, кемдер ишекне ачтырган иде инде. Рәйхана аяк-куллары туңудан аптырап, үз бүлмәсенә дә сугылмыйча аш бүлү ягына керде. Анда чагыштырмача җылы иде. Рәйхана, каз тәпие сыман кызарган кулларын уа-уа, мич буена килде һәм... сискәнеп китте. Мич артында бөрешеп кенә Хөсния утыра иде. Ул, Рәйханәне күргәч, башындагы иске бүреген салды, иңенә шуып төшкән ак яулыгын төзәтеп куйды.

Сәламен дә рәтләп бирә алмаган Рәйхана сораштыра башлады.

— Нигә бик иртәләдең, Хөсния апа? Тагын ни булды?

Җиде тулганда килергә тиешле кеше алты да тулыр-тулмас килгән. Ул тәбәнәк урындыктан көч-хәл белән генә күтәрелде. Рәйхана янына килде. Сырма бишмәтенең төймәләрен каптыра-каптыра сөйләп китте.

— Ышансаң ышан, Рәйхана, ышанмасаң — үз эшең. Беләмсең, шуның кадәр дә,— Хөсния чәнти бармагының очын күрсәтте,— йоклый алмадым. Уйландым да уйландым, еладым да еладым... Акылыма җиңеллек киләме дип торам. Өйдә булсам, бер-бер хәл кылырмын, мин әйтәм, торыйм да барыйм әле госпитальгә, димен. Уйладым, уйладым да, Рәйхана, үз-үземә хәйран калдым, исләрем китте. — Хөсния акланыргамы, аңлатыргамы җыена иде. — Минем бу яраксыз гамәлемне ирем белсә, билләһи дим, асылынып иде. Балалар әле бик бәләкәй чакта ук әйтә иде: «Кешенең бер тиененә тисәгез, миннән рәхим-шәфкать көтмәгез»,— ди торган иде. Әйтәм ич, елау гына димим, чишмә кебек түктем яшемне, рухы рәнҗегәндер инде мәрхүмемнең. Холкым холык түгел, бик авыр, үзем дә беләм. Тотнаклылыгым юк, әллә каян әллә нинди пружина гына ычкынып киткәндәй була да, кызып китәм, телемә ни килде, шуны әйтәм бит, менәтерә! Ирем мәрхүм әйтер иде исән чагында: «Син, Хөсния, дияр иде, уңган да, булган да. Эшне өздереп эшлисең. Менә тәртибең начар даначар инде»,-ди торган иде. Усал телем белән бәгыренә ут салган чакларым булды шул инде, булмады дип әйтә алмыйм. Инде менә синнән алла хакына дип сорыйм, бетерик бу низагны, бүтән тәмсез сүз әйтсәм, телем корысын! Сөйләш балаларым хакына Анна Захаровна белән, кучермәсен мине моннан. Сыңар бөртек ярмага да кагылмам, ипидер менә, кояштыр!

Рәйхана үзе дә Хөсния апасына кушылып елар хәлгә житте. Алай да кичәге гарьлек аның бәгырен өшеткән иде, каты күңелле булырга тырышып, үгет сүзе әйтте:

— Ярамаган эш ярамый, Хөсния апа. Барыбызның да хәле авыр. Шуны сылтау итеп кеше хакына керешсәк — барып чыкмас. Чыдарга кирәк безгә.

Тышкы ишек еш-еш ачылып ябыла башлады. Сестралар, врачлар килә, димәк. Рәйхана, Хөсния белән сүзне шул урында өзеп, Анна Захаровна кабинетына китте.

Бүлек начальнигы килеп чишенгән иде. Өстенә халатын киярга өлгермәгән. «Кулымнан килсә, мин Анна Захаровнага бервакытта да халат кигезмәс идем,— дип фикер йөртте кыз. —Халат аны акка төрә дә куя, бөтен матурлыгын ала. Ә хәрби кием ничек килешә үзенә! Гимнастерка өстеннән киң каеш белән билен буып куйса, карап туялмыйсың!»

— Хәерле иртә, Анна Захаровна!

— Хәерле иртә, Рәйхана. — Врачның кәефе әйбәт күренә иде. Бик мөлаем сөйләшә. — Ул таудан ничекләр менеп життең, акыллым? Бигрәк тайгак. Һәрвакыт синең өчен борчылам. Имгәнә күрмә берүк.

— Рәхмәт борчылуыгызга, Анна Захаровна. Мин тау кәҗәсенә әйләнеп барам бугай инде. Күнегеп беткәнмен... — Тайгак турында сүзне шунда түгәрәкләп, Рәйханә икеләнеп кенә Хөсния турында сүз кузгатты. — Ни, Анна Захаровна, санитаркалар ашханәгә аш алырга киталәр. Хөсния апа да барсын инде. Мин аның белән сөйләштем. Ул бүтән беркайчан да теге көнге эшен кабатламаячак...

Анна Захаровна Рәйханәгә гаҗәпсенү катыш иркәләү белән карап торды. «Бала син, Рәйханә. Бала-чага. Кичә генә Хөсниягә карата нәфрәтләнеп йөри идең, бүген инде барысын кичергәнсең...» — ди иде аның күзләре. Мәгәр аның мөлаемлеге озакка бармады, бик тиз кырыс Анна Захаровнага әйләнеп калды.

— Юк, бүгенгә бармый әле ул аш алырга! — Бүлек начальнигының сүзләре мылтыктан аткан төсле яңгырады. — Бармый! Мин үзем сөйләшәм әле аның белән тагын бер кабат. Җиңел генә уздырып җибәрмәкчемени?

Рәйханә инде ялына ук башлады. Балалары хакына дип үтенде. Ниһаять, Анна Захаровна булып Анна Захаровна чигенде.

— Ярый, барсын! Ләкин авыруларны туклandыргач, беренче эше итеп минем кабинетка керсен. Онытма!

* * *

Гаебең өчен сүксәләр, чыдавы чамасыз авыр. Тик бу очракта кеше аңлый ала: кулың белән эшләгәнне иңең белән күтәрергә тиешсең. Ялгышуның зыяны зур булса да, киләчәккә файдасы бар дигәннәре дә хак.

Кылган гаебеңне кичерсәләр дә, ансат түгел. Кемдер олы җанлылык күрсәтеп гафу кыла. Ә син бу яхшылыкка икеләтә-өчләтә әйбәтлек белән җавап бирә алырсыңмы? — шуны уйлыйсың. Җәза бирсәләр дә, ярлыкасалар да, вөҗдан газапсыз калмый.

Хөсния дә коллективының үзен бәладән йолып калуына бер сөенде, бер көенде. Шулай да көенү-кайгыруларның зуррагы алда көткән икән әле.

Үз өенең урам якка караган тәрәзәләрендә ут күргәч:

— Шөкер, сабыйларым өйдә икән! — дип куйды ул. Җилкапканы ачып, йортка керде. Ян тәрәзәне сак кына шакыды. Болдырга менеп җиткәндә, өй эченнән йөгереп чыккан аяк тавышын ишетте:

— Әнием, синме? — Эчке яктан ир бала эндәште.

— Мин, балам, мин кайттым...

Өйгә кергәч, алтынчы класста укучы улы Расих әнисенең сумкасын алып куйды, сырма төймәләрен чишәргә булышты, бияләйләрен мич өстенә күтәрде. Биш яшьлек кызчыгы Рәмзия дә әнисе кайту шатлыгыннан аның янында бөтерчек булып бөтерелә башлады. Ул әнисенең биленнән кочаклады, үбәргә дип битенә үрелде:

— Абау! Әниемнең бите боз булган! — дип тәтелдәде.

Хөсния күзләре белән олы улын — жиденче класста укучы Рәмзине эзләде. Рәмзи мич кырыендагы тимер караватка яткан, юрганын башыннан ук ябынган иде. Әнисе, сырма бишмәтен элгечкә элүгә, аның янына килде.

— Улым, ник болай иртә яттың? Авырыйсыңмы әллә? — дип сораша башлаган иде, Рәмзи йөзе белән мендәренә капланды. — Улым, дим!

Хөсния кече балаларына сораулы караш юнәлтте. Рәмзия аның ике кулына сарылды да ым кагып кына түр як бүлмәгә чакырды. Шунда белгәннәрен сөйли башлады.

— Син ачуланма инде аны, әни. Рәмзине кыйнаганнар. Күз асты күгәргән. Малайлар белән сугышкан...

— Сугышкан? — Хөсния аптырап китте. Белә иде: Рәмзинең урамда да, мәктәптә дә сугышып йөри торган гадәте юк. — Ник сугышкан? Кем белән?

Хөсния, кызуланып барып, малаеның өстеннән юрганын тартып алды һәм ике куллап улының йөзен үзенә борды. Кызының сүзе рас иде. Рәмзинең уң күз төбе шешеп чыккан һәм зур тәңкә булып күгәргән иде. Ана бу хәлне акылына сыйдыра алмаган төсле:

— Улым, җаным, тилердеңме әллә? Гомер булмаганны сугышып йөрдеңме? Ни булды? Ник төштең шундый хәлгә? — дип ачыргаланды.

Рәмзи әнисенең күзләренә тутырып карады да, ләм-мим эндәшмәстән, юрганын янә башыннан ук бөркәнде.

Тамагы ачыккан Рәмзия тәкатьсезләнеп әнисенең күлмәк итәгеннән йолкый башлады.

— Әни, дим, ашыйсым килә, әйдә ашыйк инде!

Хөсния көндезен пешереп калдырган бәрәңгене җылытырга куйды. Самавыр тергезде.

Расих белән Рәмзияне йокларга яткыргач, Хөсния сөйләнә-сөйләнә Рәмзинең аяк очына барып утырды.

— Атаң күрсәме бу чыраеңны?! Энең белән сеңлеңә шулай үрнәк күрсәтмәк буласыңмыни? Әйт, кем белән, нәрсәмә дип сугыштың?

Ул сулкылдап еларга кереште. Көне буе бәгыре сызлауга болай да гаҗиз иде инде ул. Рәмзи дә түзмәде, урыныннан торып, караватт буена басты һәм әнисенең муеныннан кочты, аның башыннан сыдырылып төшкән яулыгын рәтләде.

— Үртәмәсен, мыскылламасын дөрес булмаганны әйтеп.

— Кем мыскыллый сине, кем?

— Фатыйма апа Сәлиме. Әниең яралылар ашын урлаган, ди. Шуның өчен аны эшеннән куганнар, аның урынына минем әнине куйганнар, ди. Ник мактана? Ник сине каракка чыгара? Мин карап тик торыйммы? Карак малае булып калыйммы? Бер дә юкка... Авызына сылаган идем, ул минем күзгә тондырды. Бирәм әле мин аңа, күрсәтәм әле мин аңа карак малаен!..

Хөсниянең бөтен тәненә ялкын үрләгән төсле булды. Караватка утырган җиреннән күтәреләм дигәндә, башы әйләнеп китте, мичкә барып сөялде. Төсе качкан күзләрен улына төбәп, өнсез калды. Иреннәрен бер ачты, бер йомды...

— Борчылма, әни, борчылма син... — Рәмзи дөньяда иң якын кешесен юатырга җыена иде. — Дөрес түгел бит аның сүзе... Лыгырдый гына... Син — карак түгел, карак була алмыйсың. Мин бүтән сугышмам, син тынычлан гына. Бер сүз дә әйтмәм, түзәрмен. Сөйләсеннәр шунда!..

Хөсния утлы табага бастырылган хәлдә иде.

— Утыр, улым, аша. Менә бәрәңге боткасы, чәй дә кайнар әле. Кил, утыр, аша... — диде ана, үзен тыеп, тыныч булырга азапланып.

Рәмзи, өстендәге күлмәген сала-сала:

— Ашыйсым килми, әчәсем дә килми, йокым гына килә,— дип ятакка сузылып ятты һәм юрганы белән томаланды. Хөсния дә чаршау корылган караватка килеп утырды, утны сүндерде.

«Инде нишлим? Ни кылыйм? — Хөсния гомерендә беренче тапкыр шул дәрәҗәдә шыксыз билгесезлек, коточкыч сорау алдында калды. — Булган икән заманалар, юк-бар хәсрәтне чутка алып, җан көйдергәнмен. Менә ул кайгының кара шәл ябынганы. Менә ул кабереңә хәтле озата барачак хурлык. Ирем үлү хәбәрен алган көнне иң кара көнем дип атаган идем. Алай түгел икән әле. Атна буе өйдән кеше өзелмәде, ялгыз итмәде авылдашлар. Һәркем юатты, ил белән килгән кайгы диделәр. Ил азатлыгы өчен шәһит китте йорт башың дип юаттылар. Һәркайсы диярлек хәзинәдә барыннан китерде. Авыл Советы булышты, госпитальнекеләр ярдәм кулы сузды. Кайгының менә монысын кем белән уртаклашырга? Кем уртак итсен бу хурлыкны? Әй, Фатыйманың да авызы иләк икән инде! Балаларына хәтле шуны сөйләп тормаса?! Рәмзи,балакаем, мине яклап сугышкан бит. Инде чынын белә калса...»

Таң алды иде. Күрше этәче сөрән салды. Аңа бүтәннәре кушылды. Кышкы суык һавада этәчләр хоры башланды. Хөсния әле керфек тә ормаган иде. Әкрен генә урыныннан торды. Хәрәкәтләре шул тикле авыр иде, аякларына потлы гер асканнармыни.

— Барыйм әле, балаларым торганчы, бәлки, әйләнеп тә кайтырмын,— дип өйдән чыгып китте.

Корпус ишеге төбендә дежурлык итүче хатын Хөсниягә, тагын берәр нәрсә чәлдерергә килдеңме таң тишегеннән, дигән төсле карады. Шулай да сәламгә сәлам бирми булдыра алмады. Хөсния үзе эшли торган бүлмәгә узды. Имгә-томга саклаган шикелле саклап торган бер бит чиста кәгазен эзләп тапты. Язу-сызудан бизгән бармакларын көчләп эшкә җикте дә яза башлады:

«Эвакогоспитальнең икенче корпусындагы бүлек начальнигы Анна Захаровнага... Гариза... Мине бүгенге көннән эшемнән чыгарыгыз, үтенәм. Үзем гаепле. Бераүне дә каргамыйм. Үзе егылган еламас...»

— Анна Захаровна килүгә шуны аңа бирерсең әле,— дип, дежурныйга икегә бөкләнгән кәгазен сузды. Тегесе дәфтәр битен алмады гына түгел, Хөсниягә җирәнеп карады:

— Каракның ялчысы булмый, җанкисәгем! — дип шартлатып әйтеп куйды.— Күтәрсең дә үзең бирерсең, яме...

Хөсния кан чыгардай итеп аскы иренен тешләде. Шунда Рәйханә килеп керде һәм Хөсниянең гаризасын укыды, эштән китсәң, ничек көн итәрсең дип киңәшләште. Хөсния исә кичтән Рәмзи белән булганнарны бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Тагын Анна Захаровна белән киңәштеләр. Бу юлы киңәш-уңаш госпиталь начальнигына ук барып җитте. Начальник бик нык кәефсезләнде, кат-кат уйланды да:

— Гыйльметдинованы эшеннән азат итү кирәкмәс. Фронтовик хатыны. Яуда үлгән сугышчы хатыны. Өч бала. Эшләсен. Аңлагандыр. Контрольдә тотарсыз. Тик һәр даим намусына тукыну булып чыкмасын. Поселокта таралган сүз — бик ямьсез күренеш. Моны ничектер чикләргә кирәк. Бәлки комиссарны тагын мәктәпкә җибәрергә кирәктер. Ул бит анда әледән-әле укучылар белән очраша тора. Җаен китереп, госпиталь хәлләре тезмәсеннән бу эшкә дә сак кына кагылыр... Гыйльметдиновага бу тапны сылап калдырмау ягын карар. Аның осталыгы җитәсенә ышанам...

* * *

Ут капкан дип уйларсың, Рәйханәнең эш бүлмәсенә Зөмәрә йөгереп килеп керде. Күзе-кашы көлә, йөзе мут.

— Безгә барабызмы бүген?

— Сездә ни була?

— Кич утырабыз. Гел ат урынына эшләргә генә димәгәндер. Унтугыздан бөкрең чыгар монда... Өйдә берүзем. Әни күрше авылга бәрәңгегә китә. Патефон уйнатырбыз, бераз ял итәрбез.

— Яралыларның яңа төркемен китермәсәләр,— диде Рәйханә. Аннары нидер исенә төште кебек, кинәт сорап куйды:

— Әниең кайсы авылга бара? Госпитальдән дә бәрәңгегә баралар бүген. Әллә, мин әйтәм, үзем дә шулар белән утырып барыйммы? Китә калсам, сезгә бара алмыйм дигән сүз. Көтмә...

— Шушы суыкта үзең йөрмәсәң...

— Бер көн юлда кайтканда бәрәңгенең бер өлешен тундырганнар иде. Үзем барсам, карабрак кайтырмын, дим.

Зөмәрә иреннәрен турсайтты.

— Тыгылмаган җирең юк синең, Рәйханә. Әнә барсын өлкән повар. Корсак симертеп кенә ята бит. Ничә килограмм бәрәңге туңган икән, ахыр заман житмәгәндер лә!

Бу сүзләргә Рәйханәнең ачуы килде.

— Кем бәрәңгесе туңа дип беләсең соң? Яралылар хакы. Ил байлыгы. Һәммәбез дә шулай барысына да җиңел карый башласак, ерак китәрбез. Еллары нинди!

Зөмәрә күп уйлап тормастан әйтеп салды.

— Син генә патриотка инде! Сиңа гына күп кирәк! Көтәм, кил. Ничек килеп керсә, шулай чыгып та китте. Яшен ташымыни! Рәйханә аны орыша калды.

— Мин дә патриотка шул! Ваемсыз җан. Ярты капчык бәрәңге — яралылар өчен бер ашлык ул...

Мәгәр озак тормады, Зөмәрә янә әйләнеп керде. Песи сыман гына Рәйханә янына килде һәм колагына үрелеп:

— Дускаем, дустым, матурым, бүгенгә бер пар кием биреп торсана, ә? — дип сорады.

— Нинди кием?

— Складыңнан шинель, итек, бүрек.

— Нишлисең алар белән?

— Кичкә әйтермен, яме? Әйдәле, мин аларны складтан синең бүлмәңә кертеп куям. — Зөмәрә Рәйханәне кулыннан тартып әйди башлады. Рәйханәнең чын-чыннан ачуы кузгалды.

— Туктасана, балаланма! Ниткән киемнәр бирим ди мин сиңа? Талчукта чүпрәк сатулашкан кебек кыланасың. Исәпсез нәрсә бар дип белдеңме син ул складта?

Зөмәрә кызарынып-бүртенеп, үтә канәгатьсезлек күрсәтеп чыгып китте. Ишек ябуыннан күпме ярсынуын чамалап була иде. Тик Рәйханәнең эше муеннан, Зөмәрә кыланышларына игътибар итеп торырга вакыты бөтенләй юк иде. Ул палатадан палатага йөрде. Яңа ел борын төбендә. Корпуста концерт булырга тиеш. Сәламәтләнеп килүче яралылардан да катнашырга теләүчеләр табылды. Госпиталь җитәкчеләре моны хупладылар. Бер тапкыр репетиция сыман нәрсә уздырып карадылар үзе, әмма аңа ышанып кына сәхнәгә чыгып булмый ла инде! Һәвәскәрләрне барлыйсы, тагын бер кат осталыкларын тикшереп карыйсы бар.

Өченче палатага керүгә, койкаларның берсендә ятучы чуваш егете Потапов, култык таякларына таянды да, сикерә-атлый, өстәл янына килде. Стена буендагы урындыкны Рәйханәгә алып бирде.

— Утырыгыз, сестра! Сезне көтеп ята идем әле. Соравым бар: миңа концертта шигырьләр укырга ярыймы? Чувашча да, татарча да.

Потапов тумбочкасыннан куен дәфтәре алып килде.

— Менә Фатих Кәрим дигән шагыйрьне беләсезме?

Рәйханә көлемсерәде.

— Беләм.

Потаповның да йөзе яктырып китте:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

— Мин шул шигырьне чувашча укыйм, ярыймы? Тулысынча... Үзем тәрҗемә иттем, ярыймы? — дип күңелендәгесен сөйләп бирде. — Татарча укый торганы чуваш шигыре. Алай да ярый бит, әйеме?

— Ярый, бик ярый,— диде Рәйханә. Ул Потаповның атлыгып торуына чыннан да шатланган иде. — Рәхмәт кенә яусын сиңа, Павел! Бүген кичке аштан соң репетиция.

Бишенче палата ишеге төбендә Рәйханә туктап калды.

Палата эченнән әкрен генә уйнаган гармун тавышы ишетелә иде. Таныш көй, кыяр-кыймас кына уйныйлар. Ул ишек шакыды. Гармун тынып калды. Кыз кергәндә Микола кулындагы гармунын караватастына яшереп маташа иде. Ярамаган эш өстендә тотылган бала сыман, ул гармунын янә тез өстенә алды.

— Микола, татар көе уйный идең ич. Уйна әле, уйна...

— Концертта уйнармын, сестра. Сюрприз итеп.

— Я инде, ялындырма. Кызык ич. Украин егете татарча сыздыра!

Ишектән Самат белән Гамир килеп керделәр. Микола гармунын караватына куйды.

Рәйханә ишек төбендә басып калган егетләрнең берсен урындыкка, икенчесен караватка утыртты. Миколага дигән утыргычны идән уртасынарак алып куйды. Сынын туры тотып, башын арткарак ташлады да игълан итте:

— Гармунда украин егете — снайпер Микола Еременко. Ул хәзер сезгә, хөрмәтле тамашачылар, татар халык көен башкарачак...

Микола гармунын җайлап тотты да чәчләрен сыпырып алды.

— Це добре! Сез бу көйне уйнарга яким образом өйрәндең дип сорарсыз инде. — Ул палатадашларына елмайды. — Потому сөйләү кирәк. Безнең подразделениедә ике егет бар иде. Берсе — Ярмухаметов, икенчесе — Динмухаметов. Берсе татар, берсе — башкорт. Фрицны кыйнаганда да, будь здоров, батырлар иде. Вот шулар, как привал, әйттерәләр генә. Ярмухаметов уйный да, җырлый да. Динмухаметов аңа кушыла. Дуэт добрый. Вот без дә өйрәндек... — Ул украин акценты белән мәзәгрәк итеп җыр башлады.

— Ай булбылым, вай булбылым,

Агиделнең камышы...

Җыр тәмамлангач, тынлыкны бозып Гамир эндәште:

— Микола, дускай, тагын уйна әле.

Бүтәннәр дә сорагач, снайпер егет җырны тагын бер мәртәбә җырлап чыкты. Җыр һәммәсен берләштергән иде инде, бөтен палата Еременкога кушылды. Сүзләрен белмәгәннәр дә көйне сузыштылар.

Рәйханә, кулындагы дәфтәренә нәрсәдер теркәп, билгеләп алды да:

— Микола, концертны син башлыйсың. Беренче чыгыш синеке,— диде.

Палаталарны әйләнеп чыкты. Уйлап номер булачагы күз алдында иде. Зөмәрә дә, киреләнмәсә, җырлар да, биер дә, дип ышанырга кирәк. Рәйханә үзе җырлый да җырлый инде. Башлап йөр дә читтә торып кал имеш? Алай булмый, әлбәттә.

Кәеф китәргә бер җай да юк иде шикелле. Ләкин бүлмәсенә кайтып, ялгыз калуга, Рәйханә моңсуланды. Бөтен эчке дөньясын актарып эче поша иде аның, әллә нинди шомлы хис урап алган иде. Ул аны, башлыча, Әмирдән хат юклыктан күрә. Чыны да шул инде. Бик кыска гына хәбәре килсә дә, әйбәт хәбәр — исәнлек хәбәре булса, дөньясы түгәрәкләнер иде шикелле. Алны-ялны белми эшләп йөрергә дә риза, кешеләргә кулыннан килгәнчә ярдәмләшергә дә риза, тик җан тынычлыгы биреп Әмирдән хат килсен иде. Ник язмый ул? Яраланып госпитальдә ятканда да, атакага күтәрелер алдыннан да яза торды бит. Өч сүз булса да язды. Бернечә биткә сузылган хатлары да килде. Инде хәбәре юкка ике ай тулып китте. Һәлак булгандыр, я билгесез югалгандыр... Юк, юк. Аның үләренә күңел ышанмый.

Әмир көтәргә кушып китте, көтүемне үтенеп китте. Хатларында да көтәргә кушты. Иң соңгы хатында түгел, аннан алдагысында язган иде: «Сугыш — кузна уены түгел, Рәйханәм. Син моны мин язмасам да беләсең. Синең күз алдында сугышта яраланган арысланнар. Сугышта әллә нинди хәлләрнең дә тууы мөмкин. Хат-хәбәрсез торсам да, өметеңне өзә күрмә. Синең көтүең, синең мәхәббәтең мине салкын әҗәлдән саклап торыр, Рәйханәм»

Кичке аштан соң, әлеге дә баягы — Зөмәрә тагын килеп керде. Рәйханәнең ай-ваена карамый, үзләренә чакыра башлады.

— Шинель дә җәлләгән идең, таптык. Пальто да табылды, киез итек тә, бүрек тә. Әйдә тиз бул. Киен, төрен дә кузгалдык. Җилнең ачысы кузгалган, куыра прәме. Әйдә инде, әйләнеп -тулганып торасы түгел. — Ул иптәш кызын шулай ашыктыра башлады.

Ихластан әйтсәң, Рәйханә аның көндезге чакыруын оныткан да иде инде. Күңелгә ятмаган сүз бер колактан кереп өлгерми, икенчесеннән чыгып ук китә бит.

— Бара алмыйм мин, Зөмәрә. Берүк үпкәли күрмә. — Рәйханә кабат кыстау-сагызлануга урын калдырмаслык итеп әйтте. — Яңа ел концертына репетиция үткәрәбез. Үзең дә булсаң, зыяны тимәс.

— Әйдә, кыланма! — Зөмәрә тешләгән җирдән өзәргә җыена иде. — Репетициясез дә җырлый алам мин, бии дә алам. Акча алып эшләүче артист түгел ул хәтле ертылып тырышырга! Бел шуны, анда көтәләр.

— Кем көтә? Кайда көтә?

— Самат көтә инде, бик беләсең килсә. Икенче палатадан Гали дә көтә.

Рәйханә эш бүлмәсенең ишеген ачып карады. Егетләр шунда гына торалар дип уйлады булса кирәк. Берәүне дә күрмәгәч, кабарып чыккан ачуын Зөмәрәгә түкте.

— Син бит хирургия сестрасы, Зөмәрә. Саматның аягын ампутациядән ничек саклап калганыгызны беләсең. Савыгып җитмәгәнен дә бик әйбәт аңлыйсың. Бу салкында кая алып барасың аны? Әгәр өзлегә калса?

— Начарга юрама, яме? Самат фронтка китәргә әзерләнә. Шыңшык егетләрдән түгел ул, беләсең килсә.

— Хәзер үк чык та, егетләрне палаталарына озат! Мин беркая да бармыйм. — Рәйханә операция сестрасының чыгып китүен көтә башлады. Тегесе ишеккә таба адым ясады, мәгәр әйтәсен әйтеп чыгарга ниятләде.

— Пүлән син, утын пүләне. Матур итеп юынган пүлән! Йөрәгең кар базы! Җәлләмисең дә. Самат синең өчен акылдан шашардай булып йөри, озакламый фронтка китәр көне җитә. Син сукыр, туң йөрәк... — Туйганчы тезде Зөмәрә. Рәйханәнең бите уттай кызышты:

— Зөмәрә! Ни дип үрсәләнәсең? Син кыз кеше лә! — диде.

— Кыз кеше булганга, аларны җәлләп әйтүем. Кыланып утырма. Синең дә йөрәгеңә мүк үсмәгәндер. Әйдә, таң белән корпуска киләбез, берәү дә белми кала... Бигрәк тагын, мулла кызы!..

— Бар, чыгып кит әле, Зөмәрә. Булмас нәрсә белән кыстама. Җаны теләгән елан ите ашаган. Кашың кара, күзең кара, син үз җаеңны үзең кара. Минем җаным белән дә, тәнем белән дә сату итәргә хакың юк. Бар, юлыңда бул!

Зөмәрә артык сүз әйтүне үзе өчен кимсенүгә санап чыгып китте. Озак та үтмәде, озын төз гәүдәсен бөкрәйтеп, Хөснияләнең су ташыганда кия торган бишмәтен киеп, ишектән Самат керде. Башында Хөснияләнең иске бүреге.

— Мөмкиндер, Рәйханә?

Рәйханә сискәнеп куйды. Үз күзләренә ышанмый торды.

— Нишләп төреңдән бу сәләмәгә? Зөмәрәләргә шул килеш бармакчы идеңме? Башыма сыйдыра алмыйм. Акыллы кешегә килешкән эш түгел,— дип үпкәләде Рәйханә.

—Яратам мин сине, Рәйханә. — Ул өс-башын чишенеп, бер читтәге урындыкка куйды, палатада йөри торган киемнәреннән генә калды. — Аулакта бер сөйләшик дигән идем. Соңгы мәртәбә сиңа сүз кушып карыйм диюем иде. Ул тикле каты бәгырьле булма, Рәйханә. Мине дә кимсетмә. Кимсетүгә калганым юк минем... Мин Яңа елдан соң ук фронтка китәм. Син миңа әйт кенә: «Сугыштан кайтуыңны көтәрмен»,— диген. Вәгъдәң миңа талисман булыр...

Самат шулкадәр самими, эчкерсез иде бу минутта. Рәйханә күңеле йомшаганын тоймый да калды. Ул кемдер нәүмиз иткән сабыйны юатырга җыенган кыяфәттә Самат янына килде һәм шундый ук эчкерсезлек белән аңлатмакчы булды:

— Мин сине батыр сугышчы буларак, акыллы ир-ат буларак хөрмәт итәм, Самат. Уңышлар телим. Исән-сау әйләнеп кайта күр. Тик мин сиңа бернинди вәгъдә бирә алмыйм. Анысы булмый.

Самат аның кайнар сулышын тойды һәм тыелгысыз ашкынуын баса алмыйча, үзен-үзе белештермәстән, Рәйханәне кочагына тартып алды. Аның бу хәрәкәте шулкадәр көтмәгәндә килеп чыкты, кыз магнитка тартылгандай аның кочагына чумды. Тормыштагы бар нәрсәне оныткандай, Самат Рәйханәне суырып-суырып үбә башлады. Иреннәр бергә кушылды, сулышлар тоташ агым булып китте. Берничә мизгел шулай узды. Рәйханә дә аңлатуы авыр булган халәттә иде. Әлегәкадәр бер мәртәбә дә татылмаган хисне татый иде. Бит урталары алма алсулыгын хәтерләтә башлады, аның бөтен гәүдәсе калтырый иде шикелле. Тик бу дереләү куркудан да, туңудан да түгел, мондый кочакка керү, ник куллы ир-ат көчен тою башларыңны әйләндерми каламыни?.. Шулай да Рәйханәгә ниндидер көч килде һәм егет кочагыннан атылып чыкты. Саматка куркынган күзләрен зур ачып карап торды.

— Нишлисең син, Самат? Нишлибез без?.. Оят бит! — дип чәбәләнә башлады. Рәйханәнең чибәр йөзе сулып калган, аны табигый матурлыгы ташлап качкан иде. Оят һәм курку аны ток суккандай итте. — Бер генә нәрсә сорыйм синнән, Самат, хәзер үк чыгып кит... Хәзер үк... Икебезгә дә шулай яхшы булачак.

Аннары ул мендәрләр өеменә барып капланды. Хәзер инде аны ямьсез калтырау тинтерәтә иде.

Самат тагын бер адым аның ягына якынлашты һәм бик әкрен генә:

— Рәйханә! Акыллы бул, тыңла... — дип баягы сүзләрен тәкрарлый иде.

Рәйханә башын күтәрде. Күз яшьләрен сөртте, чәчләрен рәтләп алды һәм Саматның күзләренә текәлеп карап:

— Аңламыйсың син, белмисең син, Самат... Минем сугыш кырында бөркеттәй егетем, сөйгән ярым бар. Без вәгъдәләшкән. Без бер-беребезне шашып яратабыз. Үлгәндә дә мин аңа булган вәгъдәмә тугры калачакмын...

Түшәмне тишеп төшкән төсле, бүлмәгә Анна Захаровна килеп керде. Иске-москы киемнәр элгән урындык янында басып торган Саматны күргәч, ул да ни әйтергә белмәде.

— Бу нинди тамаша?..

Рәйханә дә, Самат та дәшми калдылар.

— Чыгып китегез хәзер үк палатагызга! — Монысы Саматка катгый әмер иде. — Сезгә, Нәҗипова, корпусның эчке кагыйдәләрен бозган өчен госпиталь җитәкчелеге алдында җавап бирергә туры килер. Иртәгә иртәнге биш минутлыкта аңлатырсыз. Ә хәзер урыннар әзерләгез, живо! Станциягә эшелон килеп туктаган. Ун яралыны безнең корпус кабул итәчәк.

Анна Захаровна чыгып китте. Рәйханә әле дә булса палатасына кузгалмаган Саматка:

— Менә нинди хәлгә куйдың мине! — дип, җитди үпкә белдерде.

— Гафу сорар идем, әшәке ният белән эшләнгән бер эшем дә юк. Син дә мине аңларга тырыш, Рәйханә... Аңлый күр...

* * *

Декабрьнең утызы көнне Рәйханә өйгә кунарга кайта алмады. Төн уртасы узгач, яралыларның яңа бер группасын китерделәр. Аларны юындырып-киендереп, даруларын эчертеп, уколларын кадап, тамакларын

туйдырып, палаталарга урнаштырып бетергәнче, кышкы таң сызыла язды. Госпитальнең хезмәт күрсәтүче барлык персоналы аяк өстендә булды һәм йокы күрмәде. Яктырганда, сестралар, санитаркалар һәм врачлар, хәтта госпиталь начальнигы үзе дә, тәмам алҗыганнар, йончыганнар иде.

Гаделша төн әйләнәсенә йокламады. Урамда эт өргән тавыш ишетелсә дә — тәрәзә буена килеп басты. Станциядән ишетелгән паровоз кычкыртканын да тыңлап ятты. Бик еш поездлар узды, яралы солдатлар кайтты ахрысы дип тә чамалап куйды. Рәйхананең ярты төнгә кадәр соңлаганына өйрәнде инде ул, кызының начар юлда йөрмәгәнен яхшы белә. Тик менә Гайнавалның борчулы сүзләре күңелгә тынычлык бирми. Аның бер сүзен колак тирәсе аша уздырса, икенчесе турында уйлана башлый. Гайнавал сүзләрен тыңлап аргач, кызы ят[illegible]гына чыгып ятарга да чамалаган иде дә, батырлыгы җитмәде. Хатыны үз «җыруын» җырлый.

— Менә мин әткән иде, дип әтерсең, якшыга төгел аның төн ката шында маташуы. Анда бик беләсең килсә, пеләмәгә асраган төсле ирләр, егетләр. Әле күрше Зәйтүнә дә әтеп торган иде. Я ходаем дир, анда бар да хатын-кызга сусаган бәндәләр. Йомышым төшеп, бер санитарка янына барган идем, исем китеп кайтым, дир. Рәйханә шулар белән мәж килә, бер аягы юк егет, Рәйхананең муенына ук асылып, каридор буйлап баралар иде, әтегез кызыгызга, ташласын ул эшен, я бала күтәреп ызбагызга кайтеп керер, дир. Война бит ул, ирләрне аяксыз-кулсыз итсә дә, мәхәббәт дигән нәрсәне бер нишләтә алмый, дир. Әнә, дир, безнең кияү продуктовый магазин директоры, шунда сатучы итеп урнаштырыгыз Рәйханәгезне, дир.

Гаделшаның бер сүз дә әйтмәгәненә ачуы чыгып, Гайнавал пышык-пышык елый башлады.

— Без Рәйханә белән кайчаклар бер-беребезне яратып бетерешмәсәк тә,җан тартмаса, кан тарта, дигәндәй... Мин аның бәхетле булуын телим. Ә син — ата каз шул, исең дә китми...

Гаделша хатынын юатырга теләпме, кызу-кызу сөйләп китте.

— Шундый да каһәрле елда партиягә язылган баланың башына бозык уй килмәс. Эш дип янып йөри ул бала. Анасына охшаган. Булсын дип, җиренә җиткереп эшли ул үз эшен. Хәленнән килсә, җәфа чигүчеләргә үз йөрәген бүлеп өләшер иде. Ничә мәртәбә кан гына бирде инде ул ранныйларга.

Гайнавал иренең шул сүзләрен генә көткән иде, күрәсең:

— Кан бирүнең дә, каһәтем, файдасы юк дип әтәләр. Әнә, Зәйтүнәнең олы кызы гәзиттә укыган. Җиткән кызга кан өләшү ярап беткән гамәл түгелдер, дир. Нацыйбы цыга торган булса, кемгәдер катын, кемгәдер ана булырга тиеш ласак әле ул. Син, ата каз булсаң да, шул хакта да уйлан!..

— Нишләп насыйбы чыкмасын, ди. — Гаделша үз кызының кияүгә чыгачагына, ирдән уңачагына шикләнми иде. — Гарип-горабамы әлләә?.. — Гаделша җәһәт кенә урыныннан торып китмәкче иде. Гайнавал көчле-юан беләкләре белән аның муенын урап алды.

— Я ярар, ярар, алланың бер үзенә тапшырдык, бераз йоклап алыйк әле,— дип, эче-тышы чәчәкле сатин юрганы белән башыннан ук томаланып, Гаделшаны да шунда чумдырды.

Гаделша үз җаена гына киенеп өйалдына чыкты. Күкрәк тутырып, саф һава сулады. Кышның сырты сынып куюга сөенде. «Без ярый ла яккан өебездә, җылы юрган астында,— дип уйланды карт, дөньяның кеме генә юк бу елларда. Яу кырындагыларга быелгы салкыннар бигрәк каныкты. Исән калганнары гомергә оныта алмаслар. Яралылары тилмереп җан бирәләрдер. Малай ни хәлләрдәдер инде? Хатларын өзми әле өзүен дә. Танкта сугыша, молодец! Медальләре бар...»

Кар мул яуган иде. Гаделша башта ишегалдын көрәде. Аннары капка төбенә сукмак ярды. Билен турайтып, тирә-ягына күтәрелеп караса, яктырып килә иде инде.

Өйгә кереп чәйләргә дә канюшняга барырга кирәк дип исәп йөртте. Мөдир көнենә генә кайсыдыр колхозга барып кайтырга җыена иде. Ат җигеп, чанасын көйләп, солысын биреп озатасы булыр...

Чәйләвен чәйләде Гаделша, тик иртәнге ризык җыюлары хәерсез сәгатькә туры килгән булып чыкты.

Почтасын кичтән таратып өлгермәгән хат ташучы иртүк капкадан килеп керде. Чолан ишеге төбендә туктап, шап-шоп китереп аякларындагы карны какты, аннан йөткергәләп алды. Өй бусагасын атлап кергәч тә, уфылдап, ишек буендагы сәкегә утырды.

— Көрт күмеп киткән бит үзегезне, ничек яшисез бу тау астында? Ул тауларны ничекләр менеп, ничекләр төшәсез? — дип сөйләнә-сөйләнә, иңсәсендәге сумканы алып, хатлар актара башлады. Кирәк хатны күптән тотып торса да, кулын сумка эченнән чыгармыйча, әле Гаделшага, әле Гайнавалга карап алды. Аннары аягүрә басты, сумкасын яңадан иңенә асып, кулындагы конвертны Гаделшага сузды һәм: «Сау булыгыз!» — дип тиз генә чыгып китте. Хат ташучы кыз андый конвертлар эчендә нинди хәбәр язылган булуын яхшы белә һәм кешеләрнең үзәге өзелгән минутларда шаһит булып торасы килми иде.

Гаделша яман хәбәрне сизенде. Идән уртасына баскан килеш, гәүдәсе чайкалып-чайкалып куйды. Әкрен генә атлап, мич янына килде, аркасын җылы мичкә терәде. Шундый иде аның гадәте. Берәр борчу төштеме, хафа килдеме, шундук мич янына барып, аркасын тери, җылы мичкә сыена иде.

Конверт ачылды. Кечкенә форматтагы саргылт төстәге кәгазьгә язу машинкасында:

— «Нияз Гаделша улы Нәҗипов Ватаныбыз азатлыгы өчен сугышта батырларча һәлак булды»,— дип язылган иде.

— Синең дә гомерең киселдемени инде, балакаем?! — дип, чүгеп куйды Гаделша.

Гайнавалга аңлатып тору кирәкми иде. Җан өшеткеч бу хәбәр аны да тетрәндерде, ул чыдый алмый еларга ябышты. Үзе елый, үзе: «Әй канәтем, канәтем, мине бәхиллә, улым, ярамаган гадәтләрем булгандыр, ярамаган авыр сүзләр дә әйткәндермен, канәтем. Гафу ит!.. Кай җирләрдәрәк салдың икән инде, канәтем, шошы башларыңны»,— дип такмаклый иде.

Гайнавал үзе елады, ә үзе ирен юатты. Дару эчермәк булды. Гаделша күзенә һични күренми иде. Миңгерәп утырды-утырды да киенде һәм эшенә кузгалды. Аннан госпитальгә барырга карар итте. Рәйханәдән дә бу хәбәрне яшереп булмаячак ич!

Рәйханә әтисе килүгә гаҗәпсенеп калды. Ел ярым эшләп беренче аяк басуы. Ул аны үзенең эш бүлмәсенә алып керде, урын бирде. Гаделшаның килүен бераздан үзенчә юрап куйды: «Иртәнгә кадәр көткәннәр дә, шаулашканнар, ызгышканнар. Шуннан соң миңа рәнҗергә дип эти монда килгән...»

Гаделшаның умыртка сөяге буйлап бик каты авырту узды, чигәләренә ике яктан ике чүкеч белән кыйнагандай булды. Хәлсезләнүен сизеп, кызына карады. Чырае киндер төсенә кергән иде. Рәйханә имәнеп китте.

— Әти, әти, нишләдең? Ни булды? Мәле мендәр, башыңны шунда куеп тор...

Гаделшаның күз алды караңгыланды һәм үзен кинәт төпсез упкынга төшеп киткәндәй хис итте. Аска таба оча шикелле иде ул. Каядыр тотынып калырга дип, кулларын җәйде һәм өстәлгә чытырдап ябышты. Әсселе-суыклы булып китте, тәненә тир бәреп чыкты. Шуннан соң беренче киеренкелек узган төсле булды. Карт акрын гына күзләрен ачты, башын күтәрде. Ул калтыранган кулын кайры туны кесәсенә тыкты. Учы пешкән шикелле булды. Әйтерсең лә, кесәсендә гади конверт түгел, утлы кисәү башы көйри иде. Учны гына пешерсә, бер хәл булыр иде, бәгырьне пешерә, үзәкне көйдерә иде ул конверт-кисәү.

— Мә, кызым, укы... Безгә дә хәсрәт суының иң ачысын эчәр көн килде. Фашист мәлгуньнәре Нияз баламның башына җиткәннәр.

Рәйханә абыйсының һәлак булу хәбәрен китергән кәгазьгә күз йөртеп чыкты. Хәле бетеп, стенага терәлде. Иреннәре калтырый, каты бизгәк өянәге эләктереп алгандагыча, теше тешкә тиеп шыкылдый башлады. Күзләреннән яшь ага, йөзенә тозлы эз сала иде.

— Ела, кызым, ела! — диде аңа әтисе. — Ела, җиңелрәк булмасмы... Күз яшьләребез фашист башкисәрләренә төшсен... Бәдбәхетләр, багалмадай күпме яшьләрнең гомерләрен кисәләр...

Кыз «кара пичәтле» хатны халат кесәсенә тыкты да, йөгереп бүлмәсеннән чыгып китте. Күп тә үтмәде, дежур врачны һәм кулына шприц тоткан сестраны ияртеп керде.

Үз гомерендә фани дөньяның кара кайгыларын байтак кичергән Гаделшаның да бу тикле хәлсезләнгәне, бетәшеп калганы юк иде. Сестра укол кадап чыкты.

Анна Захаровна килеп керде. Һични сорашмады. Рәйханә дә бер сүз дә әйтмәде, турыдан-туры җитәкчесе булган кешегә «похоронка»ны гына сузды:

— Дөньяда иң зур хәсрәт — газиз балаңны югалту. Тик, абзый, сезне тынычландырырлык бер генә сүз дә таба алмыйм. Сабыр булырга тырышыгыз. Йөрәгегезне учыгызга кысып булса да түзегез! — диде Анна Захаровна. — Ил белән күрә торган кайгы. Нык булыгыз! Йомшап калдылар, кулларыннан эш төште, дип фашист сөенә алмасын!

Гаделша докторга карап торды, теләктәшлеге өчен рәхмәт укырга теләде, ләкин кирәкле сүзләр теленә килми йөдәтте.

* * *

Госпитальдәгеләр яңа — 1943 елны каршылау кичәсендә Рәйханә була алмас дип уйлаганнар иде. Гаиләгә шундый хәбәр килгән көнне кешене концертта катнашырга, җырларга-биергә мәҗбүр итеп булмый инде. Әмма әтисен атка утыртып китүенә сәгатьтән артык вакыт узмады, Рәйханә әйләнеп килеп тә җитте. Санитаркалар, Зөмәрә, Анна Захаровна, Олег Михайлович — һәммәсе, ул күренүгә, сагаеп калдылар.

Рәйханә исә бәгырен таш итеп ныгытырга өлгергән, шыңшу-зарлану дигәннәрне күңеленнән чыгарып ташлаган, бернинди дә хәсрәт ябырылмаган төсле, бөтен эшен җиренә җиткереп эшләп йөри.

— Чакматаштыр бу кыз безнең,— диде Олег Михайлович Анна Захаровнага. — Просто молодец!

Бүлек начальнигы, аның фикерен куәтләп, үзалдына гына әйтеп куйды:

— Бер эше ир-атны оялтырлык дәрәҗәдә нык шул. Шундыйлар белән көчле дә инде без, Олег Михайлович...

Халык урыннарына таралышкач, госпиталь начальнигы Анна Захаровнага яңалык ирештерде:

— Бүген генә Мәскәүдән хат алдым... — Майорның йөзе бик җитди, сүзләре уйчан иде. — «Бөтенсоюз эвакогоспиталь отличнигы» дигән күргәзмә ачыла икән. Шул күргәзмәдә катнашучылар итеп бездән дә бер врач, бер сестра һәм бер санитарканың кандидатураларын тәкъдим итүне сорыйлар. Әлбәттә, аларның фотосурәтләре һәм автобиографияләре, шәхси листоклары кирәк булачак. Иртәгә сезнең яныгызга комиссар керер, сөйләшерсез. Сестралардан, минемчә, Нәҗипова кандидатурасын күрсәтү дөрес булыр. — Шуларны әйткәч, майор Анна Захаровнага сораулы карашын төбәп торды. — Бу, әлбәттә, минем шәхси фикерем. Хәл кылу — сезнең иркегездә...

* * *

Мен тугыз йөз кырык өченче елның бишенче январе иде. Зыкы суык көн. Кояш та «колакланып» чыккан. Әйтерсең, дөньяга жылы һәм яктылык өләшүче жисем үзе дә салкыннан куркып калган. Төкерек жиргә төшеп житмәстән ката. Кичке якта очып барган чыпчыкларның жиргә егылып төшүләрен күрергә мөмкин иде.

Сәламәтләнеп кабат фронтка китүчеләрне бик жылы озаттылар. Госпиталь житәкчеләре, дәваланучыларга хезмәт күрсәтүче персонал яуга китүчеләргә үз йөрәкләренең кайнарлыгын бүлеп бирергә риза иделәр.

Тимер юл станциясенә кадәр булыр-булмас ике чакрым ара. Савыкканнарны илтү өчен дүрт ат жиктеләр. Ат башында яшүсмерләр. Олы юлга, хәтәр сәфәргә китүчеләрнең барысына да толыплар таптылар. Озату чае хәзерләнде. Поездга кадәр вакыт бар иде але, шактый иркенләп утырдылар. Госпиталь башлыгы да, Олег Михайлович белән Анна Захаровна да, фронтка китүчеләргә хат язгалап торырга куштылар.

Станциягә кузгалыр алдыннан дәваланып житкән сугышчылар госпиталь кешеләре белән бергә фоторәсемгә төштеләр. Озатулар вакытында моңа кадәр дә фотога төшүләр булганы бар иде. Бу юлы район фотографиясеннән хатын-кыз останы Рәйханә чакырган. Рәйханәдән моны Самат бик гозерләп сораган иде. Һәм менә рәсемгә төшәр минут житкәч, Самат Рәйханә янына килеп сыенды һәм әйтергә онытмыйм дигәндәй:

— Мин сиңа хат язып торырмын, яме? — диде.

— Язарсың, Самат, язарсың. Исән генә йөри күр...

Саубуллашу минутларында Рәйханә башка нинди сүз таба алсын соң?

Фронтка китүчеләрне озаткач, Гамир күңеленә ниндидер бушлык кереп оялады. Ул үзенең дә савыккан егетләр белән бергә яу кырына китә алмавына, барыннан да бигрәк, беркайчан да андый сәфәргә чыга алмаячагына әрнеде. Гомерлеккә ябышкан шушы шыксыз-шөкәтсез уй аның йөрәген әкияттәге каракош булып өзлексез чукый иде. Каракош чукый тора, яңа ит үсә тора. Әрнү-сызлануларның очы да, кырые да булмаячак...

Аның корымдай кара уйларын палата ишеген ачып кычкырган дежур сестраның әмере бүлде:

Әгъләмов Гамир — хирург кабинетына!

Гамир Владимиров кабинетына ашыкмый гына, сүлпән генә барды. Шулай да врачта булганнан соң кәефе арулана төште шикелле.

Хирург Гамирның кулын бик жентекләп карады да:

— Ях-шы-ы-ы... — дип сузды. — Нәрсәсе яхшы? Гангрена куркынычы узды. Менә шул бик яхшы. Терсәктәге чәрдәкләнгән сөякләр әйбәт ялганган. Инде хәзер массаж, массаж... Бәлки ике-өч атнадан өегезгә дә кайтарырбыз...

Гамир озак вакытлар гипс астында хәрәкәтсез яткан, ап-ак булып, нечкәреп калган сул беләгенә, учына, бармакларына карап алды. Ит кунарга гына калса, кунар, дип уйлый иде. Ярый, язмыш коточкыч фажигадән саклады, әгәр кискән булсалар?.. Ул чагында моны күз алдына китерүе дә куркыныч!

— Рәхмәт сезгә, Олег Михайлович, бик рәхмәт! — Алга табарак сөрлегеп, Гамир коридорга чыкты. Бер буш, тыныч почмак эзләде ул. Шунда кереп, ялгызы гына озаклап утырасы килде. Күңеле ялгызлык тели иде. Корпуста андый почмакны каян табасың? Үзләренең палатасына китте. Бәхетенә, бүтәннәр чыгып киткәннәр. Ул караватына килеп ятты. Кем дә булса кереп борчымасын, сүз кушмасын өчен, йоклаганга салышып, одеялын башыннан бөркәнде. Боз кебек салкын беләгенә кайнар иреннәрен куйды. Бу кулы — аның иң зур куанычы хәзер дөньяда. Өч бармагы булмаса да, киләчәктә аны ашатачак, киендерәчәк ул, тора-бара каләмкарандаш тотарга да ярап куяр әле, дип өметләнде Гамир. Баш бармак

белән чәнти бармак исән. Кашык тотып булачак. Кырыну әсбабын тотарга да җае бар. Төймәләрне каптырырга да өйрәнми калынмас.

Уйлар шул ноктага килеп җиткәч, үз-үзеннән мыскыллы итеп көлеп алды Гамир. «Нәрсә этәчләнгән буласың? Сугыш тегермәне гарипкә әйләндердеме үзеңне? Ничек кенә әле! Кемгә кирәгең бар синең? Егерме ике яшеңнән тере гарип. Таңсылуга кирәкме син? Өйләнә алырмын дисеңме? Нәселем калыр дип хыялланасыңмы? Эшләрсең, анысы эш табылыр. Балалар укытырсың. Әмма...»

Бәхеткә бу уйларга каршы торырлык икенче Гамир да бар икән әле. Анысын бер сугуда гына иярдән бәреп төшерермен димә. Анысы хисләр колы гына түгел, акыл белән рәк эш йөртә. «Сиңамы соң сыкранырга, сержант?! Син — Ватан-ананың батыры. Батыр ярасыз булмый. Чыннан да, выше голову! Чыннан да, так держать!»-

...Гамир әтисен дә, әнисен дә хәтерләми. Аның әнисе дә, әтисе дә егерменче елның язында, Гамир күкрәк баласы чагында ук, тифтан дөнья куйганнар. Ашказар суының ярларыннан ташып чыккан елы булган. Күрше-колан аны башта сабыйлар йортына биргән, аннары инде балалар йорты. Унбиш яшенә кадәр ул шунда тәрбияләнгән. Эшләп укый-укый, урта мәктәпне тәмамлады. Заманында зур белем иде ул ун класс.

Аны мәктәп тарта, балалар тарта. Теләге — укытучы булу. Педагогия институтына керергә кирәк аңа. Югары белем алырга. Ләкин, һәрбер теләк — якын киләчәк дисәк тә, ул киләчәкнең нигезен хәзерләргә кирәк. Бер-ике ел эшләргә, өс-башны карарга, кесәгә азмы-күпме акча салырга, аннары институтка. Шулай итмәгәндә, аның турыдан-туры таяныр кешесе юк... Мәктәпкә билгелибез дип торалар иде аны, директор үзе әйтте: Әгъләмов, синдәй математиклар бик кирәк мәктәпләрдә»,— диде.

Хыялы чынга ашты егетнең. Сугышка хәтле җидееллык мәктәптә укыта башлады. Күп укыды, институтка керергә дә хәзерлек алып барды.

Беренче елын укытканда кырык биш минутлык дәрескә йөз кырык биш минут хәстәрләнгән чаклары да булгалады. Мәктәпне ташлап китәргә дә йөрде. Ә хәзер менә өзелеп мәктәпне сагына. Шул малайлар, кызчыклар арасында кинәнеп эшләр иде. Эшләр иде, андый гына көч табар иде үзендә. Тик аның белән барырлык юлдашы, тугры кешесе булсын иде. Күз алдына Таңсылуын китереп бастырды. Юк, юк... Андый гүзәлкәй каршысына бу кыяфәттә ничек барып басыйм?.. Юк, юк, аның сөйгәне, тугрылыклы иптәш булырлык кешесе юк. Таңсылу гаепле түгел... Аның ике күзенә дә яшь бөртекләре бәреп чыкты... Фашист аны гарип кенә итмәде, өзелеп сөйгәненнән аерды...

Ул урыннан сикереп торды. Тагын бер кат Таңсылу исемен кабатлады. Аннан палатадан чыгып китте. Ул Рәйханә бүлмәсенең ишеген шакыды.

— Мөмкин! — диде сестра.

Алар, бер-берсенә карашып, беравык тын гына тордылар. Аннан Рәйханә:

— Кулыгыздан гипсны алгач, тагын да чибәрләнеп киткәнсез, Гамир абый! — дип, бөтен йөзе белән елмайды.

Бу сүзләр Гамирны алыштырып куйгандай итте. Һай, бу кеше күңеле дигәнең! Кеше күңеле пыяла, бик аздан да уала, диләрме әле?.. Әйе, мәгәр бик аздан да ныгый, канатлана да ул...»

Гамир үзендә гаҗәп бер дулкынлану сизде.

— Алгебра нишли, сеңлем, мәсьәләләр?

— Әй, Гамир абый, шәп түгел әле... Яңа ел кергәннән бирле бер мисал да чишкәнем юк.

Гамир укытучылыгына бирелде.

— Мактамыйм. Алынгансың икән, ташлама.

— Бик каты куллы булмагыз инде, Гамир абый. Я бөтенләй булышмый башларсыз...

— Үзем монда чакта булышырмын. Кулдан килгән кадәр...

— Нигә, чыгаралармыни инде?

Гамир Олег Михайлович белән булган сөйләшү хакында әйтте.

— Вакыт бар әле, бар. Математиканы бераз өйрәнә алабыз әле,— дип тынычландырды.

— Госпитальдән соң кай якларга китәргә исәплисез инде, Гамир абый?

Һай бу кыз бала!.. Белепме, белмичәме — сержантның авырткан җиренә басты.

— Нәкъ шуны уйлап башымның әйләнгән чагы, сеңлем.— Гамир бу сүзләрен житди итеп әйтте.— Төп йорт юк. Әти-әни юк. Туган-тумачасыз мин. Дүрт ягым кыйбла...— Аның бит уртасы алланып китте. Оят... Кыз бала алдында зарланып басып тора, егет башың белән, колгадай буең белән... шунда кинәт кискен бер карарга килде, айлар буе үзен борчыган уйларыннан арынып өчен, тавышына ныклык, ышаныч чыгарып:

— Хат яздырыйм дип кергән идем, әгәр вакытыгыз бик тыгыз булмаса...

— Язабыз, язабыз, Гамир абый.— Рәйханә шунда ук ак кәгазь алып килде, ручка-каләмен әзерләде.— Сез утырыгыз. Суык түгелме? Җилкәгезгә менә бу сырманы салыгыз.

Гамир әкрен генә атлап урындыкка килеп утырды.

— Башладык, Гамир абый!..

— Бәгырем, Таңсылу!— диде Гамир, кулын бәйләгән марля белән маңгаен сөртеп алды.— Мин сиңа хәбәр иткән идем инде. Дүрт ай госпитальдә дәваланганнан соң тәмам сәламәтләнеп беттем дисәм дә була.— Ул тынып калды, уйлары белән бик еракка китте. «Бернинди рәнжү, зарлану сүзләре язмаска, Таңсылуның гаебе юк»... дип уйлады.

— Булды, яздым.

— ...Китәр вакытлар житте, бәгырем Таңсылу! Мин китәм. Тик белмим — кая китәрмен. Кызык хәл, минем син яшәгән җирдә генә яшисем килә, ә үзем синең яныңа түгел, каядыр башка җиргә китәргә җыенам... Мин сине сөя идем, шул сөю миңа, дәрт, куәт бирде, авыртуларны җиңәргә көч бирде, сине өзелеп сөя алганга дөньяда яшәргә өмет бирде. Сөя белгән, мәхәббәт хисләре саклый белгән кеше, нинди генә гарип булса да, ул әле кеше, ул дөньяда яшәргә тели һәм ул яшәргә хаклы. Мин киләчәктә дә озак еллар буе сөйкемле күз карашларыңны, матур итеп сөйләшүләреңне онытмый күңелемдә саклармын. Гомеремдә беренче мәртәбә сине шулай саф мәхәббәт белән яраттым бит мин. Бүгеннән соң мин ул олы мәхәббәтемнән бөтенләйгә качам...

Рәйханә карандашын кәгазь өстенә куйды:

— Язмыйм... Язмыйбыз... Мондый сүзләрне яза алмыйм мин, Гамир абый.

— Соң, нәрсә яздырыйм соң, сестра? Бу халдә мин аңа нигә кирәк? Ничек инде минеке бул дип әйтә алыйм шундый кызга? Языгыз, сестра.— Сине өзелеп сөйдем, миңа синең барлыгың турында уйлау гына да олы бәхет иде. Онытмине, Таңсылу...

Шул вакытта кемдер ишек шакыды:

— Нәҗипова! Анна Захаровна чакыра. Бик тиз! Карточкаларын алып керсен, диде. Тиз бул!— диде.

— Ярый, сеңлем, соңрак тәмамларбыз әле.— Гамир Рәйханәне чакырып алуларына шат иде кебек.

Рәйханә бүлек начальнигы янында озак булмады. Аны Мәскәүдә ачылачак күргәзмә уңаеннан сөйләшергә дип чакырганнар иде. Документларын янә бер кат барлап, карап чыктылар.

Кичке ашка кадәр вакыт бар иде әле, ләкин Рәйханә Гамирны үзе барып чакырырга кыймады. Борчылуын аңлады. Аның әйтеп торган нарын ак кәгазьгә теркәп барулары да күңелгә авыр иде. Гамир язмышын йөрәгенә якын итә торгач, кылт итеп уена бер нәрсә килде. Әгәр Таңсылуга

Рәйханә үзе хат язса? Иптәшләрчә, кордаш кызларча итеп?.. Һәммәсен бәйнә-бәйнә төшендереп... Туң йөрәкле түгелдер ич Таңсылу да.

Гамир хакында уйланулары абыйсының үлем хәбәренә килеп ялганды. «И-и-и, абыем шулай яраланып булса да кайтсын иде әле!» — диде ул, беркайчан да булмаячак хәлдән ачыргаланып. Һәм шундук: «Әмир шул хәлгә калса, нишләр идем?» — дип тетрәнеп куйды. Чыннан да, нишләр иде? Алар бит вәгъдәләшеп аерылыштылар. Әмире аңа: «Көт!» — диде, хатларында да гел шулай язды. Рәйханә дә: «Көтәрмен!» — дип өзеп вәгъдә бирде. Көтә. Кинәт шундый хат килеп төшсә? Кыз эсселе-суыклы булып китте. Юк, юк, Ватан азатлыгын яклап гарипләнгәннәр хөрмәткә лаеклылар, аларга биргән вәгъдәңә тугры булырга кирәк.

Шөбһәле уйларын таратырга теләгәндәй, Рәйханә башын селкеп куйды:

— Юк, лачын кебек вакытында яраткансың икән, ил өчен сугышта яралангач та ярата бел! — дип үзенә әмер бирде. Шундый карарга килгәч, Таңсылуга хат языйммы-юкмы, дигән икеләнүе дә бетте.

Кичке ашка кадәр Рәйханәнең хаты әзер иде инде.

«Кадерле Таңсылу!

Хатым килеп төшүгә гаҗәпләнмәгез. Заманы шундый. Хатлар төрле җирдән, көтелмәгән, таныш булмаган кешеләрдән дә килә. Күбрәк фронттан. Бу хатны сезгә Татарстандагы эвакуацияләнгән госпитальләрнең берсендә сестра-хозяйка булып эшләүче Рәйханә Нәҗипова яза.

Бездә сержант Гамир дәвалана. Ул фашистларга каршы батырларча сугышкан һәм каты яраланган. Илебез аны «Батырлык өчен» медале белән бүләкләгән. Госпиталь врачлары аның гомерен саклап калу өчен күп тырыштылар. Хәзер ул сәламәтләнеп килә. Сезгә хат яздырды. Киңәшәсе килә Сезнең белән. Мин уйлыйм һәм бик ышанам: Сез Гамир абыйны элеккечә үк кабул итәрсез. Аның Таңсылу димәгән чагы юк. Сез аны тыныч тормышта зур батырлыкларга рухландыра алырсыз әле.

Тыйнаксызлыкка санамагыз, минем дә егетем сугышта. Соңгы араларда хәбәре юкка борчылам. Әгәр яраланып кайта калса, мин аны берсүзсез кабул итәчәкмен. Аларның яу кырында күрсәткән онытылмас батырлыкларына без, кызлар, йөрәк каһарманлыгы, хисләр сафлыгы һәм вәгъдәләргә тугрылык белән җавап бирергә тиеш. Юк вакытыгызны бар итеп булса да, миңа хат язуыгызны үтенер идем.

Сезгә күп сәламнәр юллап, саулык һәм уңышлар теләп калучы:

Рәйханә Нәҗипова.»

* * *

Гаделша абзыйны өенә зәмһәрир суык чыбыркылап кайтарды. Ишекне ачып кергәч, буланып калган өй эчендә бер мәл күзләрен челт-челт йомгалап торды. Аннары — тире бияләйләрен мич куышына тыкты, шарфын муеныннан сүтте, тунын тиз-тиз әлгечкә элде, итекләрен салырга нелде. Йон оекбаштан килеш түргә узды. Сырган чалбар аша да тез күмәчләре туңуга исе китеп торды.

— Самавырны яңартсана, Гайнавал! — Беренче сүзе шул булды. — Авыз пешсә пешәр, шау кайнар килеш чәйләми хәл юк. Эчем бөрешеп туңды.

Өстәлдәге җиз подностан самавырын күтәреп алган хатыны аңа каршы әйтә куйды:

— Карыныбызга ит керми. Шыныкы эшетә, канәтем! Алдыңа табак тутырып ат ите килсә, әпәй урынына да шыны ашасаң, алай зрә калтыратмый да ул, йөрәк маем...

— Безгә ничава әле. Сугыштагылар нихәл чыдыйлардыр?.. — Соңгы араларда Гаделшаның күз алдыннан китмәс булып карлы сугыш кыры торды. Кан кызарткан кар өстендәге шыкырдап каткан мәетләр төшләренә кереп җәфалады.

— Андагыларга ходай күркәм сабырлыклар бирсен инде, ярабби. — Гайнавал иренең сүзен җөпләде. — Качан гына йитәр вайнаның канцасы?

— Житүен житәр. Гитлерының да муены астына килер. Анысына шик юк. Гөлдәй гомерләр әрәм була! — Гаделша көрсенеп куйды.

— Бездән тормый шул, бездән тормый... — Гайнавал самавырына күмер сала-сала сөйләнде. — Бездән торса, бөген үк сукыр Гитлерын пожарга тотып салыр идек...

— Бездән дә тора инде жиңүне якынайту, хатын, алай гына димә. Тырыша төшәргә тиеш без дә.

Гаделшаның тел төбен Гайнавал аңламады. Самавыры дөрләми аптырата идеме, йорт башының соңгы сүзләренә әллә ни исе дә китмәде.

Самавыр, паровоз сыман пар бөркеп, өстәл өстенә менеп утыргач, Гаделша чыннан да иреннәрен пешерә-пешерә чәй эчте, тамак ялгады. Өйгә дә мамыклы җылы таралган иде. Шунда инде Гайнавал белән бер уен уртаклашырга булды.

— Син бик үткен кеше инде үзең болай, хатын,— дип керешә ул. — Кулыңнан эш килә, сөйләсәң — сүзгә кытлык сизмисең. Сазнательный да син. Баягынак әйтеп җибәрдең, сызгырып куяммы дип торам. Гитлерны пожарга тотып салыр идек, дисең. Дөрес әйтәсең, ил белән, гавам белән бер төсле уйлыйсың булып чыга...

— Чу, чу! — Гайнавал мондый кереш сүздән шикләнә калды. Кай якка бөгә бу карт, янәсе. — Чу! Нәстә араторланып киттең? Мине партиюнный итмәк келимсең әллә?

Гаделша бер дулкынга көйләнгән иде инде, дәвам итте.

— Нәрсә ярамый сиңа минем хак сүзләремдә? Дөресен әйтәм, сазнательный син. Бу ягың минем өчен дә бик кулай, Гайнавал. Бүгенгесе көнне шунсыз ярамый, хатын...

Гайнавалның айның унбишенче кичәседәй тулы түгәрәк йөзенә аптырау галәмәте бәреп чыкты.

— Син нәстә,— диде ул кыза язып. — Берсәк кәгеп каттеңме әллә? Сургуч цалмалысы эләктеме, мәтәм. Умерда юкны такылдыйсың?

Гаделшага нәкъ менә шул кирәк иде. Гайнавалның үзен гәпкә тартып алу.

— Менә, менә, үзең дә килеп җиттең, хатын. Сүземнең тозы шунда — Кызыл Армиябезгә хәзинәбездә бары белән булышырга кирәк, димен. Син сазнательни, мин сазнательни — беренче Герман сугышында ук немецның штыгын татыган, әрнегән кеше мин. Фашистларны ищу этләнгән жан аның. Шуларны кырып-себереп бетерү хакына, мин әйтәм, таңк төзергә акча бирик, дим.

— Каян алып?..

— Анысы минем эш. Мәгез диярбез, поссоветка барып, акча җыючы комиссия башлыгына! Бездән — Нәҗипова Гайнавалдан, Нәҗипов Гаделшадан, Нәҗипова Рәйханәдән — уртак өлеш, диярбез. Гитлерга каршы яуда башын салган Нияз Нәҗиповның хатирәсе булсын безнең сумнарыбыз, диярбез. Ризамы син шундый эшкә кул куярга!..

— Акцасы булса танкка бирми дә урынын табар идем але. Әнәтеро Рәйханәнең аягындагы киез итеге, менә тишеләм, менә тишеләм дип тора. Һәр кич үзе үгә катькан саен шуны карыйм, тишелмәдеме әле, дим. Ә син шул турыда уйлап та карамыйсың. Үзеңнең әнәтерә бүрегеңнең дә колаклары кочык талагандай тырпаешып торалар.

Гаделша хатынына таба кулын селтәде:

— Һай, бүрек!.. Нәрсә ул бүрекнең колаклары тырпаюы. Эче җылы булгач... Я әйт, ризамы, мин тәвәккәлләдем.

Гайнавал иренә беравык сынап карап торды.

— Акцасы бакцада шул әле аның, бакцасы кар астында.

— Минем син килен булып төшканчегә кадәр үк еллар буе җыйган акчам бар. Мәрхүмә хатыным белән кара көнебезгә дип җыйнаган акча иде.

— Ә бу сүзләреңне мәрхүмәкәең ишетсә нишләр иде. Мескенкәем, ләхетеннән цыгар иде дә-үгә цабар иде. Нишләвең бу, Аделша, мин бит ул акцаларны тиенләп зыйдым, кара көнебезгә, дип. Улым Нияз үләнсә дә, кызыбыз Рәйханә иргә ћыкца да кирәк булыр, дидем дир, ә син...

Гаделшаның кинәт йөзе үзгәреп китте, күзләрен йомды. Иңсәсен бераз бөкрәйтә төшеп, башын аска иде һәм әкрен генә сөйләп китте.

— Әйе, әйе... Мәрхүмәкәем хезмәт ярата иде. Әртилендә икешәр смена эшләгән чаклары еш була иде. Берәр тегүчеме, кисүчеме сырхаулап китсә, аның өчен дә эшли иде. План-мазарлары тулмаса, өзгәләнә иде. Җаны көеп, пошынып өйгә йөгереп кайтыр иде дә: «Мин тагын киттем әле, картым, анда эшләрне тәмамлыйсы бар».— дип китеп барыр иде. Ачуланмый идем. «Хәерле юл сиңа, алтынкаем...» — дип, балалар белән тәрәзәдән кул изәп озатып кала идек. Шулай да акча күп алыр өчен түгел, эшем эш булсын, дип эшли иде.

Гайнавал авызын тутырып нәрсәдер әйтергә теләде, күзләренә усаллык чыгарып иренә карады. Карады, тик бер нәрсә дә әйтә алмады. Иренең бөтен дөньясын онытып үлгән хатынын сагынып утыруы аның күңеленә тиеп алды. Гаделша Гайнавалның тыныч кына үзенә карап, сүзләрен тыңлап утыруыннан бик канәгать иде. Ул сөйләде дә сөйләде. Яратып яшәгән хатыны турында уйланып утыруы, аның хакында әнә шулай кемгәдер ишетелерлек итеп сөйләве бик зур бәхет иде...

— Гомерем буе хәләл көчем белән җыйган акчам. Менә кара көннәр килде инде,хатын... Шулай итик, хатын, илебез өстенә килгән бу кара-авыр көннәрдә, тапшырыйк дәүләткә ул акчаларны.

Гайнавал башындагы яулыгын рәтләгәндәй итте, әйләнә-тирәгә карап алды, йөзе сулыгып китте аның. Әкрен генә атлап, ире утырган сандык кырыена килеп утырды.

— Соң ни инде, сезнең әллә кацан зыйган акцагыз турында ник минем белән сүләшеп утырасың. Аның өчен подпись сырларга минем ни хакым бар, ди. Барыгыз да тапшырыгыз. Булсын танкка. Рәйханәгә киез итекне болай да алырбыз...

...Акча тапшырып өч көн үткәч, бу гаиләнең куанычына чик булмады. Башта радиодан укыдылар, аннары гәзитләрдә басылып чыкты: Иосиф Виссарионович Сталин Татарстан хезмәт ияләренә рәхмәтен белдергән иде. Бу рәхмәттә Гаделша белән Гайнавалның, Рәйханәнең дә өлеше барлыгын тою аларга канат үстерде. Рәйханә «Кызыл Татарстан» гәзитәсенең шушы котлау басылган санын алып кайтып, сандык төбенә үк салып куйды. Верховный Башкомандующий тәбригендә болай диелгән иде:

«Татарстан колхозчысы» дигән танклар колоннасы төзүдә 100 000 000 сум акча җыйнаган Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне, Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз!

И. Сталин.»

Бу котлау алынган көнне Рәйханә танк колоннасына акча тапшырылганлыкка бирелгән квитанциясен куен дәфтәре битләре арасына, Әмирнең фронттан килгән фоторәсеме янына куйды. Гап-гади квитанция кәгазе бу көннәрдә аның өчен абыйсы гомерен өзгән илбасарларга нәфрәт һәм үч билгесе буларак кадерле иде.

Коридор буйлап атлаучы Гамирга Рәйханә эндәште.

— Бәлки сәлам хатын өр-яңадан язарбыз, Гамир абый. Бүгенге кәефегез теге көнне булсá, сез, мөгаен, сүзләрнең бүтәнчәрәгән сайлаган булыр идегез.— диде.

— Уйландым, сеңлем, дүрт ай буенча, шушы корпуска килеп кергәннән бирле уйланам. Сине күргәч, ул уйларым яктырганнан-яктырды, ышанып яшәгән көннәрем күбрәк булды. Менә бит безнең нинди кызлары-

быз бар, дидем. Мәхәббәткә тугрылыклы була беләләр. Намуслылар. Минем дә сугышка киткәндә вәгъдә биреп калган сөйгән кызым, Таңсылуым бар иде. Яралангач, мин аңа хат яздырдым, ике кулсыз мин, дидем. Яшермәдем, нигә яшерергә. Мәхәббәт бит ул, чын мәхәббәт бит ул... Дүрт ай өзгәләнеп хат көттем үзеннән. Бер генә юллык хат килсә дә, мин аның янына кайтып, үзен күреп сөйләшермен, аңлашырбыз, диган идем. Булмады.— Ул бер-ике адым Рәйханәгә таба атлады. Моннан ярты сәгать элек кенә гипсы алынган хәлсез кулын кызга сузды:

— Бирегез, сестра, миңа хатны. Мин аны сезнең истәлегегез итеп саклармын.— Сул кулының исән калган ике бармак арасына хатны кыстырды. Яраланганнан бирле беренче мәртәбә әйбер тоткан кулына карап Гамир эчкерсез елмаеп куйды. Аннан ишекне әкрен генә ябып чыгып китте.

Госпиталь комиссары чыгып киткәч, Анна Захаровна кабинеты буйлап йөренде. Тәрәзәдән көрән төстәге дермантин белән тышланган ишеккә кадәр нибары тугыз-ун адым. Шулай да әледән әле хәрәкәтләнеп торырга, йөренергә кирәк, югыйсә тәнгә суык үтә. Мичләргә якмыйлар да түгел, ягалар. Район оешмалары госпитальгә кулларыннан килгән кадәр булыша. Бүген менә утынга дип ике машина, биш ат китте.

Анна Захаровна азрак җылынган төсле булгач, калын йон шәленә төренеп утырды һәм өстәл тартмасыннан карандаш очлый торган пәкесен эзләргә кереште. Шунда, бүген инде ничәнче мәртәбә, улын исенә төшерде. Күзе аңардан килгән хатларга төште. Аерым конвертта саклый торган фотолар арасыннан Алешаның сурәтен алды...

Сак кына ишек шакыдылар. Кулына газетелар тотып, Рәйханә килеп керде. Бүлек начальнигы белән ул ишек төбеннән үк исәнләште. Аннары газеталарын Анна Захаровна өстәленә куйды.

— Бүген безнең корпуска хатлар күп,— диде сестра-хозяйка.— Күпләрне сөендердем. Менә сезгә дә...— Рәйханә, газеталар арасыннан ике хат алып, Анна Захаровнага сузды. Бүлек башлыгы аларны Рәйханә кулыннан йолкып алгандай алды, тик ике конверт та чит кул белән язылган иде, сагайды. Шәленә ныграк уранды, шуып төшмәгәем дигән төсле, урындыгына җайлабрак утырды. Авыр сулап:

— Улым частеннан килгән, тик хатны үзе язмаган. Ачыгыз, зинһар, конвертны,— диде, хатларны Рәйханәгә сузып.

Рәйханә үзен бик тыныч тотмакчы иде, ләкин барып чыкмады. Анна Захаровнаның хәлсезләнеп калуы аңа да күчте, шулай да, тумбочка өстендәге графиннан су салып, стаканны Анна Захаровна алдына куйды һәм конвертларның берсен ачты. Хаттагы беренче сүзләргә күз салу белән:

— Алешадан! — диде.

Анна Захаровна кипшенгән иреннәрен чылатты.

Рәйханә хатны укып китте:

«Кадерле әнием, исәнме!..

— Укы, укы! — диде Анна Захаровна.

...Озак хат язмый торуыма борчылгансыңдыр. Мин синең көйгәләк икәнеңне беләм бит, әнием. Эш шунда: моннан бер ай элек һава сугышы барышында мин яраландым. Госпитальгә керергә туры килде. Уң кулым...»

Анна Захаровна, җилкәсенә бөркәнгән шәлен салып, урындык башына элде. Аңа беркадәр җиңелрәк булып калды төсле. Ул, хатны үз кулына алып, һәр сүзен, һәрбер хәрефен йөрәгенә суыргандай, әйтте:

— Балакаем, тырыша-тырыша сул кулы белән язган...

«Әнием, борчылма, бетерешмә, яралы кулым төзәлеп килә. Врачларның ышандыруынча, унбиш көннән бөтенләй савыгып, частема кайтачакмын...»

Икенче хат улыннан түгел, ә моннан ике атна гына элек дәваланып фронтка киткән Андрей Семенов дигән солдаттан иде. Ул исән-сау үз

частена килеп житүен хәбәр иткән, моңа бик сөенүен язган. Тиздән һөҗүмгә кузгалабыз, дигән.

Анна Захаровна хатларны кулына озак кына тотып торды. Аның күз алдына улы Алеша белән Андрей килеп баскандай булды.

— Бездә дәваланган яшьләр дә үз балаларым төсле инде миңа,— дип көлемсерәде Анна Захаровна. — Аларга да бик нык няләшәсең. Ил өстенә килгән бәла кемнәрнең генә күңелләрен якынайтмый!.. Бу Семенов безгә килгәндә әнисе танымаслык хәлдә иде бит! Маңгай дисеңме, күз-колак тирәләрен әйтәсеңме — һәммә жирендә җәрәхәт иде. Житмәсә, күзләре күрми. Авызыннан сыек аш та үтми... Ә хәзер тагын һөҗүмгә! Рәхмәт, Рәйханә, шатлыклы хәбәрләр китердең, сеңлем!

* * *

Төш авышкач, корпуста мәшәкатьле җанлану сизелде.

Халатларын иңнәренә салган ир-егетләр складка юнәлделәр. Барысы да склад бүлмәсенә берьюлы сыймадылар, өчәр-өчәр кереп киенеп чыгалар. Аннары, коридордагы эскәмияләргә утырып, иптәшләрен көтәләр. Рәйханә аларга киемнәр биреп торды.

Шулчак комиссар да килде.

— Буласызмы, егетләр? — дип, хәл-әхвәл белеште. — Сез монда ничәү? Беренче корпустан — җиде, өченчедән тугыз иптәш... Атлар әзер. Урын һәммәбезгә җитә. Толыплар җитәрлек. Әллә ни зыян юк, тимер юл вокзалы барып җитмәслек ара түгел. Туңдыра башласа, тәпиләп алырбыз.

Ул һәрвакыт шулай. Сәламәтләнеп кабат сугышка китүче сугышчыларны бик җылы озата. Поезд кузгалып киткәндә дә күңелендә бер генә теләк: «Исән-сау йөри күрегез, туганнар! Берүк исән булыгыз!»

Корпус ишегалдында аларны врачлар, сестралар, санитаркалар озатып калды. Китүчеләргә кулларын болгап озак тордылар. Зөмәрә атка утырып өлгермәгәннәр арасында арткарак калып барган яшь егет белән бик үз итеп саубуллашты.

— Сау бул, Гали! Хат яз, яме, обязательно! — дип тезде дә, егетнең ике битеннән үбеп, йөгерә-йөгерә корпуска кереп китте.

Корпуста гадәти эш көне дәвам итте. Сәламәтләнеп килә торган яралыларны — озакламый фронтка яки өйләренә кайтып китәргә тиешле сугышчыларны — бер палатага, яннарына врачлар еш керергә тиеш булган авыруларны аерым бер палатага урнаштыру башланды.

Сәламәтләнүчеләр палатасында, һәрвакыттагыча, уен-көлке ишетелә. Ә тегесендә сыкранулар, уфтанулар...

Микола Еременко салават күпере кебек балкый. Госпиталь начальнигы аны үзе карап, тагын бер атна дәвалангач, фронтка китәргә рөхсәт итте. Ә хәзер ул, әнә, Анна Захаровна кабинетының ишеген яртылаш ачып, көр тавыш белән җыр сүзләрен тезә:

— Дивлюсь я на небо,
Хай думу гадаю:
Чему я не сокол,
Чему не летаю...

Анна Захаровна аңа елмаеп торды:

— Рәхмәт, Микола, беләм бит, Алешама атап укыдың бу юлларны,— диде.

Микола Анна Захаровнаның кулын каты итеп кысты.

— Бөтенегезгә дә зур рәхмәт! Терелттегез, савыктырдыгыз, фронтка китәргә рөхсәт бирдегез. Сугыштан соң барыгызны да туган авылыма кунакка алып китәм.

* * *

Мартның егерме өче иде. Иртәдән үк көн бозылды. Башта бик күп кар яуды. Ул да түгел, җил кузгалды һәм баш түбәсенә тиярдәй булып аккан болытларны куып таратты. Ялтырап кояш чыкты, җылытып җибәрде. Болай булса, гөрләвекләр йокыларыннан уяныр һәм язгы җырларын башлап җибәрер. Көн кичкә авышканда янә ябалак ябалак кар ява башлады.

Рәйханә күңеле дә әллә ничә төрлегә әйләнде бүген, ул тикмәгә генә уйнакламый икән!

Сәгать көндезге дүртенчегә авышкан иде, бер кыз бала аңа конверт китерде. Конверт тышына нибары ике генә сүз язылган: Нәҗипова Рәйханәгә.

Ни уйларга да белмәстән, Рәйханә конвертны ачты һәм бик аптырап калды. Хат шәмәхә карандаш белән Әмир тарафыннан язылган иде.

«Күз нурым, Рәйханә!

Хатымны гафу үтенүдән башлыйм. Каушама, югалып калма, сине дөньядагы һәммә кешедән дә якын күргән кешең белән очрашырга хәзерлән. Нык бул!.. Озак хат язмавымның да, хәзер туп-туры синең эш урыныңа барып керергә кыймавымның да җитди сәбәбе бар. Мин кичә өйлә вакытында Казанга, үзебезнең Яңа Бистәгә әти-әни янына кайтып төштем. Иртүк Хәрби Комиссариатка учетка бастым да поездга йөгердем. Синең яныңа... Минем вакытым иркен, сине төн уртасына кадәр дә, таң атканчыга кадәр дә көтә алам. Тик тизрәк кил, назлым!.. Мин кызлары әни белән фабрикада эшли торган Гасыйм абзыйларда. Алар сине яхшы беләләр...»

Рәйханәнең җиңелчә генә башы әйләнеп китеп, чүт кенә идәнгә егылмады... Әллә нишләде, кая барырга, ничек соң әле көтмәгәндә, уйламаганда ук каршысына килгән Зөмәрәне кысып кочаклап алды да зыр-зыр әйләндерде, ике битеннән чут-чут үпте:

— Син беләсеңме, беләсеңме, кем кайткан! Ә белмисең шул, башыңа да китермисең,— дип, Анна Захаровна бүлмәсенә кереп китте.

Зөмәрә коридор уртасында аптырап басып калды:

— Әллә инде акылына зыян килә башлаганмы, яраббем,— диде.

Гасыйм карт йортына барганда ул һичбер нәрсә турында да уйламады шикелле. Башы буш иде кебек. Аяклары да үзләреннән-үзләре атладылар. Әмма йорты каршында йөренеп торган кешене күргәч, гүя йокыдан уянып китте. Сугышка кадәрге кышкы пальтосын, колакчын бүреген, аягына киез итекләрен кигән кешенең Әмир икәненә шикләнесе да килмәде. Тик мондый ятсыну бер мизгел генә булып алды. Рәйханә, адымнарын тизләткәннән-тизләтә төшеп, Әмирнең муенына барып сарылды. Юньләп исәнләшә дә алмады, елады гына. Аны кочаклап алган Әмир кызны ничек юатырга, нәрсә дип тынычландырырга да белмәде. Бары тик көчле куллары белән якынының аркасыннан өзлексез сөеп кенә торды.

Зарыгып көтүдән, бөтенләй уйга да кертмәгәндә очрашудан туган хисләр өермәсе үтеп киткәч, Рәйханә кыяр-кыймас кына Әмирнең йөзенә күтәрелеп карады. Егетнең иң куркып торганы да шул иде. Ләкин, ни хикмәт, Рәйханә чыраен сытмады, кәефсезләнмәде, йөзен бормады. Башын арткарак ташлап, томырылып тагын бер карады да, әле беркайчан да булмаганча кыюлык күрсәтеп, Әмирне үбә башлады. Әйе, танкта янды Әмир. Битен ялкын җәлләми ялады. Керфекләр, кашлар юк диярлек. Яңак буйлары шоп-шома. Карталардагы диңгез чикләре шикелле җөйсыман эзләр. Сугышка кадәрге чибәр Әмирдән төз, таза гәүдәсе, зур куллары гына калган. Юк, алай гына түгел, кешеләргә ихтирам белән карый торган күзләре дә элекке Әмирнеке! Тавышы элекке Әмирнеке, сөйләшүе, мөгамәләсе, елмаюы анык! Җаны, рухы Әмирнеке!..

Өйгә кермәделәр. Турысын гына әйткәндә, Рәйханә картлардан яхшысынмады. Гасыйм абзыйның карчыгы Гайнавал апасын бер күрмәсә,

бер күрер, сөйләми дә калмас, арттырмый-өстәми дә калмас. Әмир аның белән килеште. Рәйхананы госпитальнең икенче корпусына озатты Әмир Рәйхананең эше беткән чакка корпуска килергә булды.

Алар бу юлы инде иркенләп утырдылар. Сөйләшәсе сүзләр тиз генә бетәрлек түгел иде. Шулай да байтак нәрсәләр ачыклана төште. Әмирне яуга озатканга кадәр якынлык өр-яңадан җыела иде кебек. Аннары ике арада шундый тойгы туды, гүя ялгыз каңгырышкан көннәр бөтенләй булмаган да.

Әмир сүзсез генә аны кочагына алды һәм, дөньяның иң зур сере хакында сөйләшергә теләгәндәй, пышылдап кына Рәйханәгә сорау бирде.

— Я, бүген нишлибез?

— Әмир, синнән башка бер минут та яшәү теләгем юк минем. Бүгеннән мин мәңге синең белән. Син кайда, мин шунда!

Чапкан җирдән өзмәк була кызый. Әмир аның ныгытып фикер йөртүен тели. Үзенең әле фронтка кабат китәсе бар. Әйдә минем белән фронтка, димәссең бит инде.

— Болаи итик, акыллым. Башта синең әти-әниләреңне күрү дөрес булыр. Мине алар белән таныштырырсың. Шуннан соң, җитәкчеләреңне күндереп, бер-ике көнгә ял ал да, Казанга барып килик. Анда минем әти-әниләр белән күрешерсең. Шунсыз ярамый. Ата-ана хакы... Алар безнең дуслыгыбызны да, ни уйлаганыбызны да белеп торсалар, хәерле булыр.

— Әмир, нигә хәрби киемнән килмәдең син?

Сорау Әмиргә бераз сәер тоелды, киемдәмени эшнең кендеге? Шулай да аңлатуны кирәк тапты.

— Күренеп торган яңу яралары өстенә офицер киеме дә... күзгә артык ташланмасын әле, дидем.

Рәйханә әле генә бүленеп калган сүзгә әйләнеп кайтты:

— Шуннан, ял иткәч нишлибез, Әмир?

— Шуннан... назлым минем, сугышабыз! Син — тылда, мин фронтта...

Рәйханә теләр-теләмәс кенә елмайды, күзләрен кысып Әмиргә карады.

— Дөрес әйттең, сугышабыз! Тик нигә син мине тылда калдырасың?— Аның күзләренә яшь тулды. — Нигә син мине үзең белән алып китәргә теләмисең? Нигә син миңа: «Рәйханә, чык миңа кияүгә!» — димисең? — Ул ачынып елый башлады. — Мин сине шул хәтле көттем, Әмир, шундый сагындым. Әгәр яраткан эшем булмаса, сине уйлый-уйлый акылдан шашкан булыр идем. Тагын синнән ничек аерылыйм? Ничек ялгыз яшим?..

Рәйханәнең өзгәләнүеннән Әмир башта югалып калды. Ул әйткәннәр турында Әмир үзе дә өзлексез хыяллана иде бит. Сугыш бетеп, исән-сау кайта алса, Рәйханәгә өйләнергә дигән карары катгый иде. Чынга ашкан шул хыял аларны бәхетле итәр кебек иде...

Гаделша карт, көрәген тотып, ишегалдында йөри иде. Яшьләрне күргәч, ул аптырап, салкыннан яшьләнгән күзләрен кулындагы бияләе белән сөрткәләп алды. Көлә-көлә капкадан керүче кызын да, аңа ияргән ир-ат затын да сәерсенеп каршылады.

— Раббем, тагын ниләр күрсәтәсең инде?! — дип уфтанып алды. Капкадан керүчеләргә каршы бармады, кулындагы агач көрәкне карга батырып кадады да баскан урынында тора бирде. Рәйханә,йөгереп килеп, әтисенең беләкләреннән тотты.

— Әти, кунак алып кайттым. Таныш булыгыз! Әмир...

Гаделша бер көнне корпуста ашап утырганнарын үз күзләре белән күргән яралы солдатлар арасыннан берәрседер дип, Әмиргә кул бирде һәм кырысрак тавыш белән:

— Исәнме, улым! — диде.

— Исәнмесез, Гаделша абзый! Сәламәтлекләр ничек?

Өйдә Гайнавал гөр килде.

— Әй, канатем, канатем, кеше катясы булгац, алданрак әтеп куялар аны, берсәк хәстәрләнеп торган булыр идем,— дип рәвешенә китерде.

Эченнән генә: «Ишеткән сүзләрем раска чыга, ахрысы, гулять иткән нәрсәседер инде... Битен каймакка буяп маэмайга бирсәң, каймагын ашар, битенә кагылмас. Бигрәк ямьсез инде, канәтем. Тумыштан микән, әллә сугышта шулай булдымы икән»,— дип уйланды һәм Әмирнең буй-сынына сөзеп карады.— Бите алама булса да, сынга яхшы, рысак кебек...»

Өстәлгә карточкага алынган икмәк, мичкә тәгәрәткән бәрәңге, гөжләп торган самавыр килгәч, Әмир акрынлап сүз башлау кирәклеген чамалады.

— Гаделша абзый, Гайнавал апа! Сезгә әйтер сүзем бар, ипләп тыңласагыз икән,— диде һәм, сабыр, салмак, һәр сүзен аңлаешлы итәргә тырышып, сөйләп китте. Сугышка кадәр үк Рәйханә белән танышып дуслашуларын, яуга китәр алдыннан бер-берсенә биргән вәгъдәләре барлыгын да, соңгы елларда хат алышып торуларын да, менә шушы кыяфәттә кайтырга туры килүен дә, Рәйханәнең өркеп калмавын, үзенә тормышка чыгарга риза булуын да сер итмәде. Әгәр өлкәннәр ризалык бирсәләр, иртәгә үк Казанга китәчәкләрен, анда үзенең эти-әниләре белән сөйләшәчәкләрен белдерде. Азактан, тәвәккәлләп, ЗАГС турында да телгә алды. Аннары, сәламәтлеге ныгып киткәч, яңадан фронтка китәсен, ә Рәйханәнең үз эшендә эшләп торачагын да искәртте.

Гайнавал: «Ай, канәтем!» — диде дә, ишек төбендәге сәкегә барып утырды. Гаделша уң учы белән иреннәрен сөртте, эчәргә дип күтәргән чәшкәсен кире өстәлгә куйды.

— Анысы шулай, улым,— диде карт, уйлана-уйлана. — Бер-береңне ярату бар, өйләнү, кияүгә чыгу гадәте дә бар. Шуның өчен кешеләр бит инде без. Шуның өнен тормыш инде бу... Язмыштыр, күрәсең... Шулай да бер дә вакыты туры килми бит әле, өйләнешеп йөрергә дим. Фронтка китәсе була дисең. Ничек килеп чыгар соң ул алай?

— Минем кайда яшәү ахыргача хәл ителмәгән әле, әти. Бәлки, мин дә фронтка китеп барырмын. Райком белән сөйләшәм дә. Әмирдән кай җирем ким минем? — диде.

Гаделша бу юлы кызына шактый усал карады.

— Шундый җиңел сөйләшәсең син, кызым, Бирәзә авылына әбиеңә кунакка барырга җыенган дип белерсең.

Рәйханә балаларча иреннәрен бүлтәйтте, дөрес сөйлим ич дигән мәгънәдә елмаеп, Әмиргә карады. Гаделшаның йөзе агарды, кинәт чырае качты.

— Әти, әти!.. Кара, әти дим... — Рәйханә этисенең кулыннан тотты. Әмир картның иреннәренә чәй тигезде.

— Хәзер, хәзер... узар... — Гаделша, көч-хәл белән кыймылдап, мич кырыена килеп, аркасын сөяде, ләкин мичнең кызуын сизмәде.

Өйдә чебен очканы да ишетелерлек тынлык урнашты.

Әмир Рәйханәгә карады, аның өчен дә борчыла иде. Кызның күзләрен сөйләп аңлатып булмаслык моңсулык баскан.

Әтисенең авыр минутлары үтеп киткәч, һаман аның янында сырпалана биреп сорады Рәйханә:

— Ризалыгыңны бир, әти. Әмирдән башка яшәве читен булыр миңа. Әнием үлгәндә ничек үзәгем өзгәләнгәнен үзем генә беләм. Әмирдән аерылуны кичерә алмам.

Гаделша, мичкә аркасын куеп, күзләрен йомып торды. Нәрсәләрдер турында төпле уй йөртмәк булды. Тик башында фикерләре чуалган иде. Башының дөп-дөп килеп гүләве, чигәләренең авырттырып кысуы, арка сөягенең сызлавы уйларга җай бирми иде. Сүз көтәләр. Ата сүзе...

Төне буе бурый-бурый кар яуды.

Иртәнгә кадәр өй ишеген дә, капканы да көрт басып китәр, дип уйланып ятты Гаделша. Таң атканын да көтмичә, кулына көрәк алып, ишегалдына чыкты. Карны көрәп, юл ача башлады. Газиз балаларым, сезгә юл ачам, сәфәр чыгарга үзем сезгә фатиха бирдем, хәерле юл сезгә, газизләрем... Шул юлдан исән-имин өемә әйләнеп кайтуыгызны көне-төне теләп яшәрмен, балакайларым, дип уйлана-уйлана көрәде Гаделша карт ак карларны...



# Әдип Маликов

## ТУГРЫЛЫК

(СОЛДАТ ДӘФТӘРЕННӘН)

Безне, диңгез, йорт-җирдән
Аердым дисең инде.
Гашыйк булсам да сиңа,
Төштә күрәм Әрине[1].

Төсмерләнә ерактан
Сихотэ-Алинь таулары.
Әнә кораб мачтасы,
Җем-җем итә байрагы.

Җитте кайтыр вакытлар
Төялеп корабларга —
Мәхәббәтем язына,
Газиз туган якларга!

1

Җырлап портка килгәндә,
Бордылар ярты юлдан.
Ишетеп шомлы хәбәр,
Чемодан төште кулдан:

«Сугыш!» Таулар сискәнеп,
Гүя артка чигенде.
...Гитлер бер селтәнүдә
Көл итмәкче илемне.

Сыкрый тайга. Наратлар
Серләшә дәһшәт сизеп.
Сафка бастым яңадан,
Юлдан өметем өзеп.

Халкым изге көрәшкә
Кузгалды ирексездән.
Тормыш күчте окопка,
Ә күзләр — прицелда.

Тураклана Туган җир,
Немец Мәскәү янында.
Дарга менә Зоялар,
Без исән-сау чагында.

Кая безнең горурлык,
Ничек чыдыйк бу хәлгә?!
Илем, ерак Атаудан
Җибәр безне ярдәмгә!

2

Барлый Верховный барсын,
Бөек постыннан торып, —
Өсти хәрби картага:
«Ерак Көнчыгыш фронт».

Бар приказ: «Кузгалмаска!»
Булмый башны ташка орып,—
Бушап калган окопны
Дошман били ашыгып.

Көтә җае чыкканны
Япон «Сугыш чукмары».
Күчә «ут күрше» булып,
Империя туплары,

[1] Әри — Башкортстанда елга исеме.

Кытайны талап йөргән
Самурай оныклары.
Чал Уралга кадәрле
Батырып теш-тырнагын,
Умырмак була, ерткыч,
Онытып тарих сабагын.
Төн буе күгебезгә
Чөя ракеталарын.

Чиктә шау-шу һәм атыш..
Коткы сала, каһәрең.

Ут чәчрәтеп, кылычын
Кайрый Гитлер куштаны.
Бастык таш кыя булып,
Үткәрмәскә дошманны!

3

Солдат, чүгеп байракка,
Ант китерә бер генә.
Яшәү законы булып,
Кала вәгъдә гомергә.

Ориентирың югалтып,
Адашканда тайгада,
Сазлыклар, таулар кичеп,
Арып хәлдән тайганда,

Көч бирә мәхәббәтең,
Изге антың Илеңә.
Атлый сыман сөйгәнең,
Кулын салып иңеңә.

Сәлам хат килсә — бәйрәм,
Арта күңел көрлегең.
Хатлар, соса шикелле,
Тукый хисләр киндерен.

Озак йөрде хатларың,
Унары бергә килде.
Унысына ун җавап
Яза идем мин, тиле.

Зарланмадым язмышка,
Яшердем зәнгеләсен —
Суырса да шул үләт
Яшьлегем хәзинәсен.

Тайга бай витаминга,
Ылыс суы нормасыз.
Сызласа да сөякләр,
«Тавык күзе» булмасын.

Төн монда шундый уяу,—
Чикне бозган «шакал»лар
Без йөргән сукмакларда
Корбан көтеп яталар.

Ут төртәләр тайгага;
Ычкындырмый форсатны,
Шуыша үлемдарлар
Шартлатырга штабны.

Ботинкалар импортный,
Сазда чери табаны.
Үз срогы чыкмыйча,
Бирмиләр бит яңаны.

Өйрәндек, башка төшкәч,
Чабатасын үрергә.
Ярамый ләкин аны
Постка киеп йөрергә.—

Ягъни, Дәүләт постына...
Чамалап алны-артны,
Сакларбыз маркабызны —
Без бит совет солдаты!

Пеләш калды егетләр
Егермедән узганда.
Ансын инде берничек
Яшереп булмый кызлардан.

«Чәч коела учмалап,
Беткәндер «ашлама»сы.
Ташласа да бөдрәләр,
Сөйгәннәр ташламасын».

Хатларыңны кадерләп,
Биштәремдә сакладым.
Калды хәтер түрендә
Студентка чакларың:

Биек туфли алуың,
Икмәк карточкаң биреп;
Һәм үкчәсез калуың
Сәхнәгә чыккач киеп.

Җәен басу юлында
Сыер җигеп йөк ташу.
Асылынып муенына,
Әткәң белән хушлашу...

Бөти итеп тагардай
Өч почмаклы шул хатлар
Үлеп сагынган чакта
Дәва булды солдатка.

4

Дүрт ел йөреп сугышта,
Финишка җиттем дигәч —
Ятып калды берәүләр,
Җиңүнең үзен күргәч.

Канаса да йөрәге,
Сынмады Ил канаты.
Кичеп тәмуг утларын,
Җиңде Совет солдаты!

Без җиңү тантанасын
Окопта бәйрәм иттек.
Ә үзебез һөҗүмгә
Зур җирдән әмер көттек.

Бар ул спирт бездә дә —
Нарком җибәргән паек.
Тотабыз символично,
Күзләребез ап-аек.

Күреп Гитлер язмышын,
Кысты япон койрыгын.
Бүгенме, иртәгәме —
Көтәбез Ил боерыгын.

Язмыш кемгә ни юрар —
Язылмаган маңгайга.
Яшисе килә, дуслар,
Юрыйк әле уңайга.

5

Юаш идем үскәндә,
Берәүгә дә сукмадым.
Йомарлап бар ачуны,
Самурайны тукмадым.

Айкадым дошман тылын,
Узып характерымнан.
Кайта идек «тел» урлап,
Саклап харакиридан.

Пулялар сызгырса да,
Миналар уласа да,
Хәнҗәр тиеп хәнҗәргә,
Чаткылар уйнаса да,

Баш бирмәдем үлемгә!
Сиздем исән каласым, —
Синең кайнар сулышың
Мине тартып аласын.

«Таң белән таң күрешми,—
Без тиеш очрашырга».

Бу якты дөнья белән
Иртәле хушлашырга!

Тимер-бетон дотларын,
Тау асты туннельләрен
Тоттык нәфрәт утына —
Күккә очты көлләре.

Тимгел-тимгел кызыл кан,
Әйтерсең, мүк җиләге.
Азат иттек Атауны,
Барлап һәрбер түмгәген.

Трамплин итеп, янәсе,
Сахалин, Курильләрне,
Алмакчы идең яулап
Безнең изге җирләрне.

Тот менә капчыгыңны!
Ант китердек юккамы?!
Тын океанда сугышка
Куйдык соңгы ноктаны!

* * *

Инде узган иде бит
Бөек Җиңү парады!
Узды тагын бер давыл,
Сирәгәйтеп араны.

Ятып калды дусларым,
Бер-бер хәбәр көткәндәй,—
Ватан намусы булып,
Кояш чыккан чикләрдә.

Сугыш булмый корбансыз,
Ансыз юк җиңү туе.
Без — үлгәннәр алдында
Бурычлы гомер буе!

Еллар яхшы-яманын
Кыл иләктән иләде.
Утта чыныкты чыны,
Җилгә очты кибәге.

Кадере артты дуслыкның!
Золым алды җәзасын.
Кайттым кояш эзеннән,
Бәйләргә Ил ярасын.

Кайттым сине күрәм дип,
Диңгез-таулар аркылы...
Суытмаган араны
Зәһәр җилләр салкыны!

# Геннадий Паушкин

# ҮТКЕЛ

ХИКӘЯ

1



Төнлә мул итеп кар яуды. Үткелдә бер генә карыш та җир кисәге калмады, кая карама — фәкать кыяташлар, еракларга тезелеп киткән ак тау түбәләре. Радистларның кар каплаган палаткасы янында постта торучы сакчы үзен, әйтерсең лә, бөтенләй үлек һәм ялангач ят бер планетада итеп хис итте. Колакка ничектер сәер тоелган бу тынлыкны ник бер тавыш бозсын — тычкан да чыелдамый, агач ботагы да сынып төшми, һич югы палата эчендәге дежур радист кыймылдап куйсын иде ичмасам. Ышанасы да килми: югыйсә, кичә генә бит әле биредә — тарлавыклар арасында, йөзләрчә тапкыр көчәйтелгән кайтаваз булып, атышлар яңгырады. Немецларның «фокке-вульф»лары җепкә асылынган үрмәкүчтәй үткел өстендә торды, сөзәклектә үскән артыш агачлары арасында төтен чайкалды. Бирегә алданрак килгән радистлар кыяны чокып мич кебек нәрсә әмәлләгәннәр һәм тауның асылынып торган стенасына терәтеп палатка корганнар иде.

Бөтен дөньяга айның җансыз нуры сибелгән. Күзләре эчкә баткан башны хәтерләтеп, ул тау сыртына күтәрелгән дә мылтыклы кеше өстенә асылынып калган, теләгәндә аңа мылтык белән дә үрелеп булыр төсле. Әмма сакчы күз карашын шиксез үлек төсле айдан алды да палаткага текәлде. Нindидер киек өнен хәтерләткән бу палаткадан кем дә булса уянып тышка чыгарга тиештер ләбаса инде...

Ниһаять, «өн» эчендә кемдер кыргыйларча кычкырып җибәрде. Сакчы, үзе калдырган иске эзләргә басарга тырышып, иптәшләре янына ашыкты.

— Әй! — дип кычкырды ул, ишек япмасының бер почмагын күтәреп. — Ни булды сезгә?

«Өн»нән беренче булып рация начальнигы өлкән сержант Букреев чыкты. Ул айга карады һәм күзләрен шинель җиңе белән каплады.

— Аһ, шайтан алгыры!

— Шул-шул менә! — дип көлемсерәде сакчы. — Теге дөньяда без хәзер, өлкән сержант.

— Ала-а-й! — диде Букреев сузып кына һәм, палата эченә кереп: — Чыгыгыз, иблис токымнары!.. — дип команда бирде.

Өч радист палаткадан чыктылар һәм, кар каплаган үткелне танымыйча, тирә-якка караш ташладылар.

— Кайсыгыз кычкырды соң сезнең? — дип сорады сакчы.

— Кем кычкырды? — диде ачуланып Букреев һәм сержант Первушинга күрсәтте: — Синме?

— Төш күрдем мин,— диде Первушин. — Албасты гәүдәле, жирән чәчле берәү өстемә ташланды. Ә мин сезне аста килеш ярдәмгә чакырам, имеш...

— Бар сукмакны кар каплаган — сугыш беткән!

— Тауда гына бетсә беткәндер, ә аста, тигезлектә, сугышның очкырые күренми әле, якташ! — диде Букреев.

Сакчы авыр көрсенеп әйтә куйды:

— Аста хәзер кояшта инжир пешә, мандариннар өлгерә...

— Мандариннар! — дип көлемсерәде Букреев, кар каплаган тау түбәләренә карап. Анда күзләрне чагылдырган якты ай нурында боз кристаллары ялтырый иде. — Мандариннар...

Төн буе диярлек кар көрәделәр, палатканы сүттеләр, аны өч яктан плитәләр белән әйләндереп алынган учак янына ук терәп, яңадан колгаларга тарттырдылар. Палатканы яңадан корган арада өчесе берьюлы күргән төш турында да, рация батареясының озакламый бетәчәге турында да, таулар арасында барган, хәзер исә кар өстенә жанвар кебек кереп поскан сугыш турында да сөйләштеләр. Рация янында кемнең кайчан дежур торасын да бүлештеләр.

Сәгать биштән Первушин дежур торырга теләк белдерде. Букреев белән Покровский, йокысыз үткән төннән соң тагын бер-ике сәгать черем итеп алу нияте белән, шинельләрен башларына бөркәнделәр дә, аркага арка куеп, нарат ботаклары өстенә яттылар.

Первушин учак тирәсенә тәгәрәгән күмерләрне бер тирәгә өеп куйды һәм биткә чын мичтән чыккандагыдай кызу килеп бәрелде. Ул ике таш плитә өстендә торган, металл кырларында күмердән төшкән ялкын нурлары уйнаган рациясенә табарак шуышып утырды.

Күмерләр яна-яна соры көл белән каплана бара. Ә таулар тезмәсе кичке эңгер-меңгер вакытындагы авылны хәтерләтә. Санчар үткеленә менгән текә сукмаклар, таш баганалар чыгып торган тар аралыклар искә төшә, солдат кирәк-ярагы төялгән атларның текә ярдан егылып төшүләре күз алдына килә. Төбеннән боз кебек салкын су аккан, ташлар арасыннан йөк хайваннарының үле гәүдәләре каралып торган «торба» һаман да хәтердән китми. Бу коточкыч сынауга хәтта хайваннар да түзми, ә солдатлар түзә. Алар, әлеге җәһәннәм юлының кайчан бетәсен дә белмичә, һаман баралар да баралар. Әгәр тәмуг дигәннәре чынлап та бар икән, алар шуны үттеләр һәм гомергә дә менеп булмас кебек тоелган биеклеккә килеп чыктылар.

Учакта күмерләр сүнеп бара, янда берничә кисәү генә калган. Первушин аларны күмерләр арасына тыкты. Астан килеп чыккан житез ялкын кытыршы коры кайрыларны ялмый башлады.

Нәкъ сәгать биштә Первушин рацияне тоташтырды, бүреген салып, наушникларны киде һәм кабул итүгә күчте. Бер минут чамасы үткәндермеюкмы, сигналлар килә башлады. Үзәктән радиограмма тапшырачакларын әйттеләр. Первушин кабул итәргә әзерләнде һәм штаб рациясе дежурныеннан радиограмманы тизрәк тапшыруын сорады: озакламый аккумуляторлар утырачак. Ә аккумуляторлар утырганда, эфирдагы барлык тавышлар сүнә баргандай була, ахырдан берни дә ишетелми башлый, әйтерсең, эфир дигән «алтынчы океан»да үлем тынлыгы урнаша.

Бәхеткә каршы, радиограмма кыска — код буенча берничә группадан гына тора иде. Первушин аны тулысынча кабул итүен әйтте дә планшеттан код таблицасын алды. Мич янынарак күчеп утырып, әлеге саннарны сүзләргә күчерә башлады.

Букреев, шинелен ачып, башын күтәрде:

— Радиограмма кемгә, безгәме?

— Безгә,— диде Первушин. — Ләкин шифровка түгел, хәзер сүтәбез аны.

— Я, нәрсә анда?
— Хәзер... Менә, тыңла: «Первушинга. 10-00 сәгатьтә партҗыелыш».
— Син бит партия члены түгел.
— Булмасам, булырмын,— диде сержант, кәгазь кисәген рация начальнигына биреп.
Букреев мич янынарак килде, радиограммага күз йөртеп чыкты, аякларын бөкләп, бераз утка карап утырды.
— Шәп уйлап таптың син, ә! Двуречьеда кояшта инжир пешә, мандариннар өлгерә, диген, ә? Капчыгыңны алырга онытма...
Букреевның төрттеребрәк сөйләргә яратуы һәркемгә мәгълүм. Тик әлеге «мандариннар» сержант Первушинның ачуын чыгарды. Һәм ул әчкебер усаллык белән:
— Сиңа ярты капчык алып кайтырмын! — диде.
— Берьюлы батареялар белән аккумуляторлар да алып кайтырсың,— диде Букреев, сержантның сүзләрен колагына да элмичә. Аннары: — «Бөркет»кә әйтергә кирәк,— дип, кыр телефонына үрелде. Әмма зуммер кнопкасына басарга өлгермәде, палаткага старшина Аникин керде.
— Хәл-әхвәлләр ничек, егетләр?
— Менә, палатканы рәтләдек,— дип җавап бирде Букреев.
— Начар түгел сезнең монда! Җылы, якты, чебеннәр дә тешләми.
Букреев Аникин бакчасына таш атарга булды.
— Чебеннәр ни эшләсен монда, старшина. Ашарга юк ич аларга!
— Кичә үгез китерделәр, тиздән ашар нәрсә табылыр,— дип өметләндерде старшина радистларны һәм, борчылуын яшермичә, өстәп куйды: «ЧП», егетләр!
Радистлар сагаеп калды:
— Нәрсә булды?
— Кар өеме ишелеп, кабельны өзгән. Бар өмет сездә.
— Аллага ышан, тик үзең дә авыз ачып торма,— диде Букреев күңелсез генә.
— Күрәм, син инде алла белән эш итә башлагансың икән. — Старшина көлемсерәп куйды һәм җылы учак янынарак елышты. — Ә эш хәтәр!
— Бәла ялгызы гына йөрми, старшина.
— Тагын ни булды?
— Аккумулятор утыра.
Старшина Букреевка борылды.
— Ә нәрсә көтеп яттыгыз соң? Күктән төшергәннәренме?
— Китерергә вәгъдә иткәннәр иде дә, әнә бит, сукмакларны кар басты.
— Рациядән бөтенесен сык, әмма элемтә булсын!
— Ә телефонистлар нишли соң?
— Икесе линиягә чыкты инде,— диде Аникин.
— Алайса өченчесен дә җибәрергә кирәк.
Букреев Первушинга ымлады.
— Артыкмыни ул сезнең?
— Бездә артык кеше була алмый,— диде рация начальнигы һәм өстәп куйды: — Двуречьега чакыралар аны — партҗыелышка. Партиягә алачаклар.

— Алайса, җыен! — диде старшина Первушинга һәм палаткадан чыкты.
Первушин старшинаны сакчы таптап бетергән сукмакта куып җиткәч, Аникин кинәт аннан сорап куйды:

— Ә син кемнең партия члены була алуын беләсеңме?
— Беләм,— дип елмайды Первушин.
— Бу — уставның беренче пункты! Бу пунктны төн уртасында уятып сорасалар да яттан белергә кирәк! Ә калганы — урындагы хәлгә карап. Чатнатып әйтерлек булсын!

— Тырышырмын,— дип җавап бирде Первушин, иртәнге эңгер-меңгердә линиягә чыккан элемтәчеләрне эзләп.

— Әнә алар!

Старшина ике солдат фигурасына күрсәтте. Тегеләре, сапер көрәге белән кар көри-көри, үткел түбәсеннән Двуречьега сузылган кабельга таба баралар иде.

— Шулар янына бар! — Старшина Первушинның иңбашына җиңелчә генә сугып куйды. — Әйт үзләренә: кабельны кулларыннан ычкындырмасыннар. Кар шундый күп, кайда җир, кайда убырыла торган кар өеме икәнен белерлек түгел...

## 2

Әйтерсең лә җегәре бетте — ай тоныкланып калды. Төн әкрен генә артка чигенә, көнчыгышта туачак көн яктылыгы беленә башлады. Әлеге эңгер-меңгерле сихри таңда диңгез тигезлегеннән өч мең метр биеклектә шәмәхә кар эчендә казынучы ике элемтәче Первушинга җир өчен ниндидер ят җан иясе булып тоелды. Ә бу «җан ияләре» түбәндәге җылы, күнелгә якын җир өстендәге кешеләр белән тоташтыручы нәзек җепне эзлиләр. Бу нәзек җеп — армиянең нервы. Әгәр ул җеп булмаса, немецларның тауларда сугышырга махсус өйрәтелгән тау-укчы корпусын диңгезгә чыгармый торучы безнең батальон кыен хәлдә калачак. Берни белмичә, күрми, сукырларча сугышырга ярамый. Бары тик катлаулы хәрби механизмның барлык частьлары арасында тыгыз элемтә урнаштырганда гына уңышка ирешеп булачак.

Кабельның өзелгән урынын табып, аны ялгау, кар каплаган биеклекне җир белән, батальонны полк штабы белән тоташтыру өчен линиягә чыккан һәм тирән карда үзләренә юл ярып баручы әлеге сугышчылар шуны яхшы аңлыйлар. Алар кар астындагы чыбыкны казып алалар һәм, аңа тотынган килеш, беленер-беленмәс яктылыкта тирә-якны күзәтеп алга атлыйлар.

Первушин өченче булып бара. Аның күзәтү офыгы киңрәк, шунлыктан ул элемтәчеләрне, тауның таш стенасына якынрак торыгыз, сукмактан читкә баса күрмәгез, дип кисәтеп тора. Кар авыр козырек булып асылынган, кичәгегә караганда ике тапкыр диярлек зурайган. Чак кына ялгыш атладыңмы, беттең диган сүз. Тирән тарлавыкта йөзүче болытлардан да өстәрәк баралар — упкынга төшеп китсәң, сөягеңне дә җыеп алалмаслар.

Линияне тикшерүче элемтәче кар астыннан чыбыкның бер очын тартып чыгарды, аны күзләренә якын китерде:

— Факт. Төененнән өзелгән!

Иптәше аның янына килде.

— Ә икенче очы кайда соң?

— Шайтаным беләме аны!..

— Нишләп соң сез кабельне бераз бушрак итеп, асылындырыбрак сузмадыгыз, дускайлар? — дип башын какты Первушин. — Шулай ярыймы соң инде? Ул, мөгаен, кыл кебек тартылган булгандыр, шуңа өзелгәндер.

— Асылындырыбрак? — Алдагы солдат көлемсерәп куйды. — Двуречьега кадәр ничек җиткердегез диген син! Маңгчтан соң нәрсә булганын беләсеңме? Ике катушка ат белән бергә упкынга тәгәрәде. Күтәреп килә алганын суздык инде. Анысы да гел төен генә иде аның.

— Әнә икенче очы! — диде катушка аскан элемтәче. — Хәзер ялгыйбыз.

— Стенага элеп куярга кирәк,— дип киңәш итте Первушин. Ул линия элемтәсен ничек сузарга икәнлеген уку-өйрәнү батальонында хәтерендә калдырган иде.

— Синнән башка да беләбез!

Бераз хәтере калган элемтәче кабель очына өзек ялгады да аны чыгып торган ташка элә башлады.

Сукмактан упкынга асылынып торган икенче очны ничек кирәк алай эләктереп алып, икесен бергә ялгагач, солдатларның берсе кыр телефонын тоташтырды. Ул трубкага өрде, зуммер кнопкасына басты:

— Алло!.. «Елга»мы? Ишетәсеңме мине?.. Яхшы... Кар ишелеп, кабельне өзгән иде. Хәзер барысы да тәртиптә!..

3

Тезелешеп киткән тау түбәләре иртәнге нурга күмелде. Озакламый кояш үзе дә күренде, тын гына торган ак кыялар өстенә күтәрелде һәм, якты прожектор булып, икенче класслы радист Первушин атлаган сукмакны яктыртты.

Сакчының кичә әйткән мәгънәсез сүзләре һаман баштан чыкмый. Ул аларны күңелгә сеңгән көй кебек кабатлый башлады: «Кояшта инжир пешә, мандариннар өлгерә...»

Чынлап та нык кына җылытты. Первушин, әйтерсең, берничә минут эчендә барлык климат зоналарын: кышны, Россиянең урта полосасында «әбиләр чуагы» дип йөртелә торган җылы көзне үтте, ә анда, аста инде инжир пешә...

— Кадалып китсен лә шул инжир дигәннәре!.. — дип кычкырып ук куйды Первушин. — Аның өчен бармыйм лабаса мин Двуречьега!

Кинәт ул кайдадыр Санчар үткеле ягында һава шары тишелгән кебегрәк бер-бер артлы шартлаган тавышларны ишетте һәм, гадәттә мондый шартлаулардан соң ишетелә торган таныш тавышны тыңлап, туктап калды.

Миналарның, кыл кебек тартылган һаваны ярып, болайга таба очуы ишетелә иде. Первушин шундук ятты. Секунд да үтмәгәндер, көчле гөрселдәү тавышы ишетелде. Первушинның йөрәге ярсып типте, колак яфраклары авырттырып зеңгелдәде. Санчар үткеленнән бәреп чыгарылмый калган немец егерьлары өчен үзенең мишень булуы күңелен рәнҗетте. Алар аны теге вакытта Маныч янындагы кебек үк эзәрлекләячәкләр хәзер. Ул чакта Первушин, елганы йөзеп чыгып, утлы боҗрадан котылган һәм сазлык-тугайлык буйлап йөгерә башлаган иде. Баш очында снаряд тавышын ишеткәч тә ятты. Тирә-якта ярчыклар сызгырып оча башлагач, «коты ботына» төште. Немецлар азартка бирелделәр, сугыш припасларын җәлләмичә, аны эзәрлекли башладылар. Прицель шактый төгәл иде: миналар берничә адым ераклыкта гына әле сулда, әле уңда ярылдылар, аны баштанаяк юеш балчыкка күмделәр. Әмма ул әле һаман да исән һәм көче барда елга борылышына йөгереп барып җитү уе белән яна иде. Соңгы тапкыр егылгач, ул озак кына кузгалмый ятты. «Бетердек» дип уйладылар булса кирәк, Донның биек ярында күзәтеп торучы «аучылар», ниһаять, тынычландылар.

Хәзер немецлар сукмак бик ачык күренеп торган Санчар үткеленнән күзәтәләр. Димәк, ничек кенә булса да таш бүлтәеп чыгып торган борылышка барып житәргә кирәк. Ә анда сукмак кырт сулга борыла һәм туп-туры түбәнгә — Двуречьега төшә.

Ул, үз-үзен тынычландырып һәм фикер туплап, таш өеме өстендә шактый ятты. Әмма болай озак ятарга ярамый: сәгать унга Двуречьега барып җитәргә кирәк. Ә вакыт күпме соң? Ул сәгатенә карады һәм шунда гына сәгатенең угы да, пыяласы да юклыгын күрде. Аны колагына китерде. Карышуны белми торган «Киров» сәгате йөри иде. Первушинның йөрәгенә җылы йөгерде: сәгать йөри, димәк, аңа да алга таба хәрәкәтләнергә кирәк! Ташлы сукмакта комачауламасыннар өчен карабины белән ременьле сумкасын аркасына ташлап, шуыша башлады. Санчар үткелендә әлегә аның хәйләсенә төшенмәделәр: шуышып баручы кешене ерактан күрү читен иде. Бу аны канатландырып җибәрде.

Дошман окулярыннан яшеренергә мөмкин булган борылышка ике йөз метрлап калгач, аның кулына кабель эләкте. Первушин аны тартып караган иде, каршылык сизмәде. Димәк, мина кыйпылчыгы тиеп, элемтә тагын өзелгән. Ул кабельнең сукмак янындагы иләмсез таштан асылынып торган икенче очын күрде. Егетләр кайтып җитәрләр, ә элемтә юк! Кире борылсалар, күпме вакыт әрәм үтәчәк! Ә ул биредә!

Первушин тар сукмакта еландай кире борылды, чыбыкның очын тешләре белән кысты һәм, немецларның менә-менә сизеп алуларын истә тотып, шуыша башлады.

Чыбыкларның очларын пәке белән чистартып бер-берсенә ялгаганчы һәм аны карабин ярдәмендә яңадан ташка элеп куйганчы ун минутлап узгандыр. Дошман күзеннән качып котылырлык борылышка кадәр күп калмаган иде. Һәм ул, бөтен көчен җыеп, аягүрә басты да йөгерә башлады: тегеләр прицельны көйләгәнче, ул борылышка барып җитәчәк!

Первушин аякларының җиргә тиюен дә тоймыйча йөгерде. Теге борылышка чаклы аз гына ара калган иде... Әмма тавышсыз ишелгән кар аның юлын бүлде.

## 4

— Кайда мин? — дип сорады Первушин, башын күтәреп. Аның янында полк санинструкторы Поспелов басып тора иде.

— Минем палаткада, якташ! Танымыйсыңмы әллә?

— Ничек инде ул синдә? — Первушин санитар раскладушкасыннан күтәрелә төште. — Ә җыелыш?

— Исенә төшкән! — диде Поспелов, кулларын җәеп. — Әйдә, бераз тамак ялгап ал. Бодай боткасы алып килдем үзеңә. Бүгенберәр нәрсә ашадыңмы соң син?

— Юк әле,— диде Первушин, һаман да биредә ничек килеп эләгүен аңларга тырышып.

— Әйдә, суынганчы аша. — Поспелов аның алдына ботка салынган котелок куйды. — Кан күп югалткансың. Ә ярасы искитәрлек түгел: чигәңне генә тырнап узган. Озакка бармас, төзәлер.

— Тәки каптырдылар бит, сволочьлар! — диде Первушин, ботканы ашап бетереп. — Борылышка барып җитәлмадым.

— Майор Мартынов удар группаны дошманның тылына алып китте. Бәреп чыгарачаклар алар егерьларны Санчар үткеленнән.

— Рәхмәт, якташ! — Первушин буш котелокны Поспеловка бирде. — Ә аккумуляторлар белән нишләргә соң? Рация менә-менә туктаячак бит.

— Аккумуляторларны синнән башка да илтерләр. Ишәккә төярләр дә берәрсен җибәрерләр, кичкә барып җитәрләр. Ә элемтә бар.

— Бармы? — Первушин урыныннан күтәрелде.

— Иртәдән бирле эшли инде.

— Аллага шөкер! — Первушин мендәргә ятты. — Димәк, мине генә каптырганнар, ә элемтәгә зарар китерә алмаганнар.

Первушин ике елганың шаулаганын ишетеп ятты. Аларның берсе диңгезгә, икенчесе, киресенчә, тау шарлавыгына таба ага. Шуңа «Двуречье»дыр инде, дип уйлады ул. Бирелә кояшта инҗир пешә, мандариннар өлгерә. Ә аның әле аларны күргәне дә юк. Шайтаныма олаксыннар ла ул мандарин дигәннәре. Шунысы кызганыч: Двуречьега җыелышка өлгерә алмады...

— Кара әле,— дип санинструкторга борылды Первушин,— син беләсеңме, кем партия члены була ала?

— Беләм.

— Әйт алайса, кем?

— Син! — диде полк санинструкторы Поспелов һәм, котелогын тотып, палаткадан чыгып китте.

Русчадан **Миргалим ХАРИСОВ** тәрҗемәсе.

## Әхмәт Рәшитов

### Тантана

Гыйбрәтләр күп күргән дөньяның
Яңарыш кичергән чорлары,
Ирекле, имин ил күгендә
Яңгырый тантана җырлары.

Һәр җирдә — авазы Җиңүнең,
Һәр җирдә — салютлар балкышы;
Ишетә, ишетә туган ил
Рәхмәтле дөньяның алкышын.

Без җиңү сабагын өйрәндек
Иң бөек байракчы Лениннан,
Ничәмә-ничә ил адымын
Тигезли без үткән юл белән.

Ал байрак күтәргән илләргә
Ничекләр кизәнмә, янама,
Киләчәк барыбер киләчәк,
Киләчәк барыбер яңага.

Тарихка без язган битләргә
Таң калып уйланыр һәр гасыр.
Туасы таңнарга караган
Тынычлык гаранты — СССР.

## Кави Латыйпов

Куллары белән сыйпый карт үләннәрне,
искә ала исәннәрне, үлгәннәрне.
Бергә йөргән коралдашларын,
сугыш юлындагы кан кордашларын,
җан кордашларын...
Укчы батальон белән
Карпат таулары аша узган юлдашларын...

Кыңгырау чәчәкләр — үлгәннәрнең кабер ташларында.
Хәбәр бирә алар исәннәргә:
сыйпагыз дип үләннәрне,
онытмагыз дип үлгәннәрне...
Карпат тавындагы кыңгырау чәчәкләрне карт ишетә,
алар аңа коралдашлары турында хәбәр биреп тора.
Чәчәкләр белән үләннәр,
исәннәр белән үлгәннәр арасында хәбәр йөреп тора.

Карт солдаттан сора...

# Алексей Яковлев,

отставкадагы гвардия генерал-лейтенанты

# ГЕНЕРАЛ ЯЗМАЛАРЫ



Алексей Ефимович Яковлевның исеме Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты ветераннарына яхшы таныш. Күренекле штаб работнигы, хәрби фән белгече буларак, ул Бөек Ватан сугышы тәгәлләнү белән үк, СССР Кораллы Көчләренең Генераль штабы заданиесе буенча, сугышның зур тәҗрибәсен өйрәнә башлый. А. Е. Яковлев Совет Армиясендә 60 еллап хезмәт итте, аны курсантлар отделениесе командирыннан армия командующие дәрәҗәсенә кадәр үскән хәрби начальник буларак та беләләр.

Отставкадагы гвардия генерал-лейтенанты А. Е. Яковлев — безнең якташыбыз, ул 1901 елны Балык Бистәсе районының Тук-Пулат (Иванаево) авылында туган. 1921—1924 елларда Казандагы керәшен укытучылар семинариясен тәмамлаганнан соң ул Татар-башкорт хәрби мәктәбендә укый. Соңрак шунда курсантлар ротасы командары, мәктәп начальнигының физик тәрбия буенча урынбасары була.

Бөек Ватан сугышында А. Е. Яковлев беренче көненнән башлап катнаша, ә аның сугышчан юлы 1945 елның 12 маенда Прагада тәмамлана.

Отставкага чыгар алдыннан генерал-лейтенант Яковлев озак еллар буе СССР Хәрби Көчләре Генераль штабының К. Е. Ворошилов исемендәге Академиясендә тактика кафедрасына җитәкчелек итте. Ул СССРның кырыклап ордены һәм медале, чит илләрнең хөкүмәт бүләкләре белән бүләкләнде.

Күптән түгел А. Е. Яковлев истәлекләр китабы язды. Түбәндә аның «Утлар аша» исемле шул әсәреннән өзек урнаштырыла.

* * *

Фролово, Иловлинская һәм Качалинская станцияләрендә дивизияне эшелоннардан бушату немец-фашист гаскәрләренең, Донны кичеп, Идел буена килеп чыккан вакытына туры килде. Һәм дивизия, әзерләнеп тә тора алмыйча, 1942 елның 29 августында һөҗүмгә күчте.

Дошман Идел ярында!.. Шушы көтелмәгән хәлнең совет сугышчыларында нинди тойгылар уятуын аңлау кыен түгел.

Шул якта туып-үскән кеше буларак, миңа Идел бигрәк тә якын. Урта агымында аеруча ошый ул миңа. Гүя җирнең бөтен матурлыгы Идел-Каманы үз кочагына алган җирләргә тупланган, Россиянең иң олы урамы дип йөртелгән Иделнең бөеклеген шушында бигрәк нык тоясың. Урманнар, болыннар, далалар аның мәһабәт агышына сокланып карый. Төрле телләрдә сөйләшүче халыклар бердәм, тату гаилә булып яши бу якларда. Һәм менә дошман шушында килеп җиткән, һәркайсыбыз өчен изге, кадерле булган елгага кул суза.

Кичекмәстән хәрәкәт итәргә кирәк иде. Дошман Дон кичүләреннән Иделгә таба танклар ярган коридорга яңа көчләр кертә, Сталинградка төньяктан һәм төньяк-көнбатыштан удар ясарга әзерләнә.

Дивизия алдына, 4 нче танк армиясе частьлары белән бергә хәрәкәт итеп, коридорны ябарга, дошманның эчкә үтеп кергән гаскәрләрен тар-мар итәргә, һич югы аның көчләрен тоткарларга, Сталинградны килгән шәпкә алу планын өзәргә дигән боерык куелды.

24 август иртәсендә дивизия Грачи совхозы, Котлубань станциясе һәм авылы юнәлешендә һәм аннары Малая Россошкага таба киң фронтта һөҗүмгә күчте. Ул дошманның өченче моторлаштырылган һәм 305 нче пехота дивизияләренең авангарды белән авыр сугышка керде, аларны Котлубань станциясеннән 8—10 километр көньяккарак алып ташлады.

Атна дәвамында 27 нче гвардия укчы дивизиясе белән бергә без дошманның пехотасын һәм танкларын кире кагып тордык, алар Идел буйлап төньяк-көнчыгышка таба плацдармны Дубовкага һәм Камышинга кадәр киңәйтергә омтылалар иде. Үз хәрәкәтләре белән безнең дивизия һәм күршеләр дошманның шактый зур көчләрен төп юнәлеш булган Сталинградтан читкә тарттылар һәм 25 километр киңлектәге фронтта тоткарлап тордылар.

25—27 августта подполковник И. Е. Косогоровның 686 нчы укчы полкы Россошка районында аеруча киеренке сугышлар алып барды. Омтылышлы удар ясап, ул дошманның коммуникацияләрен кисте һәм Сталинградка удар ясау өчен гаскәр туплавын вакытлыча туктата алды. Немецлар 50—60 танк, 30—40 самолет, пехота җибәрделәр, әмма барлык атакалар да кире кайтарылды.

Сентябрьнең беренче көннәрендә дивизия Котлубань авылыннан көньяктарак һәм көнбатыштарак урнашкан калкулыкларда оборонага күчте. Хәзер бу авыл юк инде, күпчелек өйләре янып бетте, калганнары блиндажлар ясау өчен сүтелде.

Шушы рубеждан дивизия, инде генерал И. В. Галанинның 24 нче армиясе составында, 22 ноябрьдә һөҗүмгә күчте, дошманның Сталинград янындагы группировкасын тар-мар итүдә катнашты. Аннары ул генерал И. М. Чистяковның 21 нче армиясе составына керде.

1943 елның 11 январенда дивизия өчен сугыш хәрәкәтләренең яңа мөһим этабы башланды. Камалыштагы дошманны турыдан-туры тар-мар итүгә керештек. 14 январь көнне дивизия Карповка авылыннан төньяктарак Россошка елгасына чыкты. Уңышлы һөҗүмне дәвам итеп, 16 январьга каршы төндә рейд ясадык һәм иртәнгә «Питомник» районына барып җиттек.

23 январьда дивизия частьлары Гумрак станциясеннән көньяктарак тимер юл линиясен кулга төшерделәр, 24 январь таңында 147,8 калкулыгын алдылар (дивизиядә аны гвардия калкулыгы дип йөрткәләр иде), 25 январьда «Больница» районы артта калды. Шуннан соң Сталинградның төньяк-көнбатыш чигендә үк сугышлар башланып китте, бер-бер артлы Степная, Стальная, Сосницкая, Двина урамнарын алдык. Дошманның Сталинградтагы группировкасын тар-мар иткәнче шулай алга бардык.

Монда бер дивизиянең Сталинград сугышында катнашуының кыскача хронологик фактлары гына китерелде. Әмма бу сугыш шуның өчен дә тарихи, легендар дип атала, чөнки аның тиңдәшләре юк. Бу сугышның нәтиҗәсе Бөек Ватан сугышында тамырдан борылыш булды. Тарихка бөек булып кергән бу борылыш Сталинград сугышы башланып киткәнче үк сизелә иде инде. Совет Армиясе сугышчылары һәм командирлары сугышка бик югары мораль-политик күтәренкелек тоеп керделәр. Мәскәү янындагы кебек үк дошманның Идел ярында да туктальп кына калмаячагына, җимергеч ударлар астында кире чигенәчәгенә, ахыр чиктә үз өнендә тәмам юк ителәчәгенә тирән ышандылар.

Илебезнең Кораллы Көчләрен ныгыту өчен Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте күргән чаралар шулай дип ышанырга мөмкинлек бирә иде. Фронт югары сыйфатлы коралны күбрәк ала башлады. Яңа частьлар һәм дивизияләр генә түгел, оператив берләшмәләр дә оештырыла башлады. Яңа оештырылган 9 нчы резерв армиясе дә шундый берләшмәләрнең берсе иде, 27 августтан ул 24 нче армия дип аталды.

Бу чорда партия-политик эш сизелерлек көчәйде, сугышчылар һәм командирларның кәефе беркайчан да булмаганча күтәренке иде. Сталинград сугышы алдыннан ук инде «Безнең урамга да бәйрәм килер!» дигән канатлы сүзләр еш ишетелә башлады.

Сугышчылар арасында патриотик башлангычлар һаман киңрәк җәелде. Котлубань янындагы көзге сугышлар барышында 298 нче дивизиядә башланып киткән снайперлык хәрәкәте күмәк төс алды. Аны башлап җибәрүчеләрнең берсе, тәҗрибәле аучы һәм үткен карашлы мәргән Бари Аббасов снайперларның девизын кабатларга ярата иде: «Бер фашист кимегән саен, җиңү якыная бара!» Берәр генә булса

да гитлерчыны дөмектерми калган көне булмагандыр да аның. 19 ноябрьдә, Сталинград фронтында генераль һөҗүм башланган көндә, аның исәбендә инде 130 фашист иде. 131 нчесен ул бер атака барышында кул сугышында штык белән чәнчеп үтерде, ләкин пуля тиеп үзе дә җиргә ауды. Аның коралдашлары снайперлар Николай Ниберго, Дмитрий Тимофеев, Яшнай Ептешов, Иван Бобрик һәм башкалар, һәркайсы 30 дан 100 гә кадәр гитлерчының башына җитеп, Бари өчен каты үч алдылар.

Сталинградны саклаучы совет сугышчыларының һәм командирларының патриотизмы, югары мораль-политик күтәренкелеге бигрәк тә урам сугышларында, һәр йорт крепостька әверелгән көннәрдә нык сизелде. Бәрелешләр тукталып торганда, партия һәм комсомол җыелышлары үткәрелде, иң якында торган бурычлар турында ихлас күңелдән сөйләшүләр барды. Сугышчылар да, командирлар да һәркайсы обстановканы, дошманның көчләрен һәм мөмкинлекләрен яхшы белә, җиңүнең безнең якта булачагына тулысынча ышанып эш итә иде.

Әйе, 1942 ел ахырындагы совет сугышчысы сугыш башындагыдан нык аерыла иде. Җиңүне җиңелгә санау да, каушап, югалып калулар да беткән иде. Кыскасы, безнең кешеләр дошманны сугышның бөтен кагыйдәләре буенча кыйнарга өйрәнделәр. Дөресен әйткәндә, сугышның беренче айларында полк белән командалык иткәндәгегә караганда миңа Сталинград сугышыннан соң дивизия белән командалык итү шактый җиңелрәк иде. Бу — тупланган тәҗрибә нәтиҗәсе. Сугыш хәрәкәтләре хәзер планлаштырып, тиешле средстволар туплап алып барыла, гаскәрләр күршеләре белән тыгыз бәйләнештә, бергәләп эш итәләр иде.

Шулай да һичбер вакыт армиягә корып куелган механизм итеп карап булмый. Каты бәрелешләрдә машина детальләре яки узеллары түгел, кешеләр сафтан чыга, бөтенесе өчен кеше каны, кеше гомере белән түләнә. Уңышка ирешсән дә, ирешмәсән дә — хакы бер, аны башка берни белән дә алмаштырып булмый. Шунлыктан гаскәрләр арасында масса-политик эш алып барганда кеше тормышы алга куела иде: сугышчы кирәк булганда җанын да кызганып тормасын, ләкин аны аңлы рәвештә, дошманга күбрәк зыян китерерлек итеп бирсен.

Сугышта үз-үзеңне аямаудан һәм хәтта үз-үзеңне корбан итүдән дә башка мөмкин түгел. Әмма бу сыйфатлар кешедә үзеннән-үзе барлыкка килми. Алар акрынлап, буыннар үрнәгендә, яңа тормыш өчен көрәш процессында, әзлекле тәрбия нәтиҗәсендә формалаша, 1918—1919 елларда героик Царицын оборонасында катнашкан гражданнар сугышы ветераннарының мөрәҗәгате Сталинградны яклаучыларга ничек нык тәэсир итүе хәтердә калган. Ветераннар болай дип язган иде:

«Сталинградны саклаучылар! Сөекле шәһәребезне дошманга бирмәгез, аны ничек кенә булса да саклагыз,даныгыз гасырлар буена барырлык итеп сугышыгыз!»

Һәм дан Сталинградны саклаучылардан, шул исәптән безнең 24 нче армия сугышчыларыннан да ерак йөрмәде.

56,8 биеклеге өчен барган сугышта батальон командиры яралана. Санинструктор Гуля Королева аның кулын бәйләп бетергәндә дошман контратакага күчә. Гуля бер рота сугышчыларының биеклектән чигенә башлавын күрә. Батыр кыз сугышчыларның каршысына таба йөгерә һәм аларны туктата.

— Кая сез, геройлар!— дип оялта ул чигенеп баручыларны.— Безнең юл — алга, биеклеккә таба!

Ул ротаны кирегә бора һәм: «Минем арттан!» дип кычкырып, атакага алып бара. Кызның чакыруы белән рухланган сугышчылар дошманны калкулыктан куып төшерделәр. Әмма ул үзе дошман пулясы тиеп егыла. Аны үлгәннән соң Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләделәр.

84 нче укчы полктан лейтенант Г. Г. Егоров җитәкчелегендәге разведчиклар төркеме шәһәр тирәсендәге совхозда ныгып урнашкан дошманның тылына үтеп керә һәм көтмәгәндә ут ача. Разведчикларның бу һөҗүме фронтның шушы участогында бөтен дивизиянең уңышы өчен хәлиткеч роль уйнады.

Сталинград сугышы барышында совет сугышчыларының массовый героизмы чагылыш тапты. Сугышчылар һәм командирларның аерым төркемнәре генә түгел, тулы роталар, батальоннар, полклар һәм хәтта дивизияләр, корпуслар да күмәк батырлык күрсәтте. Генераллары белән дошманның бөтен-бөтен полкларын, дивизияләрен, армияләрен әсир итеп алу Сталинград сугышы тарихына иң якты сәхифәләр булып керде.

Монда шунысын әйтеп үтү күңелле, Сталинград янында Гитлерның беренче генералын минем якташым, соңрак әйбәт фронтташ дустыма әйләнгән полковник

Сафиуллин дивизиясе сугышчылары әсир итеп алдылар. Ул бу хакта болай дип сөйли:

«Төнге икенче яртыда гитлерчыларның 297 нче пехота гренадерлары дивизиясенең исән калган солдатлары һәм офицерлары, дивизия командиры һәм штабы белән берлектә, колоннага тезелеп, ак флаг күтәреп, безнең 38 нче дивизия штабына килделәр. Аларны капитан Волощук һәм 5 автоматчы алып килде.

Ак флаг күтәреп безнең якка чыгып баручы колоннаны күргәч, немецларның башка частьларыннан да унар-унбишәр кеше аерылып, аларга кушыла килгәннәр.

Фон Дреббер Сталинград янында югары начальниклар рөхсәтеннән башка безнең якка үз ирке белән дивизиясен алып чыккан беренче немец генералы булды.

Мориц фон Дреббер белән сөйләшкәндә мин аңардан:

— Полкларыгыз, солдатларыгыз кайда, генерал әфәнде?— дип сорадым.

Фон Дреббер көлемсерәп:

— Бу хакта сезгә сөйләп торасы юк инде! Полклар кайда дисезме? Исән калганнары барысы да сезнең карамакка килделәр, полковник әфәнде! Мин үземнең солдатларыма корал ташларга приказ бирдем, әмма алар коралларын минем приказымнан шактый элек ташладылар.

Чыннан да, аның полк һәм батальон командирлары минем блиндажым янында торалар, ә аларның солдатлары, колонна-колонна тезелеп, әсирләрне җыю өчен билгеләнгән пунктка агылалар иде инде.

Сүз уңаенда әйтеп үтәсем килә: совет гаскәрләренең Ленинград блокадасын өзүләре, төньяк Кавказда һәм Воронеж районында уңышлы һөҗүм итүләре турында ишеткәч, генерал фон Дреббер бик гаҗәпкә калды. Гитлер командованиесе хәтта үз генералларыннан да дөреслекне яшереп килгән икән. Башта бик кыенсынып торган генерал озакламый иялэшеп китте, күп сөйли башлады һәм хәтта кәефе күтәрелгәндәй булды.

— Сезгә ничә яшь?— дип сорады ул миннән.

— Утыз биш.

— Шундый яшь кеше, инде ак чәчле генералны җиңеп, әсир итә алды!

Фон Дреббер сөйләшкәндә борчылып:

— Мин бу шәһәр янында әсир төшкән беренче генерал икән!— диде.

— Беренчесе, ләкин соңгысы түгел,— дидем мин, елмаеп.

— Әйе, соңгысы түгелдер,— диде генерал.— Дөресен генә әйткәндә, шәһәр янында бөҗрага килеп капкач, күп генераллар, шул исәптән Паулюс та, каршы торуның файдасыз, алай гына да түгел, җинаять икәнлеген аңлаганнар иде инде. Ләкин фюрер үз генералларының фикере белән санашмый...

Безнең сүзне телефон бүлде. Полковник Морозовның 422 нче дивизиясе штабыннан информация тәртибендә бригадный генерал Дмитриу кул астындагы 20 нче румын дивизиясенең тулысынча корал ташлавын хәбәр иттеләр.

— Менә күрәсезме, генерал әфәнде,— дидем мин,— сез хәзер икәү булдыгыз!..»

Бу — Сафиуллинның сугышчан тормышындагы күп санлы эпизодларның берсе. Ана, озак та үтмәстән, Днепрны кичкән өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелде, ул кызылармеецтан генерал-лейтенантка кадәр данлы юл үтте. Истәлек-китапларында ул узган сугыш турында күп нәрсәләр язды. Батыр, гайрәтле шәхес иде. Сталинград сугышының барышын тасвирлаганда аны Советлар Союзы Маршалы Г. К. Жуков та җылы сүзләр белән искә ала. Курск сугышы вакытында һәм соңрак, Венгриядә ул 25 нче укчы корпус белән командалык итте, 1945 елның мартыннан башлап 53 нче армия составындагы бер корпус командиры булды. Мин үзем шул армиядә башта штаб начальнигы, ә аннары командующий идем. Сугышны без аның белән бергә Маньчжуриядә тәмамладык.

Хәзер Гани Сафиуллин турында «иде» дип, үткән заманда гына сөйләргә туры килә, чөнки бу данлы генерал инде вафат булды. Казанның яңа торак массивындагы бер урам аның исемен йөртә. Совет сугышчыларының массовый героизмы турында сүз башланган икән, фронтташ дустым тормышыннан тагын бер сугышчан эпизодны искә алмыйча кала алмыйм. Шунысы өчен ул Герой дигән олы исемгә лаек булды.

Чигенеп барган гитлерчыларның үкчәләренә баса-баса, безнең частьлар Днепрга килеп җиттеләр һәм елганы килә-килешкә кичеп чыгарга әзерләнделәр. Сузарга ярамый, чөнки дошманның уңъяк ярда ныгып урнашуы. якын килмәслек итүе бар. Фронт һәм армия командованиеләренең приказлары гвардиячеләрне ашыктыра, бу районда Днепр аша юл салу кебек мактаулы бурыч куя иде.

Инде генерал-майор, корпус командиры булган Сафиуллин, урын белән яхшылап танышкач, дивизия һәм полк командирлары белән бергә кичү урыннарын

билгеләде. Су аша чыгарга кечү әйберләре җитешмәгәнлектән, суда батмаслык, азмы-күпме күтәрерлек булган һәр нәрсәне кулланырга приказ бирде.

— Немецлар мактаналар икән,— диде Сафиуллин генералларга.— Янәсе, алар Иделдә безнекеләрдән үк ярда нык торырга, бирешмәскә өйрәнгәннәр һәм хәзер Днепрда руслар үзләренә үпкәләсен! диләр. Әйдәгез, алайса, илбасарларга яңа сабак бирик: бу юлы елганы кичеп чыгарга өйрәтик үзләрен.

1943 елның 24 сентябренә каршы төндә алар елганы кичә башладылар. Салларда һәм аз санлы понтоннарда автоматчылар белән бергә полк һәм дивизия артиллериясе да аргы якка чыгарылды. Ачык позицияләргә куелган туплар, пехота белән янәшә торып, дошманга турыдан төзәп ата башладылар.

«Дошман резервлар китерә...», «көчле контратакаларны кире кагабаз...»— команда пунктына шундый донесениеләр килеп торды. Плацдармда сугышкан частьлар ярдәм көтәләр иде.

Немец командованиесе Сафиуллин корпусына каршы «Бөек Германия» дигән СС дивизиясен һәм 123 нче танк дивизиясен куйды. Өстән бомбага тоткан хәлдә, алар плацдармны саклаучылар өстенә тәүлегенә җиде-сигез тапкыр ташланып карадылар, әмма дистәләрчә ватылган һәм яндырылган машиналарын калдырып, кире чигенәләр иде.

Гвардиячеләр плацдармны кулда тотып кына калмадылар. Су аша чыгып өлгергән танклар һәм штурм авиациясе ярдәмендә алар һөҗүмгә күчтеләр һәм дошманның ике дивизиясен дә тар-мар иттеләр. Сафиуллин корпусы ачкан юлдан башка берләшмәләр дә көнбатыш ярга чыкты.

Днепрны кичкән частьларны кире елгага ташлап булмаслыгына ышангач, немецлар Верхнеднепровск шәһәрендә ныгып калырга теләделәр. Разведчиклар корпус штабына шәһәр тирәсендә көчле оборона ныгытмалары төзелү турында хәбәр итеп тордылар: гитлерчылар Днепродзержинскига юлны шушында ябарга уйлаганнар иде.

Әмма гвардиячеләрнең һөҗүм темплары фашистларның ниятен тормышка ашырырга вакыт калдырмады. Дошманның ныгытмалары әле әзер булмаган урыннарга бәреп кереп, совет гаскәрләре дошманны ашык-пошык кына казылган окопларда оборона тотарга мәҗбүр иттеләр. Пехота сугыша-сугыша елга ярына җитте. Саперлар тиз арада күпер салдылар. Шуның аша чыгып, артиллерия батареялары шәһәргә якын ук килделәр. Артиллерия утына ышыкланып, пехота атакага ташланды һәм шәһәр ныгытмаларының тылына барып чыкты. Куәтле ташкын булып безнең частьлар шәһәргә керделәр, анда бик күп трофейлар кулга төшерделәр. Днепродзержинскига юл ачылды...

Шушы көннәрдә үк безнең 80 нче гвардия укчы дивизиясе частьлары да аргы як Украинаны азат итәргә бардылар. Әмма Днепрны кичкәнче әле башка сынаулар үтәргә туры килде, гаскәрләрне чыныктыру һәм инициативаны кулдан ычкындырмау өчен аларның әһәмияте бик зур иде.

Совет гаскәрләренең 1942 елның 19 ноябрендә Идел һәм Дон далаларында башланган гигант һөҗүме уңышлы дәвам итте. Сталинград янындагы җиңүгә зур өлеш керткән өчен безнең 24 нче армия гвардия исемен алды һәм 4 нче гвардия армиясе дип атала башлады. Командующиебыз генерал-майор И. В. Галанинга I дәрәҗә Кутузов орденының иң беренчесе бирелде, ул генерал-лейтенант званиесе алды. Армиянең дүрт дивизиясенә гвардия исеме бирелде.

...Сугыштан соң төрле елларда миңа үзебез азат итешкән Европа илләренә барырга, хәрабәләрдән кабат күтәрелгән күп кенә шәһәр-авылларыбызда булырга туры килде. Кайда гына булсам да, совет сугышчысына зур рәхмәт һәм хөрмәт хисе белән караганнарын тоям. Юк, каһарманнарның гомерләре тикмәгә бирелмәде. Һәлак булган солдатларны онытмыйлар. Алар истәлеге дан һәйкәлләрендә, кешеләр йөрәгендә саклана. Бу күркәм гадәт буыннардан-буыннарга барыр.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты инициативасы буенча Волгоградта булган бер очрашу искә төшә. Бу «Бөек Ватан сугышы елъязмасы» дигән эзләнү экспедициясе алдынгыларының Сталинград сугышында катнашучылар белән очрашуы иде. Балалар, аталар, уллар һәм оныклар очрашты. Тантаналар, речьләр, истәлекләр аз булмады. Әмма бу очрашуда иң әһәмиятлесе буыннан-буынга күчеп бара торган якты хатирәләр иде.

Сугышта турыдан-туры катнашучылар дөньядан китәр, үткәндәге кичерешләр ачысын үзләре белән алып китәрләр, әмма аларның мирасы булып туган җиргә мәхәббәтнең сүнмәс яктысы калыр...

## Назыйм Хикмәт,

төрек шагыйре

# ЕГЕРМЕ СИГЕЗ ХИКӘЯСЕ

ТӘРҖЕМӘЧЕДӘН

Мин Н. Хикмәт белән 1952 ел башында таныштым. Ул чакта мин аның шигырьләрен тәрҗемә итә башлаган идем. Ул китап Казанда чыкты, Н. Хикмәт китапка бик җылы кереш сүз дә язды...

70 елларда Төркиядә Н. Хикмәт архивының бер өлеше табылды. Анда «Кешелек манзарасы»ның дүртенче китабының тулы тексты, шул исәптән 28 панфиловчыга багышланган поэма да бар.

Н. Хикмәт ерак Бурса каласында төрмәдә яткан килеш 28 панфиловчының батырлыгы турында ничек ишеткән соң? Һәм бу фактның булуын гына түгел, ә аны бөтен нечкәлекләренә кадәр ничек белгән? Н. Хикмәт иҗатын өйрәнүче совет галиме Акпер Бабаев бу турыда болай сөйли:

— Күрәсең, Хикмәт бу турыда радиодан ишетеп белгән, чөнки ерак Бурса каласының төрмәсенә газета битенең бик тиз барып җитүен күз алдына китерү читен. Шигырьдә китерелгән фактлар дөрес. Бик ихтимал, Назыйм Хикмәт Александр Кривицкийның «Красная звезда» газетасында басылып чыккан очеркын радиодан тыңлагандыр. Назыймның шигырен һәм очеркны чагыштыру моны раслый. 1941 елның ахырында бу очерк рус һәм чит ил телләрендә берничә тапкыр совет радиосыннан тапшырылды. Мин үзем ул вакытта Баку радиосында эшли идем һәм ул очеркның берничә тапкыр радиодан тапшырылуын яхшы хәтерлим...

Шунысы да билгеле, үзенең дусы төрек язучысы Кемаль Таһирга 1941 елда төрмәдән җибәргән язу хатында Н. Хикмәт: «Көн саен өч тапкыр соңгы хәбәрләрне тыңлыйм» дип хәбәр итә... Иң кызыклысы: Мәскәүдән бик еракта торган Бурса каласының тоткыны 28 панфиловчы турында дөньяда беренче булып шигырь теле белән сөйләп бирә.

Тагын бер кызыклы факт. Дубосеково янындагы алышны тасвирлап Назыйм Хикмәт аның драматик барышын эзмә-эзлекле рәвештә чагылдыра. Ул гына да түгел, поэмада Сенгербаевның Сунгурбайга, Москаленконың Масленкога әйләнүеннән башка һәм бездә Дубосеково алышы дип йөртелгән алышның Петелино алышы (213 нче калкулык — Петелино авылы — Дубосеково разъезды) дип аталудан башка берниндн төгәлсезлек тә юк. Бу факт тоткын шагыйрьнең дөнья кешеләре белән бергә булуы, үз сүзләре белән әйткәндә, «йөрәгенең иң ерак йолдыз белән бер булып тибүе» турында сөйләсә, икенче яктан, Анкара радиосыннан: «Ун көн дә үтмәс, Мәскәүдә фюрер танклары рәсми парад ясаячак»,— дигән тапшырулар барган көннәрдә Н. Хикмәтнең совет халкы җиңүенә тулысынча ышануын күрсәтә һәм бу рухи батырлык таң калдыра. Утыз ел бу поэманы югалган дип санадылар. Ләкин бу талантлы, кешеләргә олы җанлылык белән сугарылган әсәр шагыйрьнең икенче Ватаны — Советлар иленә әйләнеп кайтты. Һәм хәзер атаклы шагыйрь кулы белән язылган бу тарихи документ безнең өчен утлы елларның бер сәхифәсенә әйләнде.

Тоткын Хәлил
Көнчыгыш картасын җәеп салган
камера уртасына, идәнгә, ташка.
Карта-газетлардан кисеп җыелган,—
һәр кисәкнең үлчәме үзенә башка.
Балтика Кара диңгез кырында,
Варшава Киевнең нәкъ борын төбендә,

Орел Брянскидан искиткеч ерак,
ә Мәскәү әллә кайда,
әнә тегендә...
Хәлил күз сурәтләре төшергән
картаның читләренә, акка.
Күзләр —
кайсы алдан, кайсы ян-яктан.

Әйтте Анкара радиосы:
— Ун көннән дә калмас,
Мәскәүдә парад ясар фюрер танклары!
Ләкин Хәлил ышана: ясый алмас!

Хәлил башын чайкады,
уйлап алды сугыш башланганга биш ай узганны
һәм сызды сөрмә каләме белән
алар Мәскәү янында каннары белән сызганны.
Хәлилнең кулы кояшта янган, каратут,
бармак буыннары төен-төен, кытыршы.
Тешли-тешли чарпаланган каләме белән
сызды Хәлил тырышып фронт торышын.

Карта — гади бер кәгазь,
карта — гади бер сызым.
Картада фронт Мәскәүдән сантиметр ярымда,
ә кар яуган аланда — җитмеш километрда,
хәтта аннан азракта.
Кар каплаган туфракта
каршы тора дошманга яңа кешеләр,
кара үлемгә — балкыган тормыш
һәм Хәлил белә: бу көрәш хаклы!
Шулай булгач, дошман Мәскәүдән ерак,
ерак — яңа кеше буе чаклы!
Менә ни өчен ышана Хәлил:
бу кешеләр җиңелмәс,
җиңелмәс бу бөек ил!

* * *

Кырык беренче ел. Ноябрь. Уналтысы.
50 дивизия, унөче — танклы,
3000 туп һәм 700 очкыч һөҗүм итә Мәскәүгә.
План коточкыч:
Совет башкаласын кысымга алып ике яктан,
һәм көньяктан, һәм төньяктан өзеп оборонаны, эчкә үтү,
һәм шәһәрне тоткан көчләрне берәм-берәм юк итү.
Гитлер танк саны ягыннан өстен бүген.
Танк — мөһим корал, инкарь иткән юк.
Ләкин кирәк аныклау:
бездә кешеләр куллана танкларны,
ә аларда кешеләрне — танклар.
һәм үзләрен танк кулланган кешеләр
яу чыктылар җәйге бер таңда.
Атладылар, мундирлар өр-яңа,
атладылар, куллар канда,
атладылар җәй буе, көз буе,
ярты Европаны үттеләр.

һәм кыщкы салкын бер төндә
җәннәт каршысына килеп җиттеләр.
Чәчләре тузгыган,
мундирлары тузган,
йөзләрен сакал-мыек баскан
башларын игәннәр аска,
йончыганнар арыганнар калганнар коры кимеккә.
Күпләре килеп тә җитәлмәгән — юлда ук дөмеккән.
Мәскәүне яуларга чыкканнар
баштанаяк карга чумганнар,
яраланганнар, ачыкканнар, туңганнар.
Иңнәрендә хатын-кызлар юбкасы,
балалар оегы — бияләй кулларында...
Каршыда җәннәт,
Ләкин үтәсе — юлларында
каян гына килеп чыгалар?—
актан кигән кызыл шайтаннар тора гаскәр-гаскәр.
Тирә-якта очсыз-кырыйсыз ак карлар,
ә каршыда җәннәт, каршыда Мәскәү.

Мәскәү, Мәскәү!
Ачлыкның, суыкның һәм сугышның азагы,
үтте дигән сүз бөтен тәмуг газабы.
Мәскәү — җылы мичләр: кер, җылын!
Мәскәү — мамык түшәкләр: сузыл, ят!
Мәскәү — кайнар су: кранны гына бор!
Штык очы белән йозакларны ват,
витриналар пыяласын кыр —
кибетләр тулы байлык:
иң җылы, иң йомшак мехлар — ал да сыртыңа сал!
Адым саен икра, адым саен колбаса,
тау-тау ак май, бал!
Аша, эч — алдыңда җәннәт сые,
аннан тулы корсакка — ят, йокла, хет тәүлек буе!
Ни сугыш, ни үлем, ни партизаннар!
Аша, җылын, йокла, тор,
аннан тагын аша,
тагын йокла, тагын тор!
Теләсәң юын,
теләсәң сакалыңны кыр,
эчеп бетер «водка»ны — тамчысына кадәр,
яндыр күмерне — калмасын хәтта граммы!
Аннан сугыш бетсен дә,
өйгә кайтырга булсын — герой булып!
Шулай куелган программа.
Мәскәүне яуларга чыкканнар
яраланганнар, өшегәннәр, ачыкканнар.
Һәм ерткыч комсызлыгы белән,
карлы яланда
яралы, ач, туңган бер ерткыч комсызлыгы белән —
борын алда, койрык сыртта, күзләр тонган,—
мич янында җылы урын өчен, ашау өчен
ыргыла фашистлар алга, салып бөтен көчен.
Сырт йоннары үрә торган, күзләр яна — коточкыч!
Яный Мәскәүгә куркыныч бер ерткыч!

* * *

Кырык беренче ел. Ноябрь. Уналтысы.
Волоколамск шоссесы.
Кар өстендә немец танклары — кара шәүлә.
Барсы — егерме. Кап-каралар. Дәүләр.
Һәр берсе сукыр кәркәдән кебек куркыныч, ярсу.
Әкияттәге гыйфритләр кебек ямьсез барсы.
Әкияттәге гыйфритләр кебек барсы хәтәр.
Бәлки, чаянга да охшар иделәр,
тупас, авыр булмасалар шул кадәр.
Петелинода, окопта — солдатлар.
Барсы — егерме сигез.

Петелинода окопка килә танклар,
парадта килгән кебек — тип-тигез...
Арган солдатлар бер-берсенә карап алдылар:
сәгатьләрчә сугышып,
моннан аз гына элек
дошман батальонын кырып салдылар.
Окоп алды туп-тулы үлек...

Хәзер танклар килә, җанвар кебек үкереп.
Шул килгән җанварларны күреп,
окопта
кысты йөзем кара күзләрен
Мостафа Сынгырбай:
— Вай анам,— диде,— вай, егерме баш үзләре!
Һәм егерме баш бүре очраткандай сунарда,
көлеп куйды, уйлады эчтән:
«Туры килер боларны тунарга!»

Окопка сикереп төште Клочков,
батальон комиссары.
Күзләре зәңгәр, чәчләре сап-сары.
— Сәлам, егетләр!—
Сөенечле хәбәр әйтергә җыенгандай, тынып калды,
солдатларга карап алды.
Батальонда аңа «Диев» диләр,—
Украин Бондаренко биргән кушамат.
Ягъни, тынгы белмәс, эштән бушамас,
зәйтүн агачыдай биремле,
кырмыскадай тырыш,
кайчан ашый да, кайчан йоклый,
тыну белми әвәләнгән камыр —
Клочков-Диев кулларында тормыш.

Окоп Диевка караган: вакыт тыгыз.
— Нишлибез?
— Санадым, егетләр,
алар — егерме, без — егерме тугыз.
Димәк, кырык биш процентка
танклар кешеләрдән азрак,
кырык биш процентка
кешеләр танклардан көчлерәк.
(Диев белә:
танкларда мотор, кешеләрдә йөрәк.)
Ләкин Диев хата санаган:
бер солдат куркак иде.

Иң алдагы танк окоп өстенә менеп,
күкрәгән куркыныч киергәч тә,
немец, «Бирел!» дигәч тә,
— Бирелә́м!— диде бу куркак,
кул күтәрде бу куркак, чыкты окоптан.
Командасыз гомум залп
куркакны җиргә салды.
Окопта егерме сигез калды.

Алыш дүрт сәгать барды.
Танкларның ундүрте,
кешеләрнең җидесе карда хәрәкәтсез калды.

Алыш җиңү белән бетте.
Ләкин күренде яңа танклар, әле ераклар.
Киләләр кар ерып,
элеккеләреннән дә зурраклар.
Егерменче йөз техника могҗизасы —
туп, радио, мотор һәм тоташ корыч.
Әйтерсең, урта гасырларда
гыйльме симия я тылсым тудырган галәмәт корма.
Күренешләре шундый куркыныч!
Вакыт икендегә бара авышып.
Тынып калган окопта
яңгырады Клочков тавышы:
— Яңаларын санадыгызмы?
— Юк.
— Мин санадым: утыз.
Баягыдан калганы — алты.
Димәк, барлыгы — утыз алты.
Без егерме бер.
Якынча бер боецка
туры килә ике танк.
Егетләр, чигенмәскә!
Россия зур, ләкин
чигенер җир юк бүтән —
артта Мәскәү!

Шул чак Кужабергенов болай диде:
— Кочаклашыйк!
Барсы гаҗәпләнеп аңа карады:
батальонда иң йомык солдат иде!
Уйнамас, көлмәс, җыр да җырламас,
тартып ала алмассың авызыннан сүзен,
балык су эчендә яшәгәндәй,
яши иде үзендә-үзе.
ләкин баладай тормышка гашыйк.
Кужабергенов кабатлады:
— Вакыт барда кочаклашыйк!
Кочаклаштылар барсы...
Окопка яңа танклар килә ярсып.
Алыш ярты сәгать барды.
Танкларның тагын сигезен,
кешеләрнең тагын уналтысын үлем алды.
Кешеләрнең припаслары бетте,
Клочков-Диев кулында гына
бер граната калды...

Алып коралсыз калса да,
алып йөрәге җиңелми,
алып горур көлә.

Кешеләр бергә яшиләр,
бергә сугышалар,
ләкин һәркем үзе генә үлә.
Припасы беткәч, Кужабергенов
атылып чыкты окоптан,
су атылып чыккан кебек җирдән,
торып басты бар буена
һәм кулларын күкрәгенә куеп,
китте танкка каршы.
«Бетәм яки бетерәм!»
Азат иде бу сораудан солдатның башы.
Пулялар бүлде юлын.
Күкрәгенә куйган килеш кулын,
соңгы минутын каршылап,
солдат горур көлде.
Кужабергенов шулай үлде.

Янган танк эченнән шул мәлдә
тышка үрмәләде өч бәндә.
Житез булды Мостафа Сынгырбай:
— Вай анам,— диде,— вай,
бетерәм боларның эшен!
Суырды кыныдан пычагын, капты авызына,
ялтырады теш арасында корыч,
ә корычта ак теше,
кардан шуышты Мостафа, су кебек,
һәм аучы ысулы белән
өч бүренең түшкәсен пычакка элде.
Янында танк шартлады шул чак...
Мостафа Сынгырбай шулай үлде.

Николай Масленко,
припасы беткәч,
бер йомарлам кар атты танкка,
сүгенде,
аннан коры кул белән китте танкка каршы,
ябышты гусеница корычына,
гусеница батып керде учына,
бармаклары кысты корычны,
бармаклары түгел, корыч изелде.
Николай Масленко шулай үлде.

Соңгы гранатасын кысып,
Клочков-Диев, әкияттәге алыптай,
танкларга каршы басты,
җан көчкә гранатасын орды,
граната танкның тракларын кырды,
танк ут ачты ярсып —
пуляларны нәкъ күкрәгенә алып,
җиргә ауды Алып.
һәм соңгы минутында
тагын бер танк янганны күреп
тыныч кына йомды күзләрен,
әйтерсең йөз ел гомер сөреп,
ак кар өстендә түгел,
ак түшәктә җан бирде...
Белгән кебек яшәү бөеклеген,
үлемнең дә бөеклеген белде.

Клочков-Диев шулай үлде.

Егерме сигезнең соңгысы — Натаров
яраланган иде.
Төн җиткәч, чыкты окоптан,
артында дымлы эз — кан,
үрмәләде — кешеләр бар тарафка.
Сыкранмады, сукранмады —
тавышын саклады Натаров,
әманәт саклаган кебек,
солдат антын аклаган кебек.
ИрененДә — туңган хәбәр,
үрмәләде кешеләр бар җиргә кадәр
һәм кешеләргә тап булгач ниһаять,
сөйләде егерме сигезнең хикәятен,
йөзенә җиңеллек йөгерде
һәм сулышы өзелде.
Натаров шулай үлде.

* * *

Артларында Мәскәү —
ак бинтында кан.
Артларында Мәскәү —
аларга ышанган.
Ике йөз миллион кеше —
бер кеше кебек.
Артларында Мәскәү —
капкалары бикләнгән.
Мәскәү зениткалардан ата,
кесәсендә шигырь китабы,
бер бите бөкләнгән;
театрга, киноларга йөри Мәскәү,
Чайковскийны, Штраусны тыңлый
туплар гөрселдәве эчендә;
һәм шахмат уйный —
капланган тәрәзләр артында, дежурдан буш кичендә.
Яшь эшчеләр фронтка киткән,
яшь станоклар тылга киткән,
карт эшчеләр карт станокларны
чыгарган складтан, төзәткән, яңа иткән,
һәм карт станок, биреп бар көчен,
эшли фронт өчен.
Мәскәү сакта тора,
Мәскәү баррикадалар кора,
чокырлар казый — Мәскәү читендә...
һәм Пушкин басып тора,
шигырьләр иҗат итеп ил өчен;
бакыр кулбашларында
алсу карлар яна кичен...

Төрекчәдән **Шамил АНАК** тәрҗемәсе.

**Нур Гыйззэтуллин**

# ХАЛЫК БАТЫРЛЫГЫ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк бөтен совет халкы социалистик Ватанның азатлыгын саклап калу өчен изге көрәшкә күтәрелде. Совет солдаты «Ватаным өчен!» дип утка керде, «Бөтенесе — фронт өчен, җиңү өчен!» дигән ялкынлы чакыру тылдагыларны фидакарь хезмәткә туплады. Сугыш елларында татар халкы, күпмилләтле илебезнең барлык тугандаш халыклары белән бер сафта торып, явыз дошманга каршы батырларча көрәште. Йөз меңгә якын татар солдаты һәм офицерының орден-медальләр белән бүләкләнүе, Советлар Союзы Герое исеме алган төрле милләт вәкилләре арасында халкыбыз уллары һәм кызларының дүртенче урында торуы үзе генә дә моны ачык раслый.

«Мин, карт солдат буларак, сугыш кырларында татар сугышчыларын һәм офицерларын күп күрдем һәм аларның сугышта какшамас ныклык күрсәтүләренә һәм корыч ихтыярларына һәрвакыт сокланып киләм,— дип язды Советлар Союзы Маршалы Р. Я. Малиновский.— Советлар Союзының бәйсезлеге өчен алып барыла торган бөек көрәшебездә татар халкы үзенең сугыш эшендә чыдам һәм батыр йөрәкле солдатлары белән бөтен армиябез каршында хөрмәт казанды». «Татар сугышчылары сугыш кырларында татар халкының иң яхшы сыйфатларын — Ватанга бирелгәнлек, дошманга аяусыз нәфрәт, җиңеп чыгу өчен үлемнән курыкмау, батырлык, кыюлык, чыдамлык һәм теләсә нинди авырлыкларга да түзү сыйфатларын гәүдәләндерәләр. Алар Совет Ватаны алдындагы үзләренең хәрби бурычларын намус белән үтиләр»,— диде Советлар Союзы Маршалы Л. А. Говоров.

Сугыш елларында Татарстан партия оешмасының 54 проценты, ягъни 19 645 коммунист һәм комсомол оешмасының 51 проценты — 56 мең егет һәм кыз хәрәкәттәге армия сафына җибәрелә. Республика партия оешмасы, фронтны бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итү һәм тылда хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү эшен оештыру белән бергә, халык арасында агитация-масса эшләрен көчәйтүгә дә гаять зур игътибар бирде. Мәсәлән, 1941 елның 2 июлендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бу мәсьәлә буенча махсус карар кабул итә. Әлеге карарда Татарстан китап нәшриятына оборона-масса һәм хәрби-тарихи әдәбият чыгаруны арттыру бурычы йөкләнә. Сугыш елларында республикада татар һәм рус телләрендә 108 газета, «Совет әдәбияты» журналы даими рәвештә чыгып килә. Сугышның беренче елларында гына да Татарстан китап нәшрияты чыгарган актуаль политик әдәбиятның гомуми тиражы 700 меңгә җитә, ә лозунглар һәм плакатларның тиражы ярты миллионнан артып китә.

Әдәбият һәм сәнгатьнең халык тормышы белән бәйләнеше, партия эшенә, коммунизмның бөек идеалларына бирелгәнлеге Бөек Ватан сугышы елларында бигрәк тә ачык күренде. Совет язучыларының хәрби һәм иҗади батырлыгы 1418 көнлек героик эпопея белән, фронт һәм тыл язмышына туры килгән авыр сынаулар белән бик тә тыгыз бәйләнгән. Язучылар бу авыр көннәрдә үзләренең гражданлык һәм партиячел изге бурычларын намус белән үтәделәр, совет халкының бөек рухи күтәренкелеген һәм каһарманлыгын бөтен тулылыгы белән ачып күрсәттеләр.

«Фашизм белән сугыш, ил тормышының бар якларын үзенә буйсындырып, бу елларда милли әдәбиятларның эчтәлеген генә түгел, ә бөтен иҗади тормышның да яңа характерын билгеләде. Идел һәм Урал буе әдәбиятлары тәҗрибә һәм өлгергәнлек ягыннан төрлечә иделәр. Әгәр алар арасында иң җитлеккән татар әдәбияты гасырлар тирәнлегенә киткән традицияләргә ия булса, калган күпчелек — башкортлардан алып

комиларга кадәр — яшь һәм яңа гына үз язуларын булдырган әдәбиятлар иде. Шуның өчен аларның гомумсоюз культура фондына керткән өлешләре дә төрлечә булды, әмма алар барысы да Ватанга, халыкка тугры хезмәт итүгә бердәм омтылдылар. Чиксез үскән гражданлык хисе, тормыш белән моңа кадәр һичкайчан да булмаган тыгыз бәйләнеш, бөтен совет әдәбиятындагы кебек, аларның төп үзенчәлеге иде. Бөтен тематиканы һәм сурәтләү чараларын заман бурычлары, фашизм белән көрәш таләпләре билгеләде; язучылар үзләре дә утта, сугыш ялкыны эчендә булдылар»[1].

Сугыш башлану белән үк, барлык татар язучыларының уртак фикерләрен белдереп, өлкән әдип Шәриф Камал «Без җиңәчәкбез!» исемле ялкынлы публицистик мәкаләсендә: «Бөек социалистик илебезнең күмәк көче, явыз дошманга ачу уты белән ялкынланган хәлдә, хәзерге көндә бары бер генә максатка төбәлгән: дошманны тар-мар китерү, җир йөзеннән аны юк итү»,— дип язды.

Россия һәм Украина, Белоруссия һәм Казахстан, илебезнең башка милли республикалары язучылары белән бергә, татар әдипләре дә үз иҗатларын партия һәм халык эшенә, явыз дошманны тар-мар итүгә юнәлдерделәр.

1943 елның 4 августында фронт агитаторлары белән сөйләшкән вакытта М. И. Калинин сугышчыларның йөрәгенә үтеп керү өчен ана теленнән файдалану кирәклеген ачык әйтте: «Безнең кешеләребездә совет патриотизмын һәм милли горурлыкны тәрбияләгез, һәрбер сугышчыга үз халкының героик трдицияләре турында, ул халыкның гүзәл эпосы, әдәбияты, бөек кешеләре — полководецлары турында, азатлык көрәшчеләре турында искә төшерә торыгыз»[2].

Бөек Ватан сугышы чорында, 1942 елдан башлап, татар телендә уналты фронт газетасы чыкты. Ул газеталарда Г. Кутуй, А. Шамов, М. Максуд, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Әхмәт, Х. Госман, Ә. Исхак, Ш. Маннур, Г. Насрый, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис, Б. Рәхмәт, Г. Галиев, М. Хөсәен, Г. Халикъ-Садри, Г. Бакиров һәм башка язучылар эшләделәр. Г. Бәширов, М. Әмир, Г. Иделле, Ф. Хөсни, Х. Хәйри һәм башкалар, озак вакытлы командировкаларда булып, фронт газеталары редакцияләренә ярдәм иттеләр. Бу газеталарда Татарстан эшчеләре һәм колхозчылары тормышы, әдәбият һәм культура яңалыклары турындагы хәбәрләр дә бирелә килде, шулай ук республика газеталарында басылып чыккан кайбер әдәби әсәрләр дә урнаштырылды. Әлеге хәл фронт белән тылның үзара тыгыз бәйләнешен дә күрсәтә иде. Шулай итеп, фронт газеталары, совет сугышчыларын героик көрәшкә рухландыру белән бергә, татар совет әдәбиятының традицион гражданлык пафосын, азатлык өчен көрәше традицияләрен үстерүдә дә күренекле роль уйнадылар. Рус, татар һәм башка телләрдә чыгып килгән фронт газеталарында бергәләп эшләү, үзара яңа хәбәрләр һәм материаллар алмашу, тәҗрибә уртаклашу фронтовик журналист һәм язучыларның иҗади дуслыгын да ныгытты. Моны исә дәвылллы сугыш елларында төрле милләт совет әдәбиятларының да дуслыгы ныгу дип бәяләргә кирәк.

Сугыш елларында публицистикага мөрәҗәгать итмәгән язучы, гомумән, булмагандыр. Нәкъ менә шушы чорда татар публицистикасы өлкәсендә әле моңа кадәр күрелмәгән бер зур яңалык та барлыкка килде. Бу — язучыларның коллектив иҗаты нәтиҗәсе булган һәм хат формасына салынган публицистик рухтагы чыгышлар иде. Моның көчле эмоциональ рух белән сугарылган беренче зур үрнәге — «Татар халкының фронтовик татарларга язган сәлам хаты». Тексты К. Нәҗми, Г. Кашшаф һәм Х. Ярми тарафыннан төзелеп, аңа миллионнан артык кеше кул куйган һәм башта 1943 елның 5 мартында «Правда» һәм «Известия» газеталарында игълан ителеп, аннан соң республика һәм фронт газеталарында басылып чыккан бу тарихи документ Бөек Ватан сугышы елларындагы татар совет публицистикасының иң көчле һәм ялкынлы коралына әверелде.

Әлеге хат совет сугышчысына турыдан-туры мөрәҗәгать рәвешендә язылган һәм ул аны кискен көрәшкә, явыз дошманнан үч алырга чакыра: «һәрбер тамчы кан өчен, һәрбер тамчы күз яше өчен, һәрбер киселгән гомер өчен үч ал!.. Ятим балаларның күз яшен, тол хатыннарның аһ-зарын, бәхетсез аналарның ләгънәтен, хәсрәтле карчыкларның каргышын, бомбага салып, минага кушып, дошман өстенә яудыр!»

«Бер төнне...» исемле документаль очеркында А. Шамов әнә шул хатны фронтта укуның бер күренешен сурәтләп биргән иде:

«Гильзадан эшләнгән сукыр лампаның саргылт яктысында блиндажга җыйналган сугышчылар бу хатны укыйлар...

— Гаеп итмәгез, иптәшләр, минем күземә бик күптән яшь килгәне юк иде, әмма бүген килде,— ди шунда сержант Хәлим Әбүзаров. — Бу сүзне миңа — минем әнием,

---

[1] История советской многонациональной литературы. Т. 3. М., 1970, 480 б.

[2] «Совет сугышчысы», 1943, 26 август.

хатыным һәм кечкенә кызым Әлфия әйткән шикелле булып китте. Күңелемнең иң тирән җиренә кереп утырды. Тешләремне кысып, әчемнән ант иттем...»

Фронттагы язучылар катнашлыгында иҗат ителгән һәм, газеталарда басылып чыгып, халык арасында киң таралган «Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларыннан татар халкына җавап хаты» (1944), «Икенче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хат» та (1945) гаять зур рух күтәренкелеге тудырган күренекле публицистик әсәрләр буларак кабул ителде.

Сугыш еллары дәвамында язучылар үзләренең публицистик чыгышлары белән совет халкының фронттагы һәм тылдагы тарихи батырлыгына дан җырладылар, ялкынлы сүз белән дошманга карата чиксез нәфрәт хисе тәрбияләделәр. А. Толстой, И. Эренбург, К. Симонов һәм башка совет язучыларының публицистик чыгышлары радио һәм матбугат аша төрле телләрдә, шул исәптән татар телендә дә яңгырады. Җамбулның «Ленинградлылар — балаларым!» дигән атаклы мөрәҗәгате бөтен илгә таралды. Ә. Ерикәйнең «Аларны без гафу итмәбез!» (1942), М. Әмирнең «Бәйрәм мәңге бездә булсын!», Г. Иделленең «Яшәү көче» (1944), Г. Бәшировның «Онытылмас көннәр», Г. Кутуйның «Тетрә, Берлин!», Ф. Хөснинең «Дуслык байрагы астында» (1945) һәм башка мәкаләләр сугыш елларындагы татар совет әдәбиятында публицистик жанрның аерата ныгып китүен һәм үсүен күрсәтеләр.

Бөек Ватан сугышы елларында К. Нәҗминең ялкынлы публицистик мәкаләләренең татар әдәбиятында күренекле урын алуын билгеләп үтәргә кирәк. Бу елларда Казан радиокомитетында әдәби-драматик тапшырулар редакциясенең җаваплы редакторы булып эшләгән К. Нәҗминең публицистик хезмәтләре эфир буенча бик еш тапшырыла, һәм аларның кайберләре вакытлыча дошман оккупациясе астында калган районнарда (мәсәлән, Донбасс якларында һәм төрле фронтларда) листовкалар рәвешендә самолетлардан таратылалар. Әдипнең публицистик чыгышларында халыкларның ленинчыл дуслыгы идеясы аерата көчле пафос белән яңгырады. Мәсәлән, «Азатлык сугышы» дигән мәкаләсендә (1941) ул мондый дуслык турында, беренче чиратта, рус һәм татар халыклары арасындагы дуслык турында болай дип язды: «Ничә йөз еллар буенча, киң Идел буенда бөек рус халкы белән бергә үтелгән бөек тарихи юлны татар халкы үзе өчен иң бәхетле юл саный. Чөнки шушы юл аны чын азатлыкка алып килде, һәм ул рус халкы йөзендә үзенең саф күңелле дусын, өлкән туганын тапты...»

Публицистикада гомумән СССР халыклары арасындагы дуслык идеясе, патриотизм һәм батырлык идеяләре белән тыгыз аралашып, гаять зур көч белән яңгырады.

Сугыш чоры шартларының таләбе белән, публицистика прозаның башка жанрларына да йогынты ясый. Хикәяләрнең художество тукымасына публицистик элементлар кертү — татар совет әдәбиятының милли традицияләре белән бәйле күренеш. Хикәяләүдә публицистик элементларның көчәеп китүе татар совет прозасының рус әдәбиятыннан һәм хәрби публицистикасыннан иҗади үрнәк алуы белән дә бәйләнгән. Катлаулы социаль вакыйгалар чорында, халыкның үз Ватанын саклап калу өчен көрәшкә күтәрелгән вакытларда әдәбиятта публицистик пафос гадәттә зур урын ала. Бөек Ватан сугышы елларында да шундый хәл күренде.

Мәсәлән, М. Әмирнең «Тагын да зуррак бәйрәмгә кадәр» исемле хикәясендә (1941) совет кешеләренең тиз арада хәрби җайга күчүләре күрсәтелде. Язучы шофер егет Фатихның матур һәм реалистик образын тудыра. Сөйгән кызы Тәзкирә белән туй үткәрергә хәзерләнеп тә, «Тагын да зуррак бәйрәмгә кадәр»,— дип сугышка китүче шофер егет уйлары, публицистик пафос белән өртелеп, совет кешеләренең уртак теләге, уртак омтылышы булып яңгырый.

Мәскәүдә чыгып килгән «Литература и искусство» газетасы 1943 елның 27 ноябрендә болай дип язды: «Иллеләп фашистны юк иткән шагыйрь һәм язучы Гадел Кутуйны сугышчылар зур горурлык белән искә алалар. Кутуй башка частьта сугыша, ләкин аны монда да беләләр, монда да яраталар. Сугышчылар үзләре үк татар халкының батыр уллары турында җырлар чыгаралар, аларның солдат данын бөтен фронт буйлап тараталар».

Г. Кутуй 1944 елның июнендә кыска гына вакытка фронттан Казанга кайта һәм 20 июнь көнне Татарстан АССР Верховный Советының VII сессиясенә катнаша. Сессиядә ясаган чыгышында ул: «Ватан өчен барган изге көрәш сугышта шагыйрьнең һәм әдипнең урынын күрсәтте. Шагыйрь сүзе — сөңгегә тиң: ул дошманны чәнечте һәм чәнчә. Әдип сүзе трибун большевик сүзенә тиң: ул — совет кешеләрен батырлыкларга өнди»,— дип горурланып сөйли.

Сугышның беренче айларында ук әдәбиятның дошманны җиңү өчен бөтен көчләрне туплауны төп бурыч итеп куюы Татарстан Совет язучылары союзы органы булган «Совет-

әдәбияты» журналы мисалында да ачык күренә. Журналның сугыш башлану белән ук чыккан санында (1941 ел, № 7), Ш. Камалның публицистик мәкаләсе белән бергә, М. Җәлил, Г. Кутуй, Ә. Исхакның фашизмга каршы көрәшкә чакырган ялкынлы шигырьләре, Ә. Фәйзинең «Көлүче тавыклар турында баллада»сы басыла. Редакция шул ук санга Бөек Ватан сугышы башлануга, фронт күренешләренә багышланган хикәяләр дә урнаштырып өлгерә. М. Әмирнең «Тагын да зуррак бәйрәмгә кадәр», Г. Бәшировның «Сержант Хәйруллин», К. Нәҗминең «Тупчы Сөләйман», Г. Әпсәләмовның «Ватан улы» исемле хикәяләре беренче тапкыр журналның шул санында дөнья күрә.

«Совет әдәбияты»ның 8 нче санындагы «Бөтен көч — дошманны җиңүгә!» исемле редакцион мәкаләдә язучыларның яңа шартлардагы бурычлары ачык белдерелә: «Большевистик туры сүз массаларда дошманга каршы ачы нәфрәт, каты ачу тудырсын, миллионнарга үзенең туган иле каршында мөкатдәс бурычын төшендереп бирсен... Шагыйрьләрнең шигыре сугышчыларны геройлыкка рухландыра торган көчле чаң булып яңгырасын!.. Язучының сүзе кызылармеецның штыгы шикелле үк дошманның йөрәген үтәли тишәрлек үткен һәм көчле булсын!»

Бу чакыруда шул чордагы татар совет әдәбиятының төп юнәлеше, аның иң әһәмиятле проблемалары да ачык чагыла. Язучыларның шушы чакыруга җавап бирергә омтылулары журналның 1941 елда чыккан 8—12 саннарында ук күренә. Мәсәлән, Ф. Хөсни «Рубенс», «Күләгә», Г. Кутуй «Яшен», «Рәссам» кебек хикәяләрендә фашизмның ерткычлыгын фаш итәләр; фронт һәм тыл тормышы Г. Галиевнең «Сугыш вакытында» исемле хикәясендә һәм «Бу көннәрдә» дигән очеркында, Р. Ильясның «Минем авылдашым», Г. Әпсәләмовның «Бердәмлек» кебек хикәяләрендә сурәтләнә. Нәкъ шушы вакытларда революцион көрәш һәм гражданнар сугышы темасы яңарыш кичерә. Г. Галиев, мәсәлән, «Сугыш вакытында» исемле хикәясендә үз героеның бөтен кичерешләрен гражданнар сугышы елларында булып узган хәлләргә китереп бәйли. И. Туктарның «Ирек эзләгәндә» исемле хикәясе тулысы белән гражданнар сугышы чорына карый һәм шул ук вакытта ул Бөек Ватан сугышы вакыйгалары белән дә аваздаш.

Кыска гына вакыт эчендә шактый санда сәхнә әсәрләре язылды. Т. Гыйззәтнең «Серле казна», «Таймасовлар», Н. Исәнбәтнең «Мәрьям», М. Әмирнең «Йөрәк уты», Ф. Кәримнең «Шакир Шигаев», Ф. Хөснинең «Папирос сатучы», Р. Ишморатның «Кайту» кебек пьесалары әнә шундыйлардан.

Татар әдәбияты, үзенең милли традицияләренә таяну белән бергә, күпмиллэтле совет әдәбиятының, бигрәк тә рус әдәбиятының бай тәҗрибәсеннән файдаланды. М. Горький, В. Маяковский, Н. Островский иҗатларындагы патриотизм мотивлары Ф. Кәрим, М. Җәлил, Г. Әпсәләмов һәм башкаларның әсәрләрендә ачык яңгырады. Изге Ватан темасы әдәбиятның идея-сәнгатьчә эчтәлеген билгеләде. Татар солдатының башка милләт сугышчылары белән бер сафта торып саклаган Туган иле һәм шулай ук Татарстан образлары һәр әсәрдә лейтмотив буларак үткәрелде, бөтен ил бердәмлеге һәм халыклар дуслыгы идеясе белән бергә кушылды.

Сугыш елларының авыр сәгатьләрендә совет кешесе күңеленең иң түренә үтеп кереп, аның партия һәм бөтен җәмгыятебез тәрбияләгән җиңелмәс рухи көчен күрсәтүдә лирик жанрлар аерата зур роль уйнадылар. Бу чорда әдәбиятның халык иҗатына һаман күбрәк мөрәҗәгать итүенең дә сәбәпләре шуңа бәйләнгәндер. М. Җәлил, мәсәлән, үз иҗатында татар халык дастаннары һәм әкиятләре стиленнән еш файдалана; Ф. Кәрим һәм Ә. Ерикәй, һәрберсе үзенчә, халык иҗатының образлы системасына һәм яңгырашына таяналар. Ш. Маннурның бер шигыре турыдан-туры халык дастаннарының традицион герое Җик Мәргән исеменнән татар сугышчыларына мөрәҗәгать формасында языла. Н. Исәнбәтнең «Түләк» дигән пьесасы да халык иҗатына нигезләнгән. Борынгы заманнан ук халык күңелендә сакланып килгән баһадирлар бу еллар поэзиясендә үзләре сугышчыга әвереләләр.

Бу елларда батырлыклары белән бөтен халыкларга үрнәк булган реаль геройларга игътибар аеруча көчәйде. Мәсәлән, легендар рус кызы Зоя Космодемьянская илебездәге бөтен милли әдәбиятларның диярлек, шул исәптән татар әдәбиятының да героинясына әверелде. Әгәр Н. Арслановның «Зоя» («Рус кызы») исемле поэмасы үзенең образлы-сурәтләү төзелеше белән гаҗәеп дәрәҗәдә милли булса, Ш. Мөдәррис «Тупчы Вәһап» дигән поэмасында татар сугышчысының батырлыгын күрсәтү өчен рус халык былиналарының традицион сурәтләү чараларыннан файдалана. Төньяк-Көнбатыш фронтта язылган бу поэмада шагыйрь шушы якларның тарихын искә ала. Чөнки нәкъ шушы җирләрдә Русь иленә кылыч белән кергән дошман яулары ничә тапкыр үзләренең һәлакәтен тапты бит! Поэманың эпик интонациясе дә рус былиналары һәм татар дастаннарына барып тоташа.

Үзенең «Моабит дәфтәрләре»ндә М. Җәлил гадәти булмаган, әмма тулысы белән конкрет шартларда көрәшкән батыр сугышчы образын сурәтләде. Шагыйрь иң катлаулы

хәлләрдә кеше язмышы мәсьәләләрен күтәрә, аларга социалистик җәмгыятебезнең идеяәхлакый позицияләреннән якын килә.

Белгәнебезчә, дошманның үз өендә аяусыз көрәш алып барган М. Җәлилгә соңыннан Советлар Союзы Герое дигән исем бирелде, ә фашист тоткынлыгында язган әсәрләре Ленин премиясенә лаек булды. Бу исә — Ватан хакына эшләнгән искиткеч гражданлык һәм поэтик батырлыкның, туган илгә мәхәббәтнең иң югары бәяләнүе. Рус шагыйре Алексей Сурков һәм азәрбайҗан әдибе Сәмәд Вургун совет язучыларының Икенче съездында Җәлил поэзиясен бик хаклы рәвештә «совет язучыларының авыр сынау көннәрендә дә, җиңү көннәрендә дә үз халкы белән бердәм булуының», «дошманга горур нәфрәтнең» югары үрнәге дип билгеләп үттеләр.

Мин ант иттем: соңгы тамчы каным,
Күкрәгемнең соңгы сулышы,
Бөтенесен сиңа, сиңа бирәм,
Ватанымның изге сугышы!

Шагыйрь Фатих Кәрим дә үзенең каһарманлыгы белән шул антына тугрылыклы булып калуын раслады...

Татар совет поэзиясен «солдат поэзиясе» (П. Антокольский сүзләре) дип бәялиләр икән, ул шушы бөек бәяне нәкъ менә Бөек Ватан сугышы елларында яулап алды. Чыннан да, бу чор татар поэзиясендә совет кешесенең дошманга нәфрәте дә, туган илгә кайнар мәхәббәте, моңы һәм шатлыгы да көчле яңгырады. «Авыр чорда халкың: «Үлым!» дисен, «Таянычым!» дисен, туган ил», дип сугышкан совет солдаты поэзиянең үзәк героена әверелде. Аның иң интим тойгылары да Ватанга мәхәббәт белән аерылгысыз үрелгән. Г. Хуҗиның «Россия» (1944) дип аталган шигъри ораториясе совет халкының патриотик хисләренә һәм батырлыгына гимн булып яңгырады. С. Хәким, Ш. Маннур, Ш. Мөдәррис, Ә. Фәйзи, С. Баттал, Ә. Исхак, М. Садри, Ә. Ерикәй һәм башка бик күп шагыйрьләр чын мәгънәсендә солдат поэзиясе үрнәкләрен бирделәр.

Сугыш вакыйгаларының масштабы һәм драматизмы, бөек сынаулар, Ватан һәм тарих алдындагы изге бурычны үтәү зарурлыгы героик үткән белән кызыксынуны сизелерлек көчәйтте. Бу бигрәк тә драматургия өлкәсендә көчле чагылды. 1942 елда Т. Гыйззәт Бөек Октябрь революциясе алды елларындагы халык хәрәкәтенә багышланган «Ташкыннар» исемле драматик трилогиясенең икенче китабын — «Даулы көннәр» пьесасын тәмамлый. Ә. Фәйзи «Пугачев Казанда» дигән тарихи драмасының яңа вариантын яза. Язучы М. Гали, режиссер Х. Уразиков белән бергә, 1944 елда «Каюм Насыйри» исемле тарихи-биографик драма иҗат итә. Н. Исәнбәт «Нур Заһит (Мулланур Вахитов)» дигән тарихи-революцион драмасын тәмамлый. Ләкин тарихи темага багышланган кайбер әсәрләрдә үткәндәге вакыйгаларның социаль-сыйнфый эчтәлеген анализлауга җитәрлек игътибар бирелмәде. Партия Үзәк Комитетының 1944 ел, 9 августта кабул иткән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында»гы карарында «Чит иллардән килгән илбасарларга каршы, царизмга һәм алпавытлар, капиталистлар изүенә каршы рус, татар һәм СССРдагы башка халыкларның бергәләп көрәшүләренең тарихын өйрәнүгә һәм яктыртуга, татар халкының атаклы эшлеклеләрен, галимнәрен һәм революционерларын, Бөек Ватан сугышы геройлары булган уллары популярлаштыруга аеруча игътибар бирү кирәклеге ачык әйтелде.

Тылдагы совет кешеләре дошманны тар-мар китерүдә армиягә ярдәм итү өчен үз көчләреннән килгәннең бөтенесен, хәтта мөмкин булганнан да артыгын эшләделәр. Татар әдәбиятында чиктән тыш авыр шартларда үзләре өчен дә, фронтка киткәннәр өчен дә эшләгән ялкынлы совет патриоткаларының образы беренче планга куелган әсәрләр аз түгел. Мондый геройларны күп санлы очерк һәм хикәяләрдә, шигырь һәм поэмаларда күрергә мөмкин. Мәсәлән, Кави Нәҗминең «Хәят апа» исемле эпик поэмасында (1942) сугыш авырлыгын үз җилкәсендә татыган татар эшче хатыны сурәтләнә. Хәят язмышында автор фронт һәм тыл бердәмлеген декларация рәвешендә түгел, бәлки чын художникларча чишә. Хатын-кызларыбызның тылдагы фидакарь хезмәте драматургиядә дә ачык күрсәтелде. Бу елларда иҗат ителгән драма әсәрләреннән М. Әмирнең «Миңлекамал» пьесасы (1944) бигрәк тә уңышлы булды. Бу әсәрдә колхоз авылы хатын-кызлары җилкәсенә сугыш елларында төшкән авыр сынаулар аеруча тормышчанлык белән сурәтләнде.

Совет кешесенең сугыш һәм тыл героеның характерын ачып, язучылар халык язмышын Коммунистлар партиясе белән, коммунистик идеалларның тантанасы өчен көрәш белән бәйләделәр. Совет кешесенең көче һәм җиңелмәс рухы чыганагын алар максатка ирешүдәге идеялелектә, мораль сафлыкта, социалистик җәмгыять тарафыннан тәрбияләнгән тирән аңлылыкта һәм чын мәгънәсендәге кешелек матурлыгында күрделәр.

Совет күпмилләтле әдәбиятларының үзара иҗади бәйләнешләре Ватан язмышы хәл ителгән вакытта тагын да көчәйде. Фронтларда төрле милләт вәкилләренең бер сафта торып уртак максатлар өчен көрәшүе совет халыкларының ленинчыл дуслыгын тагын да ныгытты. Бу хәл исә, табигый рәвештә, милли культуралар арасындагы бәйләнешләрнең дә моңа кадәр күрелмәгән дәрәҗәдә үсүенә китерде.

«Бөек Ватан сугышы,— дип белдерде А. Сурков совет язучыларының Икенче Бөтенсоюз съездында ясаган докладында,— СССР халыкларының барлык язучыларын бердәм һәм дус семья итеп тагын да тыгызрак туплады, тематиканың һәм материалның берлеге белән, әдәбиятның яшәве һәм намусы өчен тагын да көчәйгән гомуми җаваплылык хисе белән аларны туганлаштырды, күп милләтле укучылар аудиториясе алдында әдәбият һәм әдипләрнең авторитетын чиксез күтәрде, әдәбиятның халык белән аерылгысыз бәйләнешен ныгытты».

Моның иң ачык мисалларыннан берсе — Бөек Ватан сугышының беренче елларында Татарстанга күчеп килгән күренекле рус совет язучылары белән татар әдипләренең бергәләп хезмәт итүләре. Казанда һәм шулай ук Чистай шәһәрендә Л. Леонов, К. Федин, М. Исаковский, К. Тренев, Н. Асеев, М. Алигер кебек атаклы язучылар яшәде. Әлеге шәһәрләр А. Фадеев, А. Толстой, П. Павленко, В. Инбер, А. Твардовский, А. Сурков, М. Бубеннов кебек әдипләрне дә хәтерли. СССР Язучылар союзының рәсми үзәге Казанның Бауман йортындагы Матбугат йортына урнаша, Г. Тукай исемендәге клуб вакытлыча язучылар һәм аларның семьялары өчен гомумторак булып хезмәт итә.«Безнең республиканың бу ике шәһәре Бөек Ватан сугышы елларында бөтен Советлар Союзының иң зур әдәби фикер үзәкләре булды»[1], дигән бәя белән килешмәскә мөмкин түгел.

А. М. Горький вафат булганнан соң СССР Язучылар союзының генераль секретаре итеп билгеләнгән атаклы рус совет язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе А. Фадеев Бөек Ватан сугышына кадәр үк татар әдипләре белән якыннан аралаша. Сугыш елларында ул Татарстанга берничә тапкыр килә. 1941 елның ахырында һәм 1942 елның башында ул драматург Т. Гыйззәттә, Татар дәүләт академия театрының режиссер-артисты С. Булатовта һәм бер ай чамасы скульптор С. Ахунда яши. 1941 елның Октябрь бәйрәме көннәрендә ул Чистайга СССР Язучылар союзының әдәби фонды эшләре белән килә, шул чакта «Темп» кинотеатрында, язучыларның Укытучылар йортында үткәрелгән җыелышында докладлар белән чыгыш ясый, шул ук Укытучылар йортында 1941 елның 28 ноябрендә А. М. Горький турындагы истәлекләрен сөйли. А. Фадеевның татар язучыларының киңәшмәсендә ясаган докладны һәм башка чыгышлары нигезендә язган «Ватан сугышы һәм совет әдәбияты» исемле мәкаләсе 1942 елда «Пропагандист» журналының 17 нче санында басылып чыга, һәм ул бөтен совет күпмилләтле әдәбиятының Бөек Ватан сугышы еллары өчен төп бурычларын билгеләгән программ документ буларак кабул ителә.

Сугыш елларында Чистайда СССР Язучылар союзының филиалы эшли. Аның председателе К. Федин була. Бөек Ватан сугышы еллары рус совет әдәбиятының шактый сандагы күренекле әсәрләре Чистайда иҗат ителәләр. Мәсәлән, А. Твардовский 1941 елның кышында һәм 1942 елның язында фронттан ике тапкыр гаиләсе янына килә һәм үзенең атаклы «Василий Теркин» поэмасын, әле ул матбугатта чыкканчы ук, Чистайда әдәби кичәләрдә укый. Л. Леоновның атаклы «Ябырылу» («Нашествие») пьесасы Чистайда языла һәм беренче тапкыр ул Чистай шәһәр театрында Ленинград өлкә театры коллективы тарафыннан куела. М. Исаковскийның бик күп җырлары, шул исәптән атаклы «Катюша»сы Чистайда языла.

...Бөек Ватан сугышының зур авырлыклар һәм югалтулар белән тулы газаплы көннәрендә дә халыкта җиңүгә ышаныч беркайчан да какшамады. Бу ышаныч әдәбиятта да үзенең югары чагылышын тапты. Әдәбият шул ышанычны ныгытуга хезмәт итте, зур иҗат ялкыны белән җиңүгә чакырды. Ниһаять, бөтен табигать уянган ямьле май көнендә Бөек Җиңү килде!

«Җиңү!

Кырык беренче елның кызу җәендә ул әле алга чакыручы өмет иде. Туганнарыбызны, газиз кешеләребезне караңгылатылган юллар буенча фронтка озатканда һәм алардан борчылып хат-хәбәр көткәндә, без аның турында уйлый гына идек әле. Бүген ул чынбарлыкка әйләнде һәм дошманның башкаласы өстендә, әкияттәге ут кошы төсле, ал байрак булып югары күтәрелде».

1945 елның 9 май көнендә яңгыраган бу сүзләре белән Кави Нәҗми халкыбызның уртак шатлыгын белдерде.

Бөек Җиңү көннәреннән соң узган кырык ел эчендә безнең бөтен тормышыбыз, кешеләр дә, әдәбият та нык үсте. Ләкин күпме генә вакыт узмасын, без Бөек Ватан сугышы елларын онытмабыз. Бүгенге бәхетебез өчен һәлак булган геройлар һәрвакыт безнең йөрәктә яшәр. Һәм без моннан кырык ел элек яулап алынган тарихи җиңүне бервакытта да онытмабыз!

[1] Климентовский В. А. Русские писатели в Татарской АССР. Казань, 1960, 6 бит.

## Җәмил Гыйлманов,

тарих фәннәре докторы

# БӨТЕНЕСЕ — ФРОНТ ӨЧЕН

Партиябез Үзәк Комитеты кабул иткән «Совет халкының 1941—1945 елларда Бөек Ватан сугышында җиңүенең 40 еллыгы турында»гы карарында әйтелгәнчә, «Советлар Союзының Бөек Ватан сугышында җиңүе социализмның өстенлекләрен, аның гаять зур экономик, социаль-политик һәм рухи мөмкинлекләрен бөтен тулылыгы белән ачты». Бөек Ватан сугышы партия һәм халыкның аерылгысыз бердәмлеген, эшчеләр сыйныфы, колхозчы-крестьяннар һәм интеллигенция союзының, СССР халыклары дуслыгы һәм туганлыгының какшамаслыгын, совет тылының гаҗәеп ныклыгын күрсәтте.

Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен барган изге сугышта Коммунистлар партиясе совет халкының рухландыручысы һәм оештыручысы булды. «Бөтенесе фронт өчен, бөтенесе дошманны җиңү өчен» дигән өндәү бу көннәрнең төп лозунгысына әверелде.

Илне индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, культура революциясен тормышка ашыру нәтиҗәсендә Советлар Союзы социализм казанышларын саклауга әзер иде. Ләкин фашист илбасарларның хыянәтчел төстә кинәттән һөҗүм итүе илне һәм армияне чиктән тыш авыр шартларга куйды. Мәгълүм булганча, сугыш башланганда, дошманның берничә вакытлы өстенлеге бар иде.

1941 елның җәенә фашистик Германия бөтен Европаны диярлек басып алды, бу илләрнең хуҗалык ресурсларыннан һәм кешеләреннән файдаланды. Сугыш тәҗрибәсе туплаган немец-фашист гаскәрләре илебезгә бәреп керү алдыннан тулы хәрби хәзерлеккә китерелгән иде h. б. Мондый шартларда капиталистик илләрнең берсе дә җиңү яулап алу түгел, хәтта азмы-күпме вакыт каршылык күрсәтә дә алмаган булыр иде.

Партия Үзәк Комитеты, СССР Халык Комиссарлары Советы партия һәм совет оешмаларына илебез тормышын хәрби җайга үзгәртеп кору, аны бердәм хәрби лагерьга, какшамас тылга әверелдерү бурычы куйдылар. Бөтен көчләрне дошманга отпор бирүгә мобилизацияләү өчен 1941 елның 30 июлендә Дәүләт Оборона Комитеты оештырылды. Ил тормышын хәрби җайга үзгәртеп корганда партия үзенең бөтен эшчәнлеген төп максатка — дошманны тар-мар итүгә буйсындырды.

Промышленностьны хәрби максатларга җайлаштыру илнең шактый зур өлеше дошман кулы астында калган вакытта, гаять авыр шартларда алып барылды. Бу шартларда фронтны экономик яктан тәэмин итүнең бөтен авырлыгы илнең көнчыгыш районнарына, шул исәптән Татарстанга да туры килде. Сугыш барышында промышленность базасы безнең илнекеннән дүрт тапкыр өстенрәк булган дошманны экономик яктан да җиңү кирәк иде.

Фронт арсеналына әйләнгән тыл республикалары арасында Татарстан лаеклы урын алды. Ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру нәтиҗәсендә сугыш алды елларында куәтле индустриаль-аграр республика булып үскән Татарстанда фронт кирәк-яраклары җитештерү өчен бөтен мөмкинлекләр бар иде.

Бөтен предприятиеләрне тиз арада оборона продукциясе җитештерүгә күчерү башланды. В. В. Куйбышев исемендәге кинопленка фабрикасы алдында авиациядә кулланыла торган яңа сортлы пленка чыгару бурычы куелды. Мондый сыйфатлы пленкадан башка зур күләмдә нәтиҗәле һава разведкасы алып бару һич мөмкин түгел иде. Казан фабрикасының Кызыл Армияне пленкалар белән тәэмин итүче бердәнбер предприятие булып калуы да бу бурычның гаять җитдилеген ачык күрсәтә. Дошман объектларын зур биеклекләрдән төшереп алу өчен яраклы әлеге пленка чын-чынлап «армиянең һавадагы күзе»нә әйләнде. Алга таба фабрикада бу продукциянең яңа төрләрен, шуның өстенә аэрофотокәгазь, госпитальләр өчен рентген пленкасы h. б. җитештерү үзләштерелде. Фабрика коллективы сугышка кадәргедән 4 тапкыр зуррак планны үтәүгә иреште»[1].

---

1 Абдуллина Р.Г., Аблязов Г.И. Очерки истории Казанского химзавода им. В. В. Куйбышева. Казань, 1970. 74—84 бб.

Илебездә бердәнбер булган Казан кетгут заводы да зур хәрби заказлар алды. Яралыларны сафка бастыру өчен бик күп кетгут һәм ефәк җеп кирәк иде. 12 шәр сәгать, ә кайбер көннәрне тәүлекләр буе цехтан чыкмыйча эшләп, бер З. Пеплова бригадасы гына көнгә 50 мең ампула кетгут эшләп чыгара алды. Бу кадәр кетгут 50 мең яралыны саклап калырга җитәрлек[1]! Сугышка кадәр халык куллануы товарлары житештергән ясалма күн, автогараж җиһазлары һ.б. заводлар сугыш кирәк-яраклары эшләп чыгаруга күчтеләр. Казан мех комбинаты фронт өчен бүрекләр, бияләйләр, мех аяк киемнәре, очучылар өчен мех эчле комбинезоннар һәм шлемофоннар тегә башлады. «Спартак» аяк киемнәре комбинаты сугышның беренче көннәреннән ук армия өчен аяк киемнәре тегүне оештырды. Җиңел, җирле һәм кооператив промышленность предприятиеләре армия өчен кием-салым, парашютлар, төрле чехоллар җитештерә башладылар. Болар барысы Татарстан промышленностен тамырдан үзгәртте. 1942 елның 7 январенда «Кызыл Татарстан» газетасы болай дип язды: «Республикабызда фронт заказларын үтәүдә катнашмаган бер генә завод та, фабрика да, мастерской да юк.»

Эвакуацияләнгән предприятиеләрне кабул итү, урнаштыру, сафка бастыру буенча гаять зур эшләр башкарылды. Республикабызда Украинадан, Белоруссиядән, Мәскәү һәм Ленинградтан һ.б. урыннардан күчеп килгән 70 зур һәм уртача предприятие эшли башлады[2]. Шулар арасында Мәскәүдән Горбунов исемендәге авиация заводы, Воронеждан моторлар төзү заводы, 2 нче Мәскәү сәгать заводы (Чистай шәһәрендә), автогараж җиһазлары заводы, Гомель аяк киемнәре фабрикасы һәм башкалар бар.

Сафка бастырылган завод-фабрикалар тиздән фронтка ПЕ-2, төнлә очучы ПО-2 бомбардировщиклары, башка бик күп корал һәм сугыш кирәк – яраклары җибәрә башладылар, аларның күләме арткаsuccessfullyнан-арта барды. Баштарак «Рус-фанер» дип көлеп каршы алынган ПО-2 самолеты гитлерчылар өчен «төнге үлем»гә әйләнде, андый самолетны бәреп төшерүчегә 5 мең марка күләмендә бүләк вәгъдә ителде.

ТАССР Халык Комиссарлары Советы каршында Бөтенсоюз Эвакуацияләү Советы вәкиле З.В. Тинчурин җитәкчелегендә эвакуацияләнгән җиһазларны һәм кешеләрне каршы алу һәм урнаштыру буенча махсус совет эшләде[3].

Татарстан җирендә дошман басып алган өлкәләрдән килгән 266 мең кеше урнаштырылды. Казан шәһәрендә яшәүчеләр саны 401 меңнән 515 мең кешегә җитте[4]. Татарстан хезмәт ияләре меңләгән рус, украин, белорус һәм башка милләт кешеләрен ачык йөз белән каршы алып яшәү һәм эшләү өчен мөмкин булган бөтен шартларны тудырдылар.

Татарстан промышленносте уңышлары кадрлар хәзерләү мәсьәләсен хәл итү белән нык бәйләнгән иде. Сугыш елларында Татарстанда хезмәт резервлары системасында 52 мең, ә барысы 167 мең квалификацияле эшче хәзерләнде[5].

Фронт өчен җитештерүнең көннән-көн артуына гомуми хезмәт күтәренкелеге, социалистик ярышны, «күп йөзчеләр», рационализаторлар, күп станокчылар, комсомол-яшьләр фронт бригадалары хәрәкәтен киң җәелдерү нәтиҗәсендә ирешелде. Социалистик ярышның киң җәелгән формаларының берсе — «ике йөзчеләр» хәрәкәте иде. Ул хәрәкәт Горький автомобиль заводы комсомол-яшьләренең «Үзең өчен һәм фронтка киткән иптәшең өчен эшләргә!» — дигән чакыруыннан башланды. Татарстанда «ике йөзчеләр» хәрәкәтен 1941 ел планын 1 августка үтәгән «Спартак» комбинаты кисүчесе Нәфисә Хәбибуллина башлап җибәрде. Аннан үрнәк алып З. Галиуллин, А. Токмакова, Э. Дашкин, Ф. Хәмзина, С. Шәрәфетдинова, М. Сәрвәрова, Т. Трифоновалар хезмәт күрсәткечләрен күпкә арттырдылар.

Бөек Октябрь юбилееп, Кызыл Армия көнен, Беренче Май бәйрәмнәрен каршылау алдыннан социалистик ярыш тагын да кызыбрак китә иде. Октябрь алды социалистик ярышы барышында Горький автомобиль заводы эшчеләре В. Шубин һәм В. Тихомировлар башлангычы тәэсирендә Татарстанда да комсомол-яшьләр фронт бригадалары хәрәкәте киң җәелде. Хезмәт нормасын 150—200 процентка үтәгән браксыз эшләүче бригадаларга бирелә торган бу исемне 1942 елның июлендә инде 204 бригада йөртә иде. 1945 елның июлендә социалистик ярышта 3084 комсомол-яшьләр бригадасы катнашып, шуларның 1642 се фронт бригадасы исеменә лаек булды. Бу бригадаларда 18625 яшь эшче эшләде[6].

---

1 Советская Татария. 1970. 8 май.

2 Марксизм-ленинизм институты Үзәк партия архивы (алга таба — ЦПА ИМЛ), 17 ф., 88 тасв., 91 эш, 24 б; КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы, 15 ф., 29 тасв., 88 эш, 5б.

3 ЦПА ИМЛ, 17 ф., 22 тасв., 2525 эш., 148 б.

4 История Великой Отечественной войны Советского Союза 1941—1945 гг., М., 1961, 2 т., 548—549 бб.

5 Очерки истории партийной организации Татарии. Казань, 1973, 188 б.

6 Комсомол Татарии в цифрах и фактах. Казань, 1958, 43—44 бб.

Татарстан «күп йөзчеләре» арасында шулай ук «меңчеләр»дә барлыкка килде. Ф. Габдрахманов, А. Бирюков, И. Журавлев һәм башкалар әнә шундыйлардан иде. Алар производствода төрле җайланмалар һәм яңалыклар куллану нәтиҗәсендә хезмәт җитештерүчәнлеген ун тапкырга күтәрделәр.

Кузнецк металлургия комбинаты хезмәт коллективы башлангычы белән киң колач алган Бөтенсоюз социалистик ярышы промышленность планнарын үтәү һәм арттырып үтәүдә зур әһәмияткә ия булды[1]. Бу ярышның әйдәүчеләре һәркайда коммунистлар иде. Уңыш миллионнарча эшчеләрнең көндәлек батырлыгы белән яуланды.

Кинопленка фабрикасының бер цех коллективы бер ай буена ял да итмичә эшләде. Башка цехлардагы кебек биредә дә хатын-кызлар гына иде. Күз алдына китерүе дә кыен. Һәр көнне цехта 12 сәгать! Ә өйдә күпме дөнья мәшәкатьләре, балалар...

Шимбә көнне төшке аштан соң цехка фабриканың баш инженеры М.И. Мумжиев килде. Кызыл почмакка барлык хатын-кызлар җыелды. «Иптәшләр,— дип сүз башлады Мумжиев,— сез бу айда көчләрегезне кызганмыйча фидакарьлек күрсәтеп эшләдегез. Сезнең һәркайсыгызның ял итәргә хакы бар. Ләкин фабрика бу көннәрдә фронт өчен тиз арада мөһим задание үтәргә тиеш. Нишләргә?..» М.И. Мумжиев үз каршында йончыган кешеләрне, аларның йокысызлыктан кызарган күзләрен күрсә дә сыкрану сизмәде. Бары тик аларның: «Ә нинди сүз булырга мөмкин. Кирәк икән — эшлибез!»— дигән сүзләре генә ишетелде. «Әлбәттә, чыгабыз. Беренче мәртәбәмени?»— дип рухландырды иптәшләрен арадан хатын-кызларның берсе. Үзара сөйләшә-сөйләшә арганлыкларын да онытып алар эш урыннарына таралдылар. Ә иртәгесен барысы да цехта иде[2].

Татарстан промышленносте сугыш елларының авыр сынавын намус белән үтте. 1945 елда тулай продукция җитештерү 1940 ел белән чагыштырганда 219 процент тәшкил итте[3]. Республикабыз фронтка берәзлексез 600 төрле корал, сугыш кирәк-яраклары, обмундирование, шул исәптән планнан тыш 500 миллион сумлык продукция җибәрде[4]. Машиналар төзү, металл эшкәртү зур темплар белән үсте.

Бу төр продукция җитештерү сугыш елларында 6,8 тапкыр артты[5]. Җиңел, җирле һәм кооператив промышленностьлары да армиябезгә гаять күп продукция җибәрделәр. Сугыш елларында республикабыз промышленносте 3 миллионнан артык комплект эчке кием, 2 миллион комплект җәйге обмундирование, 1 миллионга якын шинель, 1,5 миллион чамасы плащ-палатка, 4 миллион пар киез итек әзерләп җибәрде. Татарстан предприятиеләре көн саен бер полкны өс киеме белән, бер дивизияне аяк киеме белән тәэмин итteләр[6]. 1941—1945 елларда эшләп чыгарылган кием-салым һәм аяк киемнәре 3 миллионлы армияне киендерергә җитәрлек булды.

Республикабызның ул еллардагы казанышлары беренче чиратта эшчеләрнең, инженерларның, хезмәткәрләрнең фидакарь хезмәтләре нәтиҗәсе иде. «Безнең эшчеләр сыйныфы,— диде М.И. Калинин сугыш тәмамланганда,— сугыш авырлыкларын җиңүдә шундый ныклык, хезмәткә өйрәнүдә шулкадәр түземлелек, шулкадәр аңлылык һәм хезмәт дисциплинасы күрсәтте ки, башка бер илдә дә моңа мисал табылмастыр[7].

Сугыш елларында Татарстан промышленностенда җитештерүче көчләр зур үсеш алган булса, авыл хуҗалыгында исә сизелерлек кимеде. 1941 елның көзенә кадәр генә дә Татарстаннан фронтка 3150 йөк машинасы, 390 иң яхшы трактор җибәрелде[8]. Транспорт чараларын мобилизацияләү алга таба да дәвам итте. Тракторларны ягулык һәм запас частьләр белән тәэмин итү сизелерлек кимеде. Нәтиҗәдә колхозларда тракторлар эшләгән эш кискен кимеде. Сугышка озату сәбәпле эшче атлар саны да икеләтә кимеде[9].

Авылдагы эшкә яраклы халыкның 30 проценты фронтка яки промышленностьта эшләргә алынды. Болар барысы да республикабыз авыл хуҗалыгының ул вакытта нин-

---

1 Правда, 1942, 7 май.

2 Абдуллина Р.Г., Аблязов Г.И. Күрсәтелгән хезмәт, 95 б.

3 Народное хозяйство РСФСР. М., 1957, 109—110 бб.

4 Кызыл Татарстан. 1945, 25 июнь.

5 50 лет ТАССР. Казань, 1970, 28—29 бб.

6 Социалистик Татарстан, 1965, 8 май.

7 Калинин М.И. О моральном облике нашего народа. Л., 1945, 20 б.

8 КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы, 15 ф., 22 тасв., 423 эш, 128 б.

9 ТАССР ҮДА, 128 ф., 2тасв., 106 эш., 28 б.

ди авыр хәлдә калуын күрсәтә. Коммунистларның күпләп фронтка китүе сәбәпле авыллардагы партия оешмалары сафлары да сирәгәйде. 1943 ел азагында республикабызның 3885 колхозында 582 оешмага берләштерелгән 3693 партия члены бар иде.

Сугыш шартларында авыл хуҗалыгы алдында торган катлаулы мәсьәләләрне хәл итү һәм урыннарда партия җитәкчелеген ныгыту максаты белән, ВКП(б) Үзәк Комитетының 1941 ел 17 ноябрь карары белән авылларда партиянең Гадәттән тыш органнары — МТС һәм совхоз политбүлекләре оештырылды. Татарстанда ул вакытта 56 совхозда һәм 106 МТС та политбүлек оештырылды[1]. Алар урыннардагы район партия комитетлары белән берлектә политик һәм оештыру эшләрен киң җәелдереп җибәрделәр.

Авыл хуҗалыгы өчен механизаторлар, колхозлар өчен җитәкче кадрлар хәзерләү һәм үстерү системасы оештырылды. Мәсәлән, 1942 елда гына да колхоз, совхоз һәм МТСларга җитәкчелек эшенә 10 меңнән артык хатын-кыз тәкъдим ителде[2]. Кул астындагы хезмәт ресурсларын нәтиҗәлерәк файдалану чаралары да күрелде. 1942 елның 13 апрелендә партия Үзәк Комитеты һәм Совет хөкүмәте «Колхозчылар өчен мәҗбүри хезмәт көне минимумын арттыру турында» карар кабул иттеләр. Хезмәткә яраклы һәр колхозчыга кайда яшәвенә карап 100 дән 150 гә кадәр хезмәт көне эшләү мәҗбүри ителде.

Ил алдындагы бурычны тирән аңлап, Татарстан авыл хезмәтчәннәре кыр эшләрен вакытында башкарып чыгу өчен барган социалистик ярышны киң җәелдерделәр. 1942 елда Орджоникидзе крае хатын-кыз тракторчылары чакыруына Татарстанның 112 хатын-кыз трактор бригадасы кушылды[3]. 1943 елда ярышка кушылган трактористкалар саны ике тапкыр артты. Бу ярышта беренчелекне Казанбаш МТСыннан М. Гыйниятуллина җитәкчелегендәге бригада яулап алды. Бригадага комсомол өлкә комитеты һәм республика Наркомземының күчмә Кызыл байрагы тапшырылды. Шушы бригадада эшләүче тракторчылар А. Әлмиева һәм С. Сабирова «Социалистик авыл хуҗалыгы отличнигы» значогы белән бүләкләнделәр.

Сугыш елларында партия-совет оешмалары системалы рәвештә авылга шәһәр ярдәме оештырдылар. Урып-җыю чорында республика районнарында ел саен шәһәр, дән меңләгән кеше эшләде.

Татарстан колхозчы-крестьяннарының патриотизмы аеруча хезмәтне интенсивлаштыруда күренде. 1943 елда 300 дән 400 гә кадәр хезмәт көне эшләгән колхозчылар саны сугыш алды елы белән чагыштырганда 2 тапкыр, ә 400 дән артык хезмәт көне эшләүчеләр саны 3 тапкыр артты[4].

Колхозчыларның моңа кадәр күрелмәгән хезмәт батырлыгына карамастан, сугыш елларында чәчүлек җирләре мәйданы өчтән бер өлешкә кимеде. Бер гектардан җыеп алынган уңыш 4,1 центнерга калды. Нәтиҗәдә 1942—1945 елларда җыеп алынган икмәк күләме 1941 ел белән чагыштырганда 2,5 тапкырга кимеде.

Дуңгызларның баш саны — 2,5 тапкырга, атлар саны 2 тапкырга кимеде. Шуңа да карамастан, Татарстан илгә шактый күләмдә авыл хуҗалыгы продукциясе бирә алды. 4 мең колхозның меңгә якыны ел саен дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәп барды. Алар арасында Буа районының Коминтерн исемендәге, Минзәлә районының «Кызыл Йолдыз», Актаныш районының «Кызыл көч», Алабуга районының «Яшь көч», Арча районының «Спартак» һ.б. колхозлар бар. 4 ел барган сугыш дәверендә Татарстан илгә 131 млн. пот икмәк, 39 млн. пот бәрәңге һәм яшелчә, 56 мең пот ит, 200 млн. литр сөт, ярты млн. поттан артык йон, дистәләрчә мең пот май, сало, бал, 11 млн. пот печән һ.б. продукция тапшырды[5]. Колхозчыларның нинди авырлыклар белән тормыш иткәннәрен күз алдына китерсәң, бу хезмәт нәтиҗәләре тагын да зуррак бәяләнә.

Республиканың фән һәм культура хезмәткәрләре дә «Бөтенесе фронт өчен!» дигән лозунг белән эшләде. Казан учреждениеләре һәм шәһәргә күчеп килгән Фәннәр Академиясе институтлары фәнни хезмәткәрләренең оборона проблемаларын тормышка ашыруга керткән гаять зур өлешен генә күрсәтеп үтик. Мәскәү һәм Казан галимнәре илебез оборонасы өчен зур әһәмиятле ачышлар ясадылар.

Татарстандагы югары уку йортларының флагманы — Казан дәүләт университеты 1941 елның сентябрендә үк сугышка бәйләнешле фәнни-тикшерену эшләре планын әзерләде. Химия факультетында профессор Б.А. Арбузов җитәкчелегендә салкынга чыдам синтетик каучук һәм диенлы катнашмалар өлкәсендә эзләнүләр

---

[1] ЦПА ИМЛ, 112 ф., 1 тасв., 37 эш, 39 б; 2 тасв., 1 эш, 86 б.
[2] ЦПА ИМЛ, 17 ф., 1 тасв., 1942 эш, 42 б.
[3] ЦПА ИМЛ, 112 ф., 4 тасв., 21 эш, 38, 79 бб.
[4] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы, 15 ф., 25 тасв., 47 эш, 44 б.
[5] Шарафиев С.М. Татария в новой пятилетке. Казань, 1947, 9—10 бб.

алып барылды. Университет химиклары хәрби медицинага зур ярдәм күрсәттеләр: доцент Репа теш цементы эшләп чыгаруның яңа ысулын уйлап тапты; шулай ук Казан предприятиеләрендәге производство калдыкларыннан кыйммәтле медицина препаратлары эшләп чыгару оештырылды. Сугыш елларында Н.Г. Чеботарев, Л.М. Миропольский, Б.В. Силивановский, Е.И. Тихвинская, В.И. Баранов, Н.П. Резвяков һ.б. университет галимнәре оборонага кагылышлы фәнни хезмәтләрендә шактый әһәмиятле нәтиҗәләргә ирештеләр.

Авиация һәм химия-технология институты галимнәре дә хәрби заказларны вакытында үтәүгә зур өлеш керттеләр. Двигательләрдә яну процессы, терсәкле валларның динамик ныклыгы, моторларны кышкы шартларда кабызып җибәрү буенча эзләнүләр алып барылды.

КХТИның 30 дан артык фәнни хезмәткәре предприятиеләргә якыннан ярдәм итүгә күчте. Әйтик, профессор Г.Х. Камай сугыш башлануга үзенең киңәшләре, тәкъдимнәре белән кетгут заводында технология процессын тизләтүгә, продукциянең ассортиментын киңәйтергә, хәрби медицина өчен бик кирәкле кетгут эшләп чыгару күләмен арттырырга ярдәм итте. Институтның С.Н. Ушаков җитәкчелегендәге пластмасса кафедрасы оборона өчен кирәкле яңа төр пластмассалар алу ысулларын уйлап тапты, ясалма күн заводына яңа төр продукция эшләп чыгарырга ярдәм итте. Академик А.Е. Арбузов җитәкчелегендә эшләүчеләр фосфор-органик катнашмалар өлкәсендә берничә ачыш ясадылар, җирле чималдан хлор җитештерүне оештырдылар[1].

Авыл хуҗалыгы, ветеринария институтлары хезмәткәрләре авылларга фәнни һәм практик яктан зур ярдәм күрсәттеләр.

Медицина фәне хезмәткәрләренә гадәттән тыш авыр һәм җаваплы бурыч йөкләнде. Медицина учреждениеләре сугышның беренче көннәреннән үк хәрби мобилизациядә, госпитальләр оештыруда катнаштылар, яралыларны дәвалауга керештеләр. Иң җаваплы бурычларның берсе халык һәм хәрби хезмәткәрләр арасында йогышлы авырулар таралуга юл куймау булды. Профессорлар Л.И. Шулутко, Н.В. Соколов, Ю.А. Ратнер, И.В. Домрачев, В.А. Гусынин, Б.Г. Грецберг, С.М. Алексеев, И.И. Русецкий, А.В. Вишневский һ.б. медицина белгечләре яраларның үзенчәлекләрен өйрәнү, аларны дәвалауның яңа ысулларын табу, камилләштерү буенча фәнни эзләнүләр алып бардылар[2].

Гомумән әйткәндә, бөтен фәнни фикер дошманны тизрәк тар-мар итүгә юнәлдерелгән иде.

Татарстан иҗат интеллигенциясе дә дошманга каршы көрәшнең алгы сафларында булды. «Кызыл Татарстан» газетасының 1941 ел, 25 июнь санында Татарстан язучылары: «Кулыбызга мылтык һәм каләм тотып, данлы Кызыл Армия сафларына басарбыз һәм бөтен талантыбызны, белемебезне, көчебезне биреп, гомеребезне дә кызганмыйча, Ватаныбыз өчен сугышырбыз».— дип яздылар. Алар үз антларын намус белән үтәделәр. 1943 елда 64 Татарстан язучысының 36 сы фронтта иде. Тылда калганнары көндәлек матбугатта дөнья күргән әсәрләре белән халыкны дошманга отпор бирүгә өндәп партиягә зур ярдәм иттеләр. М. Җәлил, Г. Кутуй, А. Шамов, М. Максут, Ә. Еникәй, Р. Ишморат, Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Әхмәт, Г. Галиев, Ә. Исхак, Ш. Маннур, Г. Насрый, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис һ.б. кайбер язучылар фронтта татар телендә чыга торган газета редакцияләрендә эшләделәр. Бу елларда басылып чыккан әсәрләрен язучылар сугышчыларда һәм халыкта Туган илгә, партиягә мәхәббәт, дошманга нәфрәт хисе тәрбияләүгә багышладылар. Сугыш елларында татар язучыларының 220 китабы дөнья күрде. Алар арасында Г. Бәшировның «Сержант Хәйруллин», М. Әмирнең «Миңлекамал», К. Нәҗминең «Артиллерист Сөләйман», Ә. Еникинең «Бер генә сәгатькә», Ф. Кәримнең «Разведчик язмалары» һ. б. әсәрләр бар.

Татарстан хезмәт ияләре фронтка ярдәм итү буенча бөтенхалык хәрәкәтенең төрле формаларында актив катнаштылар: оборона фонды оештыруда, Кызыл Армияне коралландыруга акча җыюда, хәрби заемнарга һәм лотереяләргә язылуда, сугышчылар өчен җылы киемнәр җыюда һ. б.

Республикабыз хезмәт ияләренең фидакарь хезмәте бөтен совет халкы хезмәтенә кушылып, Бөек Ватан сугышында дөньякүләм тарихи җиңүне тәэмин итте.

---

[1] История Великой Отечественной войны Советского Союза, т. 2, 541 б.

[2] Красная Татария, 1943, 22 июнь.

# ҖИҢЕЛМӘС ТУГАНЛЫК

Советлар Союзының Бөек Ватан сугышындагы җиңүе — илебез халыкларының интернациональ бердәмлеген раслау ягыннан да тарихи әһәмияткә ия булган гаять зур вакыйга.

Мәгълүм булганча, Бөек Октябрь революциясе алдыннан капиталистик Россия милли каршылыклар белән әчтән тәмам таркалып беткән иде. Беренчедән, патша хөкүмәте һәрвакыт рус милләтен башка халыкларга каршы куеп килде, икенчедән, рус булмаган халыклар арасында да, беренче карашка хәл итә алмаслык булып тоелган каршылыклар ярылып ята иде. Әгәр бу күзлектән карасак, чыннан да, егерменче гасыр башында дулкын-дулкын булып кабынган милли каршылыклар аркасында Россиянең аерым регионнарга бүлгәләнеп беткән кебек булуын күрер идек: әнә төрле халыклар яшәгән Кавказ, күпмилләтле Урта Азия, менә Казахстан, Урал, Урта Идел буе...

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң элгәре изелеп яшәгән төрле милләт халыклары тигез хокукка ия булдылар, милли культураларын үстерү — мәгариф системасын, матбугатны, милли әдәбият һәм сәнгатьне булдыру өчен гаять киң мөмкинлекләр алдылар. Күп кенә халыклар үзләренең тарихи үткәннәрен фәнни нигездә өйрәнергә керештеләр. Беренче карашка, әлбәттә, халыклар бер-берсеннән ераклаша төшеп, үз казаннарында гына кайный башладылар дигән тәэсир туарга мөмкин иде. Гитлер Германиясенең башкисәр җитәкчеләре һәм идеологлары Советлар Союзына илбасарларча һөҗүм итү планын төзегәндә әнә шуны да уйлап эш иттеләр. СССР халыкларының бердәмлеге какшар, ил политикасында кискен борылыш булыр һәм милләтләр арасында янә бер-берсен күрәлмаучанлык башланыр дип өметләнделәр алар.

Язучы А. Кешоковның 1942 елның көзендә, Төньяк Кавказда булган тарихи вакыйгаларга нигезләнеп язылган «Сынган дага» исемле романындагы капитан Локотошның үзен борчыган шомлы сорауларга җавап эзләве күңелләргә тетрәндергеч тәэсир ясый: «Дошманны Днепрда да, Донда да туктата алмадык, ә монда, Кавказда, тоткарлый алырбызмы? Тау халкының чыдамлыгы җитәрме? Кавказ — таулар һәм мәңгелек карлар иле генә түгел. Кавказ — ул кайчандыр бер-берсе белән бугазга-бугаз килгән халыкларның милли характерлары, гореф-гадәтләре. Ватанны ярату хисе үз-үзеңне саклау инстинктын җиңә алырмы? Ә кинәт стенада тишек пәйда булса, һәм шул тишек аша дошман идеяләре агынтысы болганчык су кебек түргә юл алса?.. Әйе, төрле телдә сөйләшүче кешеләрне интернационализм рухында тәрбияләүгә караганда, алар йөрәгендәге милли тойгыларны уяту җиңелрәк».

Әлеге табигый хәвефләнүгә һәм шулай ук фашизм тарафдарларының рәхимсез максатларына хәлиткеч җавап бирелде инде. Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политикасы СССР халыкларының үзәңнарындагы милли тойгының интернационализм тойгысын көчәйтүче факторга әйләнәчәген алдан ук күрде.

Немец-фашист илбасарлары илебезгә хыянәтчел һәм мәкерле төстә басып кергән көннән үк халыкларның рухи тормышында бер сыйфат — патриотизм кискен күтәрелеш алды. Үзенең характеры һәм социаль-психологик төзелеше буенча патриотизм — гаять катлаулы тойгы ул. Туган җиргә, туган телгә, культурага, үз халкының гореф-гадәтләренә карата булган мәхәббәт — патриотизмның аеруча мөһим бер үзенчәлегедер. Бу хакта татар халкының сөекле улы бөек шагыйрь Габдулла Тукай «Милләткә» исемле шигырендә бик ачык итеп, аңлаешлы итеп әйтте:

Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаит, милләтем;
Сыйххәтеңдер — сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер — гыйлләтем.

Сән мөкатдәс, мохтәрәм гыйндемдә варлык нәрсәдән;
Сатмазым бу кяинатә милләтем, миллиятем[1].

Изүче сыйныф вәкилләре элек-электән үк әлеге изге тойгыларны үзләре файдасына кулланырга — халык йөрәгендә шовинизм уты кабызырга, басып алу сугыш-

[1] Шигырьнең хәзерге әдәби телгә күчермәсе:
Барлык уем кичен дә, көндезен дә сезнең турыда, милләтем;
Синең саулыгың — минем саулыгым, синең авыруың — минем авыруым.
Син минем каршымда барлык нәрсәдән изге һәм хөрмәтле;
Милләтемне һәм миллиятемне (милләтне сөюемне) бөтен дөньяга алмашмам.

лары башларга омтылдылар. Совет җәмгыятендә исә патриотизм тойгысы халыкларның интернациональ бердәмлегенә, аларның рухи якынаюына илткән уңай бер факторга әверелде.

Сугышка кадәрге елларда партия һәм хөкүмәт органнары, профсоюз һәм комсомол оешмалары совет халкын интернациональ рухта тәрбияләү буенча зур эш алып бардылар.

Чирек гасырдан да кимрәк вакыт милли культураны, көнкүреш шартларын, традицияләрне, гореф-гадәтләрне социалистик башлангыч нигезендә яңадан төзү өчен, дөресен генә әйткәндә, аз иде. Ләкин Октябрьдан соң ирекле хезмәт ияләренең кугәтле иҗади омтылышы, партиянең күпкырлы тәрбия һәм культура-агарту эшенә зур әһәмият бирүе совет кешеләренең рухи дөньясында һәм этник аңнарында тамырдан үзгәреш башлануга китерде. Совет халкының рухи тормышындагы яңарыш-үзгәрешләр хакында сүз алып барганда, илебездәге культура революциясенең матур йомгаклары хакында да истән чыгармаска кирәк. Социализм төзүнең ленинчыл планын тормышка ашыруда, хезмәт ияләренең аңлы рәвештә шул эшкә тупланууында аның әһәмияте әйтеп бетергесез зур булды.

Сугыш хәрби-стратегик һәм экономик планда гына түгел, СССР халыкларының милли-этник тормышына да зур тәэсир ясады. Аның беренче айларында ук ун миллион кеше көнчыгыш районнарга эвакуацияләнде. Идел буе, Закавказье, Урта Азия республикаларына руслар, украиннар, белоруслар, молдаваннар, латышлар, литвалылар, эстоннар, еврейлар һәм башка милләт халыклары килеп урнашты. Аларны һәрьяклап — торак белән, кием-салым, азык-төлек һәм эш белән тәэмин итәргә, ә балалар укуларын дәвам иттерсеннәр өчен уңай шартлар тудырырга кирәк иде.

1942 елның сентябрендә генә Татарстанга 176 мең кеше эвакуацияләнеп килде, шулар арасыннан унбер меңе балалар йортында һәм интернатларда тәрбияләнүче сабыйлар иде. Аларның күпчелеге якыннарын, туганнарын югалту кайгысын кичергән, фашист чолганышында калып, сугышның ни икәнен үз күзләре белән күргән. Эвакуацияләнеп килүчеләрне каршы алучылар да сугышка туганнарын озатканнар һәм инде кайберләре кайгылы хәбәрләр дә алганнар.

Идел буенда һәм илебезнең башка төбәкләрендә яшәүчеләрнең шундый авыр көннәрдә чын мәгънәсендә интернационализм үрнәге күрсәтүләре хакында әдәбиятта һәм матбугатта бик күп тапкырлар язылды. Әмма шуны да әйтеп үтәргә кирәк, тылда бөтенесе дә шома гына бармады, кайбер төбәкләрдә артта калганлык һәм искелек калдыклары ара-тирә үзен сиздерде. Ә бит сугыш аркасында 25 миллионга якын кеше күченүгә дучар булды. Алар күңелләрендә нинди истәлекләр саклый икән? Ул кешеләрнең балалары, оныклары бу турыда нәрсә уйлыйлар, бүген аларның башка халыкларга булган мөнәсәбәте нинди икән? Болар — абстракт сораулар түгел, чөнки алар бүгенге тормыш чынбарлыгына да кагыла. Әлбәттә, кешеләрнең сугыш вакытындагы үзара мөнәсәбәтләрен күз алдына китерү җиңел түгел. Сугыш кешеләр алдына әллә никадәр сынаулар китереп куйды. Алар әдәбиятта, драматургиядә, кинода, рәсем сәнгатендә һәм сәнгатьнең башка өлкәләрендә чагылдыруга һәм фәнни тикшеренүләргә мохтаҗ әле.

Промышленность предприятиеләреннән, фәнни һәм иҗади учреждениеләрдән, уку йортларыннан эвакуацияләнгән кешеләрнең барысына да игътибар, кайгырту, җан җылысы кирәк иде. Аларның бик күбесе бу җылыны алды, кайгыртуны тойды, үзләренең яңа күршеләре, хезмәттәшләре белән дуслашты. Гаять киң халык массаларының фронт яны районнарыннан тылга күчүе, тылдагыларның фронтка китүе белән бәйле процесслар, тиешле оешканлык һәм тәртип партия, профсоюз, комсомол оешмаларының совет органнарының көндәлек эше, аларның социалистик көнкүрештәге хокук һәм әхлак нормаларын үтәүгә булган таләпчәнлеге нәтиҗәсендә тәэмин ителде.

Шәһәрләрдә, авылларда, промышленность предприятиеләрендә, колхоз-совхозларда көтелмәгән хәлләр аркасында барлыкка килгән күп милләтле тирәлек төрле милләт кешеләренең бер-берләре белән якыннан танышуларына, милли культура, гореф-гадәт, традицияләрнең бер-берләренә үтеп керүенә уңай йогынты ясады. Болар милләтләрнең үзара якынаюында бик көчле фактор булды. СССР халыкларының рухи тормышындагы интернациональ моментларны нык көчәйтте. Армия сафларындагы һәм тылдагы төрле милләт халыкларының нәкъ менә шушы елларда арадашчылык теле булган рус теленә игътибары тагы да арту юкка гына түгел.

Культура өлкәсендәге милләтара мөнәсәбәтләр 1943 елның көзеннән, ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советының чираттагы карары нигезендә промышленность предприятиеләре, фән, сәнгать, культура учреждениеләре, уку йортлары дошманнан азат ителгән районнарга кабат күчерелә башлаган

чордан өр-яңа агымга керде. Эвакуацияләнеп килгәннәрне туган җирләренә озату СССР халыклары тугандашлыгының, ленинчыл дуслыкның тантанасына әйләнде. Бу төрле милләт кешеләренә аларның бер-берсенә бик якынайган булуларын төшенделәр, совет халкына хас булган социалистик коллективизмны көчәйтеп җибәрде. Ә социализм шартларындагы коллективизм — ул бердәмлек, тигезлек, иптәшлек һәм уртак җаваплылык принципларына корылган бергәлек дигән сүз. Сугыш елларында коллективизм кешеләрдә рухи ныклык булдырырга, аларга оешмаганлык, күңел төшенкелеге кебек сыйфатлар белән көрәшергә ярдәм итте.

Сугыш вакытында совет кешеләрен интернациональ рухта тәрбияләүдә матур әдәбият һәм публицистика зур роль уйнады. Һәр халык, әдәби һәм публицистик язмалар аша, тормыштан алынган геройлар белән үз телендә сөйләште. Татар укучысы шагыйрь Нури Арсланның госпитальдә язган «Зоя» поэмасы аша кыю рус кызы образын, аның үлемсез батырлыгын бөтен йөрәге белән кабул итте.

Гадел Кутуй:

Хыял күзем белән илгә карыйм,
Карап туймыйм — рәхәт күңелгә!
Рус шәһәрен ярсып яклаганда,
Күзләремә Казан күренә!

— дип язды.

Яисә менә герой-шагыйрь Муса Җәлилнең 1942 елның мартында, Украинада, Волхов фронтында язган «Туганлык» исемле шигырен искә төшерик. «Украина, минем туган илем — Татарстанның туган апасы!» дип, шагыйрь үз халкы исеменнән бөек Т. Шевченко халкына эндәшә:

Бер ананың туган балалары —
Ташкын булып бергә кузгалдык.
Һичкайчан да, һичбер көч алдында
Җиңелмәс бу изге туганлык.

Әсәрләрдә, героизм һәм патриотизм хисләре белән бергә пролетар интернационализм идеяләре, халыклар дуслыгы һәм тугандашлык хисләре дә зурлап искә алынды. Бу — милләтләр һәм халыклар бердәмлегенең иң төп закончалыкларыннан берсе иде. Сугыш башланган көннәрдә үк шагыйрь Әхмәт Ерикәй шушы хакта бик ачык итеп әйткән иде:

Дуслык булган җирдә — зур җиңү бар,
Дуслык хисе бездә югары!

Дуслык, туганлык, үзара ярдәмләшү һәм халыклар арасындагы хезмәттәшлек — СССРның чын мәгънәсендә какшамас һәм куәтле ил булуын раслаучы факторлар. Сугыш вакытында Ватанга мәхәббәт һәм пролетар интернационализм сыйфатлары тагы да катлаулырак һәм күпкырлырак була барды. Һәм бу — илнең көндәлек тормышында бик ачык чагылды. Иң мөһиме — халык массаларының иҗтимагый аңы сугыш тәҗрибәсе белән баю нәтиҗәсендә, илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче халыклар өчен интернационализмның социалистик әхлак һәм марксистик-ленинчыл идеология күрсәтмәләреннән көндәлек тормыш нормасына әверелүе юнәлешендә яңа зур адым ясалды.

**Гомәр САБИРҖАНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# КАҺАРМАНЛЫК ЕЛЪЯЗМАСЫ

Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган Татарстан уллары һәм кызлары турында күп томлы очерклар китабы[1] басылу, һичшиксез, бик әһәмиятле вакыйга. Аны тарихчы галимнәребез Җәмил Гыйлманов һәм Альберт Айнетдинов төзегән.

Бу документаль очерк һәм зарисовкаларның авторлары — танылган язучылар, журналистлар, тарихчы галимнәр, сугыш һәм хезмәт ветераннары. Алар бик зур хезмәт куюны сорый торган эзләнү эше башкарганнар, күп санлы чыганакларны — архив материалларын, үзәк, җирле, фронт газеталарында басылган язмаларны, ветераннарның истәлекләрен һәм хатларын, документаль җыентыкларны өйрәнгәннәр.

Болар бөтенесе герой якташларыбызның үлемсез батырлыклары турында тарихи дөреслек белән сөйләп бирү мөмкинлеге тудырган. Аларның һәркайсының тормышы төрле дәрәҗәдә Татарстан белән бәйләнгән. Кайберләре безнең республикада туган, балачагын үткәргән, икенче берләре яшәгән, укыган һәм Бөек Ватан сугышы алдыннан эшләгән, Татарстаннан фронтка киткән. Китапка шулай ук сугыштан соң Татарстанга кайткан, эшләгән һәм хәзер дә республикабызда яши торган кешеләр турындагы очерклар да кертелгән.

Һәрбер очерк алдыннан геройның фоторәсеме бирелгән. Аларның күбесе фронтта төшкән фотолар, кайберләре исә геройның бердәнбер фотосы, шуңа күрә бигрәк тә кыйммәтле һәм кадерле. Байтагы моңа кадәр басылмаган. Шулай итеп, китапларда беренче мәртәбә герой якташларыбызның фронт фотоларыннан иң тулы галерея төзелгән.

Китапта геройларның биографиясеннән кыскача мәгълүматлар китерелә, тормыш юлындагы әһәмиятле вакыйгалар әйтеп үтелә. Бу тарихи язмалар аларның һәркайсының биографиясен яңа мәгълүматлар белән баета. Авторлар күп кенә геройларның кайсы елда, кайсы шәһәрдә яки авылда туып-үсүен, кайда укуын, эшләвен беренче мәртәбә ачыклый алганнар. Батыр якташларыбызның партия сафларына яки комсомолга кайчан кабул ителүе турындагы мәгълүматлар да игътибарны җәлеп итә. Герой сугышка кайчан алынган, кайда, нинди званиедә сугышкан — мондый мәгълүматлар да кызыксыну уятырлык. Бу белешмәләрне басып чыгаруның тагын бер әһәмиятле ягы шунда: якташларыбызның — герой солдатларның, сержантларның, офицерларның, генералларның сугышчан юлы турындагы эзләнү эшен дәвам иттерергә мөмкинлек ачыла.

Шунысын да ассызыклап әйтү кирәк: Татарстан сугышчыларына Советлар Союзы Герое исеме бирү турындагы СССР Верховный Советы Президиумы Указларының төгәл даталары бирелә беренче мәртәбә игълан ителә. Бу югары исемнең кемнәргә һәлак булганнан соң бирелүе дә ачыклана. Шулай ук геройның туган җирендә, ул яшәгән авылда, районда, шәһәрдә, укыган мәктәптә, эшләгән коллективта, хезмәт иткән яки сугышкан хәрби частьта аның истәлеге ничек мәңгеләштерелү турындагы мәгълүматлар да бирелә.

Шулай итеп, әлеге биографик мәгълүматлар Советлар Союзы Героеның онытылмас образын тудырырга мөмкинлек бирә. Ватан хакына батырлык кылганга кадәр каһарманнарның кызыклы, матур, кабатланмас тормыш кичерүләрен, марксизм-ленинизмның үлемсез идеяләрендә, халыклар дуслыгы һәм пролетар интернационализм идеяләрендә тәрбияләнүләрен аңларга ярдәм итә.

Китапларда һәр геройга берничә бит кенә багышлана. Әмма документлардан файдаланып, кызыклы, үтемле итеп язылган бу очерк һәм зарисовкаларда геройлар кылган батырлыкның зурлыгы, матурлыгы ачыла. Һәр очерк — табыш, герой турында яңа сүз. Алар элекке басмалардан фикер тирәнлеге, фактлар яңалыгы белән аерылып торалар. Язмалардан сугышның кайнар сулышы, шул еллар пафосы, совет патриотлары йөрәгендә янган революцион ут бөркелеп тора.

[1] Герои Советского Союза — наши земляки (Сборник документальных очерков и зарисовок в трех книгах). Казань, книга первая, 1982; книга вторая, 1984.

Китапларны төзүчеләр һәм авторлар Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган якташларыбызның санын ачыкларга тырышканнар. Алар ике йөздән артык икән.

Кемнәр соң бу каһарманнар? Нинди фронт юлларыннан атлаганнар? Нинди һөҗүм һәм бәрелешләрдә кан түккәннәр? Халыкның массовый героизмын нәрсә китереп чыгарган? Геройлардан кемнәр Берлинга барып җиткән? Ә кемнәр Җиңү көнен якынайту хакына гомерен биргән, яу кырында ятып калган? Укучы шушы сорауларның барысына да китаплардан җавап табар.

Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек булган кыю татар егете Гыйлфан Батыршин — Татарстаннан чыккан беренче Герой. 1938 елның 30 июлендә японнарның Квантун армиясе, чикне бозып кереп, Хасан күле янында Заозерная һәм Безымянная биеклекләренә урнашкан совет чик буе заставаларына һөҗүм ясый. Шушы бәрелештә чик сакчысы Гыйлфан Батыршин тиңдәшсез батырлык күрсәтә. Ул отделение белән дәүләт чигенең үзләренә тапшырылган өлешен бөтен көченә саклый, дошман уты астында алты мәртәбә күлне йөзеп чыга, барлык яралы сугышчыларны һәм командирын коткара. Ватан сугышын ул хәрби академия тәмамлап каршылый. Майор званиесендә фашистлар белән бик күп бәрелешләрдә катнаша. Аның күкрәген яңа орденнар һәм медальләр бизи. Сугыштан соң да ул чик буенда совет кешеләренең тынычлыгы һәм иминлеге сагында тора. Совет делегациясе составында 1947 елны Г. А. Батыршин Токио шәһәрендә япон хәрби җинаятьчеләрен хөкем итү процессында катнаша. Ләкин өйгә кайтканда алар утырган самолет аварияга очрап, диңгезгә егыла...

Чик буе заставасында, геройга багышланган стенд янында яшь солдатлар Ватаныбызга Гыйлфан Батыршин кебек соңгы сулышкача тугры калырга ант итәләр.

1940 елның кышкы-язгы айларында ак финнарга каршы сугышларда якташларыбыз күрсәткән батырлыклар онытылырлык түгел. Мөслим районының Исәнсеф авылы егете Гыймазетдин Вәҗетдин улы Вәҗетдинов, Саба районында туып-үскән пулеметчы Александр Кузьмич Ксенофонов, Балтач районы Кенәбаш авылыннан разведчик Бакый Сибгатулла улы Рәхимов һәлак булганнан соң Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек дип табылды.

Ак финнарга каршы сугыштан исән чыгып, Бөек Ватан сугышы кырларында батырларча һәлак булганнарның язмышы һәм сугышчан юлы игътибарга лаек. Советлар Союзы Герое, дүрт сугышта (беренче бөтендөнья һәм гражданнар сугышларында, фин кампаниясендә һәм Бөек Ватан сугышларында) катнашкан Михаил Петрович Кирпонос һәм Сәхип Нурлыгаян улы Майскийларның героик тормыш юлы һәм сугышчан батырлыклары да соклану уята. М. П. Кирпонос 1934 елда Татарстан АССР Верховный Советы исемендәге Казан пехота училищесы начальнигы итеп билгеләнә. Генерал-полковник, Көньяк-Көнбатыш фронт командующие М. П. Кирпонос 1941 елның 20 сентябрендә сугышчан постында һәлак була. Советлар Союзы Герое, подполковник С. Н. Майский, укчы полк командиры, аннары механикалаштырылган бригада командиры була. Идел ярындагы авыр сугышларда, Сталинград янында кыю командир авыр яралана һәм госпитальдә үлә.

Советлар Союзы Герое дигән югары исемгә 1940 елның мартында ук лаек булган якташларыбыз Х. И. Ибраһимов, М. В. Дмитриев, Г. Л. Нигъмәтуллин Бөек Ватан сугышының дәһшәтле бәрелешләрендә катнашып, кырык үлемне җиңеп, исән калганнар.

Китапларның авторлары һәм төзүчеләре үткәргән эзләнү эше Татарстанда туып-үскән егетләрдән Бөек Ватан сугышы елларында иң беренче булып Советлар Союзы Герое исеме Түбән Кама районы Прости авылы егете Никита Фадеевич Каймановка бирелү фактын раслый. Ул чик буе гаскәрләрендә хезмәт итүче өлкән лейтенант була.

Геройлар турындагы очеркларда тупланган документаль материал Бөек Ватан сугышының барлык фронтларында Татарстан сугышчыларының башка тугандаш халыклар белән иңгә-иң торып, массовый каһарманлык үрнәкләре күрсәтүләре хакында ышандырырлык итеп сөйли.

Советлар Союзы Геройлары булган Татарстан уллары һәм кызларының 154е — бөек Ленин партиясе члены, 34 сугышчы — ВЛКСМ члены. Димәк, батырлык һәм кыюлык өчен югары исемгә лаек булучыларның 93 проценттка якыны коммунист яки комсомол.

Ватан өчен сугышларда танылган сугышчыларның яшен күрсәткән белешмәләр дә игътибарга лаек. Өлкән буын коммунист сугышчылар белән бергә сугыш фронтларында совет чорында тәрбия алган яшь коммунистлар һәм комсомоллар да онытылмас батырлыклар эшләде. Шушы 200 дән артык Советлар Союзы Героеның 145е югары исем бирелгән чакта 20—30 яшьтә генә була, ягъни аларның күпчелеге — Бөек Октябрь яшьтәше һәм совет чынбарлыгы шартларында үскән.

Без сугыш елларында Советлар Союзы Герое исемен алган каһарманнар арасында татар халкы вәкилләренең сан ягыннан дүртенче урында торуы белән горурланабыз.

Рус баһадиры Александр Матросов батырлыгын 300 дән артык кеше кабатлады. Сугышчан бурычны үтәү хакына гомерләрен аямаган өчен безнең якташларыбыздан Бөгелмә районының Сугышлы авылы егете, КПСС членлыгына кандидат, сержант Газинур Гафиятулла улы Гафиятуллин, Югары Ослан районы егете, КПСС члены, сержант Алексей Петрович Исаев, Биектау районының Тимошкино авылы егете, КПСС члены, рядовой

Николай Дмитриевич Липатов Герой дигән бөек исемгә лаек булды. Илебездәге һәр халык Ватанга үз Матросовын бирде.

Укучы исемнәре аз билгеле булган геройлар: Фәйзулла Хаҗи улы Әгъләтдинов, Николай Николаевич Алтынов, Сабир Әхтәм улы Әхтәмов, Федор Алексеевич Баталов, Михаил Тихонович Гарнизонов, Анатолий Степанович Калашниковларның батырлыгы турында да белер.

Китапларны төзүчеләрнең һәм авторларның тагын бер зур хезмәте шунда: алар беренче мәртәбә Татарстанда формалашкан частьлар, дивизияләр, полклар сугышчыларының моңа кадәр аз билгеле булган батырлыкларын тасвирлый алганнар. Татарстаннан чыккан генераллар — Биектау районының Алат авылында туып-үскән Алексей Осипович Ахманов, Минзәлә районының Матвеевка авылы егете Василий Николаевич Гордов, Казаннан Александр Васильевич Кирсанов, Гани Биккинович Сафиуллин, Чирмешәннән Иван Никитич Конев һ. б. турында беренче мәртәбә документаль чыганакларга таянып сөйләнелә.

Сугыш геройларының рухи бөеклеге аларның фронттан язган хатларында, көндәлекләрендә чагылыш тапкан, күп кенә очеркларда әнә шундый яңа материаллар файдаланылган. Сугыш тынган арада төрле сугышчылар тарафыннан язылган бу хатлар бер рух, бер уй-теләк — фашизмга нәфрәт, Ватанны иксез-чиксез ярату белән сугарылган.

«Мин үлемнән курыкмыйм,— дип яза Муса Җәлил 1942 елның маенда. — ...Без үлемгә җирәнеп карыйбыз дип әйтәбез икән, бу чыннан да шулай бит... Бөек патриотизм хисе, үзеңнең җәмәгать функцияңне тулысынча аңлау кешене шәхси курку хисләреннән өстен күтәрә...

Әгәр мендә шулай уйласаң — мин шулай уйлыйм — үлем һич тә куркыныч түгел. Ләкин без шулай уйлап кына калмыйбыз, без моны шулай тоябыз, шулай хис итәбез. Бу инде бу нәрсә безнең халкыбызга, каныбызга сеңгән дигән сүз...»

Туган халкыңа мәхәббәт, аның хакына үз-үзеңне корбан итәргә әзер тору хисе белән тулы фронт язмалары хәрби бурычка тугрылык анты кебек яңгырый. Фронт хатларының һәрбер сүзеннән совет сугышчылары сөекле Ватаннары хакына кылган эшләренең олылыгын, бөеклеген тоясың.

«Әнием! Кичә яуда без берничә сугышчан дустыбызны югалттык. Алар безнең арада юк инде хәзер. Әмма аларның даны мәңге яшәр. Тиздән, ә бәлкем менә хәзер үк, без яңадан сугышка керербез. һәм мин, әнием, һәлак булган иптәшләрем өчен каты үч алырга ант итәм»,— Михаил Фомин Курск дугасында сугыш башланыр алдыннан язган хатында әнә шулай ди. Шушы сугышта Фомин, батырлык күрсәтеп, һәлак була.

Очеркларда китерелгән бу материаллар һәм документлар бөек батырлыкны бөек идеяләр генә тудыруын раслыйлар. Үзенең азатлыгы, намусы һәм мөстәкыйльлеге өчен көрәшә торган илне җиңеп булмый.

Советлар Союзы Геройлары — халкыбызның даны һәм горурлыгы.

Герой якташларыбызга багышланган күптомлы китап чыгару аларның каһарманлыгы турындагы якты хатирәнең мәңге онытылмаячагын тагын бер кат раслый. Бүген аларның батырлыгы совет кешеләрен нык үскән социалистик җәмгыятьне камилләштерү хакына, җирдә тынычлык һәм бәхет хакына яңа героик эшләргә канатландыра, яшьләргә патриотик тәрбия бирүдә бетмәс-төкәнмәс чыганак булып тора.

Азат **ҖӘЛӘЛЕВ,**
тарих фәннәре докторы, профессор.

# ПРИКЛАДКА КУЕП ЯЗЫЛГАН ХАТЛАР

**Аның исеме Матбугат йортында Татарстан Язучылар союзы Бөек Ватан сугышында һәлак булган батыр каләмдәшләребезгә куйган мәрмәр тактага язылган: Мөхәммәт Әхмәтгалиев...**

**Сугышка кадәр шактый танылып өлгергән талантлы яшь шагыйрьнең (1920—1943) көндәлек язмалары, фронттан туганнарына язган хатлары сакланган. Бу санда без шул хатлардан берничәсен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.**

1 ГЫЙНВАР 1943 ЕЛ. Сеңелем, үзеңә генә дип язам, исәнме, кадерлем! Йомшак җилләр, Казанга кадәр исеп, чәчләреңне сыйпап, битеңнән үбеп, Яңа ел сәламнәремне, сеңелем, сиңа илтсен иде дим. Әле генә кино карап кайттык. «Каин һәм Артем». Әйбәт кенә. Бүген — ял, Яңа ел хөрмәтенә. Менә, парта артына утырып, тәмәке кабыздым. (Абый тартырга өйрәнгән икән дип уйлама, сеңелем. Мин тартмыйм. Хәзер менә эч пошканнан гына.) Төтен эчендә ябык йөзеңне, моңсу күзләреңне күрәм. Сагындым сине, сеңелем. Шулкадәрле сагындым.

Обедка барып кайттык. Тамак тук, ә җан? Тәнгә — азык, җанга — юк...

Сеңелем, бу сугышлар башлангач, ялгыз калып, үз-үземә урын таба алмый газапланган идем мин, очына чыга алмадым уйларымның. Ә менә хәзер, өскә шинель кигәч, кулга мылтык алгач, мин үз урынымны таптым. Мин хәзер бәхетсез әниләрнең, синең кебек моңлы күзле сеңелләрнең гомерләрен саклаучы солдат булдым. Илдә кош та югалмый, диләр. Син дә, мин дә үз бәхетебезне табарбыз әле. Без аны көрәштә генә табарбыз. Тиздән, синең бәхетеңне яулап табар өчен, Көнбатышка китәрмен, бәхетле җиңүчеләр арасында мин дә Казанга кайтырмын әле, сеңелем! Ышанма син, сеңелем, юрау-багуларга, ышанма. Бәхетең, үз кояшың табылыр, мин бәхетсез, миннән булмый, димә син. Була!— диген, булдырам!— диген. Кырыкка ярыл, тырыш. Халык арасына чык. Яхшы иптәшләр (егетләр арасыннан да) тап. Киемнәреңне кайгырт, театрга, кинога, танцыга да йөрергә тырыш. Әмма үз дәрәҗәңне төшермә. Күңелеңне дә төшермә, авырлыкларны җиңеп чыгарга тырыш, аптырап торма. Сугыш озакка бармас, мин дә исәнсау кайтырмын.

Абыең Мөхәммәт.

13 АВГУСТ 1943

*«Сез бу хатны минем укыганда,*
*Мин бик күптән үлгән булырмын...»*

Такташ

Бәлкем, көйгән сугыш кырларында
ерткыч фашистларны кырырмын.—
Сез бу хатны минем укыганда,
Кайнар каным агар чирәмгә,
Канлы калҗа эзләп, канат җилпеп,
Козгын очар минем тирәмдә.
Рәсмегезне сезнең, әнкәй бәгырем,
Соңгы тапкыр бәлки үбәрмен.
Автоматтан, бәлкем, дошманнарга
Үлем ядрәләре сибәрмен.
Бәлкем, шулай булыр.
Ә бүген мин,
Рәсмегезне алып кулыма,
Сагышланып карыйм һәм күз салам
Борылмалы тормыш юлыма.

Күз алдыма килә томан аша
Сабый чаклар, мәктәп еллары.
Айлы язгы кичләр, Кабан күле,
Бөдрә таллы Идел буйлары.
Их, Казаным, нурлы Казаным син,
Таныш миңа һәрбер сукмагың.
Күңелемне минем яктырталар
Йолдыз кебек якты утларың.
Их, Казаным, синнән туйган идем,
Хәзер менә шундый сагындым.
Былчырагың, чират, тузаның да
Минем өчен якын, ягымлы.
Казан, Казан, синдә калды әнкәй,
Туганнарым, якын дусларым.
Синдә калды кайнар мәхәббәтем,
Чия бакчам, җырчы кошларым.
Кайнар яшьләр белән күмәр идем
Синдә калган әткәй каберен.
Кайтырмынмы сиңа, күрә алырмынмы
Их, Казаным минем, кадерлем.
Күктә йөзә болыт, шуңа кунып
Очар идем туган илемә.
Мин бер генә тапкыр карар идем
Әнкәемә, энем, сеңлемә...
Сез бу хатны минем укыганда
Кайнар яшегезне түкмәгез.
Минем өчен теләк теләгез сез,
Мине уйлап газап чикмәгез.

Сезне үбеп, улыгыз Мөхәммәт.
Хәрәкәттәге армия.

P. S. Мөгаен бүген без сугышка керербез. Иртәдән бирле «Катюша» җырлый, самолетлар оча. Әле менә 2 самолетны бәреп төшерделәр. Шулай, язганын күрербез, әнкәй, әйе бит. Тиздән күрешүгә өметләнеп, улыгыз.

22 АВГУСТ 1943 ЕЛ.

Сәлам сезгә, минем кадерле туганнарым — әнием, сеңелем, энекәшем, Зәйнәп апа! Менә без алгы сызыктан нибары 2 генә чакрымда. Бер урманда. Кичә кич, юл тәзә-түне калдырып, монда килдек. Килгәндә немец безне мина утына тотты. Миналар, сызгырышып, баш өстеннән оча башлауга, без тирләп-пешеп алга чаптык. Кайберәүләр тубыктан су эченә егылдылар. Мин дә, егылып, балтамны югалта яздым. Килүгә, чокырлар казып ятып йокладык. Ә төштән соң тагын өч-дүрт йөз метр китеп, тагын чокыр (щель) казыдык. Менә минем чокырым: озынлыгы бер метр 70 см, киңлеге 70 см, тирәнлеге 1 метр чамасы. Чокырны бүрәнәләр белән, җир белән капладым. Белмим, шул чокырда кунармынмы, тагын ары китәрбезме? Дошман артиллериясе һәм минометлары аткалый. Снарядлар, миналар җуылдап очып үтәләр. Ә без чокырда... Әле яңа гына немец самолетлары безнең тирәне бомбага тоттылар. Җир ду килеп селкенә Гомумән, күнектек инде. Бу урыннан немецларны 4-5 көн элек кенә куганнар. Без резервта, шуңар һөҗүмгә кермәдек әле. Бүген 22 се. Сездән аерылганга 1 ел да 3 ай тулды. Әйтергә генә ансат,ниләр генә күрмәдек без шул арада. Исән-сау кайтсам, хикәят итеп бер төн буе сөйләр идем үткәннәрне. Мин хәзер комсомолец инде. 17 августта билет алдым. Менә шул хәзергә үзем турында. Энекәш, син эшкә кермәдеңме әле? Шәүкәткә бар. Ул урнаштырыр. Әни, минем бу прикладка куеп язган хатымны укы да, теләктә бул. Ә аннары йөрәгеңдә булган кайгы-хәсрәтләреңне түкми-чәчми озын итеп хат яз. Сеңелем, син дә хат яз. Ә мин, вакыт булса, һәр көн язармын монда булганнарны. Хушыгыз.

Сәлам белән улыгыз Мөхәммәт.
Хәрәкәттәге армия.

# ФРОНТ МӘЗӘКЛӘРЕ

Көлү — һөҗүм коралы... Шинельле юмор... Шундый һәм шуңа охшаш бүтән исемнәр белән Бөек Ватан сугышы елларының һәр төрле матбугатында, шул исәптән төрле фронтларда милли телләрдә чыккан газеталарда (татарчалары уннан артык санала) сатира-юмор почмаклары яки битләре еш һәм күп басылды. Әйе, аз түгел иде көр күңелле һәм җор сүзле Василий Теркиннар, зирәк һәм тапкыр Хуҗа Насретдиннәр — фронтның алгы сызыгында, окоплар белән блиндажларда да, дошман тылындагы партизан учаклары янында да!.. Чакма ташыннан сибелгән очкыннар кебек, шул шук-шаян сөйләмнәрне энҗе бөртекләре чүпләгәндәй берәмтекләп җыю һәр әдәбиятта бөрөзлексез дәвам иттерелә һәм, әлбәттә, озак дәвам итәчәк әле...

Бүген хөрмәтле укучыларыбызга төрле елларда, төрле җирләрдә һәм төрле телләрдә чыккан чыганаклардан сайлап, сугыш еллары халык иҗаты үрнәкләрен туплап, шагыйрь Зәки Нури Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышлап махсус әзерләгән шундый чәчәкле букетларның берсе тәкъдим ителә.

## Соңгы куану

Кәефе тәмам кырылган Гитлер хәрби хәрәкәтләр картасына иелгән килеш тирән сагышланып үзалдына мыгырдый икән:

— Таллинны бирдек... Риганы бирдек... Чехословакиянең Раховын бирдек...

Шулчакны ашыгып адъютант аңа телеграмма кертә:

— Сезнең бертуганыгызның хәрби училищеда укучы улы бер экзаменын да бирә алмаган...

Гаять куанган Гитлер урыныннан кинәт сикереп торып:

— Менә рәхмәт ичмасам... Менә рәхмәт... Бернәрсәне дә бирмәгән...[1]

## Авиация һәм пехота

— Украинада безгә дә һавага күтәрелергә туры килде.

— Әллә син, Ганс, авиациягә күчтеңме инде?

— Юк, партизаннар минасы чәлпәрәмә китергән эшелоныбыздан минем дә ничек күкләргә күтәрелүем искә төшкәннән генә әйтәм...

## Танымады

Баласын ияртеп бер фрау зоопаркта йөри. Бер читлектә маймыл күргәч, шул малай сорый икән:

— Әллә сугыш беттеме инде, әни?

— Юк әле, балам, әмма тиздән бетәчәк. Ник сорыйсың әле син моны?

— Ә алайса Геббельс ник бу төрмәдә утыра?

---

[1] Бу сатираны «Крокодил» журналы 1944 елның октябрь санында бастырганда аңа менә нинди искәрмә өсти: «бүгенге көннәр немец-фашистлары телендә поражение (җиңелү, тар-мар ителү сүзе) «Бирү... Бирелү...» кебек төшенчәләр белән йомшартып аңлатыла башлады...»

## Барысы да тәртиптә

— Алло!.. Штабмы бу? Совет самолетлары бомбага тотканнан соң чигенүче Шнельс гаскәрләре нинди хәлдә?

— Барысы да тәртиптә шикелле, пан майор! Полковник гәүдәсенең бөтен өлешләре табылды... Ә башын эзләү әле дәвам итә...

## Юл уңаена карап...

Немец офицеры үзенең денщигын битәрли:

— Күпме әйттем инде син дуракка, «минем итекләрне көнбатыш якка каратып куй», дип. Инде чолганышта калуыбызны белмисең дәме әллә, аңгыра?

## Кирәкле күнегү

— Бу Карл кулларын ник алай бер күтәреп, бер төшереп маташа. Сигналчы булырга өйрәнәме икән әллә?

— Әйе. Әсирлеккә бирелү күнекмәләре ясый...

## Бердәмлек

— Сез капитан Мюллер солдатлары турында ишеттегезме әле? Соңгы сугышта берәве дә чигенмәгән ди.

— Һөҗүмгә чынлап шулай бердәм керделәр микәнни?

— Юк, бөтенесе бергә әсир булырга дәррәү кул күтәргәннәр.

## Сәбәбе ачык

— Руслар турында уйладым исә, куркудан тешләрем тешкә тими башлый.

— Бүтәнчә булмый да. Чөнки тешләреңне руслар күптән төшереп бетерде ич инде.

## Кемне ничек сәламләргә?

— Рядовой Попер, лейтенантны ничек сәламләргә тиешсең син?

— Үзебезнекен бер кулны күтәреп, ә русныкын — ике кулны..

## Беркатлылык

— Эти, синең берәр партизанны якыннан күргәнең булдымы?

— Партизанны якыннан күргән кеше, улым, бу дөньяда инде бүтән бернәрсәне дә күрә алмый...

## Ачыклабрак аңлату

— Әни, руслар минем әтине әсир иткәннәр дип ишеттем. Дөресме бу?

— Беләсеңме, балам, әтиең синең русларны үзе пленга алган, ләкин алар бик күп булып чыккан да әтиеңне дә үз якларына алып киткәннәр.

## Хуҗа Насретдин фронтта

* * *

Хуҗа Насретдин, фриц кыяфәтенә кереп немецлар тылында йөргән вакытта, бер лейтенантка очраган да сорау биргән:

— Я, обер-лейтенант Шан-Раппе, бу позициядә без озак торачакбызмы?

— Фюрер приказында «актык солдат калганга хәтле» диелгән.

— Алайса озак түгел икән,— дигән Хуҗа.

* * *

Хуҗадан:

— Тимер тәре алган фашистка тагын нинди тәре бирәләр?— дип сораганнар.

— Агач тәре,— дигән Хуҗа.

* * *

Бер фрицның:

— Беләсезме, самолет һавада оча, су асты көймәсе су астында йөзә,— дип акыл сатып утырганын ишеткәч, Хуҗа:

— Киресенчә дә була. Мәсәлән, соңгы вакытта фашистларның «фокке» дигән самолетлары күбрәк су астында йөзә, ә су асты көймәләре һавага оча,— дигән.

* * *

Татарстан егете гвардеец Гәрәй бу арада фашист танкларын «майлап» йөри. Минем күз алдымда ул фашистларның бер танкын «майлап» күрсәтте. Җайлап-«майлап» җибәрүгә танк шунда ук дөрләп китте![1]

---

[1] Беренче Балтик буе фронтында татар телендә чыккан «Алга, дошман өстенә!» газетасыннан. 1944 ел.

# ҖИҢҮГӘ РУХЛАНДЫРГАН ҖЫР

Фронт җыры... Үзара каршылыклы булып тоелучы шушы ике сүз солдат күңелендә никадәр хисләр уята. Туплар атканда да тынмаган җыр, дошман өстенә атакага ыргылган җыр, рейхстагны алышкан, Җиңү яулашкан җыр!... Дәһшәтле сугыш елларында халкыбызның рухын канатландырган мондый җырларны без бүген дә тирән дулкынланып тыңлыйбыз: алар тарих кайтавазы булып ишетелә, алар хәтер чаңы булып яңгырый. «Фронт җыры»... Бөек Ватан сугышы ветераны Юрий Ананьевның шулай исемләнгән картинасын караганда да солдатлар белән бер сафта Җиңү яулашкан җыр агылгандай тоела.

Шунысы үзенчәлекле: утлы фронт юлларыннан узса да, сугыш тематикасы рәссам иҗатының төп юнәлешен билгеләми шикелле. Композицияләрдә туплар гөрелтесе дә «ишетелми», яшәү белән үлемнең йөзгә-йөз килүе дә күренми. Әлеге үзенчәлек, мөгаен, шуннан киләдер: автор героик үткәнне бүгенге чынбарлык фонында, сугыш фаҗигасен яшәү матурлыгы призмасы аша күрсәтергә омтыла.

...Алмагачлар чәчәккә күмелгән. Шушы ак «фонтаннар» итәгендә чал чәчле ветеран транзистордан агылучы фронт җырын тыңлый. Таныш моң бәгыреңе өтеп ала, сугыш хатирәләрен уята. Аклык белән өртелгән агач ябалдашлары арасыннан яу кырында ятып калган полкташларның йөзләре чагылып киткәндәй була. Дошманнан азат ителгән шәһәр һәм авыллар күз алдына килә...

Бабасы күңелендә хисләр өермәсе кузгаткан җырны яшүсмер малай да бик бирелеп тыңлый. Йөзе балаларга хас булмаганча җитди: мөгаен, ул да сугыш турында, китаплар һәм кинофильмнар аша гына белгән сугыш турында уйлыйдыр. Ветеран һәм яшүсмер... Картина әнә шушы ике буын вәкилләренең портреты буларак кабул ителә. Халык батырлыгы турындагы хәтер портрет геройларын үзара аерылгысыз итеп бәйли. Әлеге тыгыз бәйләнештә өлкән буынның фашизмны җиңеп, яшь буынга бәхетле тормыш бүләк итүе символлаштырып бирелгән. Кыскасы, гади һәм шул ук вакытта тәэсирле сурәтләү чаралары белән гәүдәләндерелгән бу образларга күпкырлы һәм тирән мәгънә салынган. Ветеран һәм яшүсмер... Аларның уйчан күзләрендә бүгенге киеренке дөньяның язмышы турында борчылу да чагыла. Рәссам чакыра: без үткән сугыш фаҗигасен онытмау белән бергә тәттән, тынычлык өчен бөтен көчебезне куеп көрәшергә дә тиешле.

**Юрий ГОРШУНОВ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Туфан Миннуллинның «Моңлы бер җыр» исемле пьесасы буенча куелган спектакльдән күренеш. Муса ролендә — РСФСРның халык артисты Р. Таҗетдинов.

Рөстәм **МАНСУРОВ** фотолары.


Икенче биттәге плакатны **Йосыф ВӘЛИӘХМӘТОВ** ясады.

## БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ҺӘЛАК БУЛГАН ЯЗУЧЫЛАРЫБЫЗ

Муса Җәлил (1906—1944)
Абдулла Алиш (1908—1944)
Фатих Кәрим (1909—1945)
Гадел Кутуй (1903—1945)
Нур Баян (1905—1945)
Рәхим Саттар (1912—1943)
Хәбра Рахман (1914—1942)
Демьян Фәтхи (1906—1943)
Хәйретдин Мөҗәй (1901—1942)
Мифтах Вәдүт (1915—1942)
Рахман Ильяс (1908—1943)
Мөхәммәт Әблиев (1902—1944)
Кәшфи Басыйров (1906—1943)
Александр Бендецкий (1911—1943)
Мөсәгыйть Мостафин (1909—1941)
Мансур Гаяз (1917—1943)
Әгъзам Камал (1918—1943)
Әхмәт Гыймадов (1915—1943)
Исхак Закиров (1911—1944)
Исмәгыйль Шәфиев (1913—1943)
Хәмит Кави (1906—1944)
Касыйм Вахит (1916—1942)
Макс Гатау (1913—1941)
Мөхәммәтша Мамин (1905—1943)
Аитзак Аитов (1908—1941)
Мөхәммәт Әхмәтгалиев (1920—1943)
Габдулла Галиев (1920—1941)
Әхтәм Әминев (1918—1942)
Сөләйман Мөлеков (1920—1941)
Лотфи Вәлим (1910—1943)

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)